# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Марат КӘБИРОВ. Һәркем җирдә үз бәясен яулый. *Шигырьләр*. ....................................3
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Кышлар үткәч кайтырмын... *Мистик бәян*. ....................................8
Рифат ҖАМАЛ. Сагынуларым сиңа барыберме?.. *Шигырьләр*. ....................................35
Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Калымчы Җәүдәт. *Повесть*. ....................................39
Эльверт ХӘМӘТШИН. Еллардан маяк куям... *Шигырьләр*. ....................................85
Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ. Урам балалары. *Повесть*. ....................................89
Хәнәфи БӘДИГЫЙ. Авылдан килгән чыпчык. *Аллегорик поэма*. ....................................123
Әмирҗан МОТАЛЛАПОВ. Гаилә. *Бәян*. ....................................127

ЯҢА ИСЕМНӘР

Фәридә ХӘСӘНОВА. Сурәт янса, җан – мәңгелек. *Шигырьләр*. ....................................139

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....................................142

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Орхан ВӘЛИ. Бадәм артларыннан күтәрелә ак ай... *Шигырьләр*.
*(Төрекчәдән Рәмис АЙМӘТ тәрҗемәләре)*. ....................................144

«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Фирдәвес ЗАРИФ. Мин дөньяны күрәм. *Хикәя*. ....................................148

*Фотоархив:* Шәриф Хөсәеновның тууына 90 ел. ....................................156

«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ

Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА. Ике әни. *Очерк*. ....................................158

ДӘРДЕМӘНДНЕҢ ТУУЫНА – 160 ЕЛ

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. «Соңгы тамчы каным фида...». ....................................165
Җәгъфәр РӘМИЕВ. Газаплы язмыш. *Шигырь*. ....................................174
*Фотоархив:* Рәмиевләр гаиләсенең тормыш мизгелләре. ....................................174

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Таяну ноктасын эзләгәндә... ....................................176

КИТАП КҮЗӘТҮ

Иса ГАБИББЕЙЛИ. Шигъри дуслык күперләре. *(Айсылу ИМАМИЕВА тәрҗемәсе)*. ....................................183

*Төрки әдәбиятлар һәм заман:* Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Үзбәкстан әдәбиятында модернизмның яңаруы: Фирганә мәктәбе. ....................................186

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Камил КӘРИМОВ әзерләде*. ....................................188

*Печән базары:* Раушан ШӘРИФ. Шәрифизмнар. ....................................189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....................................190

КАЗАН УТЛАРЫ
*(«Огни Казани»)*
*№ 11 (1165) 2019*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Мөдәррисова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.10.2019, график буенча 30.10.2019, басылып чыгу вакыты 08.11.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-3066. Тираж 4354.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2019 ел



Марат
Кәбиров

# ҺӘРКЕМ ҖИРДӘ ҮЗ БӘЯСЕН ЯУЛЫЙ

## Таулардагы уйлар

Авыр уйдан арып туктап калдым,
Тау үренә менеп бастым да:
Яуланмаган үрләр – баш очымда,
Яуланганы – аяк астымда.

Егыла-егыла, яра ала-ала,
Үрләр яулап гомер ителде...
Үзем исләмәстән кемнәрнедер
Яралап та киттем шикелле...

Түбәләрнең төрлеләре булды,
Көмеш дигәннәрем кар булды,
Алтын дигәннәрем чүп-чар булды,
Шатлык дигәннәрем зар булды...

Егыла-егыла, яра ала-ала,
Үрләр яулап гомер ителде...
Аяк аста таулар тезелеп калган,
Мәгънәсез бер түмгәк шикелле...

Җиңү микән, җиңелүләремме,
Аяк астындагы бу үрләр?!.
Бәхет микән, бәхетсезлек микән
Үрләр яулап үткән гомерләр?!.

Марат КӘБИРОВ (1970) – *шагыйрь, прозаик; «Онытма таңнарны», «Мәхәббәт яңгыры», «Китап» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Ил

Илдә чыпчык үлми, диләр.
Чыпчыклар... үлми әле...
(Илләре нинди дә аның,
Чыпчыгы нинди әле...)

Бөркетләр иле бит бу ил!
Тарихка гына кара:
Аның узган юлларыннан
Җиңүләр генә кала.

Ярсып узган юлларында
Җиңүләр кала аның:
Җиңә чит ил дошманнарын,
Җиңә... үз балаларын.

Кайда гына атласа да,
Җиңүсез юллары юк.
Бары тик бер дәвердә дә
Бәхетле булганы юк.

Андый-мондый ил түгел бу,
Барсын да җиңгән ил бу.
Илдә чыпчык үлми, диләр...
Бөркетләр үлгән ил бу!

## Сер

Ничә еллар беләм. Син барыбер
Минем өчен бетмәс сер, дисең.
Никадәрле мине беләсең син,
Шулкадәрле мине белмисең…

Мин үзем дә әле үземне бик
Тулысынча белеп бетермим.
Бер карасаң, бәхет китерәм мин,
Бер карасаң, берни китермим.
Бер карасаң, бик тә акыллымын,
Бер карасаң, артык тилемен…
Бер карасаң…
Тик бер карау өчен
Туган кешемени инде мин?!

Мин бер карар өчен яшәмәдем,
Бер карама миңа, мең кара.
Меңәр тапкыр меңнәр карасаң да,
Ачылырга торган сер кала.

Ничә еллар беләм, син барыбер
Минем өчен бетмәс сер, дисең…
Ничә еллар мине беләсең син,
Ничә еллар мине белмисең…

## Мөһаҗирләр җыры

Туып-ускән илең бит ул,
Гомер иткән ил бит ул...
Илләреңнән чыгып китү
Бик җиңел түгел бит ул.

Илем, дидем. Җаннар аттым.
Канады канатларым.
Газапларны эчкә йотып,
«Илем», – дип кабатладым.

Илем минем сөюемне
Күңеленә иш итмәде.
Нурларымны күрмәде ул,
Моңымны ишетмәде.

Бар баласы арасында
Иң тугры бала идем.
«Кал!» – диеп әйтмәде илем,
«Кал!» – дисә, кала идем.

«Бер үпкәм, бер әрнүем юк», –
Димим. Бар! – Күңел бит ул...
Туып-ускән илең бит ул,
Үзеңнең илең бит ул...

## Нинди бәхетлеләр булганбыз бит

*Чаба-чаба,*
*Куып җитәбез, дип,*
*Без бәхетне узып киткәнбез бит…*

Нинди бәхетлеләр булганбыз бит,
Үзебез генә белмәгәнбез бары.
Бәхетеңне табу җиңел икән,
Авыр ул бәхетне танулары.

Бәхет һәрчак артык алда кебек,
Булмас сыман аны куып җитеп.
…Ярты гомер киткән инде үтеп,
Үткәннәрне киләчәктән көтеп.

* * *

Әллә нинди сәер чагым,
Барсыннан бизгән чагым.
Кайларгадыр – кайтмас җиргә,
Китәсем килгән чагым.

Илемнән дә, көнемнән дә
Өметне өзгән чагым.
Мин түзмәсәм, кемнәр түзәр,
Дип кенә түзгән чагым.

* * *

Ахмакка да башы кадерлерәк,
Ташка алыштырмас ул башын.
Хәтта асылташка бирмәс башын,
Ничек кенә ахмак булмасын.
Өч тиенлек баш та асыл таштан
Күпкә кыйммәтрәк булганда,
Асылташлар сарайларны бизи,
Асыл башлар ауный урамда.

## Моңаеп калма

Яңгырлар ява
Киткән юлларга.
Ашыкма берүк
Авыр суларга.

Тамчылар тамсын,
Еласын болыт...
Яшик болыттан
Югары булып.

Кара болытка
Куркып карама.
Без якты булсак,
Болыт тарала.

Китте ул, диеп,
Моңаеп калма.
Безнең иң якты
Көнебез – алда.

Өметең өзеп,
Моңаер булсаң,
Сөюем – кояш,
Кояшка ышан!

Кояш сүнми дә,
Сүрелми бер дә.
Ул кайчагында
Күренми генә.

## Кичү

Бу ярлардан теге ярга
Йөзеп чыгалмаганнар.
Җиңәмен дип кергәннәр дә
Җиңеп чыгалмаганнар.

Бу ярлардан теге ярга
Чыгалыр сыман идем.
Беркем салмаган басманы
Мин салыр сыман идем.

Суы салкын. Кага дулкын.
Ник кердем бу суларга?!
Бер чылангач, кире юл юк –
Кала җиңеп чыгарга.

Бәхет сорамыйм Ходайдан,
Сорыйм чыдамлык кына –
Бу ярлардан теге ярга
Йөзеп чыгарлык кына.

## Бәхет

Мин синең бәхетең,
Мин – синең яныңда.
Кадеремне белеп кал,
Яныңда чагымда.

Әгәр син күрмәсәң,
Мин балкып кабынмам.
Күрмәсәң – югалам,
Югалсам – табылмам.

Югалсам, табылмам –
Үзәгең өзелер.
Барлыгым сизелмәс,
Юклыгым – сизелер.

Син бәхет эзлисең,
Узышып җил белән.
Мин сине тоталмый,
Артыңнан йөгерәм.

## Күзгә күренмәс кеше

Их, кемнәргә сөйлим серләремне...
Кемнәр тыңлар?.. Тыңлап, кем аңлар?..
Мин үзем юк сезнең арагызда,
Эзем генә бара урамнан.

Беркем күрми... Теләсәң ни эшлә...
Бер уйласаң, шулай кызык та.
Эзем генә бара...
Ул эзләрне
Сызып булмый. Булмый бозып та.

Шундый чакта күренәсе килә,
Бер тоясы – күренү серләрен...
Ә бәлки, мин кеше түгелмендер,
Эз генәдер, бәлки, җирдә мин...

Их, кемнәргә сөйлим серләремне...
Кемнәр тыңлар?.. Тыңлап, кем аңлар?..
Бер эз генә булып узып барам
Гомер дигән нәни урамнан.

Әй!..
Һәркемнең дә үз газабы бардыр,
Шул газапка һәркем түзәдер...
Үзең булып, эзең булмауның да
Әрнүләре – үзәк өзәдер.

## Кайларга китердең син мине

Кайларга китердең син мине?!. –
Дисең син, капланып иңемә...
...Яшьләрең тамганын күрмимен,
Яшьләрең тамганы сизелә...

Мин сине бәхетле иттемме (?) –
Гомерең: әрнүдән – әрнүгә...
Беләм, син күнегә алмыйсың,
Мин күнгән әрнүләр тәменә.

«Елама, җаным», – дип юатмыйм.
Ела син, елыйсың килгәндә.
Мәңге дә яңармас моң булып,
Бер үтәр бу мәлләр бездән дә.

Кайларга китердең, дисең син...
Кайларга китердем? Белмимен...
Елларны югалта-югалта
Мин җирдә нәрсәдер эзлимен.

Кайларга куйыйм соң мин аны,
Язмышка уралган давылны?..
Кемнәргә ташлыйм бу гомерне,
Кайларга бәрим бу җанымны?!.

Башкалар яши бит, дисең син...
Аларның юллары башкадыр...
Әрнемә, яныңда мин барда,
Минсезлек әрнүдән башланыр.

«Кайларга китердең син мине?!» –
Капланам язмышның иңенә...
...Яшьләре тамганын күрмимен,
Яшьләре тамганы сизелә...

*«Шифалы куллар» әдәби конкурсы*



Рәмзия
Габделхакова

# КЫШЛАР ҮТКӘЧ КАЙТЫРМЫН...

МИСТИК БӘЯН

## 1. Китү

Капка турыларына таныш мотоцикл килеп туктау белән, аны гына көтеп торгандай, Сәвия йөгереп тә чыкты. Елмаеп, Гаязга сәлам бирде дә:

– Бүген кая барабыз? – дип сорады.

– «Ат» үзебезнеке, кая әйтсәң – шунда! Синең боерыкны гына көтәбез! – диде егет.

Аның кәефе шәп иде. Хәер, сөйгәне янына килгән һәр егетнең күңел түрендә бөркетләр оча, ә йөрәгендә былбыл сайрыйдыр.

Кыз бераз уйланып торды:

– Су керәсем килә! Әйдә Усия буасына!

– Шүрләмисеңме? Караңгыдааа... су төбеннән... бичуралар чыгааа... – диде Гаяз, сүзләренә шомлы авазлар кушып.

Сәвия көлеп җибәрде:

– Куркыта да белмисең! Бичура суда түгел, өйдә була бит!

Сәвия Казанда табиблыкка укып йөри. Авылга җәйге ялга кайткан чагы. Гаяз белән мәктәп елларыннан ук дуслашып йөриләр. Укуын тәмамлап, кулына диплом алгач та, Сәвия туган авылына эшкә кайтырга ниятләп тора. Баштарак шәһәр үзенә тартты тартуын, киләчәк язмышын башкала белән бәйлисе иде. Әмма Казанга килеп ай да яшәмәде, авылын өзелеп сагынды, шау-шулы, ыгы-зыгылы бу кала аның өчен түгел икән. Гаяз да шәһәргә китәргә атлыгып тормый. Аңа авылның таллы су буйлары, офыкка тоташкан кыр-басулары, шомырт үскән әрәмәләре, хәтта кычыткалы тыкрыкларына тиклем якын.

– Ышанасыңмы, Сәвия, дөньяда иң күңелле эш – җир сөрү! Күз алдыңа китер: күк читенә тоташкан басуга син хуҗа, артыңда буразналар сызылып

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА (1959) — *шагыйрә, прозаик; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Күзгә яшен», «Көмеш төн», «Кар өстендә миләшләр» һ.б. китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

кала, баш очында ак болытлар йөзә. Әмма син ялгыз түгел, тракторың артыннан, дымлы, җылы җирдән үз ризыкларын табучы кошлар озатып йөри. Тургай-чыпчыгы гына түгел, каргасы да иптәш. Үзебезнекеләр бит!

Шулай ди Гаяз. Ул да бер хыялый инде.

Егет белән кызның күңеле аяз, юллары туры, киләчәкләре якты әлегә. Икесенең дә исәбе авылда, туган җирдә төпләнеп калу.

Яңгыр яуса да, боз яуса да, боларның очрашмый калган киче юк, бергә чакның кадерен белергә кирәк! Бу юлы, буага барышлый, борчак басуына кереп чыгарга булдылар. Борчакның бик тәмле, сусыл чагы хәзер. Әмма инде караңгы төшеп килә, кайда сабак-яфрак та, кайда кузак – күренми. Кул белән капшанып кына җыйдылар. Гаяз кесәләренә, Сәвия итәгенә тутырды.

– Хатыйп абый кебек без, – дип куйды кыз. – Ул гомер буе шулай, әйберләрен капшанып-кармаланып табадыр, әйеме?

– Сукырларның бармагы сизгер була. Бакча буйларындагы читәнне талчыбыктан үзе үргән бит ул. Йортларын ничек карап тора! Кул кушырып утырмый.

– Син белгәнне мин дә беләм, – диде Сәвия. – Әлмәттә сукырлар цехында эшли ул. Авылга кайткач, гел әти янына килә, ниләр генә сөйләшмиләр! Әтием әйтә, Хатыйп абыең кебек укымышлы кешеләр сирәк, ди. Сукырлар өчен махсус китаплар бар икән, төрткеле-төрткеле. Бармакларын шул төрткеләр буйлап йөртеп укыйлар. Гаҗәп бит, әйеме?

– Кеше барыбер җайлаша инде. Сукыр килеш машина йөртүчеләр дә бар әле.

– Булмас! Йөртә ди сиңа! Чамалап алдаш, мине тилегә санама, – дип ачуланган була Сәвия.

– Син артык башлы шул, унны бетереп туган! Казанда укыйсың бит! – дип үрти Гаяз.

Итәк-кесәләренә борчак тутыргач, бу икәү буага юнәлде. Ләкин салкын дип, суга кермәделәр. Бүгенге очрашу урыннары текә ярдагы йөз ботаклы каен төбе булды. Шул каенның кытыршы тәненә аркаларын терәп утырдылар да, сөйләшә-сөйләшә, кузак шартлаттылар.

Һәр көнне очрашкан гашыйклар ни турында сөйләшә?

– Ууу, йолдыз күп бүген! – дип соклана Сәвия.

– Төн аяз, шуңа барысы да күренә. Чүпликме? – ди Гаяз.

– Нәмәрсәмә? Нишлисең аның белән?

– Сиңа бүләк итәм.

– Ә мин аны кая куйыйм? Бакчабызда таш болай да җитәрлек.

– Йолдызны таш белән бутама инде.

– Алар көндез югала бит, төнлә генә балкыйлар.

– Чөнки көндез кояш бар!

– Йолдызлар күктә генә кирәк. Җирдә матурлык болай да күп.

– Һәр кеше аны арттырырга тиеш! – дип, акыл сата егет.

Сәвия бераз уйланып тора да, бала-чага сыман кул чәбәкләп, кычкыра:

– Гаяз, беләсеңме, нишлик? Әйдә без синең белән агач утыртыйк! Пар агач! Яхшы истәлек бит! Әнә Хатыйп абый үзләренең бакчасына күпме нарат утырткан! Авылда яшеллек күп булган саен яхшы, кислород чыганагы бит ул.

Гаяз көлә:

– Сиңа кислород җитмиме әллә?

– Ярар инде, көлмә. Картайгач, шул пар агач янына килеп утырырбыз.

Гаяз тагы көлә:

– Борчак ашарбыз! Борчак ашагач, һава тагы да сафлана инде ул.

– Картайгач, борчак ашарлык тешең калса ярый ла!

– Син врач бит, дәваларсың. Бөтен өмет синдә, Сәвия!

Менә шулай юк-бар сөйләшеп үтә аларның кичләре. Шул арада көлешәләр, үртәшәләр. Өшисең, дигән булып, егет кызны кочагына ала, ялындырып киреләнмәсә, Сәвиясенең алмадай битләреннән, җиләктәй иреннәреннән үбә...

Яшьлек сөяр-сөелер өчен!

Ә төн яшьләр өчен.

Һай, авылда ял көннәре бигрәк тиз үтә... Студент Сәвия тагын шәһәргә китә...

***

Гаяз кайтканда, тәрәзәләр караңгы, беркайда ут янмый иде. Хәер, беренче генә тапкыр түгел. Әнисе аны көтеп утырмый, иртә ятып йоклый. Әмма улының аяк тавышларын ишетеп, барыбер уяна: «Улым, синме?» – дип сорый иде.

Бу юлы дәшүче булмады. Өйдә шомлы тынлык иде. Күңеле нидер сизенеп, Гаяз почмак якка күз салды: әнисенең караваты җыелган килеш тора. Егет бөтен җирдән карап-эзләп чыкты, тик әнисен тапмады. Өйдә дә юк, мунчада да, бакчада да... Сәер, бу вакытта кайда булыр ул? Аптырагач, күршеләрнең ишеген шакыды. Йокламаган булган, күрәсең, Нәгыймә апасы ишекне тиз ачты. Гаязны күргәч, еларга җитешеп, мескен тавыш белән такмаклый башлады:

– И бәбкәм, әниеңне район бүлнисенә озаттылар бит. Ярый әле, вакытында кереп-күреп өлгердем. Ярый әле, чүпрәм беткән иде. Чүпрә алырга дип, сезгә сугылган идем... Керсәм, әниең идәндә тәгәрәп ята. Үлгән дип котым очты. Ярый әле, исән! И Аллам... Хәерлегә булсын инде...

Гаяз аны тыңлап та бетерми үзләренә йөгерде. Егетнең ниятен чамалап алган Нәгыймә артыннан өзгәләнеп кычкырып калды:

– Төнлә барып та йөрмә! Барыбер кертмиләр. Иртән, якты күздә барырсың!

Ләкин Гаяз аны ишетмәде, ярсулы хисләрен тыя алмыйча, әле суынырга да өлгермәгән матаен кабат кабызды...

Төнге юл буш иде, шуңа «ат»ын зур тизлек белән, җилләрне дә уздырып куды егет. Әйтерсең, соңга кала, әнисенә ярдәм итәргә өлгерми. Әйтерсең, анда, хастаханәдә, бары тик аны гына көтәләр...

...Аны беркем туктатмады. Ишекләр үзләреннән үзләре ачылды.

Коридорда утырган дежур сестра да берни сизмичә, өстәл өстенә капланып йокымсыравын белде. Гаяз кызу-кызу адымнар белән туп-туры реанимация бүлмәсенә юнәлде.

Ул атылып-бәрелеп палатага килеп кергәндә, әнисе тәрәзә буенда басып тора иде. Аяк тавышын ишетепме, ишек ягына борылып карады, Гаязы каршына килеп басты. Бер тын бик борчылып, кызганып улына карап торды. Күзләреннән яшь тамды. Кулын сузып, улының йөзен сыйпады, иңеннән кочты:

– Әй, улым...

Шулчак палатага кара күлмәкле, дегет кара чәчле бер кыз ярсып килеп керде. Кергән уңайга Гаязның яңагына китереп сукты:

– Что ты наделал, подлец?! Подонок! Ты испортил всю мою жизнь! Гори в аду, несчастный! – дип кычкырды да ничек керсә, шулай ярсып чыгып та китте.

– Әй, улым... – дип кабатлады әнисе.

Бу вакытта сәгать төнге ике иде...

## 2. Ике яр арасында

Көзге төннәр караңгы була. Бигрәк тә ноябрь ае шыксыз. Болай да караңгы көн бик тиз шомлы төн кочагына кереп югала. Мондый төннәрдә болай соңлап йөрисе түгел дә бит, тоткарланды шул Сәвия. Бераз өстәмә акча булыр дип, урында ятучы бер карчыкны карарга алынган иде. Әбинең кызы көндез әнисен карый, ә кичләрен ниндидер оешмада идән юа. Менә шул арада авыруга күз-колак булып утырырга кирәк. Күп дигәндә, дүрт-биш сәгать. Ләкин бүген карчыкның кызы никтер соңлап кайтты. Гаебен аңлап, гафу үтенә-үтенә, Сәвияне тукталышка кадәр озатып куйды үзе тагы.

Трамвайдан төшкәч, әле шактый җәяү барасы иде. Атлаган саен халык кими торды, ә инде үз урамына борылганда, Сәвия япа-ялгызы калды... Шулчак артта дөп-дөп басып килгән аяк тавышы ишетелде. Сәвия борылып караса, ни күрсен – аны кара күлмәкле, дегет кара чәчле бер кыз куа килә! Инде чапса да, әллә кая китә алмас иде. Шүрләвен сиздерергә теләмичә, тиз-тиз атлавын белде. Менә инде тегенең еш-еш тын алганына хәтле ишетелә. Сәвия аны үткәреп җибәрмәкче булып, читкә тайпылган иде... Кинәт башы чыңлап китте дә гөрселдәп җиргә ауды...

***

Шул мизгелдә Сәвия өчен сәер хәлләр башланды да инде. Караңгы урам да, шәһәр дә кинәт югалды. Хәтта җир, күк тә күренмәс булды. Кайсы якка караса да, күзләр чагылырлык аклык кына иде. Әйтерсең, кар эчендә басып тора, әйтерсең, үзе дә – кар бөртеге... Күзләре бу аклыкка иялэшә төшкәч, моның ниндидер бүлмә икәнен чамалап алды кыз. Түрдәге ак өстәл артында өч кеше утыра иде. Барысы да көмеш чәчле, ап-ак йөзле, юка иренле. Буйлары да, кигән киемнәре дә бертөсле. Өч ирнең дә өстендә яңа яуган кардай кетердәп, балкып торган ап-ак халат.

– Йә, саумы, яңа кеше! Син сынауга әзерме? – дип сорады беренчесе.

Сәвия аптырап калды. Бар кыюлыгын җыеп, пышылдап кына әйтте:

– Нинди... сынау?

Аңа сөйләшергә бик авыр иде, иреннәре көчкә ачылды. Моңарчы белмәгән-хәтерләмәгән иде, сүз әйтер өчен дә көч кирәк икән.

– Сорауга җавап бир: син әзерме? – дип кабатлады ир.

– Белмим... – диде кыз.

– Иң зур хыялың нинди иде?

– Укуымны уңышлы тәмамлап, диплом алу... Яхшы табиб булу... Кешеләргә ярдәм итү...

– Шул хыялыңны тормышка ашырырга әзерме? – дип сорады икенче ир.

– Әзер, – диде Сәвия. Бу юлы тавышы көчлерәк яңгырады.

– Тагы да хыялларың бармы?

«Гаязны күрәсем килә!» – димәкче иде Сәвия. Ләкин әйтмәде, билгесез затларга йөрәк серен ачарга теләмәде.

– Һәркемнең яшерен сере бар, – диде өченче ир, аның уйларын укыган кебек. – Кешеләргә ярдәм итәсем килә, дисең. Төгәл итеп әйт, нинди кешеләргә? Кемнәргә?

– Кемгә ярдәм кирәк – барысына да, – диде Сәвия җавабының хаклыгына тамчы да шикләнмичә.

– Исереккә, каракка, кеше рәнҗетүчегә, сугыш чукмарына... – сорау бирүче җөмләсен шунда өзде, аннары гына: – дамы?! – дип төгәлләде.

Бик авыр сорау иде бу. Сәвия бер мәл аптырап, уйланып торды.

– Исереккә... каракка... Әйе, барыбер дә ярдәм итәр идем... Мөгаен, калганнарына да... Кемгә ярдәм кирәк, барысына да ярдәм итәр идем...

– Бу синең антыңмы?

– Әйе. Мин ярдәмгә мохтаҗ һәркемгә булышыр идем. Кем булуына карамастан. Мин бит сугышчы да, тәртип саклаучы да түгел. Мин – табибә.

– Алайса бар! Антыңны үтә!

Сәвия як-ягына каранды, ләкин ап-ак диварлардан башка берни күрмәде.

– Кая барыйм соң?..

– Җирдә сигез миллиардка якын кеше яши. Бар, туташ, һәркемгә дә ярдәм ит! Син табибә бит.

Кыз каушап калды. Бу кырыс ирләр кемнәр соң? Ни кирәк аларга?

– Зинһар, җибәрегез мине, – дип ялварды Сәвия.

– Кая? – дип сорады игезәкләрнең берсе.

– Өйгә, туган авылыма! Минем хыялым үзебезгә кайтып эшләү иде.

– Ниһаять! Бер ачык җавап, хак сүз ишеттек. Исеңдә калдыр, туташ, беркем дә ялгызы бөтен кешегә ярдәм итә алмый. Әүвәл үзең яшәгән җирдә тәртип урнаштырырга, якын-тирәдәгеләргә игелек кылырга кирәк. Килешәсеңме?

– Килешәм, – диде Сәвия. – Гафу итегез. Сез кем соң? Бу нинди имтихан?

– Без – синең ярдәмчеләрең – Төнге фәрештәләр. Ярдәм кирәк булганда, Җидегән йолдызга карап, безгә эндәшерсең.

Сәвия елмайды:

– Бу бит төш кенә, әйеме? Сез шаяртасыз, әйеме?

Әмма игезәкләр елмаймады. Йөзләре җитди, карашлары кырыс иде.

– Шуны да онытма: йолдызлар таш түгел, һәрберсенең үз нуры бар! Йә, хәерле юл, туташ! Вакыт җитте, сынавыңа кереш!

Шулай диделәр дә югалдылар...

«Сәер, болар минем хакта барысын да белә... Юк, булмас. Төш кенә бу...» – дип уйлады Сәвия.

Күзен ачканда, ул ниндидер караңгы, тынчу бүлмәдә ята иде...

***

Күпмедер вакыттан соң ишек ачылды, бүлмәгә ут яктысы сузылды. Шул яктылыкка ияреп, юантык гәүдәле зәңгәр халатлы бер хатын килеп керде. Почмакта утырган Сәвиягә игътибар да итми, киштәдән нидер алды да чыгып китте. Сәвия әкрен генә басып ишеккә килде, алда озын коридор күрде. Коридор буйлап, ике яклап та ак ишекләр тезелеп киткән, агач идәннәр кызгылт көрән төскә буялган. Бик таныш җир инде бу үзе. Сәвия коридор буйлап китте, юлында чуар халатлы, нурсыз йөзле бер хатынны очратып:

– Нинди йорт бу? – дип сорады.

Хатын аңа күз дә салмыйча, дәшмичә үтеп китте.

Сәвия ишекләрнең берсенә төртте, тик ул ачылмады. Сәер, дип уйлады кыз. Кайда соң мин? Кайсыдыр бүлмәдән, бик кырыс, таләпчән хатын-кыз тавышы ишетелде:

– Бүген санэпидемстанциядән киләләр, бөтен җирне ялап чыгыгыз!

Шул тавыш артыннан ук аның хуҗасы күренде. Бу авыл хастаханәсенең өлкән шәфкать туташы Хәкимә Вәкиловна иде.

«Мин авылда, үзебезнең больницада!» – дип шатланып уйлады Сәвия. Аңа нидер булган, тик үзе белми-сизми калган. Кыз, сөенә-сөенә, баш табиб кабинетына юнәлде. Ул кергәндә, Мәҗит Даймасов бик бирелеп ниндидер журналлар актарып утыра иде, Сәвиягә игътибар да итмәде.

– Исәнмесез! Мин нишләп монда? Миңа ни булды? – дип сорады кыз.

Ләкин аны ишетмәделәр. Бераздан Даймасов кәгазьләреннән арынып, башын күтәрде, Сәвиягә туп-туры карап торды. Әмма кызның кабинет уртасында үзенә төбәлеп басып торуына исе дә китмичә, урыныннан кузгалып, чыкты да китте. Сәвия аның артыннан иярде, соравын кабатлады:

– Миңа ни булды? Мин нишләп монда?

Бу юлы да соравы җавапсыз калды. Кызның күзенә диварда эленеп торган авырулар исемлеге чалынды, ул үзенең фамилиясен эзләде, ләкин тапмады. «Мин йокламыйм, уяу ич! Ни булды соң?!» – дип аптырады ул.

Шулчак диварга сөялеп торган ач яңаклы, сап-сары йөзле бер ябык ирне күреп алды. Бая гына бу кеше монда юк иде, кай арада чыгып баскандыр.

– Эзләмә, син исәннәр арасында юк, – диде ул. Авызын зур ачып, ямьсез итеп көлеп куйды. Аннары Сәвиягә озын, ябык кулын болгап, дивар эченә кереп китте...

Куркынган кыз: «Бу мөмкин түгел! Күземә генә күренде. Ник саташам соң мин?» – дип уйларга өлгермәде, колагына кемдер пышылдады: «Ышанмасаң, көзгегә кара!» Сәвия, ялт итеп, тавыш килгән якка борылды, тик анда беркем юк иде. Шулчак каршыдагы палата ишеге ачылып, аннан таяк белән чиләк күтәргән хатын килеп чыкты да коридор идәнен юарга кереште. Үз күзләре белән күреп торды Сәвия, идән чүпрәге берничә тапкыр аның аяклары аша узды. Бу коточкыч күренеш иде, ул куркып, ачынып кычкырып җибәрде. «Ышандыңмы?» – дип хихылдады кемдер, бәлки, нидер...

«Димәк, мин үлгәнмен... Үлгәнмен?! Ләкин уйлыйм, күрәм, ишетәм бит, йөрим, сөйләшәм... Ничек алай була соң ул? Димәк, үлгәннән соң да яшәү бар... Ләкин ул башка, бөтенләй башка... Мин бар да, юк та. Җаным исән, ә тәнем юк... Кайда ул?!» – Сәвиягә куркыныч булып китте, ул идәнгә чүгәләп, үксеп елап җибәрде. Аны беркем ишетмәде, күрмәде, өстенә басып диярлек, этә-төртә үтә тордылар...

Ул өенә кайтырга булды. Үлеме-тереме, кадерле кешеләре янында яшәр... Хәер, нинди яшәү... торыр. Һәр көнне әнисен, әтисен күрер, тавышларын ишетер. Шунда җанына тынычлык табар. Ничек, ни өчен бу хастаханәгә килеп эләккән ул, шунысы берничек аңлашылмый.

Кыз тышкы ишеккә юнәлде. Урамда буран котыра, җил дулый, ишеп яуган карлар арасыннан берни күренми. Кай арада кыш килгән соң? Кичә генә кара көз иде ләбаса. Гаҗәп халәт, Сәвия ни җилне, ни салкынны тоймый... Капкага килеп җиткәч, аның каршында ап-ак киемле олы гәүдәле таныш түгел бер зат пәйда булды, юлын бүлеп басты. Карашы бик кырыс иде.

– Борыл! – дип боерды ул бик кырыс, көчле тавыш белән. – Син ант бирдең! Сынау урынын үзең сайладың.

Шул чакта Сәвия төшен искә төшерде, әмма төш булмаган икән ул. Менә ничек... Димәк, ул шунда хезмәт итәргә тиеш. Ләкин ничек? Куллары берни тоймый, үзен күрмиләр, сүзен ишетмиләр... Почмакта посып ятмас бит. Бу сынау күпмегә сузылыр? Еларга җитешеп, Сәвия юлыннан кире борылды. Ә теге зат юкка чыкты...

***

Беренче көнен Сәвия баш табиб артыннан йөреп үткәрде. Кыш булгач, хастаханәдә ятучылар шактый, палата саен өч-дүрт кеше. Кайсы салкын тидергән, кайсы таеп егылган, кайсының эче авырта, биле сызлый... Култык таягы белән йөрүчеләрне санамаганда, авыр чирлеләр юк үзе. Алары да тик ятмый, титаклап булса да, әрле-бирле йөренеп торалар. Бүзәр хастаханәсендә телевизор юк, хатыннар гайбәт сөйләп, шәл-оекбаш бәйләп, ир-ат халкы шахмат уйнап, домино сугып, көн үткәрә...

Сәвия баш табиб Мәҗит абыйның сүз-киңәшләрен тыңлап, күңеленә сеңдереп йөрде. Даймасов, иртәнге обходны үткәреп, үз кабинетына кереп киткәч, әниләр һәм бәбиләр палатасына юнәлде. Анда күңелле, анда тормыш гөрли! Бәбиләр елый, әниләр көлә. Беркем уфтанмый, зарланмый. Яшь хатыннар бала сөя, көлешә-көлешә, авырлы чактагы галәмәтләрен, кызык-мәзәк хәлләрне сөйлиләр. Берсе иреннән күгәргән килька балыгы, икенчесе акбур таптырган, өченчесе бензин исе дип саташкан... Буш караватка сузылып ятып, Сәвия шуларның шат тавышын, сабыйларның елавын рәхәтләнеп тыңлады. Акушер Мөнәвәрә Исламовна берничә тапкыр кереп, әниләрнең дә, бәбиләрнең дә хәлен белешеп чыкты. Аның артыннан хатыннар мәдхия яудырып калды:

– Әй бу Мөнәвәрә апа! Алтын да кеше инде. Исән генә булсын! Кулы шул хәтле җиңел! Йомшак тавышы белән дә булыша. Бөтен авыртуларны онытасың.

– Әйе шул, район роддомындагы Тамара түгел инде. Ул бит кешечә сөйләшә дә белми. Әйтерсең, үзе бала тапмаган, ни икәнен белми...

– Безнең авыл Фәридәнең беренче баласы шуның аркасында әрәм булды да инде. Баланың зур икәнен дә белеп торганнар, ярып кына аласы бит! Юк, соңгы чиккә кадәр сузганнар... – дип уфтанды әниләрнең иң олысы.

– Шуннан, тапканмы соң?

– Кая, юк инде. Үзе аңын югалтып егылгач, сабые үлгәч, ярганнар... Кем әйтмешли, после пожар... Шалкан кебек малайны үтерделәр, наданнар! Бер ышаныч юк аларга. Шуңа күрә Бүзәргә килдем дә инде.

Яшь әниләр бишенче бәбиен алып кайткан апаның сүзен хуплап:

– Әйе шул, ярый әле, монда килгәнбез. Мөнәвәрә апа үз эшенең остасы инде! Куллары шифалы! – диештеләр.

Сәвия хатыннарны көнләшеп тыңлап торды. Нинди бәхетле алар!

Ә Сәвиягә карын астында бала йөртергә дә, сабый сөяргә дә насыйп булмаган икән... Ана бәхетләрен татырга өлгермәде шул...

Нигә шулай иртә үлде соң ул?!

Аһ, нинди зур үкенеч, яшәргә дә өлгерми, ямьле тормыш белән хушлашулар...

## 3. Серле ярдәмче

Төнлә ишек дөбердәткән тавышка сискәнеп уянды ул. Атылып урамга чыкты. Ишек төбенә бер атлы килеп туктаган иде. Кыска тунының төймәләрен дә каптырмаган 50-60 яшьләрдәге ир тынгысызланып, баскан урынында таптанып тора. Борчулы карашы хастаханә ишегенә юнәлгән, үзе әледән-әле чанасына әйләнеп карый. Ниһаять, ишек ачылды, анда бүген төнге кизүдә торучы шәфкать туташы Гөлшат күренде.

Ир аның каршына атылды:

– Коткарыгыз, сестра! Зинһар коткарыгыз! Тизрәк!

Ләкин йокысыннан айнып бетмәгән Гөлшат тыныч иде:

– Ни булды шул хәтле? Авылыгыз янмыйдыр бит?

– Авыл түгел, йөрәк яна! Зинһар, ярдәм итегез! Улымның хәле бик авыр! Үзе ут кебек яна. Эчем авырта, ди. Косты, эче китте. Ни булган – белмибез. Иванкинодан без. Атны юл буе чаптырдым. Зинһар, ярдәм итегез!

Гөлшат чана янына килде, толыпны ачып, авыруга күз салды. Анда очлы борынлы, киң маңгайлы 14-15 яшьләрдәге малай ята иде. Кыз кулын аның маңгаена куйды, бишмәтен күтәреп, эченә баскалады да:

– Абый, бу безнең авыру түгел бит. Тизрәк районга илтегез, – диде.

Абзый коелып төште:

– Как так? Ничек инде алмыйсыз? Күрәсез бит, кеше үлеп ята. Районга 25 чакрым, ни булмас ул арада? Юлы юл түгел, кар баскан.

– Аңа срочно операция кирәк! Бездә ясамыйлар.

– Элек ясыйлар иде бит! Хатынның үт куыгын сездә алдылар.

– Элек бит ул. Хәзер рөхсәт юк. Вакытны әрәм итмәгез, районга илтегез.

Сәвиянең сабырлыгы бетте. Ул да егетне күрә, хәлен бик яхшы аңлый, авыртудан йөзен чытып, ыңгырашып яткан бу бала шулкадәр кызганыч. Ничек тә ярдәм итәргә кирәк! Ләкин ничек? Гөлшат сүзендә дә хаклык бар, Бүзәр хастаханәсендә хирургия бүлеге күптән ябылды. Ләкин авыруны бу хәлдә ерак юлга чыгару да куркыныч, сукыр эчәгесе, барып җиткәнче шартлавы бар...

– Өлгерә алмыйлар! Күрә торып үлемгә җибәрәбез! – дип кычкыра Сәвия.

Әлбәттә, аны ишетмиләр.

Шулчак үзеннән сорау алучы сәер затлар, аларның сүзләре исенә төште. Бик авыр булса, ярдәм кирәксә, безне чакыр, диделәр түгелме соң? Әлегәчә аларга эндәшкәне булмады. Ләкин бу очракта ул читтә басып кала алмый. Сәвия йөзен күккә күтәреп, карашын Җидегән йолдызга төбәде дә өч тапкыр:

– Төнге фәрештәләр! – дип аваз салды.

Ни буласын, нинди ярдәм киләсен ул үзе дә белми әле. Ләкин башка чара юк, бу егетнең газапларына чик куярга, аны коткарырга кирәк! Шулчак башы әйләнеп китте, йөзенә кемдер кайнар сулыш өргәндәй булды. Сәвия үзенең кулларын тойды, бармаклары егетнең кайнар тәненә кагылды. Мин тоям, димәк, мине дә күрәләр, ишетәләр. Менә нидә икән Төнге фәрештәләрнең ярдәме!

– Әгәр без алынмасак, районга барып җитүләре шикле, – дип Гөлшатка дәшмәкче иде, әмма аны күрмәде. Кай арада юкка чыкты соң ул?

– Абзый, әйдәгез, ярдәм итегез. Улыгызны алып керик, – диде Сәвия.

Аны ишеттеләр!

Әле генә, кабул итәргә теләмичә, аяк терәп каршы торган кырыс шәфкать туташының кинәт йомшак дәшүенә күңеле булып, абзыйның күзләре яшьләнде. Хисләнеп, дулкынланып:

– Ай рахмат! Дай вам Бог, дай вам Бог... – дип сөйләнде.

Ике яктан култыклап, егетне процедуралар бүлмәсендәге ятакка кертеп салдылар. Ләкин абзый тынычланмады, хафаланып сорады:

– Әллә операцияне үзең ясамакчы буласың? Врачыгыз кайда?

– Мин авыруны операциягә әзерли торам. Ә врачны сез алып килерсез. Ерак түгел, монда гына яши ул. Санитаркабыз юлны күрсәтер, – диде Сәвия.

Аларны озаткач, «Шалтыратып, Мәҗит абыйны уятырга кирәк, җыена торсын», – дип, Сәвия табиб кабинетына юнәлде. Үтеп барганда, карашы шкаф пыяласына төште, үз күзләренә ышанмыйча, сискәнеп-куырылып китте:

пыялада аның чагылышы түгел, ә Гөлшат иде! Шул мизгелдә кыз башыннан әллә ничә төрле уй узды: «Менә ничек... Шулай булуы мөмкинме?! Бу бит шаккатмалы хәл! Ул хәзер Гөлшат булып калачакмы?» Ләкин баш ватып, елап утырырга вакыт юк, тизрәк эшкә керешергә, егеткә ярдәм итәргә кирәк! Калганын иртәгә уйлар...

Ун минут та үтмәде, ашыга-кабалана Мәҗит абыйсы килеп керде, кулын юып, халатын, перчаткаларын киеп, авыру янына килеп басты...

«Операция уңышлы үтте!» – Даймасов, канәгать елмаеп, шулай диде. Сүзгә ни саран булса да, кызга мактау яудырды:

– Кеше үлемен өстебезгә алганчы, инструкция бозган өчен хөкем итсеннәр, шулай бит? Ә син молодец, сеңлем! Карап торышка куркак, җебегән сыман, ә кирәк чакта кыю икәнсең. Гомер буе хирург ярдәмчесе булып эшләгән тәҗрибәле ассистент диярсең!

Ни дисен Сәвия? Үзенең медицина институтында укып, хирургия бүлегендә практика үткәнен дә, Төнге фәрештәләр турында да, мизгел эчендә Гөлшатка әйләнеп куюын да ул Мәҗит абыйсына сөйли алмый бит. Таң ату белән барысы да үз урынына кайтачак, Сәвияне беркем күрмәячәк...

Ә иртән операция ясалган авыру янына укол кадарга, температура үлчәргә Гөлшат үзе керер. Егет аңа күзләрен тутырып карар да гаҗәпләнеп әйтер:

– Это были не вы... Вчера была другая...

Ләкин Гөлшат аны аңламас.

***

Шулай итеп, Сәвия беренче чирканчык алды. Кешеләргә ярдәм итү серенә төшенде ул. Кирәк булса, чал чәчле игезәк агайларның тылсымы белән башка тәнгә күчеп, тиешле эшне башкара ала икән. Ләкин төнлә, бары төнлә генә! Менә ни икән ул «Төнге фәрештәләр»! Нинди генә хикмәтләр юк бу дөньяда!

Бер көнне җитмеш яшьлек Минҗамал әбине китерделәр. Тиктормас карчык, сарыкларга печән ташлыйм дип, лапас башына менгән. Ә төшкәндә, баскычыние белән улак өстенә егылган. Больницага аны улы белән килене китерде.

– Салмагыз, өйгә кайтарыгыз! Әҗәлем җиткәндер, – дип карышты әби. Көчкә үгетләп, алып калдылар. Килене, бу хәлгә үзен гаепле санап, акланды:

– Кем кушкан инде аңа?! Кичен үзем салган булыр идем. Һәр көнне эштән соң кагылып, ярдәм итеп чыгам лабаса. Балалар да һәр йомышын үтәп тора. Ни дип менәргә иде инде...

Акланмаса да, беләләр, Минҗамал әбине биш баласы биш якка тарта, үзләренә яшәргә чакыра, әмма карчык: «Үз өемдә – үз көем, берегездә дә торасым килми!» – дип, тәки ялгызы яшәп ята.

«Башым нык шаулый, поезд тавышы ишетәм», – дип зарлангач, Минҗамалны бер кешелек палатага салдылар: «Бер үзенә – бер бүлмә, тынычлап ятсын!» Йөдәтүче, борчучы юк, тәрәзәләр бакча ягына карый, типтын. Әмма Минҗамал абыстайга тыныч ятарга язмаган, күрәсең. Ул саташа башлады. Һәр иртәдә обход вакытында эчкә баткан күзләрен кабат тәгәрәтеп чыгарырдай булып, бик гасабиланып зарлана:

– Мәҗит энем, яныма киләләр бит... Әйтәм инде, алып китегез, тик зинһар, күземә күренмәгез, куркытып йөрмәгез, дим.

– Кемнәр килә, Минҗамал апа? – ди Мәҗит.

– Ак бөркәнчек ябынган бер яшь кенә хатын килә. Килә дә, балам дип,

чәчемнән сыйпый. Бөтен тәнем чымырдап китә шул чакта. Юрганымны рәтләп яба. Мин аның адымнарын, җилен сизәм хәтта. Чын мәгәр, ышаныгыз. Чәчләрем үрә тора. Тын алырга да куркып бастырылам. Ни кычкыра, ни урыннан кузгала алмыйм. Үлеш инде, балалар... Нишләргә хәзер миңа? Һәр төндә килә бит... Йокым йокы түгел. Кайтарыгыз, зинһар, өемә. Ялгыз яшәсәм дә, өйдә болай саташканым булмады. Төннең үткәнен дә сизми кала идем...

– Сотрясение, баш мие селкенү нәтиҗәсе, саташу гына бу, – дип тынычландыра Мәҗит карчыкны.

– Юк-юк, саташу түгел. Валлаһи дим, ап-ачык күрәм мин аны! Зинһар, башка бүлмәгә, кешеләр янына күчерегез! Ялгызым куркам, тилерәм мин монда.

– Ярый, шулай итәрбез, – ди Мәҗит.

Сәвия дә бу вакытта палатада, боларның сөйләшкәнен ишетеп тора. Бу сәер хәлләргә ул аптырамый, хастаханә коридорында буталып йөрүче затларның берсен үзе дә күрде. Төнлә түгел, әле яп-якты иртәдә. Бер күрүдә котын алды, һәр төндә килә башласалар, акылдан да язарсың. Минҗамал әбине бик кызганды кыз. «Миңа зыян сала алмаслар», – дип, төнне карчык янында үткәрергә булды.

Ак бөркәнчек ябынган хатын төн уртасында килеп керде. Сәвияне күргәч, туктап калды. Чебиләрнекедәй чыелдавык нечкә тавыш белән:

– Ник син монда? – дип сорады.

– Ә син ник монда? Ник кеше куркытып йөрисең?

– Иркәлисем килә бит...

– Башкаларны иркәлә. Нигә бу әбине борчыйсың?

– Сиңа әби, ә миңа бала. Мин бит аны туйганчы сөя дә алмадым. Ул шундый елак бала иде, минем куенымда гына тынычлана иде. Ә мин аны ятлар кулына калдырып киттем. Их, балам-багалмам... – Өрәк Минҗамал әбинең аяк очына килеп утырды да арык куллары белән аны сыпыра башлады.

– Уятма, борчыма аны, – диде Сәвия.

– Аның мәңгелек йокысы якынлаша. Ул үзе дә сизә. Шуңа мине күрә, курка. Моңарчы аның янына килергә ярамый иде. Хәзер генә рөхсәт булды. Аны алырга җибәрделәр мине. Әнисе икәнемне белми ул. Каян хәтерләсен, өч яше дә тулмаган иде бит. Син соң беләсеңме: ачлык елында күпме халык кырылды монда! Шул каберлек хастаханә бакчасында калды хәзер. Җәен дә, кышын да, чаганнарны сырып алып, каркылдаган каргалар каян килә дип беләсең? Авыруларны борчучы мин генә түгел. Нечкә җаннар сизә, тик таныйсылары килми. Үзләрен төш күрдем, саташтым дип тынычландыралар. Бик катлаулы шул дөньялар. Анда да, монда да...

– Каргалар күп шул, бик шомлы кычкыралар, – диде Сәвия.

– Киткәннәргә дога кирәк. Мондагылар догасыз ята, – дип җаваплады Өрәк.

– Ә син алай куркыныч түгел икәнсең... – диде Сәвия. – Гомере беткәч, әҗәле җиткәч, әбине монда яткырудан, дәвалаудан файда да юктыр инде... Әйт, нишлик?

– Әби түгел, минем кызым ул! Кызымны өенә кайтарыгыз! – диде Өрәк. – Үз нигезендә җан бирсен. Син ярдәм итә аласың, шулай бит?

– Белмим... Рөхсәт булырмы?

– Хуш, килештек! Сүз бетте! – диде хатын һәм шундук юк булды...

Ул китте дә барды, ә Сәвиягә баш ватарга калды. Кем белән, ничек башкарырга бу эшне?..

– Йә, бүген ничек хәлләр? Йоклап булдымы? – дип сорады Даймасов обход вакытында.

Минҗамал елмайды:

– Сөбханалла, бик тыныч йокладым! Беркем борчымады, килүче булмады.

– Башка палатага күчәсеңме?

– Юк, Мәҗит энем, өйгә генә кайтарыгыз мине. Әйтәм ич, хәлем бик яхшы, бер җирем дә авыртмый! Башым да шауламый. Йокысызлык аркасында гына авыртынганмын икән.

Мәҗит карчыкны тыңлап, кан басымын тикшереп карады да шаккатып, баш чайкады:

– Төн эчендә күпме үзгәреш! Әйтерсең, бүген кияүгә бирерлек ять-яшь кыз!

– Әйтәм бит, авырмыйм, терелдем мин. Чыгарыгыз мине.

– Ашыкмагыз әле, апа. Кан анализларын да тикшереп карыйк. Барысы да яхшы булса, чыгарырбыз. Өеңә тынычлап кайтырсың.

Әмма Минҗамал карчык икенче көнне көтеп тормады. Баш табиб эшен бетереп, өенә кайтып китүгә, ул да әйберләрен җыеп, арткы ишектән бакча ягына чыкты. Йөгерә-атлый капкага юнәлде. Урамга чыккач, аның адымнары салмакланды, картларча бөкрәя төшеп, аягын көчкә сөйрәп, ава-түнә атлап китте...

Сәвия аны капка төбендә озатып калды.

Икенче көнне Минҗамал абыстайның дөнья куйганын ишеттеләр...

***

Авыруның язмышы дөрес диагноз куюга бәйле. Саулыкка юл шуннан башлана. Кичке якка әнисе җитәкләп килгән Фоатка Даймасов нинди диагноз куярга белми аптырады. Чөнки егет баш авыртудан, күңел болганудан зарланды. Ә баш авыртуның да, күңел болгануның да йөз төрле сәбәбе бар, кул белән капшап кына белешле түгел. Даймасов авыруның бүген кайда, нишләп йөрүе, ни ашау-эчүе белән кызыксынды. Ләкин Фоат урынына әнисе җавап бирде:

– Эштән кайтты да тирләп-пешеп кар көрәде... Кичен башын тотып егылды. Аптырап килдек инде, Мәҗит. Зинһар, ярдәм итегез! Бигрәк интегә бит бала.

Колхозда төрле эштә эшләп, әле һаман буйдаклар сафында йөрүче утыз яшьлек «бала» дәшмәде, башын учлап, йөзен чытып, чайкалып утыруында булды. Мәҗит аның кан басымын, температурасын үлчәп карады.

– Косасың килмиме?

– Килә... – диде егет, ыңгырашып.

– Алайса бар, бармагыңны авызыңа тыгып, косып кил, – дип киңәш бирде Мәҗит аптыраганнан. Егет әйләнеп килгәч:

– Йә, җиңеләйдеме бераз?

– Юк... – диде Фоат. – Башым ярылырдай булып авырта...

– Кан басымың түбән, температураң югары. Бу килеш кайтарып җибәрә алмыйм, ятарга туры килер. Иртән иртүк анализлар тапшырырсың.

Табибның бу сүзләрен ишеткәч, ана кеше гасабиланырга тотынды:

– Ни булган соң улыма? Нинди зәхмәт бу? Үтә торган чирме?

– Әлегә төгәл диагноз куя алмыйм. Иртәгә, анализларны карагач, ачыкларбыз, – диде Даймасов.

Өлкән шәфкать туташы Хәкимә Вәкиловна төнге кизүдә үзе калырга булды. Авыруга температураны төшерә, авыртуны басып тынычландыра торган уколлар ясалды. Улы йокыга талгач кына, әнисе өенә кайтып китте...

Ә Сәвия ул төнне коридорда радио тыңлап утырды. Аны, кичке концерт тыңлыйм дип, бер агай кабызып куйган иде. Концертын тыңлады да палатасына кереп китте. Ә радиода кичке яңалыклар башланды. Элек Сәвия ил хәбәрләре, дөнья хәлләре белән әллә ни кызыксынмый иде. Бүген йотлыгып, бирелеп тыңлап утыра. Чыбыклар, дулкыннар буйлап агылган сүзләр аны гүя чын тормыш белән бәйли.

Ни битараф кеше булсаң да, үзең яшәгән ил вакыйгаларыннан читтә калалмыйсың. Ике еллар элек ил башлыгы вафат булгач, студентларны институтның актлар залына җыйганнар иде. Сәхнә түренә күкрәген бихисап орден-медальләр бизәгән «Генсек»ның олы портреты куелды. Башта ялкынлы чыгышлар булды, аннары тын калып ил башлыгы белән хушлаштылар. Сәвия яхшы хәтерли, ул көннәрдә илдә матәм булды, байраклар төшерелде. Радиодан да, телевизордан гел матәм көе агылды, экранда кара кайгыга баткан бик җитди кыяфәтле кешеләр бер-берсен алыштыра торды. «Бу олы кайгы безне тагы да ныграк берләштерер. Ленин сызган юлдан тайпылмабыз! Кадерле Леонид Ильич Брежневның исеме хәтерләрдә мәңге сакланыр! Яшәсен Коммунистлар партиясе!» – дигән купшы сүзләр күп яңгырады. Аннары Андропов дигән бик кырыс карашлы ир дәүләт башлыгы булып куйды. Инде ул да вафат икән... Шулай инде, һәр ел кемнедер алып китә, кемнедер алып килә. Картлар ярар инде, алар яшисен яшәгән. Вакытсыз өзелгән гомерләр җәл... Кем уйлаган, Гаяз белән Сәвиянең гомере шул тиклем кыска булыр дип?!

Шулай уйланып-моңланып утырганда, Сәвия каршында кинәт кенә Фоат пәйда булды. Кызга шаккатып карап торды да:

– Бәрәч, Сәвия! Син дә мондамыни? Кайчан кайттың? – дип сорады.

Сәвия сискәнеп китте. Ничек әле Фоат урыныннан кузгалган? Ул бит шул кадәр көчсез, хәлсез иде. Шул арада уколның тәэсире беткәнме? Ә Сәвияне, чынлап та, күрәме ул?! Исеме белән эндәште бит. Монда башка Сәвия юк лабаса! Нинди могҗиза булды бу?!

Кыз күңелендәге давылны егеткә сиздермәскә тырышып:

– Мин хәзер монда эшлим бит, – дигән булды.

Фоат аны ишетте.

– Шулаймыни? – дип кайтарып сорады. – Врач булсаң, шуны әйт: нинди хикмәтле укол кададыгыз сез миңа? Шаккатмалы хәл бит! Уянып киттем, тордым... Карасам, үзем караватта ятам, үзем басып торам. Ике мингә әйләндем, аңлыйсыңмы? Иң гаҗәбе шул: бер җирем авыртмый! Валлаһи, Сәвия, шундый рәхәт! Очып йөрим менә, тәнем шундый җиңел! Кайтып китәм мин, нишләп ятыйм монда?! Әнине шатландырыйм әле.

– Юк, китмә! Бар үз урыныңа! – дип кычкырды Сәвия.

Үзе тизрәк ул яткан палатага юнәлде. Фоат, шабыр тиргә батып, дер-дер калтырап, урынында ята иде. Көчкә тын ала, сулышы өзек-өзек. Сәвия ярдәмчеләренә аваз салырга ниятләп, ишеккә атылган иде, Хәкимә апасына килеп бәрелә язды. Аның артында ук «икенче Фоат» күренде. Ул шәүлә сыман шуып, койкасы янына килде, башын иеп, аяк очында бераз басып торды да кинәт һавада эреп юкка чыкты...

Хәкимә Вәкиловна, авыруның билгеләре буенча тычкан бизгәге түгелме икән, дип шикләнгән, шуңа бу вируска каршы препарат биргән. Анализ нәтиҗәләре дә әлеге диагнозны раслагач, Фоатны ашыгыч рәвештә район хастаханәсенең инфекция бүлегенә озаттылар. Савыгып кайткач, бәхетле егет авыл табибларына рәхмәт әйтергә килде. Ә Сәвия, адым да калмый, аның

артыннан ияреп йөрде. Кызның шуны бик беләсе килә иде: ул төндә аны күргәнен,ниләр сөйләгәнен хәтерлиме икән Фоат? Ләкин егет бу хакта ләммим сүз әйтмәде. Күрәсең, хәтерләмидер. Яки ярамыйдыр, шулай булырга тиештер...

***

Сәвия балалар ярата. Үзе гаиләдә төпчек булгач, аңа эне-сеңелләр җитмәде. Иптәш кызлары, апа булып, кечкенә туганнарын ияртеп йөргәндә, аларга гел кызыгып-көнләшеп карый иде. Кунакка нәни балалы туганнары килсә, Сәвиягә бәйрәм, ул аларны үзе белән ияртеп, урамга чыгып китә, таган атындыра, су коендыра, сәпиттә йөртә. Әнисе көлеп: «Сиңа нәнке генә буласы икән», – ди иде. «Нәнке» түгел, күп балалы әни буласы килә иде Сәвиянең. Гаязына да ныклап ышандырды: «Безнең биш балабыз булачак! Ике малай һәм өч кыз!»

– Ә нигә кызлар күбрәк? – дип аптыраган иде Гаяз.

– Малайларда өмет юк. Алар оча да китә. Картайгач, әти-әнине килен түгел, кызлар карый. Кызлар мәрхәмәтлерәк.

– Ялгышасың, малайлар түгел, кызлар очып китә.

– Элек шулай булган, ә хәзер алай түгел! Малайлар хатыннан артмый, – дип, күңеленә сеңеп калган олылар сүзен кабатлый Сәвия.

– Син дә мине әнидән тартып алмакчы буласыңмы? Чамала, бездә кызлар юк. Әнинең бөтен өмете миндә, – диде Гаяз.

Егетеннән шундый сүзләр ишеткәч, Сәвия уңайсызланган иде.

– Синең әниең миңа да бик якын. Нурсинә апа зыянсыз кеше бит ул. Ант итәм, ташламыйбыз аны! – дип акланды.

– Мин сиңа ышанам, – дигән иде Гаяз.

Нурсинә теге чакта район хастаханәсеннән терелеп кайтты кайтуын. Ләкин авыр кайгы аңа ныгырга бирмәде, хәсрәтле уйлары җанын кимерә, тормышын кояшсыз итә иде. Ул яшәүдән туйган сыман йөри, улы турында ялгыш сүз чыкса да, үксеп елый башлый. Баласын, әле җитмәсә бердәнберен җуйган анадан да бәхетсез җан бармы бу дөньяда, аны юатырлык сүзләр, көчләр бармы?!

Беркөнне хастаханәдә Нурсинәнең күршесе Нәгыймә пәйда булды. Ашказаны авыртып килгән, Һинд иленнән кайткан иң яхшы дарулар белән дәваланып ята хәзер. Авырса да, теле тик тормый үзенең. Палатада иртәдән төнгә кадәр аның көр тавышы яңгырап тора. Шуны белгән Сәвия бу палатага еш сугыла, Гаязның әнисе турында сүз чыкмасмы дип өметләнә. Көтүе бушка булмады, күршесен телгә алды Нәгыймә:

– И туганнар, безгәме соң зарланырга? Картлар үлем көтә, яшьләр үлеп китә дигәндәй. Менә Нурсинә: «Мин үлсәм, Гаязым нишләр?!» – дип йөри иде. Үзе исән калды, ә Гаязы китеп барды. Мескенкәем, дөнья яктысын күрми хәзер... Шул чакта әйттем бит мин ул тискәре малайга, йөрмә төнлә матайга атланып, дидем. Күңелләрем сизгән икән. Юк бит, тыңламады сүземне. Анасына күпме хәсрәт салды. Үзе дә юк, кеше баласын да харап иткән. Ул бәрдергән кыз шул атнада кияүгә чыгасы булган икән. Туй күлмәгендә күмгәннәр мескенне...

Сүзгә түбән оч Оркыясы кушылды:

– Анда да канат өзелгән, монда да... Казанда бырачка укып йөрүче Сәвия белән кушыласы иделәр бит. Камил кызын әйтәм.

– Ул кыз кияүсез калмас анысы. Әнисенә охшаган, бик чая, үзенә дигәнне өзеп ала. Кызларга кияү булыр, анага ул табылмас... – дип уфтанды Нәгыймә. – Нурсинә мескенкәем, яшәвемнең бер яме калмады, дип елый. Гаязының

үлеменә әле һаман ышанмый бит ул. «Күрдем мин аны, каршымда басып торды», – ди. Күзенә күренгән, саташкан инде. Өч көн һушсыз ят та... Гаязын үзеннән башка озаттылар. Артык зур хәсрәт шул. Аллам сакласын! Балаларыбыз исән булсын!

Сәвия хатыннарның һәр сүзен ишетеп торды. Сәер, аның үлеме турында бер сүз булмады. Кияү табылыр, диделәр. Әллә соң авылда аның исән түгеллеген белмиләр дәме? Казанда укуда дип кенә уйлыйлармы?!

***

Бер төндә төтен исенә тончыгып уянды ул. Үлгәннән бирле ис тойганы юк иде. Бу юлы ап-ачык тойды, төтен исе күзләренә, борынына кереп әчеттерде. Айнып китсә, бернинди ут-төтен юк. Ләкин ис бар, ни хикмәт, тоя бит ул аны!

Сәвия коридорга чыкты. Анда да шикләнерлек әйбер сизмәде. Барча бүлмәләрне айкап чыкты, ут юк, төтен юк, ә янган ис бар! Бу хәлгә аптырап, кабул итү бүлмәсендәге диванга килеп утырды. Көтәргә, күзәтергә кирәк, нindидер билге, кисәтү булырга тиеш бу. Бераз утыргач, тәрәзә янына килеп, урамга күз салды. Чү, инешнең теге ягында, алар урамында ниндидер яктылык шәйләнә түгелме соң? Кыз урамга атылып чыкты. Яктылык түгел, ут ич бу, ут ялкыны! Кемнеңдер йорты яна... Алар тирәсендә. Бәлки... Кызның бөтен җанын шом, курку ялмап алды.

– Төнге фәрештәләр! – дип ачыргаланып кычкырды ул. – Миңа сезнең ярдәм кирәк!

Бу юлы ул беренче тапкыр ир-ат кодрәтен тойды, ләкин башта моны аңламады-тоймады әле, бар көченә өйләренә таба йөгерде. Бары тик, урам буйлап чапкан уңайга: «Пожар! Коткарыгыз! Янабыз!» – дип кычкыргач кына, тавышының ирләрчә нык, көчле икәнен чамалап алды. Хәер, аңа барыбер иде, өлгерергә, тизрәк әнисен, әтисен коткарырга кирәк! Күңеле сизгән, янгын чынлап та, аларда булып чыкты, чоланнарын ялкын ялмап алган иде. Тәрәзәләр караңгы, димәк, берни сизми йоклыйлар. Ә ишеккә якын килмәле түгел, ут дөрли, бердәнбер юл – тәрәзә аша. Сәвия карга батырып куйган көрәк белән бар көченә кизәнеп, тәрәзә пыяласын коеп төшерде дә:

– Әти!!! Әни!!! Янасыз бит! Уяныгыз! Тизрәк чыгыгыз!!! – дип кычкырды.

Тәрәзә уемыннан эчкә керергә ниятләгән иде, өлгермәде. Каршында әтисе үзе пәйда булды. Йокы аралаш:

– Закир, ни булды? Ник тәрәзәне ваттың? – дип сорады.

– Янасыз! Пожар! Тизрәк чыгыгыз. Әнине уят!

Шунда гына әтисе ялкын шәүләсен күреп алды, куркудан ярсып кычкырды:

– Фәрдия! Тор тизрәк! Фәрдия! Янабыз!

Ул төнне Сәвия төне буе авылдашларына булышып йөрде. Салкынны да, арганны да сизмәде. Районнан янгын сүндерүчеләр килгәндә, ут инде бастырылган, халык тарала башлаган иде. Шунда гына әтисенең яланаяк икәнен күреп алды Сәвия. Үзенең кем икәнен онытып:

– Әти, салкын тидерәсең бит! Мә, минем киез итекне ки, – дигән иде...

– Закир, әллә саташасың инде, – дип, әтисе читкә китеп барды.

Ялгышын аңлап алган Сәвия аның артыннан иярде:

– Камил абый... Камил дим! Аяксыз каласың бит! Биргәндә ал, ки аягыңа! – дип ялынды.

Ләкин әтисе салкынны тоймый иде булса кирәк. Кисәк кенә борылды да:

– Әй, Закир! Һаман мине кайгыртасың. Сиңа нинди рәхмәтләр әйтим икән?!

Син булмасаң, янып үләсе идек бит! Аллага шөкер, чоланга гына зыян булды. Үзебез дә исән, йорт та! Аллага шөкер! – дип хисләнеп, Сәвияне кочып алды.

Икенче көнне хастаханәгә килде ул. Аягы өшеп, салкын тидереп түгел, яланаяк тәрәзә аша сикергәндә, табанына пыяла кадалган икән. Янгын вакытында берни сизми чапкан, иртән генә сизеп-күреп алган. «Зыян юк», – дисә дә, Мәҗит аны дәваланырга салды, зыян булгач, соң була инде ул, диде.

Сәвия барысын күреп-ишетеп торды, әтисенең исән-сау булуына шатланды. Шул чакта баш табиб янына ниндидер йомыш белән хастаханәнең хуҗалык мөдире Закир килеп керде. Аны күрүгә, бинтка уралган аягы турында онытып, әтисе урыныннан сикереп торды, тегенең иңеннән кочты, кулларын кысты:

– Менә кем коткарды безне! Каян, ничек күреп алдың, Закир туган? Төн уртасы иде бит. Сине һичшиксез бәхилләтербез, рәхмәт яугыры!

Ни гаҗәп, Закир бер дә аптырап калмады:

– Күрдем инде... Бөтен халык күрде бит... – дип мыгырданды.

Әмма үзе, йомышын әйтергә онытып, тиз генә чыгып та китте. Чынлыкта ул бу төндә шыр исерек булып, хатыны өйгә кертмәгәнлектән, мунчада кунган иде...

Әтисе хастаханәдә ике атналап ятып чыкты. Бу көннәр Сәвия өчен бәйрәмгә әйләнде. Ул гел газиз кешесе янында булды, аның йокысын саклады. Һәр көнне әнисен күрү бәхетенә дә иреште. Рәхәтләнеп, сөенеп, аларның чөкердәшүен тыңлады. Бер көнне әтисе әйтеп куйды:

– Фәрдия, әйтсәм, ышанырсыңмы икән? Ул төндә бит «Әти!» дип кычкырдылар. Шаккаттым инде бу хәлгә. Аннары Закир тагы «Әти» дип эндәште. Әллә мин саташтым, әллә ул...

– Булгандыр инде. Куркудан әллә ниләр ишетерсең... – дип җаваплады әнисе.

– Малайлардан хәбәр бармы соң? Син бу хәлләр турында аларга язып торма инде, борчылмасыннар. Солдат хезмәте болай да тынгысыз.

– Язаммы соң?! Ниемә кирәк? Икесеннән дә хат килде. Сәвиябез генә онытты безне...

– Борчылма, җае юктыр. Укый да, эшли дә, ничек өлгерсен? «Кышлар үткәч, кайтырмын», – диде түгелме соң?

– Исән-имин йөрсен инде. Әллә нигә күңел бер дә тыныч түгел... – дип көрсенде әнисе.

Ә кызлары, бер чарасыз калып, яннарында басып тора иде...

## 4. Элемтә бар!

Бик кызык хәлгә дә очрады әле Сәвия. Аны күрүче, ишетүче табылды бит! Һәм бу тылсымчы зат биш яшьлек Айрат иде. Чана шуганда, таш баганага килеп бәрелеп, кулын сындырган малайны районга озатып тормадылар. Мәҗит ага үзе шәп итеп гипс салып куйды. Әнисе бик үтенгән: «Зинһар, үзебездә калсын», – дигән. Районга барып, хәлен белеп йөрергә вакытым да, җаем да юк, дигән. Гөлүсә фермада сыер сава, буш вакыты булды исә, улы янына йөгереп килә. Кайчакта куна да кала. Янында әнисе булмаса, малай йоклый алмый, уяна да шыңшый. Сәвия һәр төндә шул бала янына кереп утыра башлады. Ни могҗиза, беренче кичтә үк Айрат аңа төбәлеп:

– Син кем? – дип сорады.

Сәвия, сорауның үзенә атап бирелүенә шикләнеп, тирә-якка күз салды, артына борылып карады. Ләкин алар янында башка беркем юк иде. Икеләнеп кенә дәшкән булды:

– Мин... яхшы апа...

Айрат аны ишетте, шунда ук җавап та бирде:

– Ә минем сиңа «Матуг апа» диясем килә. Ягыймы?

– Мин матурмыни? – дип елмайды Сәвия.

Малай баш какты: « Әйе!», янәсе.

Сәвия үзен күрүче, ишетүче булганга сөенеп туялмый. Аның тормыштан, исән кешеләрдән һич тә аерыласы килми. Бу сизгер малайга рәхмәте чиксез, шуңа да һич авырсынмыйча, төннәр буе аңа кызыклы шигырьләр, күңелле әкиятләр сөйли.

– Мин сине ягатам, Матуг апа, – ди Айрат.

– Мин дә сине яратам,– дип кочып ала аны Сәвия.

Айрат, зур күзләрен тутырып, сөенеп елмая:

– Матуг апа, сит китмә, яме!

– Китмим, – дип юата Сәвия. – Тынычлап йокла.

Сәвиягә кайда сөялсә дә барыбер. Ул төне буе малай янында утыра.

Көндез әнисе килгәч, Айрат өзми-куймый, Матур апасы турында сөйли.

– Яхшы төшләр күргәнсең, – дип юата әнисе.

Шул ук палатада тамагына салкын тидергән нәни кызы белән ятучы Наташа аларны аңламый, шулай да аптырап әйтеп куя:

– Странный он у вас. Всю ночь сам с собой разговаривает и смеётся.

– Ысмийутса иты хорошо! – дип сөенә Айратның әнисе.

***

Әлмәттә яшәп яткан Хатыйп абыйсын авыл хастаханәсендә очратырмын дип, башына да китермәгән иде Сәвия. Ялга дип кайткан җирдән авырып, шунда ятарга калды ул.

Ике кала арасындагы олы юл Бүзәргә кагылмый үтә. Автобустан төшкәч тә, дүрт-биш чакрым җәяү атлыйсы. Кышларын машина йөри торган юлны трактор чистартып тора. Шул ук вакытта кар тотар өчен басуны да ермаклый. Хатыйп автобустан төшкән дә әнә шул ялгыш юлдан китеп барган. Ярый ла, «КА-700» тракторында эшләүче Фазыл үзенең биек кабинасыннан күреп алган моны. Ярый ла, төн булмаган! Ләкин шул арада Хатыйп өшеп, бик нык салкын тидереп өлгергән. Күзе күрмәгән килеш, кышкы юлга чыгарга ничек тәвәккәлләгәндер.

Өзлегеп китеп, үпкәсенә дә салкын бәрмәсен дип, табиб Даймасов аны ятарга салып куйды. Хатыйп күбрәк палатада утыра, үзе белән алып килгән төрткеле калын китапларын укый. Сәвиягә кызык, керә дә читтән күзәтеп тора. Шаккатарсың, бармаклар китап укысын әле!

Бер керүдә, әрсезләнеп, ул Хатыйпның янына ук килеп басты, китап битенә күз салды. Ир шундук сискәнеп башын күтәрде, йомык күзләре белән як-якка каранып алды:

– Монда кемдер бар... Кем бар монда? Ник дәшмисең? Кем син?

Сәвия курка калды, үзен карак сыман хис итте, әкрен генә кузгалып ишеккә юнәлде.

– Тукта, качма! Башта кем икәнеңне әйт!

– Мин... – диде Сәвия әкрен генә. Үзен ишетмәүләренә өметләнде.

Ләкин аны ишеттеләр!

– Хатыйп абый, мин... – Ни дияргә дә аптыраш. Кыз алдашырга булды. – Мин күрше авылдан... эээ... туганымны карашырга килгән идем...

– Ярый, кем булсаң да. Әйтәсең килмәсә, әйтмә. Син миңа кайнар чәй ясап алып кил әле. Авызым кипте.

Сәвия тагы аптыраашта калды. Чәй ясар өчен дә Төнге фәрештәләрне чакырмас бит. Башына килгән уйдан сөенеп, Айрат янына йөгерде. Малай рәсем ясап утыра иде, «Матуг апа!» дип кычкырып, Сәвия кочагына атылды. Ярый әле бу вакытта палатада беркем юк, юкса баланы саташа дип уйларлар иде. Кечкенә булса да, булдыклы егет икән Айрат, «Матуг апа»сына ияреп, аш-су бүлмәсенә керде, өстәлдә торган чәйнектән кырлы стаканга чәй агызды. Әлбәттә, ул инде суынган иде. Кайнар булмаса да, кеше йомышын аяк астына салу түгел, чәйне Хатыйп кулына кертеп тоттырдылар.

Айрат әдәп кагыйдәләре белән санлашып тормыйча:

– Абый, син нигә күзләгеңне ачмыйсың? – дип, турыга бәреп сорады.

– Ачылмый шул алар, – диде Хатыйп моңсу тавыш белән. – Сукыр бит мин, балам.

– Күзең йомык булгач, син гел йоклыйсың алайса. Көндез дә төш күрәсең, әйе бит?

– Юк, көндез йокламыйм. Кояшны күрәм мин. Күктә кояш булганда, минем дә дөньям якты, – диде Хатыйп. Аннары як-ягына каранып:

– Сеңлем, сулышыңны тоям, син дә монда бит. Ник дәшмисең? – диде.

– Чәй кайнар булмады инде, суынган... – дип акланды кыз.

– Ярый, бусына да рәхмәт. Инде барыгыз, арыдым мин.

Айрат белән тотынышып чыгып барганда, арттан әйтеп калды:

– Сеңлем! Тавышың бик ягымлы, тыңларга рәхәт. Шулай кергәләп йөр. Миңа әңгәмәдәш булырсың.

Икенче кергәндә, Сәвия аннан наратлары турында сорады:

– Хатыйп абый, ник бакчагызга наратлар утырттыгыз сез?

– Ә син каян беләсең?

Кыз үзенең ялгышын аңлап, тамак кырып куйды:

– Эээ... Туганнарыма кунакка килгәч, алар күрсәткән иде...

– Көлделәрме? Гаепләделәрме?

– Юк. Ник гаепләсеннәр? Матур бит. Сезнең төз наратларны күргәч, мин дә үзебезнең бакчага утырттым әле.

– Әйбәт иткәнсең. Наратлар гаскәриләр кебек җил-давылдан ышыклый, җан-тәнгә яшәү көче бирә. Ләкин нәни чакта аларның үзләрен сакларга кирәк. Үзебез утырткан агачлар өчен дә җаваплы без, аңлыйсыңмы шуны? Алар янында һава да икенче, шифалы. Күзем күрмәсә дә, күңелем сөенә шуларга. Иң ышанычлы, көчле агач ул нарат!

– Ә чаган?

– Аларның исе юк. Мин бит ис буенча гына аерам.

– Бүлнис бакчасында күп алар. Шунда каргалар оялаган. Бер агачта әллә ничә оя. Көне-төне кычкыралар. Сез дә ишетәсездер. Шомлы шундый...

– Аларга да каядыр сыенырга кирәк. Каргалар, гадәттә, кортлы агачка оялый, – диде Хатыйп. – Ул чаганнар бик карт инде, сугышка кадәр утыртылган. Минем яшьтәшләр.

– Бу бакчада ачлыктан үлгәннәрнең уртак кабере бар, диләр. Чынлап та шулаймы, Хатыйп абый?

– Шулай, диләр шул...

– Аларның җаннары тыныч түгелдер.

– Сәер сүзләр сөйлисең син, сеңлем. Үлгәч, кайда ятсаң да, барыбер инде ул... Мәетнең җаны юк бит.

– Бәлки, бардыр? – дип сорады Сәвия сукыр килеш тә күрә торган шундый акыллы, зирәк абыйсыннан аңлау көтеп. Сәвияне ишетте бит ул!

– Бәлки, бардыр... – дип кабатлады Хатыйп, уйга калып һәм икеләнеп. – Ник әле миннән сорау аласың?

– Сезнең белән сөйләшергә рәхәт. Сез – бик акыллы, көчле кеше.

– Әй, сеңлем... Көчле булмый ни хәл итәсең?! Тормыш үзе өйрәтә. Күзсезгә бер адым атлар өчен дә күпме көч кирәк! Ярый әле, укырга өйрәттеләр. Француз егетенә рәхмәт.

– Сезне ул укыттымы? Сез французча укыйсызмы? – дип гаҗәпләнде Сәвия.

Хатыйп абыйсы тыйнак кына елмаеп куйды:

– Менә бу нокталы шрифтны әле үткән гасырда гына Луи Брайл исемле француз уйлап тапкан. Унбиш кенә яшьтә булган, ә нинди зур игелек кылып калдырган, күпме кешегә белем юлын ачкан! Итекче малае гына югыйсә. Үзе дә сукыр була ул. Менә бит нинди башлы кешеләр бар!

– Ә сез нинди китаплар укыйсыз, Хатыйп абый? Мөмкин булса, кычкырып укыгыз әле... – диде Сәвия.

Ир, тумбада яткан китабын кулына алып, бер битен ачты. Һәм әкрен генә, салмак тавыш белән укый башлады. Бармаклары ак битләр буйлап йөгерсә дә, карашы читкә, тәрәзәгә төбәлгән иде. Сәвиянең башына сәер уй килде: «Сукырларның күзе гел ял итә, арымый...»

– «Җир өстен төрле төсләргә күмеп, гөлләр чәчәк ата. Аллы-гөлле күлмәкләрен кигән күбәләкләр, дөньяның гүзәллегенә сокланып, вальс бии. Җир күкрәгеннән ургып чыккан чишмә, зәңгәр күкне күрүенә сөенеп, бар дөньяны яңгыратып көлә. Ерак юллар гизеп, туган якка кайткан кошлар, сайрый-сайрый яр сайлый, оя кора. Бар тереклек хәрәкәттә. Бар тереклек үзенчә яшәешне мактый, матурлыкка мәдхия җырлый. Ләкин күзе ачык булса да, күңеле сукыр кешеләр бу гүзәллекне күрми: «Ник тудым, ник яшим, яшәвемнең мәгънәсе нидә?» – дип баш вата, кемгәдер үпкә-дәгъвасын белдерә. Алар зарланып, йөз җыерып утырганда, шатлык тулы мизгелләрен кочагына кысып, яннарыннан Тормыш үтеп китә. Килер вакыт, кеше гаҗәпләнеп һәм үкенеп әйтер: «Үтте дә китте гомер. Гүя яшәмәдем...» Ә син яшә, күзеңне, күңелеңне ач! Дөньяның төрле авазларын тыңла. Битеңне назлы җилгә куй, кояш балкышын күзәт. Тауларга мен, яланаяк хәтфә чирәмнәрдә йөгер, баллы чишмә суларын эч, диңгездә коен. Яшә син, яшә! Яшәү шундый рәхәт бит!»

Шул җиргә җиткәч, Хатыйп абыйсы тынып калды, Сәвия ягына борылып:

– Килешәсеңме? – дип сорады.

– Матурлыкны бар кеше дә күрәдер инде ул, – диде Сәвия.

– Күңеле сукырлар күрми. Андыйлар да бар, сеңлем...

– Сез күрәсез, әйеме?

– Күрмәсәм дә, дөньяны бик гүзәл итеп тоям мин. Тормыш ямьсез була алмый, тәмле дә ямьле дә ул! Шулай бит?

– Әйе... – диде Сәвия.

Ләкин тавышы үтә дә боек, сагышлы иде. Тормышның ямен-тәмен аңларга, татырга өлгердеме соң ул?! Ярый ла, Хатыйп абыйсы, күрмәсә дә, ишетә аны. Шул да зур юаныч. Юкса, ни тере, ни үле булмыйча, беркем белән сөйләшә алмыйча, саташып бетәр иде...

Сәвия бу палатага икенче көнне дә кагылды. Бүлмәдәшләре чыгып

киткәч кенә, Хатыйп абыйсына сәлам бирде. Чал чәчле ир, аны гаҗәпкә калдырып:

– Әйт әле, сеңлем, матурмы син? – дип сорады. – Кызганыч, тавышыңны гына ишетәм, үзеңне күрмим.

– Әллә тагы... – диде Сәвия, каушап.

– Тавышың бик тәмле. Үзең дә матурдыр. Хәер, миңа бар кеше дә бер төсле булып тоела. Аларны күргәнем юк. Барысы да минем кебектер инде.

– Юк, Хатыйп абый, кешеләр төрле-төрле.

– Шулаймыни? Тавышлары төрле, анысын беләм. Тагы кай яклары белән аерыла соң алар? – дип сорады Хатыйп серле елмаеп.

Дөньяда шул гомер яшәгәч, җавапны үзе дә беләдер, юри үртәп сорыйдыр, дип уйлады Сәвия.

– Борын, күз, авыз, чәч... Һәр кешедә үзенчә инде...

– Шул аерма бөтен кешегә җитәме? Ул борын, авыз, күзләр төрле кешедә төрле булсын өчен, бик күп кирәктер бит. Сәер икән.

Сәвия пырхылдап көлеп җибәрде.

– Көлмә, сеңлем, минем үз гомеремдә бер кешене дә күргәнем юк.

– Сез бит укыйсыз. Китапта рәсемнәр дә бардыр?

– Рәсемне тулаем күрү кирәк. Бармак аны булдыра алмый. Күз кирәк. Һай, күз кирәк шул!

– Хатыйп абый, ә сезнең яратканыгыз бармы?

– Ник булмасын?! Әниемне яратам. Әтиемне дә яратыр идем, ул сугыштан кайтмады...

– Мин мәхәббәт турында әйтәм бит... Кызларны ярату турында... – диде Сәвия.

Егетләр күз белән ярата, диләр, ә күзсезләр ничек ярата икән? Менә шуны беләсе килде Сәвиянең. Ләкин Хатыйп абыйсы аның соравын җавапсыз калдырды.

– Кызларны кем яратмый?! – дип елмайды гына.

– Мәхәббәт бик серле ул, әйе бит, Хатыйп абый? – дип сорады Сәвия. Аның Хатыйп абыйсын күбрәк сөйләштерәсе килә иде.

– Бернинди сере юк аның, сеңлем. Гадилектә галилек, диләрме әле? Мәхәббәт – яраткан кешеңне кайгырту ул. Өшемәсен, ач булмасын, борчылмасын, еламасын, бәхетле булсын... Шул гына.

– Шул гынамы?! – Сәвиянең тавышында гаҗәпләнү дә, моңсулык та бар иде. Күрәсең, җавап аңа ошап бетмәде.

– Ник, бу азмыни?! Аналарның мәхәббәте шундый түгелме? – дип сорады да, үз фикерен ныгытып куйды Хатыйп. – Сеңлем, минем дә сиңа бер соравым бар. Синең күңелең җылы, әмма җилең салкын. Синнән кар исе килә. Шуның серенә төшенә алмыйм. Ник алай ул?

– Кхым-кхым... Энем, кем белән сөйләшәсең син? Баядан бирле күзәтеп, тыңлап торам. Янында беркемне күрмим. Театр уйныйсыңмы әллә?

Бу тавышны ишетеп, Хатыйп та, Сәвия дә сискәнеп ишек ягына борылып карадылар. Ни чыгарга, ни керергә белмәгәндәй, бусагада бер карт басып тора иде. Сәвия аны танып белми, башка авыл кешесе, Хатыйп абыйсы белән бер палатада дәваланып ята. Сөйләшү белән мавыгып, ишек ачылганын искәрми дә калганнар. Хатыйп кулы белән бушлыкка төртеп:

– Менә ич, сеңел белән гәпләшәбез. Яшьләр белән сөйләшү күңелгә рәхәт бит ул, – диде.

Аның, үз янында кеше булуына тамчы да шикләнмичә ясалган бу хәрәкәте Сәвияне оялырга, үзен гаепле сизәргә мәҗбүр итте. Ни дияргә дә белмичә:

– Әй, онытып та торам... Хатыйп абый, миңа бит ни... Җылы су алып килергә кушканнар иде, – дип ашыгып чыгып китте.

***

«Мәхәббәт – яраткан кешеңне кайгырту ул», – диде Хатыйп абыйсы.

Бәлки, чынлап та, шулайдыр? Гаяз аны кайгыртмадымыни? Беренче сыйныфтан бирле фәрештә урынына сакламадымы? Ысылдап өстенә килгән казларны куды, каршысына усал эт чыкса, аны үзе белән каплап, ике арага гел ул килеп басты. Берәр юньсез малай этеп җибәрсә, Сәвияне яклап, тегенең өстенә ташланды. Таеп егылса, кулын сузды. Өшесә, курткасын салып бирде...

Мәктәпкә укырга кергәнче авылларында шундый кыю, акыллы малай бар икәнен Сәвия белми дә яши иде. Гаяз аны үзе сайлады. Беренче сыйныфта укыганда ук, малайлар кызларны бүлешкән. Сәвия өчен Сакау Мансур белән Гаяз арасында сугыш та булган, имеш. Әлбәттә, Гаяз җиңгән, улмы соң инде аста калучы?! Шуннан соң Сәвиягә «Гаяз кәләше» дигән кушамат тагылды. Хәер, аңа гына түгел, сайланган кызларның һәммәсе кемнеңдер кәләше булып куйды.

Яңа ел бәйрәменә парлап бию әзерләгәндә, Сәвияне күрше малае Булат белән бастырганнар иде. Ләкин шунда ук аның кулыннан Гаяз килеп тотты һәм кычкырып, кистереп әйтте:

– Сәвия белән мин биим!

Алар сыйныфында кызлар күбрәк булып, барысы да алгы рәттәге парталарда утыра иде. Ә малайлар, кызлар артына качып, укытучы Мәйсәрә апа әйтмешли, «Камчатка»га елышкан, дәрестә гамьнәре юк. Бераз игә кермәсләрме дип, кызларны малайлар белән аралаштырып утыртырга булдылар. Сәвиягә партадаш булып, әлеге дә баягы Сакау Мансур эләкте. Тик бер генә дәрес утырды ул кыз янында. Тәнәфестән соң, Мансур икенче рәткә күчкән, ә Сәвия кырында авызын ерып Гаяз утыра иде.

Менә шундый иде Гаяз. Сәвиянең һәр сүзен, боерыгын үтәргә әзер торган җан-тән сакчысы иде ул. Казаннан кайтканда да, олы юлга чыгып, әтисе түгел, гел Гаяз каршы алды. Яз-җәйләрен мотоциклы белән, ә көз-кышларын тракторы белән чатка чыгып басар иде. Озатты, каршы алды... Сөйгәненең җылы ышыгында, җил-салкын тоймый, чәчәк атасы гөл иде Сәвия. Әллә соң артык бәхетле булырга да ярамыймы икән?!

Теге иртәдә Гаяз турында коточкыч хәбәрне ишеткәч, Сәвия моңа ышана алмады. Әле кичен генә янында көлеп, шаярып йөргән кешенең мәңгелеккә югалуы һич тә мөмкин түгел иде. Тормыш бу кадәр гаделсез була алмый! Ни өчен әле шундый яхшы, япь-яшь кеше үләргә тиеш, ди?! Булмас, дөрес хәбәр түгел бу. Сәвия әнисенә дә шулай диде: «Ышанмыйм!!! Ялгышканнар... Бутаганнар... Башка кеше үлгән, Гаяз түгел. Менә күрерсез, ул исән!»

Нурсинә бу вакытта хастаханәдә аңсыз ятса да, Гаязны туган йортыннан озаттылар. Әмма никтер йөзен карарга рөхсәт булмады. «Нык имгәнгән, танырлык түгел икән, шуңа күрсәтмиләр», – диеште халык. Бүзәр авылында шатлыгы да, кайгысы да уртак. Гаяз белән хушлашырга халык күп килде. Укытучылар, җитәкчеләр дә килгән иде. Сөйләүчеләр күп булды. Сәвиянең колагына:

– Тырыш, уңган егетебез, безнең өметебез... Үкенечле үлем... Җаны

тынычлык тапсын... Урыны җәннәттә булсын... – дигән сүзләр килеп иреште.

Егетне кызгандылар, апа-әбиләр, йөзләрен яулык очы белән каплап, үкседеләр. Бик авыр көн булды ул Бүзәрләр өчен. Ә көн чалт аяз, кояшлы иде. Кем инде мондый көнне җир астына кереп ята?!

Юк, ышанмады Сәвия бу хәлгә, Гаязны башка беркайчан да күрә алмасына ышанмады. Шуңа күзеннән бер тамчы яшь тә таммады. Ниндидер тамаша карагандай катып басып торды: «Кайтыр ул, менә күрерсез, кайтыр... Андый кеше югала алмый. Бүген кемнедер күмәләр, тик Гаязны түгел... Ялгышлык бу, бик зур ялгышлык...»

Казанга китәр көннәре якынлашкач, шулай да егетнең кабере каршына килеп басты үзе. Чардуган да, таш та куелмаган туфрак өеменә, шунда кадап куелган ап-ак шома тактага, анда язылган кадерле исемгә гаҗәпләнеп карап торды.

– Гаяз... Син, чынлап та, мондамы? – дип сорады.

Үзе үк җавап бирде:

– Юк бит, әйеме? Син монда юк... Кайда соң син? Кайчан кайтасың? Мин сине көтәм...

Шундый сәер иде ул көннәрдә кызның күңел халәте.

Ләкин шул ялган, «Гаяз үлмәде, ул кайтачак» дигән буш өмет Сәвиягә яшәү көче бирде. Шул өмет белән ул пар-пар агачлар утыртты. Шул өмет белән Казанга китеп барды. Әнисеннән: «Кызым, Гаяз исән! Ялгыш башка кешене күмгәннәр», – дигән сөенечле хәбәр көтте. Көннәр, атналар үтә торды, тик ул көткән сөенечле хәбәр килмәде. Әмма Сәвия өметен өзмәде, иләс хыяллар белән үз ялганына үзен ышандырырга маташты...

Инде менә үзе дә үлде... Үлгәч, теге дөньядагы якыннарың белән очрашасың, дип сөйләнәләр иде. Ләкин Гаяз монда да юк бит... Бәлки ул да кайдадыр, ниндидер сынау үтеп йөридер... Бу дөньяның кеше аңламастай кануннары да бар икән.

***

Сәвия бу халәттә яшәешкә дә күнекте. Һәр көнне Мәҗит абыйсына ияреп йөри, авырулар тарихын, табиб билгеләгән дәваларны өйрәнә. Һәр көнне чал чәчле, аз сүзле, тыныч холыклы бу кешенең сабырлыгына, олы җанлы, кече күңелле булуына соклана. Авыруның кемлегенә, яшенә карамастан, табиб һәркемгә елмаеп, үз итеп дәшә, олыларга «апа-абый», ди, кечеләргә «энем-сеңлем» яки «улым-кызым», ди. Ул килеп керү белән авырулар җанланып китә, артыгын зарланмаска, көр күренергә тырыша. Беркемнең дә, аксакал, мөхтәрәм табиб каршында көчсезләнеп, мескенләнәсе килми. Күреп тора Сәвия, Мәҗит абыйсының үз саулыгы да чамалы, ул еш кына әле кан басымыннан, әле бил-аяк сызлаудан укол кадата, әле тел астына тиз генә ниндидер дару-төймә салып куя. Чигәсен уып, йөзен газаплы җыерып утырган мизгелләрен дә күрде Сәвия. Ләкин кабинетына берәрсе килеп керү белән, башын күтәрә, сыгылып төшкән иңнәрен калкыта, берни булмагандай көр тавыш белән сөйләшә башлый...

Сәвия Мөнәвәрә Исламовна биләмәсенә дә еш кагыла, аның эшен дә читтән генә күзәтеп тора. Кайчакта бик ярдәм итәсе килә дә, юк шул, куллары тоймый. Төнлә килүчеләр янында, Мөнәвәрә апасын алыштыра алмый, чөнки авыл акушеры һәрвакыт уяу, чакыруга йөгереп килеп җитә. Ләкин тормыш бит бу, гел бер эздән генә бармый. Түбән Кама шәһәрендә төзелештә эшләп йөрүче улы, өченче каттан егылып зәгыйфьләнгәч, хәсрәткә баткан ана, ял алып, аны

тәрбияләргә китеп барды. Бәби табарга җыенган әниләрне районга юлларга булдылар. Ләкин бу хакта белмәгән-ишетмәгән хатыннар барыбер Бүзәр хастаханәсе каршына килеп басты. Менә шундый чакларда Сәвия тагын серле игезәкләргә мөрәҗәгать итте:

– Төнге фәрештәләр! Сезнең ярдәм кирәк!

Шуннан соң сменада кайсы шәфкать туташы булса да: «Мин булдырам, мин эшлим!» – дип, җиң сызганып, килгән хатыннарны бала таптырырга кереште. Бары тик катлаулы хәлләр булганда гына, районнан «Ашыгыч ярдәм» чакырдылар. Нинди сере бардыр, күпчелек сабый бу дөньяга килү өчен, гадәттә, төнне сайлый. Ләкин якты вакытта аваз салырга теләүчеләр дә җитәрлек. Ә Сәвия, үзегез беләсез, ярдәмчеләрен төнлә генә чакыра ала, көндезен, бик теләсә дә, берни кыла алмый.

Иртәнге уннар тирәсендә, хастаханәгә, инде тулгагы башланган бер хатынны китергәч, шәфкать туташы коелып төште. Тизрәк баш табиб янына атылып керде:

– Мәҗит Ногманович! Бала табарга килделәр! Нишләтик?

– Кабул итәргә кирәк! Ник шул кадәр курыктың? Кулыңнан килә бит, – диде Даймасов.

Әминә ни диярге белми, башын иде.

– Миннән булмас, Мәҗит Ногманович... Сез ярдәм итсәгез генә... – дип мыгырданды.

– Сәер... Бер була, бер юк. Ничек аңларга моны?!

Даймасовның карашы да, тавышы да бик кырыс иде. Төнге вакыйгаларны ничек аңлатырга да белмәгән Әминә алдашырга, хәйләләргә мәҗбүр булды:

– Бүген... бүген минем хәлем юк, Мәҗит Ногманович... Башым әйләнә, кулым калтырый...

Соңгы чигенә җиткәч кенә хастаханәгә килеп, баласын бусагада таба башлаган хатынны районга озату түгел, туп-туры кушеткага кертеп салырга туры килде. Әмма сабыйны Әминә түгел, Даймасов кабул итте...

Үзе шулай да киңәшмәләрдә горурланып күкрәк какты:

– Бездә универсаль кадрлар эшли! Безнекеләр барысын да булдыра!

***

Барысын да булдырабыз дип, белемена, зур тәҗрибәсенә таянып, үз көченә ышанып эшләп йөрүче табибның үзенә дә ярдәм кирәгер дип кем уйлаган?!

Төн уртасы иде ул.

Сәвия ул төндә йокламады, палатадан-палатага кереп, авыруларның хәлен белешеп йөрде. Алай-болай ярдәм кирәксә, ул әзер торырга тиеш. Урамда көчле җил-буран, шуңадырмы, олы яшьтәге кешеләр йокысызлыктан интегә, аяк-куллары да ныграк сызлый. Үч иткәндәй, төнге дежурда көн үтсенгә генә йөрүче бер пошмас практикант кыз иде. Кичке уколларны ясап, даруларны өләште дә «Уф, арыдым!» дип диванга тәгәрәде. Имеш, кичә йокламаган, егете белән очрашкан. Төн уртасында чырылдап кычкырган телефон тавышын да ишетмәде хәтта. Трубканы санитарка Зөлфия алды. Ә Сәвия ишетеп торды:

– Кызлар! Мәҗит абыегызның хәле бик начар! Нишлик? Районга шалтыратыйкмы?

Бу Фәһимә апа тавышы иде.

Зөлфия бер мәл аптырап, югалып калды. Аннары, трубканы ташлап, Венера янына йөгерде. «Булмас... – дип икеләнде Сәвия. – Бу кызда өмет юк...»

Барысы да һәрвакыттагыча тиз арада хәл ителде... Венера берни сизми йоклап калды, ә Сәвия, җәһәт кенә беренче ярдәм өчен кирәкле медикаментларны алып, урамга атылды. Ни хикмәт: бу юлы аны капка төбендә туктатучы булмады. Хәер, бу төндә ул «Венера» бит...

Мәҗит абыйсы аңсыз ята иде. Тәне ут кебек кайнар, йөзе, муеннары шешенгән. Сәвия аның йөзен үзенә борып, авызын ачты. Авыз эче лайлаланган, теле зурайган иде. «Аллергиягә охшаган» дип уйлады кыз. Борчылып, ни кылырга белми ире янында таптанган Фәһимәгә шунда ук боерык бирде:

– Тизрәк «Ашыгыч ярдәм» чакырыгыз! Шок булмагае.

– Хәзер, хәзер... – дип угаланды Фәһимә. – Ни булганын да аңламый калдым бит.

Сәвия авыруның авыз эчен чистартып, теленә басты. Ирнең сулыш алуы иркенәеп киткәндәй булды. Шуннан соң гына кан басымын үлчәде, ул артык түбән, ә пульс ешайган булып чыкты. Ярый әле, үзе белән адреналин, супрастин инъекцияләрен алган иде, тизрәк шуны кадады.

Район табиблары килгәндә, Мәҗит аңында иде инде, хәле шактый җиңеләйгән. Ул Сәвиянең кулын кысып, көчсез тавыш белән булса да:

– Рәхмәт, кызым… – дип әйтә алды.

Аны озаткач, Фәһимә Сәвияне чәй эчәргә кыстый башлады. Тамагы кипкән иде, бер сүзсез ризалашты кыз. Бик тәмләп эчте чәйне. Күптән инде ризык тәме тойганы юк бит.

– Бигрәк тәмле хәлвә, – диде ул. – Әллә чикләвек белән инде.

Шулай диюе булды, Фәһимә урыныннан сикереп тә торды:

– Ай Аллам! Белмәдем бит! Чикләвек беләнмени ул?!

– Әйе, – диде Сәвия аптырап. – Ә ни булды?

– Соң бит абыеңа чикләвек ярамый! Белмәдем бит! Үз кулым белән иркәемне үтерә яздым. Балаларына ни дияр идем?! Әле дә син килеп өлгердең, балам! Әле дә син коткардың! Яшь кенә булсаң да, булдыклы икәнсең, кулларың шифалы. Мең рәхмәт, балам, игелегеңне мәңге онытмабыз!

Баш табиб район хастаханәсендә ике атна ятып чыкты. Эшкә килү белән бөтен коллектив алдында Венерага рәхмәтен әйтте. Тегесе бу хәлләрне белсә дә, берни хәтерләми иде. Күзләрен челт-челт йомып, кыенсынып елмаеп басып торды. Әйтер сүз тапмады...

Хастаханәдәге сәер хәлләр турында алар үзара сөйләшәләр, баш ваталар, ләкин серенә төшенә алмыйлар иде. Шуңа күрә баш табиб алдында телләрен генә тешлиләр…

## 5. Кайту

Ике дөнья арасында адашып йөргән көннәрдә байтак кешегә ярдәм итте, шактый авыруны юатты Сәвия. Ләкин барыбер үзеннән, эшеннән канәгать түгел иде. Күп көннәре бушка узгандай тоелды, кулларын эшләтә алмаганга үртәлде. Эчтән генә игезәкләргә үпкә белдерде: «Йә, кем инде өрәккә шундый бурыч йөкли? Кирәк саен сезне ярдәмгә чакырып, чит кешегә әйләнәсем килми, үзем буласым килә!»

Колагына кайдандыр: «Иртәгә сынауның соңгы көне!» – дигән өн килеп ирешкәч тә, шатланмады. Бәлки алда тагы да катлаулырак, куркынычрак сынау көтәдер. Ни дисәң дә, монда үз авылы, таныш кешеләр... Туган йортына кайтып, әти-әнисен күрә алмаса да, хәл-хәбәрләрен белеп тора.

Ул кичне Сәвия урамда, баскыч төбендә үткәрде, йолдызларны күзәтте, авыл тавышын тыңлады. Кайдадыр этләр өрде, клуб ягыннан гармун тавышы ишетелде... Шулчак каршында әллә кайдан таныш сын, газиз йөз пәйда булды. Гүя күктән төште. Сәвия сискәнеп, урыныннан сикереп торды:

– Гаяз?! Син?!

– Әйе, мин...

Әйе, бу ул, соңгы кичтә очрашкан Гаяз... Киемнәре дә, кыяфәте дә шул ук. Ләкин үзе бөтенләй башка. Ул кичтә Гаяз бәхетле иде, гел шаярды, көлде. Ул кичтә Гаязның киләчәге бар иде, ул иртән уянып, кояшны күрәсенә, өр-яңа көнен башлаячагына тамчы да шикләнми иде. Ә бу Гаязның җаны үлгән, күзләре сүнгән...

– Син ничек монда? – дип сорады Сәвия.

– Качып килдем...

– Ярамый бит! Үзең беләсең. Барыбер табачаклар...

– Беләм... Ләкин мин сине шул кадәр сагындым! Бер генә тапкыр булса да күрәсем килде.

Сөйгәне өчен бик борчылып, Сәвия киңәш бирергә ашыкты:

– Син аларга каршы барма, Гаяз! Кушканнарын үтә!

– Үтим. Ләкин бер генә тапкыр тәртип бозарга да ярыйдыр. Сәвия, иртәгә син безнең дөньядан китәсең. Юллар озакка аерыла. Мин сине тиз генә күрмәячәкмен.

Кыз гасабиланып сорады:

– Нишлик соң, Гаяз? Нишлик?!

– Минем өчен бөтен юллар ябык. Мин читлектәге кош хәлендә...

– Бу коллыктан котылу өчен нишләргә кирәк?

– Мин синнән баш тартырга тиеш...

– Баш тарт, рәнҗемәм. Мин синең ирекле булуыңны телим.

– Беләм. Ләкин булдыра алмыйм. Синнән баш тарту гына аз аларга. Мин үзем таптаткан кызның сөйгәне булырга тиеш. Аның каршында тезләнеп, кулын үбеп: «Сине генә яратам, синнән башка беркем кирәкми!» – дияргә тиеш. Аңлыйсыңмы? Ә мин бу сүзләрне сиңа гына әйтә алам. Ул бик әшәке кыз. Аны ап-ак туй күлмәгеннән җирләгәннәр, күмү белән күлмәге каралган. Чөнки елата-елата, кеше ярын тартып алган. Мин ул явызны тамчы да кызганмыйм. Ничек итеп, аңа «яратам» дип әйтим? Синнән башка миңа беркем кирәкми!

– Гаяз... Сиңа мин кадерлеме, әллә ирекме?

– Син кадерле! Син янымда булсаң, мин кол булырга да риза. Син миңа түзәргә көч бирәсең.

– Син ирекне сайла! Ирек мөһимрәк! Һәр җан ирекле булырга тиеш! Шунда гына ул теләгән җиргә бара,теләгән кешене ярата ала!

– Монда ирек башка. Син әлегә аңламыйсың, – диде Гаяз моңсу гына.

Сәвия дә ямансулап башын иде:

– Алайса, сиңа бик авыр икән... Ә мин берничек ярдәм итә алмыйм... Мин дә бит ирекле түгел.

– Иң авыры: әниемнең хәсрәтле йөзен, күз яшьләрен күрү. Аны миңа һәр көнне күрсәтәләр... Газапларым тагы да көчәя. Әниемнең яшисе килми, үзенә үлем тели. Ә бу зур гөнаһ икән. Әй, Сәвия... Үкенечләрем утта яндыра... Менә шул инде ул тәмуг газабы.

Гаязның карашы әйтеп бетергесез сагышлы, чарасыз иде. Сәвия аны ничек

юатырга белмәде. Янына килеп, иңнәреннән кочып алды. Ике җан бер-берсенә сыенып, шактый басып торды.

– Син мине тоясыңмы?

– Тоям, – диде Гаяз.

– Мин дә тоям. Сәер, әйеме? Алай булгач, без мәңгелектә бергә була алабыз, әйе бит?

– Юк шул, Сәвиякәй! Кавышырга өлгерми калдык бит... Никахсызлар мәңгелектә кушыла алмый! Менә шунда фаҗига!

Шулчак алар янында дегет чәчләрен уйнатып, кара күлмәкле кыз пәйда булды. Сәвиягә игътибар да итеп тормый, ямьсез итеп кычкырды:

– Вот ты где!!! Кем рөхсәт итте сиңа качарга?! Син гел минем янда булырга, һәр сүземне, йомышымны үтәргә тиеш! Шулаймы?! Ник рөхсәтсез качтың?! Син минем колым! Миңа буйсынмасаң, урының тәмугта булачак! Мәңгелек тәмугта!

– Мин болай да тәмугта инде... Аз гына вакыт бир миңа, бер генә минут!

Ләкин кара күлмәкле кыз Гаязга чат ябышып, аны үзенә тартты. Аңа буйсынып чигенә-чигенә, егет һаман Сәвиягә карады, бар көченә кычкырды:

– Сәвия! Ике дөнья арасындагы пәрдә бик юка! Ишекләр күп. Онытма мине, Сәвия! Мин сине яратам! Мин сине беркемгә алыштырмыйм!!!

Сәвия, сөйгәне артыннан атлады, кулларын сузып, аны кочып алмакчы булды, ләкин куенына җил генә килеп сыенды...

Кара күлмәкле кыз да, Гаяз да мизгел эчендә юкка чыкты...

***

«Исән чакта кавыша аламадык, үлгәч тә юллар аерыла. Ник шулай булды соң?!» – Сәвиянең кычкырып елыйсы килде, әмма никтер елый да алмый икән... Аяз күкнең якты йолдызларына карап, озак ямансулап утырды әле ул. Кем белә, бәлки, иртәгә аларны да күрә алмас... Шулай уйланып-сагышланып утыра торгач, онытылып киткән...

...Күзен ачканда, ул кабат ак бүлмәдә, ак халатлы игезәкләр каршында басып тора иде. Аларны күрү белән Сәвия кабаланып сорады:

– Без Гаяз белән кавышабызмы?

– Юк! – дигән өметсез җавап ишетте. – Ул синеке түгел. Син дә аныкы түгел.

Кызның җаны сагыш күленә чумгандай булды, ул яшьсез елый иде:

– Мин аны яратам! Мин аның белән булырга телим!

– Гаязның юлы кыска булды. Ул төнгә ашыкты. Ә сиңа әле бик күп яңа таңнар каршылыйсы.

– Кайда? Ничек? Сез миңа яңа сынау әзерләдегезме?

Игезәкләр бер-бер артлы җавап бирде:

– Һәр көнең сынау булачак. Кешеләргә игелек кыл! – диде беренчесе.

– Туган җиреңә хезмәт ит! – диде икенчесе.

– Яшәүдән соң үлем, үлемнән соң яшәү бар! – диде өченчесе.

Шулай диделәр дә юкка чыктылар. Ап-ак диварлы бүлмәдә Сәвия ялгызы басып калды. Ак төс тә, күпкә китсә, ачуны китерә, ярсыта икән. Диварлар да, идән-түшәмнәр дә ап-ак төстә булгач, үзеңне бушлыкта эленеп торгандай хис итәсең. Кыз ачу белән идәнгә типте, диварны төя башлады, аяк-кул белән түгел, әлбәттә, уйлары белән генә. Шулчак тибрәнеп торган ап-ак ефәк пәрдәләр күреп алды. «Пәрдә булгач, бәлки, монда тәрәзә дә бардыр,» – дип уйлады ул. Шатлыгыннан очып китәрдәй булды: тәрәзә бар һәм ул ачык иде! Борынына

дымлы чирәм, шомырт исе килеп ягылды. Ә бит моңарчы ул ни салкынны, ни җылыны – бернинди ис тоймады! Ни үзгәрде соң? Кыз тәрәзәдән үрелеп караса, аста әнисе, әтисе басып тора. Алар аңа елмаеп кул болгыйлар.

– Кызым, уян инде! Зинһар, күзеңне ач, безнең янга кайт! – дип ялвара бик таныш тавыш.

Сәвия тәрәзә төбенә менеп баса да, аска атыла. Барыбер үле ич, ни булсын ди аңа? Гәүдәсен булса да алып китсеннәр, үз куллары белән җирләсеннәр. Аны әтисе тотып-күтәреп ала:

– Кайт инде, кызым! Зинһар уян, күзеңне ач! – ди.

Сәвия, тырышып-көчәнеп, күз кабакларын күтәрә, томан эчендә, дымлы керфекләре арасында басып торган әтисен күрә...

***

Ул тормышка яңадан кайтты. Беренче көннәрдә өн белән төш арасында буталып йөрде әле. Озак-озак үзенең кулларына, көзгедәге чагылышына карап торды. Әле бер, әле икенче әйберне тотып карады. Әнисе белән әтисе аны гаҗәпләнеп күзәтте.

– Миңа онытырга кушканнар иде... Никтер оныта алмыйм... Төнге фәрештәләр бар икән... Чакырсаң, ярдәмгә киләләр... – дип сөйләнде кыз.

Камил кызы акылдан язган, диючеләр булды. Казанда бик каты кыйнаганнар, акылын җуеп, айлар буе югалып йөргән икән, диделәр.

Хәер, бу сүзләрдә хаклык та бар иде. Чынлыкта, яман ният белән ияргән бәндә, тимер кисәге белән кызның башына суга. Сәвия аңсыз егылгач, талый да куркып кача. Кызны чит кешеләр күреп алып, ашыгыч ярдәм чакыра. Ул кыш буе хастаханәдә мәрткә китеп ята. Ә өйдәгеләр аны укып, имтиханнар тапшырып йөри дип уйлый... Һаман-һаман бернинди хәбәр булмагач, эзләргә керешәләр, Казан кырындагы бер хастаханәдән табып алып кайталар.

– Аңа тынычлык, ял гына кирәк, барысы да үз урынына кайтачак. Борчылмагыз, кызыгыз сәламәтләнер, – дип юата аны дәвалаучы табиб.

Әлегә шуңа ышанып, өметләнеп яшиләр.

Кайчакта Сәвия үзе дә икеләнә, бәлки, чынлап та, ул саташкан гынадыр? Бәлки, барысы да төш кенә булгандыр? Вакыт үткәч тә онытылмый торган бик ачык, эзлекле-эчтәлекле төшләр була бит ул. Гүя йоклаган килеш нindидер кино карыйсың. Алай дисәң... Сәвия күргәннәр чыннан да тормышта булган лабаса! Миңлекамал әбинең кинәт китеп баруы хак, Хатыйп абыйсының авылга кайтканда, юлда адашуы, авырып, хастаханәдә ятуы да хак! Сәвия җайлап кына әнисеннән сораша-белешә тора. Хәер, сорашмаса да, аңларлык – чормалары да чынлап янган бит, ул якта бүрәнәләр кап-кара, әтисе әле һаман аксап йөри...

– Закир килеп коткармаса, янып үләсе идек, – ди әнисе.

Юк, саташмый Сәвия. Барысын да хәтерли ул. Гаяз белән соңгы тапкыр сөйләшүе дә истә. Сөйгәне күңелдән чыкмый, аны өзелеп юксына. Кызгана да. Их, никләр генә шул кадәр ашыкты, ашкынды икән ул?! Әллә әҗәл үзе шулай чакырганмы? Кеше ярын тартып алган кызыйның юлын бүләр өчен нәкъ менә Гаяз кирәк булганмы?! Кадерле кешесен югалтучылар, теге дөньяда күрешербез, дип өметләнә. Ә Сәвиянең ул өметен дә өзделәр...

Ни гаҗәп, серле дөньяларны гизеп, ул кабат исәннәр сафына басты. Юкка гына бирелмәгәндер бу бәхетле билет! Бер көнне дә бушка уздырмаска кирәк! «Тегеннән» кайткач, ул шыпырт кына шигырьләр яза башлады. Ни хикмәт, үзеннән-үзе күңелдә туып торалар. Ул серле юлларны онытмас өчен дәфтәргә

төшереп бара Сәвия: «Үлем белән яшәү арасында калган чакта өмет, әҗәлләргә каршы калкан булып, син басасың килеп...»

Гаязның әнисе Нурсинә апаны ярдәменнән калдырмас ул. Аны караңгы, өметсез уйлардан араларга тырышыр. Әйе, башкарасы эшләр күп әле! Ачлык елында вафат булганнарның каберен торгызып, Истәлек тактасы куясы бар. Мондый изге эшкә беркем дә каршы килмәс, Бүзәрләр игелекле, бердәм халык, өмә оештырырлар. Минҗамал әбинең әнисе, безгә дога кирәк, диде бит. Авылда дини картлар җитәрлек, ачлык корбаннары рухына дога кылырлар. Шуннан соң, бәлки, күңелгә шом салып каркылдаучы каргалар да тынычланыр. Киләчәктә хастаханә бакчасына, черек чаганнарны кисеп атып, яшь агачлар утыртасы булыр. Шомырт, алмагач, чия, юкәләр язларын ак чәчәккә, хуш искә күмелеп, күзләрне, күңелләрне сөендерер, авыруларга көч, өмет бирер. Гүзәллек һәр җирдә булырга тиеш, ул үзе дәва бит.

Сәвия һәр көнне арт бакчага чыга, үзе утырткан агачлар янына килеп, озак-озак уйланып утыра. Тынгысыз карашы якты дөньяны күзләп, матурлыкка сокланып туймый. Яр астында җырлый-җырлый Сай инеш ага. Баш очында кошлар сайрый. Күктә болытлар йөзә, җылы туфракта кырмыскалар йөгерешә. Табигать яши, сулый, кояшка, язга сөенә. Әнә, аның агачлары, көздән үк җиргә чытырдап ябышып, карлы-буранлы салкын кышларны исән-имин чыкканнар. Язгы җилнең назлы сулышын, кояшның җылы нурларын йотып, бөреләре яшел күзләрен ачкан, сусыл, нәфис яфраклары күккә үрелеп маташа. Килер вакыт, шаулап үсеп китәрләр, бакчага гына түгел, су буена, авылга ямь бирерләр.

Тормыш гел яңарып, үзгәреп тора. Әле һаман аксап йөрсә дә, әтисе осталар чакырып, яңа веранда төзергә керешә. Зур, иркен, якты булачак ул. «Бәлки, януы хәерледер дә, юкса яңартырга тәки кул җитмәс иде», – дигән була әтисе... Киләсе язларда Сәвия дә укуын тәмамлар, өстенә ак халатын киеп, тормыш сагында торучы җир фәрештәләре сафына басар. Һәркем бу дөньяга игелек кылырга килә. Һәркем туган җиренә, үз халкына хезмәт итәргә тиеш.

Тагы... Шигырьләрен китап итеп чыгарыр! Алар да кеше җанын дәвалый, яшәргә көч бирә бит. Сәвия моны бик яхшы тоя. Бер китабын Мәҗит абыйсына бүләк итәр. Укысын да сөенсен әле, үзенә багышлап язган шигырь дә булачак бит анда:

> Синең кулда – кеше өметләре, мәрхәмәттә – көчең!
> Рәхмәт сиңа изге эшең өчен,
> Ак халатлы, пакь күңелле, җылы куллы кешем!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рифат
Җамал

# САГЫНУЛАРЫМ СИҢА БАРЫБЕРМЕ?..

***

Сагынганда, карыйм тулган айга,
Ай да хәтта болыт артында.
Сөймисең дә, беләм, сагынмыйсың,
Нигә күңел сиңа тартыла?
Сагынганда сине, җилне тыңлыйм,
Сезнең яктан җилләр исәләр.
Йөрәгем дә тынып тыңлар кебек,
Сиңа сәлам әйтте, дисәләр.
Ай да качкан, җил дә тынды инде,
Син дә мине күптән оныттың.
Ә шулай да күкнең почмагында
Җемелди күк соңгы өметем.

***

«Миңа барыбер!» – дип хатлар яздың...
Аңламадым – нәрсә барыбер:
Сагынуларым сиңа барыберме,
«Сөям» – диюемме тагын бер?

Бүтән инде «Сөям» димәм сиңа,
Сөюләрем булгач барыбер.
Үтәр вакыт. Синнән хатлар килер:
«Сөям», диген, җаным, тагын бер!»

Бәргәләнер йөрәк, талпыныр да –
Сөю булмас аңа барыбер.
Учларыма кысып йөрәгемне,
«Сөям», димәмен мин тагын бер.

---

Рифат ЖАМАЛ (1951) – *шагыйрь һәм галим, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе; «Күңел сүрәләре», «Ташта үскән чәчәкләр», «Өзгәләнмә, күңел» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Син язарсың: «Еллар үткән саен
Сине генә сөям барыбер!»
Тик бит сөю, җаным, кабатланмас,
Сөю була бары, бары бер.

***

Кошлар да киләләр, китәләр,
Сөю дә нәкъ шуның шикелле.
Минем дә сөюем киттеме,
Гомерем көзе дә килдеме?!
Юк әле, юк әле, мин исән,
Һаман да ашкынам, омтылам.
Язларын көтәдер күңелем,
Кояшка омтылган кош сыман.

***

Син, картлык, йөрмә әле,
Күңелдә яз гына.
Язымда каламын,
Булса да аз гына.

Син, картлык, килмә әле,
Кит әле янымнан.
Мин әле китә алмыйм,
Китә алмыйм язымнан.

***

Сагынмамын, димә. Сагынырсың,
Сагынырсың үлеп, өзелеп.
Миннән сәлам булыр кыр казлары –
Сезнең якка очкан тезелеп.

***

Сине сөйгәнемне сөйлим җилгә,
Бәлки, сиңа илтеп җиткерер.
Җил пышылдар: «Сине сөя!» – диеп,
Синең йөрәгең дә җилкенер.

***

Язлар булып килгән идең,
Көзләр белән китәсең...
Янә язлар килер, диеп,
Һаман сине көтәмен.

***

Бар да уза, дип язылган...
Килешәмен сүзсез.
Ә шулай да бу дөньяда
Һични узмый эзсез!

***

Табигатьнең дүрт фасылы,
Тәүлектә дә дүрт вакыт.

Һәрбер вакыт киләсесен
Җитәкләп килә, алып.
Минем бары ике фасыл –
Бәхетле айлы төннәр,
Сине көтеп, синсез үткән,
Кояш тотылган көннәр.

***

Кемнәр генә булмас иде кеше!
Мин дә – хыялдагы үзем күк.
Кеше Алла булыр кебек, әгәр
Җитсә аңа бары түземлек.

***

Яшь чаклар да бар иде шул –
«Безгә диңгез тубыктан».
Олыгайгач чыгып булмый
Тездән түбән сулыктан.

***

Мин килермен иртән кояш булып,
Мин килермен кичен ай булып.
Мин килермен өзелеп сагынганда
Йөрәгеңә җылы май булып.
Мин килермен сиңа яңгыр булып,
Керфегеңнән яшең юармын.
Җилләр булып исеп кайгыларың
Ярсып таратырмын, куармын.

***

Мин китәрмен,
Җырым калыр.
Кемдер аны
Җырлап барыр.

***

Гомер үтте,
Баю җитте,
Нигә көрсенә?

Иң байның да,
Иң юкның да
Гомере бер генә.

## Инетта

Ялындырасың,
Ялыктырасың,
Ябыктырасың –
Ябык торасың!

***

Кеше гомерен үлчиләр
Узган еллар белән.
Бәлки кирәктер үлчәргә
Үткән юллар белән.

***

Эзлә, эзлә...
Бәлки, таба алырсың
Үзеңне дә.

***

Дошманың сукканга
Син һәрвакыт әзер.
Дустың чиертсә дә
Буладыр бик авыр.

## Сөю

Сорап килми,
Сорап китми...

***

Матурлыкны күргән чакта
Күңелеңә хис килер.
Нәҗес белән янәшәдә
Үзеңнән дә ис килер.

***

Нигә сине, нигә сине
Юксынам?!
Синнән башка ошбу дөнья
Юк сыман.

***

Тузан күтәрелә,
Дөньяны тутыра...
Аннары утыра.

***

Ниләр җитми бу күңелгә,
Инде тагын ни кирәк?
Ник ашкына, ник ашкына,
Ник ашкына бу йөрәк?!



Хисаметдин
Исмәгыйлев

# КАЛЫМЧЫ ҖӘҮДӘТ

ПОВЕСТЬ

Җәй. Төш вакыты. Рәхимсез эсселек. Ару-талуны белмәс чыркылдык чыпчыклар да, кояштан качып, кыек асларына кереп посканнар. Барча агачүләннәр, эсседән әлсерәшеп, кояшка баш игәннәр. Тик су буендагы таллар һәм зирек агачлары гына, ә безгә барыбер дигәндәй, гамьсез. Әз генә җил иссә дә ярар иде. Үч иткән кебек, анысы да юк бит. Күктә бер болыт әсәре булса иде ичмаса.

Безнең, алты кешелек ремонт-төзүчеләр бригадасының, сыер абзарларын кышка әзерләп, төзәтеп йөргән көнебез. Әле менә эсседән һуш алынып, төшке ашны «үзләштереп», ял итеп ятабыз.

Джон белән Яшка, иренеп кенә сөйләшеп, күләгәдә утыралар. Улакларны ничегрәк урнаштыру турында гәпләшәләр, ахры. Джон да, Яшка да аларның чын исеме түгел, бу аларга тагылган кушамат кына. Чынлыкта, Джон ул – Фәнил, Фатыйх абзый малае. Аңа бу исемне яшьрәк чагында кызлар артыннан күп чапкан өчен колхоз рәисе Габделхак абзый таккан, диләр. Имеш, Фәнил эштә гел йокымсырап йөри икән.

– Син, энем, төне буе, Дон Жуан кебек, кунак кызлары артыннан чабасың да, көне буе аяк өсте йоклап йөрисең. Юньләп эшләмисең. Ташла бу гадәтеңне, – дип шелтәләгән колхоз рәисе.

Моны дүрт сыйныф белемле бригадир Оборот Гыйльми абзый да ишетеп калган, икенче көнне Фәнилне бар халык алдында, колхоз рәисенә охшатырга тырышып:

– Син энем, теге Джон кебек йөрмә. Төне буе чабасың да, көне буе йоклыйсың, – дип кабатлаган, имеш. Шул көннән башлап Фәнилгә Джон кушаматы ябышып калган.

Ә Яшка ул – Җәүдәт, Яшка дип күрше Тәтербаш авылы чувашлары кушкан. Яшка – безнең бригадада күптәннән инде, арабызда иң олысы һәм иң остасы. Балта-пычкы эшендә, гомумән, төзү-төзәтү дигән алыштыргысыз кеше. Белмәгән эше юк. Ә Айратның кушаматы икәү: Бройлер һәм Чорнапәр. Ул – авылда мулла вазифасын башкарган Динияр абзый улы. Бу кушамат аңа

---

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ (1953) – *язучы-прозаик; «Зимагур» исемле китап авторы. Башкортстанның Стәрлебаш районында яши.*

тулы гәүдәлегә күрә. Гәүдәсе тулы булуына карамастан, ул иң җитезе һәм безне эшкә әйдәләп кенә торучы бер тиктормас бәндә. Әле ул бер читтәрәк сузылып ятып йокы сүтә. Айрат үзенең кушаматын бик яратып бетерми, шуңа да без аны әтисенең кушаматы белән – Чорнапәр дип йөртәбез. Ә иң яше һәм мондый эшләрдә иң тәҗрибәсезе, иң хәйләсезе – Ришат. Аны безнең шабашниклар бригадасына әтисе Тимергали абзый китереп кушты. Урамда трай тибеп, эт сугарып йөрмәсен, өйдә тик ятканчы эшкә өйрәнсен, дип. Ришат та – бик тынгысыз малай. Эш ягыннан бигрәк тә. Ә менә теле бөтенләй ару-талуны белми. Әле тегесен, әле монысын сораша. Кыскасы, төбенә тоз коя. Һәм дә безнең бригада өчен бик кулай. Кушкан эшне җиренә җиткереп бик җитез башкара. Иң яше булганга, аны йә «тегесен эзлә», йә «монысын китер» дип йөгертәбез. Ул безнең ярдәмче-йомышчы малай. Әлегә кушаматы да юк. Минем янда «Алтмышлы», ягъни «Кабакбаш» Мәҗит ята. Аңа бу атаманы башы олы булганга биргәннәр. Бүрек-кепканың 62 нче үлчәмлесен генә кия ала.

Менә шулай итеп без, төзүче-төзәтүчеләр бригадасы, колхозның сыер абзарларын кышкылыкка әзерләп йөрибез. Халык телендә безне калымщиклар да, шабашниклар да диләр. Кайберләре «Әрмәнтрест» дип тә җиффәргәли.

Көндәгечә, Ришат үзенең төрле-төрле сораулары белән йә беребезнең, йә икенчебезнең теңкәсенә тия. Әле дә менә барыбызга да мөрәҗәгать итеп:

– Ә нигә безне калымщиклар дип атыйлар? – ди.

Ришатның соравын ишетеп, Джон белән Яшка бер мизгел тынып тордылар да, ишетмәмешкә салышып, яңадан улаклар турындагы әңгәмәне дәвам иттерделәр. Айрат-Чорнапәр, эләккәндә йоклап калыйм әле дигән кебек, бөтенләй хырылдап ук җибәрде. Күрәсең, бүген дә таң белән торып, сыер савып көтү кугандыр. Әнисе Зилә апа бу арада чирләбрәк тора, диделәр. Алтмышлы Мәҗит юри ишетми. Үзе белән алып килгән гәзитләрен укып ята. Мин дә тегенең соравын колагыма элмим. Тырышып-тырышып, бәләкәй кул пычкысын үткерлим һәм күңелемнән генә: «биредә ремонт эшләрен кайчанрак бетереп булыр икән», дип уйлыйм. Ришат – бик ныкыш егет. Теге соравын кабатлый. Шунда Алтмышлы Мәҗит:

– Син, энем, юк-бар сорау белән баш катырма. Мә, укы. Анда барысын да язалар, – дип, Ришатка кесәсеннән таушалып беткән гәзит чыгарып бирде.

Ришат һаман:

– Ун ел укый-укый мием череде инде, – дисә дә, гәзитне алып, караштыра башлады. Шулай да Мәҗитнең игътибарын җәлеп итә алганына шатланып, аңа якынрак күчеп утырды да үзенең баягы соравын тагын кабатлады:

– Мәҗит абый, нигә алай атаганнар да, нигә бүтән төрле түгел? – дип, ныкышыпмы-ныкыша.

Ришаттан котылып булмаячагын аңлады бугай Мәҗит:

– Например, ягъни мәсәлән, элек бездә кәләш алыр өчен кызның әти-әнисенә аерым хак – калым түләгәннәр. Ул кайчакны бик кыйммәт тә булган. Ә кайчак исем өчен генә түләгәннәр. Калым түләү йоласы Урта Азия халыкларында, ягъни мәсәлән, мөселман илләренең күбесендә әле дә бар.

Ришат, Мәҗитнең кармакка эләккәнен сизеп, үзенең сорауларын яудыра да башлады:

– Ә, Мәҗит абзый, син Сәвия апаны алганда, калым түләдеңме? Ә ничек танышып киттегез?

Мәҗит, бу хәйләкәр малайның эчке серләрне дә актарып тышка чыгартырга әзер икәнен аңлап алып, кырт кисте:

– Юк, мин түләмәдем. Безнең заманда андый нәрсә калмаган иде. Калым түгел, аякка юньле итек тә сатып алып булмый иде әле. Апаңны урлап кына алдым мин. Комачаулама. Әнә, укы гәзитеңне, – дип, алдында яткан гәзитне укырга кереште. Теге малайның сораулары бетмәгән икән:

– Ә нигә тагын шабашниклар дип тә атыйлар?

Ришатның сораулары Алтмышлы Мәҗитне тәмам ялыктырды шикелле. Ул бөтенләй читкә борылып утырды да тегеңә карамый гына:

– Инде, энем, монысын гүпчим белмим. Мөгаен, ул сүз безнеңчә түгелдер. Значит күп укыган, белсә ул беләдер, – ди.

Бу сүзе миңа кагыла инде. Туры килгәндә, кадалып алгалый шулай. Чөнки минем техникумга кереп тә азагына барып җитә алмаганны белә. Икенчедән, элек сөйләгәндә «значит» сүзен кыстырып сөйләргә яратканга бу сүз миңа кушамат булып тагылды. Ул сүзне әйтмичә сөйләшер өчен миңа күп көч салырга туры килде.

– Шабашка, шабашник сүзе «шабаш» сүзеннән. Шабаш ул – яһүдләрнең шимбәсе, ягъни эшләми ял итә торган көннәре. Хәтердә дә юк инде. Ә менә икенче төрле мәгънәсен нindидер бер китаптан укыган идем. Юньсез кара көчләрнең бергә җыелып бәйрәм итеп киңәш кора торган җыелышлары шулай атала, – дип, үзалдыма сөйләнеп алдым. Һәммәсе дә тып-тын калып, бу тагын нәрсә әйтер икән дип көтә башладылар. Мин дәшмим. Тегеләр көтә. Тик Ришат кына түземсезләнеп:

– Кара көчләр кемнәр алар? – ди. Шунда Мәҗит үзенең белемен күрсәтергә тырышып:

– Кара көчләргә, энем, җен-пәриләр керә, белмәсәң, картәниеңнән кайтып сора, – диде дә, сүз бетте дигәнне аңлатып, үзенең гәзитләрен укырга тотынды. Хәзер миңа чират җитте шикелле. Чөнки Ришат минем янгарак елышып утырды.

– Ә ул җыенга кайчан җыелалар? Аны берәр кешенең күргәне бармы? – ди. Мин инде үземнең элекке ишеткәннәремне, укыганнарымны исемә төшерергә тырышып:

– Шабаш ул, энем, елның билгеле бер көнендә генә була. Аны шул җен-пәриләр белән бәйләнештә булган кешеләр, ягъни сихерчеләр генә белә. Анда албасты, убыр, җен-пәри һәм шайтаннар җыела. Бу шабашта алар киңәш коралар, тәҗрибә уртаклашалар. Шуннан соң үзләренең сихерләнгән эчемлекләрен эчеп, агулы үләннәрен тартып һәм шуларның майларын сөртенеп, исерешеп, оргия оештыралар, ягъни туй итәләр. Кем кемгә өйләнгәнен дә, кем кем белән йоклаганын да белмәссең. Әллә шайтан сихерче белән, әллә сихерче шул пәри-шайтаннар белән.

Ришатның күзләре кызыксынудан ялтырый ук башлады. Мин һаман тырыша-тырыша пычкы үткерлим. Бу хакта бүтән сүз куертып торырга уем юк. Моны сизеп, Ришат:

– Теге агулы үлән дигәннәре наркотиклардыр инде. Наркоманнар шуларны тартып-эчеп тилерә, диләр бит. Ә менә сезнең берәрегез шул наркотикны тартып караганыгыз бармы? – ди. – Кешегә ничегрәк тәэсир итә икән?

Мин ваемсыз гына:

– Юк, энем, юк. Андый-мондый юньсезлектән Алла сакласын. Хәзер тәмәкене ташлаганга да бер ун еллап була инде. Тәмәкесе дә, аракысы да кирәк

нәрсә түгел. Сиңа дә рөхсәт итмим. Ул нәрсәләрне генә түгел, хәтта виносын да тәмләп карама, энем. Аны, юньле нәрсә булса, гарәпләр эчәр иде, – дим. Ну бу маңка малайны, тик сүз куертырга гына булсын.

– Аракы белән тәмәкесе ярый инде аның. Алама булса, хөкүмәт чыгармас иде. Менә берәр наркоманны күреп карасаң ярый. Нindirәк булалар икән? Шәһәрдә алар тулып ята, диләр, – ди. Шунда Алтмышлы Мәҗит түзмәде, гәзитләрен читкә этәреп куйды да:

– Аның аракысы да, тәмәкесе дә шул наркотик кебек нәрсә инде. Берсе дә юньлегә алып бармый. Мин эчеп карадым инде. Фәтүәсен күрмәдем. Шушы тәмәкесен дә ташласам, котылыр идем, – диде. Мәҗит, чынлап та, элек бик эчте шул. Теләсә нәрсә эчкәннән ашказанында нindидер чир барлыкка килгән. Чак адәм рәтенә кереп бара.

Шулчак Ришат кинәт кенә:

– Әйтәм, Яшка абзый запойга китсә туктый алмый. Караңгы төннәрдә дә аракы эзләп күрше авылга хәтле барып кайта, – дип әйтеп ташламасынмы! Бу инде Яшка абзыйның капкасына деготь буяуга тиң иде. Безнең сүзгә катнашмый баядан бирле колак кына салып утырган Яшка, борылып, Ришатка күзенең агы белән карап алды. Монысын Ришат күрмәде, Яшка белән Джонга арты белән утыра иде. Яшка авыр гына көрсенеп тамак кырды. Эчкән көне булса, ул бу маңка малайның сүзләренә колак та салмас иде. Бер өч-дүрт көн менә авызына да алганы юк.

Ришат әллә тәрбиясезлеге белән, әллә яшьлеге аркасында һаман шул наркотиклар тирәсендә сүз куертуыннан туктамыйча:

– Аракы наркотик түгел. Наркотик кулланганнар биш-алты ел гына яши, диләр. Укыганым бар. Көне-төне аракы эчкән Яшка абзыйга әнә бернәрсә дә булмый. Хәтта кыш көнендә былтыр салам эскерте төбендә дә йоклаган. Эчкән кешегә нәрсә булсын аңа! Юк, аракы наркотик түгел ул, – дип кабатлап әйтеп куйды. Җитмәсә, Яшка абзыйдан җөпләтергә теләп:

– Шулаймы, Яшка абзый? – дип тә өстәде. – Кайсыгызның наркотик кулланып караганы бар? Йә, әйтегез. Ул нindirәк нәрсә була ул? – дип, һаман такылдавын белә үзе. Монысы инде чиктән ашты. Хәтта Джон да түзмәде, ачуланып һәм гадәтенчә, кыза башласа сакауланып, «р» хәрефен төшереп калдырып:

– Син нәссә, Ышшат туганым? Олы кеше туында шулай сөйлисең? Баламут. Әле син молокосос кынасың. Тәүдә Яшка абзыең кебек дөнья котеп каа да, аның яшенә җит. Исә син. Баламут. Тимегали абзыйга әйтәм әле, сытыңны каезласын, – диде һәм тагы «баламут» дип кабатлап куйды. Тирә-як тып-тын калды. Яшканың гына авыр-авыр сулап көрсенеп куйганы тынлыкны тагын да шомлы, тагын да авыррак, газаплырак итеп тоярга мәҗбүр итә. Ришат та ләпелдәвеннән туктап, үзенең арттырыбрак җибәрүен аңлапмы, әллә Джонның кисәтүеннән шикләнепме, читкәрәк китеп утырды да күзләрен челт-челт йомып: «Мин нәрсә инде? Гаеп миндәмени?» дигән кебек, әле миңа, әле Мәҗиткә карап тора башлады. Без дәшмибез. Ә инде мин, Ришатны бөтенләй күрмәмешкә салышып, Яшка абзыйны күзәтәм. Абзыйның куллары ара-тирә калтырап китә. Ул аларны кая куярга белми, нәрсәдер эзләгәндәй, чалбар кесәләренә тыгылып ала. Гөнаһ өстендә тотылган кеше кебек беребезгә дә карамый. Ахырда түзмәде, дәшми-тынмый торып басты да якында гына аккан инешкә төшеп китте.

Джон Ришатны шелтәләвен дәвам иттереп:

– Ришат энем, карап торуга әйбәт кенә егеткә охшагансың да ул. Тик тозсыз син, баламут, – диде дә үләнгә сузылып ятты.

Һәркем үз уена батты. Мин яңадан пычкыга тотындым. Үзем Яшка турында уйлыйм. Ул күрше авыл кешесе, шунда туган, шунда үскән. Безнең авылга урта Азия якларыннан гаиләсе белән кайтты. Авылдагы бер иске өйне очсызга гына сатып алып, шуны тәртипкә китереп яши башлады. Берничә ел эчендә яңа өй торгызды. Тормыш иптәше Сәгыйдә апа гына, нишләптер, бик каты авырып, тиз арада дөнья куйды. Абзый салган өр-яңа йортның да, үзләре гаилә корып читтә яшәгән балаларының да игелеген күрә алмады, мәрхүмә. Элек Яшка авызына да капмаган аракыны. Апа үлгәннән соң гына эчә башлады шикелле.

Әнә Яшка абзыйның инештән менеп килгәне күренде. Ул ничектер картаеп, бәләкәйләнеп калгандай булса да, якынрак килгәч, чамалыйм: әле беләгендә көч-куәт сизелеп тора. Инешнең салкын суында юынып алган. Йөзе сафланып, кызыллык йөгергән. Килеп җиткәч, әле үләннәре дә тураерга өлгермәгән әүвәлге урынына барып утырды да еракка-еракка, офыкка карап тора башлады. Күзләре тулы моң, сагыш. Үзе бик җитди. Нәрсәдер уйлый. Бер нык кына көрсенеп алды. Күрәсең, Ришатның тозсыз сүзләренә хәтере калды шикелле.

Еракта, кайдадыр биектә-биектә тилгән баласының, әнисен юксынып, «пи...б...ик-ки...юк, пи...б...ик-ки...юк» дип елавы ишетелеп киткәли. Дөнья ничектер бөтенләй моңсуланып калды, күңелләргә ниндидер әйтеп бирә алмаслык авырлык кереп урнашты. Шунда Яшка абзый, барыбызны да аптыратып, ниндидер бер ят, карлыккан тавыш белән, мин әйтер идем, гыжылдаган-ышылдап торган тавыш белән:

– Шула-а-а..й,– дип сузып куйды. Әзрәк торгач: – Әйе. Хатыныннан аерылган, канаты каерылган. Ә канаты каерылган – теләсә дә оча алмый. Сөйгәненнән аерылган – теләсә дә коча алмый, – дип, рифмага китеребрәк әйтеп куйды да тынып калды. Сизелеп тора: нәрсәдер сөйләргә чамалый. Күрәсең, кайдан, нидән тотынырга гына белми. Бераз торгач, тагы: – Шула-а-а..й, – дип сузып куйды һәм, тамак кырып, сүз башлады: – Ул елны да җәй бик матур килде. Шофёр булып эшләп йөри идем. Шәп заманалар. Мортаза авылындагы Хаҗи абзый – силсәүиттә, Кунафин Габделхак абзый – колхозда рәис. Әйтәм бит, безнең «Искра» колхозының гөрләп торган чагы...

Без барыбыз да Яшка абзыйны тыңларга әзерләндек. Ә ул беребезгә дә карамый, беребезгә дә игътибар итмичә, аягына кигән кунычлы галошны салып читкә этәрде. Аннан җеп оекларын кояшка үлән өстенә җәйде. Әрекмән яфрагы өзеп, тирләгән аяк бармакларын шуның белән сөрткәләп алды. Уң аягының чалбар балагын өскәрәк күтәреп, аягындагы божра рәвешендә кызарыбрак торган, күптән төзәлгән җәрәхәт җөен кулы белән баскалап сыпырып, көлемсерәп куйды.

Безгә һаман игътибар итми, әйтерсең лә, үз-үзе белән сөйләшә. Балагын төшерде дә сүзен дәвам итте:

– Кич рейстан кайтып төшсәм, әни капка төбендә үк елап басып тора. Мин шөбһәләнеп әнидән сорыйм:

– Нәрсә булды, әни, нигә төсең качты? Нигә елыйсың? – дим. Әни:

– Улым, Ташкенттагы җизнәң үлеп киткән. Әле генә апаңның телеграммасы килеп төште, – ди. Нәрсә әйтергә дә белмим, әнине юатып тынычландырмакчы булам, әмма сүз таба алмыйм. Әни шунда яшь аралаш:

– Син, улым, иртәгә юлга чыгарсың инде. Җизнәңне җирләргә, аны соңгы юлга озатышырга беребезгә барырга кирәк булыр, – ди. Минем башка һаман бер

юньле уй килми. Имән кебек ир-егет иде минем җизни, нәрсә булган? Нинди фаҗига? Әнинең кулында җилфердәп торган телеграмманы алып укыйм. Анда: «Ирем үлде. Әлфия» дип кенә язылган. Әлфия – ул безнең иң олы апа. Үзбәкстанда торалар. Телеграмманы тагын берничә кат укып, әйләндергәләп карадым да, әнигә:

– Мин хәзер, – дип, туп-туры колхоз рәисенә киттем. Ул эштән яңа гына кайткан булып чыкты. Ихатасында бит-кулын юып тора. Габделхак абзый өенә килеп мәшәкатьләгәнне бик яратып бетерми. Минем исәнләшүгә коры гына җавап бирде дә:

– Нәрсә булды? – ди. Мин:

– Җизни вафат булган. Шуны җирләргә барырга кирәк, – дим. Бу тәүдә:

– Бетмәс, кайда бару ди ул, – дип кырт кисте. Әллә бүтән уйлар белән мәшгуль иде, әллә минем әйткән барып җитми торды. Борылып китеп тә барды. Мин аптырарга да, нәрсә әйтергә дә, нәрсә уйларга да өлгермәдем. Ул да түгел, яңадан минем кырга килде дә йомшаграк итеп:

– Җизнәң кайда, Әмир авылындагысын әйтәсеңме? Мин аны кичә генә районда шәйләп алдым, йөгереп йөри иде әле ул, – ди.

– Юк, бу олы җизни. Үзбәкстандагысы, Әлфия апаның ире, – дим. Шунда гына Кунафин абзый бөтенләй йомшап:

– Алай икән, алай. Апаңны беләм. Әлфия безнең чама. Мәктәптә бер тирәдәрәк укыдык. Машинаңны инженер Эдуардка илтеп тапшыр. Иртәгә шофёр тапсын. Минем шофёр теге Тәтербаш Володькага бар, Эстәрлетамакка кадәр төшереп куйсын. Кунафин абый әйтте диген, – ди. Мин, эшнең болай уңай хәл ителүенә шатланып:

– Безгә Уфага аэропортка кадәр әйбәт булыр иде, Габделхак абзый, – дип, исеме белән дәшәм. Бу минем кулдан телеграмманы үрелеп алып, үзе укый, үзе:

– Эстәрлетамакка хәтле ни дә, аэропортка хәтле ни. Үзең әйтерсең, – диде дә, сүз бетте дигән кебек, телеграмманы кире сузды. Мин рәхмәтләр әйтеп чыгып киттем.

Хәлне күршедә генә үзләре гаилә корып яшәгән сеңелкәшләргә дә җиткердек. Сеңелкәш тә барырга булды. Шулай итеп, бар дөньяны кияү белән кодаларга калдырып, чыгып киттек.

Аэропортка килеп төшкәндә, төн уртасы иде.

– Самолёт бер сәгать элек кенә китте. Киләсе рейс алдагы атнада шушы көнне генә була, – дип, телеграмманы укып та тормый кире бирде дә кассир хатын, – атнасына бер генә рейс, – дип өстәп куйды.

Башка таяк белән суктылармыни. Шунда теге хатын тәрәзәсеннән үрелеп:

– Ташкент шәһәренә Уфа аша скорый поезд бар. Бүген иртән үтә. Өч көн дә узмас, Ташкентта булырсыз. Әле генә тимер юл вокзалына шалтыраттым, – дип, безне җанландырып җибәрде. Такси яллап, вокзалга юнәлдек.

Көч-хәл белән, ниһаять, без поездда китеп барабыз. Кәефне әйтеп торасы да түгел, бөтенләй юк. Мин тамбурда, бер-бер артлы тәмәке көйрәтәм, әни белән сеңелкәш ах та ух киләләр, берсеннән-берсе бәләкәй балалары белән тол калган апаны жәллиләр. Җизнине җирләргә өлгереп булмый инде. Өчесен, җидесен укытып, хәер-сәдакалар таратып, Коръән укытып кайтырбыз, ичмасам, дип, үзебезне үзебез тынычландырабыз.

Термез дигән шәһәрдә безнең поезд озак кына торып, чым-чыкыр балаларын ияртькән әллә никадәр үзбәкләрне төяп, тагы алга кузгалды. Без барасы станса ерак кына булса да, әйберләрне җыештыргалап куйдык. Мин тамбурга тәмәке

көйрәтергә чыктым. Ә тәмәке беткән. Берәрсеннән сорарга дип чамалыйм, юк. Үч иткән кебек, үзбәкләр тел астына сала торган тәмәке чәйни. Ул да булмый, поезд тагы бер стансага килеп туктады. Ун минут тора, диделәр. Мин дә перронга төштем. Исәп – аякларны язарга, тәмәке дә алырга. Бер киоскка бардым – бикле. Икенчесе дә эшләми булып чыкты. Перрон тулы халык. Тегесен-монысын саталар. Шунысы гаҗәп: сатучылар барысы да бала-чага. Тик тәмәке генә юк. Шунда йөргән берәүдән:

– Кайдан тартырга табарга була? – дип сорыйм. Ул чинар агачлары күләгәсендә утырган үзбәк картына күрсәтә. Карт янына килсәм, чәйни торган тәмәке сата булып чыкты. Алдындагы әрҗә өстенә төрле-төрлесен банкаларга салып куйган. Бабайдан урысчалап тәмәке сорыйм. Бабай аңламый, шуннан татарча сорарга мәҗбүр булдым. Әрҗә астыннан кыйммәтле тәмәкеләр чыгарып салды да, һәрберсенә төртеп, хакларын әйтә. Кыйммәтле, ягъни фильтрлы сигаретлар гына. Минем исә андыйларны җенем сөйми. Чүпрәк урап тарттың ни дә, фильтрлы тәмәке тарттың ни. Безгә бит, булгач-булгач, катырагы һәм төтене күбрәге булсын. Мин:

– Юк, бабай, безгә үзебезнекен бир. Гадирәген, суырган саен төтене катырак чыксын, – дим. Шунда бабай алан-йолан каранып алды да үзе утырган урындык астыннан биш бөртек тәмәке алып:

– Якшы, бик хуп, шәп, шәп,– дип, тәмәкесен мактарга тотынды.

Биш бөртек тәмәкегә берәр кап «Прибой» хакы түләп алдым. Алдым инде, тартасы килә бит. Кесәдә акча да барлыкка бар инде анысы. Җитмәсә, теге карт:

– Тагын кил, олан, иртәгә катырагын, яхшырагын алырсың, – ди. Спикүлән, шайтан алгыры. Башындагы чалмасы кыйшайгыры. Ни «Беломор» юк, ни «Прима» сигареты.

Ул да булмый, безнең поезд, кузгалабыз дигәнне аңлатып, сызгыртып алды да көчәнүдән дөбердәп тартышып куйды һәм җай гына кузгала башлады. Йөгереп барып үземнең вагонга утырдым. Әни белән сеңелкәш бәләкәй генә табын корганнар. Озакламый барып җитәргә тиешбез, шуңа да тамак ялгап алырга уйлаганнар. Ашап алгач, гадәт буенча, берәр сигарет көйрәтергә дип, тамбурга чыктым.

Сигаретны кабызып, бер-икене суырып җибәрүгә, әллә нәрсә булды. Аяклар көзән җыергандагы кебек тартышырга, баш әйләнеп укшытырга тотынды. Сумсадан шулай булгандыр дип, эчтән генә сумса сатучы малайны әрлим. Китте укшытып! Әйтерсең лә, бугаздан берәү буып тоткан. Баш әйләнә, күз аллары караңгыланып, тез буыннары йомшарып, гәүдәне тотмас хәлгә килде. Кайда ул тәмәке кайгысы, төтен ләззәте турында уйлау. Тарта башлаган сигаретны ташладым да, чак атлап, үземнең утырган урынны эзләп киттем. Әллә саташам, әллә төш күрәм. Тирә-яктан әллә нинди тавышлар ишетелә, кешеләр әллә нинди котсыз сыннар булып күренәләр. Алар, бер карасаң, кеше рәвешенә кереп, мине тынычландырырга, җитәкләп үземнең урынга алып барырга чамалыйлар, бер карасаң, җен рәвешенә кереп, мине тәмугка, әллә нинди упкыннарга өстериләр. Чәчләрем үрә торды, аска да җибәрдем шикелле. Курку әллә нинди кыргый шатлык белән алышынып, үз-үземне белештерми көлә-көлә, тыела алмый елап та җибәрәм.

– Мин әниең бит, мин әниең бит, әниең. Җәүдәт балам, нәрсә булды сиңа? Тукта, балам, кая барасың? Бу мин бит, әниең, – дип, берәү тарткалый. Зиһенем ачылып бетми. Минем җиңгә ябышкан берәү:

– Мин сеңелкәшең, – ди. Тавыш килгән якка карыйм. Юк, әнине дә,

сеңелкәшне дә күрмим, алар урынына әллә нинди куркыныч, гарип җенпәриләр генә күренә. Кемдер:

– Саф һавага алып чыгыгыз, саф һавага, – дип кычкыра. Мине берничә үзбәк тамбурга өстерәп алып чыктылар шикелле. Бит-колакларны угалыйлар, кайнар яшел чәй эчерергә чамалыйлар. Үтереп эчәсе һәм ашыйсы килә башлады. Бераздан үзбәкләрнең мине шелтәләгәннәрен чынлап торып аңлый башладым. Кәефем кырка үзгәрде, мине битарафлык биләп алды. Мыгырдый-мыгырдый үземнең купега кереп киттем. Тик һаман тынычланып бетмәгәнмен икән. Тагын үтереп тәмәке тартасы, төтен суырасы килә башлады. Мин үземчә үзбәк сумсасыннан агуландым дип уйлыйм. Һаман бу хәлләр теге бабай миңа саткан хикмәтле сигарет төтененнән икәнен уйлап җиткерә алмыйм. Әни, белгән догаларын укып, мине өшкерергә чамалый. Мин аларны тынычландырып:

– Бая ашаган сумсадан гына шулай булдым. Хәзер үтә ул, – дидем дә тагы һава суларга тамбурга чыктым. Чөнки җиңелчә генә укшыту һәм баш әйләнү үтеп бетмәгән. Чыксам, күзем бая үзем ташлаган тәмәке төпчегенә төште, каһәр суккыры. Ятамы ята, күз кыздырып. Житмәсә, һәрберсенә берәр кап «Прибой» хакы түләп сатып алдым. Жәл, яртылаш та тартылып бетмәгән сигарет. Комсызлык бит инде. Ничек итсә иттем, чит күзләр күренми, оялып торырга түгел. Үзем ташлаган сигарет. Кулларым калтырануын җиңеп, сигаретны кабызып, комсызланып, тиз-тиз төтен суырырга тотындым.

Бетте. Бүтән суырганмындырмы, юкмы? Анысын хәтерләмим. Мине коточкыч хис биләп алды. Калганы өзек-өзек куркыныч бер кино кебек кенә. Вагон тәрәзәсен нәрсә беләндер ватып, шуннан җәһәннәмгә, әллә кайда, бер томан кебек куе, күзгә сылашып торган караңгылыкка сикердем. Һәм шуның белән баста! – диде дә Яшка абзый, тынып калды.

Тирә-як тып-тын, без дә дәшмибез. Тик биектә-биектә, әллә кайда, тилгән балаларының алмаш-тилмәш сагышлы кычкырып куйганнары гына ишетелеп китә.

Ришат түземсезләнеп:

– Ул «басты» дигән сүз нәрсәне аңлата инде? – дип куйды. Шунда Джон «бу тынлыкны нигә боздың, юньсез», дигән кебек үрелеп, Ришатның кабыргасына төртеп алды да тегеңә күзләренең агын әйләндерде. Ришат, үз гаебен аңлаган көчек шикелле, читкә үк китеп утырды. Без барыбыз да аны күзләребез белән шелтәләп өтәбез. Ул моны сизеп, кызарынып-бүртенеп башын аска иде. Яшь шул әле, яшь, мәлгунь. Армиягә барырга да яше көзгә генә җитә.

Җәүдәт абзый тамагын җиңелчә генә кыргалап:

– Баста, ул, улым, «бетте, нокта, точка» дигәнне аңлата. Нимесчә «капут» дигән сүз. Урысча «конец», менә шулай, белмәсәң, бел.

– Азактан гына, аны да әле Сәгыйдәнең әтисе, ягъни бабай аңлаткач кына белдем. Мин теге үзбәк бабаеннан тәмәке дип сатып алган сигарет наркотик булган икән. Әйтер идем, юньле әйбер түгел. Юк, бик тә алама нәрсә. Берүк тәмләп тә, хәтта кулыгызга да тотып карамагыз. Аллаһ хакы өчен дип әйтәм. Хәтта шуның белән шаярган кеше янында да тормагыз. Ул бит – егетләр, алама эш, алама гадәт, йогышлы чир белән бер. Мәсәлән грипп, үләт чире кебек. Яки менә дуңгыз абзарына кереп кенә чыгасың, ә исе нинди начар булып киемгә, тәнгә сеңә. Тәүдә киемгә, аннан тәнгә, аннан аңга-зиһенгә сеңеп, кешене кол итә. Кеше юкка чыга. Шуңа да, Ришат улым, наркоманны, алама кешене күрсәң, урап үт. Аламалыгы сиңа йокмасын. Әмма аламалык шулай йогышлы булган кебек, яхшылык та тирә-якка тиз тарала. Яхшы кеше кырында басып торсаң

да, яхшылыгы сиңа сеңә, сиңә күчә. Умартачы кешедән бал, чәчкә исе килсә, яхшы кешенең дә яхшылыгы нур булып чәчелә, тирә-якка тарала. Улым, син «наркотик ничек була икән, тәмләп карарга иде», дигән сүзләрне сөйләү генә түгел, ул турыда уйларга да җирәнергә тиешсең. Акылың булса, нәтиҗә ясап, уйлап кара, улым, – диде дә тынып калды абзыебыз.

Беркавым дәшми торганнан соң, сүзен әллә кайдан башлаган кебек, мин әйтер идем, бөтенләй башка нәрсә турында сөйләгән кебек, җай гына дәвам итте:

– Уйлый алырлык хәлгә килгәндә, мин бер тар гына сукмактан китеп бара идем. Бараммы, барам. Әйтерсең лә, чөгендер басуыннан кайтып киләм. Тәүдә игътибарга алмаган идем, карасам, тирә-якта – биек-биек таулар. Ерактагыларының башлары болытларга тигән, түбәләрендә ялтырап ап-ак кар ята. Әйтерсең лә, чалма ураган, сакаллары җилгә тузган пәһлеван бабайлар намазга утырып, сәҗдәгә оеганнар. Зур-зур ташларны урый-урый, сукмак алга, каядыр билгесезлеккә чаба. Ерактагы тау битендә бәләкәй-бәләкәй иген басуларын чамалыйм. Анда-санда әз-мәз сарык-кәҗә, сыер көтүләре күренә.

Башымда бер юньле уй юк, атлап китеп барам шулай. Ташларга бәрелеп, аякларым авыртуын сизә башладым. Карасам, яланаякмын, табан асларым кабарып, чиләнеп чыккан. Авыртуга чыдый алмый җиргә утырдым да тирә-якка каранам. Кая китеп барам мин? Гомумән, минме соң ул? Әллә бер куркыныч саташу гынамы? Алай дияр идең, аяклар түзеп торгысыз итеп сызлый. Һичбернәрсә хәтерли дә, уйлый да алмыйм. Әйтерсең, мине икенче бер чит дөньяга илтеп ташлаганнар. Хет үтерсеннәр, үземнең кем икәнлегемне, кайдан килеп, кая китеп баруымны әйтә алмас идем. Баш түбәсенә эленгән кояш рәхимсез кыздырып, миемне бораулый. Аны да минем зиһенем кабул итәрлек хәлдә түгел, кояшка да аптырап карыйм. Киемнәр ертылып беткән. Өстә чак эләгеп торган ертык майка гына. Чалбарның тездән аскы өлеше теткәләнеп төшкән. Ерактагы теге тау бабайлар миңа аркаларын борып утырганнар да ап-ак болыт сакалларын җилдә җилфердәтәләр. Алар мине күрмиләр дә, миңа игътибар да итмиләр. Минем шул тау – бабайлардан эчәргә су сорап, кычкырып елап җибәрәсем килде.

Нәрсә эшләргә дә, кая барырга?! Ничек итсәм иттем, аякка басып, тирә-якка карыйм. Берничә чакрым алдарак агачлы бер уйсулык күренә, шул якка барырга уйладым. Юк, бер адым да атларлык түгел. Табан асларыма меңәрләгән энәләр китереп кададылармыни. Мин, авыртуга түзә алмый, киредән җиргә авам.

Болай күпме ятарга була? Нәрсәдер эшләргә кирәк бит. Ишеткәнем бар, кеше ризыксыз бер ай чамасы яши ала, ә сусыз атнадан артык тора алмый икән. Ә мин күпме йөргәнмендер дә, кайчан соңгы тапкыр су эчкәнмендер – белмим. Әллә кичә генә, әллә атна элек. Болай ятып булмый бит инде, киттем мүкәләп. Мүкәләп киттем дип, әйтүе генә рәхәт. Минем халәттә булып карамаган кеше моны аңламас та, белмәс тә...

Шунда Җәүдәт абзый, янында гына үсеп утырган әрекмән өзеп алдына җәйде дә аякларын яфраклар өстенә куйды.

– Шулай мүкәләп алга барам. Бер йөз метрлап барам да, аркама ятып, хәл алам, бераз барам да хәл алам. Күпмерәк барганмындыр, тезләр канап чыкты. Колакка кайсы яктандыр чылтырап су акканы ишетелде. Игътибарлабрак тыңласам, ишетелмәгән дә кебек. Мин инде нык сусаудан колагыма шулай ишеteләдер дип тә уйлый башладым. Ничек кенә булмасын, бу мине дәртләндереп җибәрде. Сизеп торам, тиз арада су эчмәсәм, мин бөтенләй

егылачакмын. Тамак кипте, телне авыз эчендә әйләндереп алырлык түгел. Күзләрне йомганда, күз кабаклары, күз алмаларына ябышып, аларны кыра.

Су гөрелдәве ныграк ишетелә башлады. Минем сукмак уйсулыкка килеп чыкты. Су тавышы ныклап ишетелә, тик үзе генә күренми. Хәтта исе борынга килеп бәрелгән кебек булып китте. Курка калдым, сусаудан күземә күренә башладымы әллә, дип уйлыйм. Чынлап та, тавыш ап-ачык ишетелә, тик су үзе генә юк. Якындагы яр буенда карлыгачлар очканы күренә, алар мине күреп, ныграк чыркылдашырга тотынды. Шулай булгач, тавыш ялган булмаска тиеш. Бәрәкалла, ташлар астыннан агып ята түгелме соң су? Шулай шул. Мин, шатлыгымнан, «яшибез әле» дип кычкырып ук җибәрдем. Титаклап ташлар өстенә килеп мендем дә ташларны актарырга чамалыйм. Ә алар нинди әле, кузгата да алырлык түгел. Шоп-шомалар, берсеннән-берсе зурлар. Су миннән бер метр чамасы аста гына ага, ләкин тәмләп карарга һичбер әмәлен табармын димә. Эче куыш камыш, йә курай-мазар да күренми. Мин елап җибәрдем, тик күздән яшь дигән нәрсә чыкмады. Шулай да күзләрне ачып-йому җиңелләште.

Менә бездә нинди рәхәт! Бөтен дөнья ямь-яшел, дым-су җитәрлек. Нинди саф, салкын сулы инеш агып ята! – дип, Яшка абзый кулы белән ишарәләп куйды. – Күпме телисең, эч, юын, коен. Хөррият, оҗмах. Тик күпләр кадерен генә белмиләр. Шушы оҗмах сулары кебек суларның ярларына чүп-чар түгәбез, суын пычратабыз, – диде дә тагы тынып калды абзый.

– Бу ташлар астындагы елганың, мөгаен, өстәнрәк аккан җире дә бардыр, дип уйлыйм. Елганың башына таба киттем. Киттем ди сиңа, көтеп тор, һаман мүкәлим инде. Бөтен теләк – тик су, туйганчы су эчәргә. Шушы ташлар астыннан аккан елганың суын туйганчы эчеп, әрнегән аякларымны шул суга тыгып утырсам, үлсәм дә үкенмәс идем кебек.

Күрәсең, бу елга яз көнендә шаулап-гөрләп, ташлар өстеннән агадыр да, җәйге челләдә саегып, ташлар арасына кереп посадыр. Һәм мин, сусаудан акылын җуяр хәленә җиткән Алла колы, елгадан мәрхәмәт көтеп, алга мүкәлим. Кырда гына челтерәп су агып ята, ә эчеп булмый. Тора-бара күзгә камыш-күрәннәр ешрак чалына башлады. Сукмагыма игътибарлабрак карыйм. Юк, бернинди дә эз-фәлән күренми. Шулай да берничә урында кәҗә эзләренә охшаган уемнар ярылып ята. Ниһаять, алда уйсулык кебек җир башланды. Үләннәр дә сусыл һәм ямь-яшел. Мин һаман мүкәләвемне дәвам итәм. Бөтенләй хәл бетте, тик «алда су булырга тиеш» дигән уй гына мине һаман алга барырга, мең газаплар белән мүкәйләргә мәҗбүр итә. Сукмак, текә кыядан гына торган ярга терәлә язып, уңга, елгага таба борылды. Һава сафланып, җиләсләнеп китте. Ах, егетләр, нинди зур шатлык! Минем учларым дымлы баткакка килеп батты. Мин бу баткакка битемне куям, чиләнеп әрнегән табаннарым белән басам.

Каршыдагы кыяташның астагы ташлары арасыннан су саркып, күлләвек хасил иткән. Күрсәгез иде, егетләр, ничек шатланганны! Түзмәдем, тагын елап җибәрдем. Суга килеп капландым да, эчәм дә эчәм, эчәм дә эчәм. Ә суы соң, суы нинди, тешләрне сындырырлык салкын! Тик бераз шүрлим, чөнки ач кеше кинәт күп ашаса үлә, дигәнне ишеткәнем бар иде. Монда да шулай булмаса ярар иде дип уйлап алдым да эчүдән туктадым. Шулай да яңадан суга капланам. Тәмам сусыным канганчы эчтем.

Карыйм, кәҗә-сарык эзләре күренә. Ләмдә дә этнекеме, бүре эземе ярылып ята. Мөгаен, кыргый җәнлекләрдер. Кыргый җәнлекләр йөргәч, кешеләр яшәгән урын ерактыр, дигән уй кинәт кенә башымны ярып килеп керде. Су эчкәч, чүлмәк тә арурак пешерә башлады, ягъни башка юньлерәк уйлар килә.

Ничек тә кешеләрне табарга кирәк дип уйлыйм. Беләсезме, башка бүтән уй кереп тә чыкмый. Поездда барганым да, әни белән сеңелкәш тә. Башта тик шул бер генә уй: су да, су иде бит. Хәзер кешеләрне генә табасым калды.

Аяк табаннарымның әрнүен басар өчен, аягымны суга тыгарга булдым. Уң аягымны тыккан гына идем, кинәт кенә әллә нәрсә булды. Мине нindидер шом, курку биләп алды. Шулкадәр куркыныч. Тирә-якны күзләрем белән яшен тизлегендә айкап чыктым. Юк, ул-бу күренми. Кемдер бик нык күзәтә төсле тоелды миңа. Кузгалырга да куркып, башымны гына борып, үзем килгән сукмакны, ул-бу була калса дип, таш йә берәр агач кисәге эзләп тирә-якны, аяк асларын карыйм. Андый чакта үзегез беләсез бит, бер юньле нәрсә күзгә чалынса, ичмасам. Тезләрем ташларга бәрелеп актарылып, кансырап бетсә дә, әлеге минутта янымда үрелеп алырлык бер таш кисәге юк.

Куркуымны җиңеп, икенче аягымны да суга тыгып утырмакчы булып, аз гына кымшанган идем, янымда гына бер нәрсә калын тавыш белән ырылдап җибәрде дә яман итеп ысылдап куйды. Тавыш килгән якка ялт итеп баксам, бернәрсә дә күренми. Мин әйтерсең лә таш булып каттым. Тик аркадан гына нindидер салкын бөҗәкләр йөгерешә. Шул мизгелдә генә күрәннәр арасыннан ике күзнең туп-туры миңа карап торганын шәйләдем. Нинди күзләр, малай! Чәчләр үрә басты, каз тәннәре калыкты. Теге аучы Газинурның иң зур этеннән берничә тапкыр зуррак бер ерткыч җанвар! Мине күзәтә! Хәзер мин дә ерткычтан күземне алмыйм. Гәүдәсен дә чамалап алдым. Юлбарыс булырга тиеш түгел бу дип уйлыйм. Алар бит Ерак Көнчыгышта һәм Һиндстанда гына яши. Шулай карашып торабыз бер-беребезгә. Шушы ерткычның ризыгы булыр өченме мин ничәмә чакрымнар мүкәләп килдем?.. Хәзер бу мине ботарлап ташлаячак, һавада үләксәләр эзләп очкан козгыннар калдыкларымны үзләренең азыгы итәчәк. Кычкырырга чамалыйм, куркудан тавышым бугазыма төер булып тыгылды. Нишләргә? Андый вакытта кискен хәрәкәт ясарга ярамаганлыгын ишеткәнем бар. Ә ерткыч койрыгы белән җиргә шап та шоп сугарга кереште. Күрәм, сыртларындагы йоннарын кабарткан, авызын зур ачып, миңа ырылдый, ысылдый. Казык тешләрен күрсәгез, малай, менә шушындый озынлыкта булыр, – дип, Яшка абзый имән бармагын күрсәтеп алды.

– Менә шул секундта, кая секунд, секундның нindидер меңнән бер өлешендә башыма барып җитте: качарга, читкә сикерергә, югыйсә миңа – үлем! Бу уйны уйлап та бетермичә читкә сикердем. Әмма ерткыч җитезрәк булып чыкты. Ул да минем өскә ыргылып, тырнакларын батырып, сум итемне чалбар белән бергә аерып та төшерде. Гөрселдәп барып төштем дә аны-моны уйлап өлгермәдем, бар көчемне җыеп, торып йөгердем. Бер-ике адым сикерергә өлгердемме-юкмы, нәрсәдер аягыма китереп сукты да абынып егылдым. Һәм шул арада өстемә бер авыр нәрсә килеп төште. Мин һушымны югалтып караңгылыкка очтым.

Күпме ятканмындыр, дөресрәге, асылынып торганмындыр, белмим. Чөнки һушыма килгәндә, бер аягым өскә таба тарттырылып куелган, юньләп тын алырлык та түгел, күкрәк турымнан бер юан гына агач аркылы баскан иде. Шунда кинәт теге ерткыч җанварны күреп алдым. Җай гына бүрәнә астыннан шуып чыкмакчы булам, кайда ул! Селкенерлек тә түгел. Минем кузгалырга чамалаганны сизепме, ерткыч ырылдап ала да тагын йонлач койрыгын җиргә шапылдатырга тотына. Мин баштүбән асылынып торам дияргә була. Авыртуга түзә алмый, тешләрне кысып, ничек итсәм иттем, гәүдәне кыбырдата алдым. Ерткыч, шуны сизеп, минем өскә сикерде. Инде «беттем» дип күзләрне йомсам,

ул сикергән урынында шапылдап җиргә килеп төште. Шунда гына абайладым: ул да нәрсәгәдер эләккән булып чыкты. Эчкә җылы йөгерде. Гомерем бар икән әле. Һәрхәлдә бу ерткыч мине өзгәләп, ботарлап ташлый алмаячак.

Менә шул минутта гына, ниһаять, үземнең кемлегем, әни белән сеңелкәшне ияртеп, Үзбәкстанга китеп барганым искә төште. Ә менә монда ничек итеп килеп чыгуымны һич хәтерли алмыйм. Мине төшенкелек биләп алды. Шушы тозакта үләргә туры килер микәнни дип уйлыйм. Боттагы җәрәхәттән шактый гына кан аккан, җитмәсә, һаман җайлап кына саркуын белә. Яра өстенә кара яу булып чебен җыелган. Көчсезлектән тешләремне шыгырдатып, тавышсыз гына елап җибәрдем. Бүрәнә астыннан чыгарга була, яткан җиремне кулларым белән тырнап казырга керештем. Юк, булдырып булмый, бер аяк өскә таба каерылып тарттырылып куелган. Түзеп тора алмаслык авыртудан һушымны югалтам. Белмим, күпме булгандыр бу хәл, тагы аңыма килеп, яткан урынымны казыйм, тагын һушымны җуям. Ничектер, камышлар кыштырдаганга яңадан зиһенем ачылып китте. «Ерткыч үзе генә булса ярар иде» дип, Аллага ялварам. Тагын берәр ерткыч була калса дип, аны куркытырга була, яман итеп кычкырып җибәрдем. Кеше-мазар булса, тавышымны ишетеп калыр дигән өмет тә бар. Кинәт кенә барча дөньяны яңгыратып нәрсәдер шартладымы, мылтыктан аттылармы? Шунда теге ерткыч яткан җиреннән бик усал ырлап, миңа ташланмасынмы! Ләкин, килеп җитәр-җитмәстән, шапылдап тәгәрәп килеп төште дә тынып калды. Яшен уты кебек зиһенемне ярып үткән коточкыч авыртудан тагы һушымны җуйдым.

Аңыма килгәндә, ниндидер ярымкараңгы бер өй эчендә ята идем. Түшәмдәге төннек кебек тишектән генә бераз яктылык төшә. Мин ниндидер лайлалы, юеш бер биләүгә төрелгәнмен. Борынга чи ит, кан исләре килеп бәрелде. Үтереп су эчәсе, ашыйсы килә. Торырга тырышып, теге лайлалы биләүдән чыгарга чамалыйм. Шулвакыт, күзләрне чагылдырып, ишек ачылып китте һәм олпат гәүдәле ике ир килеп керделәр. Яткан урын-җирем белән күтәреп, мине тышка алып чыктылар. Бөтен дөнья яп-якты, күзләр камаша. Үземнең йомшак тирегә төрелгән булуымны абайладым. Ирләр янына ап-ак сакаллы бер карт килеп басты. Кулы белән ишарәләп, мине тиредән чыгарырга кушты. Бөтен тәнемә ябышкан чи тирене җайлап куптарып алдылар. Анадан тума калуыма оялып, тәнемне кулларым белән каплап, яным белән әйләнәм. Алар ниндидер таныш булмаган телдә сөйләшә-сөйләшә мине карыйлар, яраларымны тикшерәләр. Шулай да аларның минем сөннәтле булуым һәм дә мөселман икәнем турында сөйләшүләрен чамаладым. Шуннан тегеләр гәүдәмнең билдән астагы өлешенә ап-ак җәймә яптылар. Теге аксакал өйрәтеп тора, бу ике ир тәнемне юеш чүпрәк белән сөртеп, җәрәхәтләремә ниндидер май сылыйлар. Шуннан мине чиста киемнәргә киендерделәр. Үземнең киенерлек тә хәлем юк, аларның ярдәменә мохтаҗмын. Бездәге келәт сымаграк җәйге өйгә алып кереп, шулпа белән сыйладылар, сарык итеннән иде, ахрысы. Чәйдән соң аксакал миңа касәгә салып ниндидер төнәтмә тоттырды. Бик үк тәмле булмаса да, эчеп куйдым. Эчеп бетерүгә башым җиңелчә генә әйләнеп китеп, авыраеп, йокыга чумдым.

Мине шулай атна чамасы дәвалап, адәм рәтенә керттеләр. Дәвалаучыларым минем белән сөйләшеп-сөйләшеп карыйлар, тик бер-беребезне аңламыйбыз. Шулай да чамаладым: мин тау барсына дип корылган тозак-капкынга эләккәнмен. Теге мине җәрәхәтләгән барс та шуларның берсенә эләккән. Тау барсының көч-куәте күчсен һәм тизрәк савыксын дип, мине шуның тиресенә төргәннәр. Күрәсең, ярдәме тиде, тиз арада аякка бастым. Таякка таянып,

өй алдында йөри башладым, әз-әзләп тирә-як белән танышам. Авыл бик зур түгел. Тирә-ягы биек-биек таулар белән уратып алынган. Яссы түбәле йортлар барысы да биек балчык койма белән уратып алынган. Әйтерсең лә, бәләкәй генә ныгытма-кирмәннәр. Кайбер коймалар таштан. Ихаталарның күбесендә бакча, алмагач, груша үсеп утыра. Һәр йорт алдында диярлек йөзем куаклары һәм алар өйләрнең кыекларына кадәр үрләгәннәр.

Беркөнне шулай ихатада титаклап йөреп ятам. Йорт хуҗасының хатыны булса кирәк, олы яшьтәге апа, ниндидер бик моңлы көй көйли-көйли, йорт алдындагы тандыр дигән, җиргә чокып эшләнгән мичтә нәрсәдер пешереп булаша. Бәләкәй китмәнгә охшаш балта белән тал, корыган мамык куагы чыбыкларын кискәләп, теге мичкә яга башлады. Мин апа янына килеп, аңа ярдәмләшергә тотындым. Аяк авыртса да, кулда көч бар бит. Үзем чыбык-чабык тураклыйм, үзем апаның җырын тыңлыйм. Нинди көй дип тә әйтеп булмый, бик тә таныш. Безнеңчә, татарча көй бит бу. Ишеткәнем бар мондый көйне. Мин апаның җырлаганын тыңлыйм һәм үземнең туган якларны, әни-сеңелкәшләрне искә төшерәм. Ничек тә үземнең исән-имин икәнлегемне хәбәр итәргә иде дип уйлыйм. Менә апа җырлап бетерде дә, игътибар белән тыңлаганымны сизеп, елмаеп нәрсәдер сорый. Мин аңламыйм дип башымны чайкыйм да аңа татарча дәшәм. Урысча дәшкәләп карадым, юк, аңламыйм, ди. Тагын үзебезчә дәшәм. Тандырдагы утка күрсәтеп, «ут», «төтен» дигән булам. Камырга күрсәтеп «камыр», «он» дим, суга күрсәтеп «су» дим. Апам бераз уйланып торды да шатланып һәм мине шатландырып:

– Яхшы, яхшы, – дип кабатлап, миңа карап елмая. Һәм мине аптыратып, ап-ачык итеп: – Әни, әти, Ватан, Казан, – дип әйтеп салмасынмы! Мин «кемнәр болар?» дип уйлыйм. Һәрхәлдә, үзбәк түгелләр. Казанны белгәч, татарлардыр. Тик нишләп татарча белмиләр? Һәм мин дә, апага карап, үземә ымлап:

– Мин – татар, Казаннан, – дим һәм үземнең исемемне әйтәм.

Апа бүтән дәшмәде, нәрсәдер уйлап, сүзсез калды. Ничектер моңсуланып, күңелсезләнеп китте.

Мин шулай утын, чыбык-чабык ваклап бирәм, тегесен-монысын эшләшәм. Апаның исемен дә белдем – Сәгыйдә икән. Теге ике яшь таза ир аның олы балалары булып чыкты. Алар гаиләләре белән күрше генә яшиләр икән. Апа белән шулай икәүләшеп лыбырдашабыз. Шуннан ул үзләре яшәгән өйнең ачык ишегенә башын тыгып:

– Рәхимә! – дип кычкырды да килеп, тандыр авызына иелде. Өйдән ап-ак йөзле, кыйгач кашлы, сылу гәүдәле бер кыз килеп чыкты. Мине күреп, тиз генә йөзен яулык чите белән каплады. Күзләре генә ут булып елтырый. Битен яртылаш каплагач, ул тагын да чибәррәк, тагын да ымсындыргыч булып китте. Үз гомеремдә бу кадәр сылу кыз күргәнем юк иде. Күрәсең, Рәхимә – Сәгыйдә апаның кызы, чөнки алар бер-берсенә бик тә охшаган. Шулай бер мизгел бер-беребезгә карашып тордык. Мин кулларымны кая куярга белмим, кызарам. Өстемдәге киемнәр капчык кебек асылынып тора. Үземнекеләр кияргә бөтенләй яраксыз булып, теге ирләрнең яшьрәгенең киемнәренә чорналган идем. Алар чиста булсалар да, миңа зур. Бер хәерче бала кебек күренәмдер инде читтән.

Апа яңа гына пешеп чыккан сумсаларны озын саплы кашык белән алып табакка тутыра һәм Рәхимәгә нәрсәдер сөйли. Кыз апаны тыңлый, үзе утлы карашы белән мине яндырып-яндырып ала. Мин аңардан күземне ала алмыйм. Ул ачуланамы, елмаямы, әллә шыксыз киемнәремне күреп, миннән көләме?

Белмәссең. Менә хәзер көлеп, пырхылдап җибәрә дип көтәм. Юк. Ул күзләре белән тагын бер өтеп алды да капкадан чыгып китте. Сәгыйдә апаның нәрсәдер дәшкәненнән һушыма килеп, кызарганымны күрсәтмәскә була, чыбыкларны утынлыкка ташый башладым. Апа коштабактагы сумсаларны өйгә алып кереп китте дә пешерергә әзерләгәннәрен күтәреп чыкты. Мин мич кырыена килеп, апаның аларны мич эченә ничек ябыштырганын карыйм. Чөнки бездә сумсага охшаган вак бәлешләрне әни олы мичтә пешерә торган иде. Сәгыйдә апа бик җитез кылана, сумсалар мич эченә ябышып та беттеләр. Апа минем аны бик игътибар белән күзәткәнне күреп, тагын нәрсәләрдер сораша, сөйли. Тик мин елмаеп, «әйе, әйе» дигән кебек, башымны гына кагам. Апа өйгә кереп китте. Үзем яшәп, йоклап йөргән җәйге алачыкның ишек төбендәге ташка барып утырдым. Теге тәмле сумсалар белән чәй эчәргә озакламый мине дә чакырачаклар. Уйларым әледән-әле Рәхимәгә әйләнеп кайта. Бүтән көннәрне дә ул сирәк-саяк кына күренеп киткәләде киткәләвен, тик ул чакта минең хәлләр шәптән түгел иде.

Күп тә үтми, Рәхимә бер бик карт әбине ияртеп кайтып та керде. Әби йөзем агачы күләгәсендәге урындыкка килеп утырды да, озак кына догалар укып, амин тотты. Сәгыйдә апа да аңа ияреп битен сыпыра. Мин дә, кулым белән битемнән ниндидер күренмәгән пәрдәне алып ташлаган кебек кыланып, амин тотам.

Гомумән, бик диндар кешеләр яши бу авылда, адым саен дога укыйлар да амин тоталар, биш вакыт намазны калдырмыйлар. Авыл дигәннән, монда авылны кышлак дип йөртәләр.

Әбием миңа бераз карап-карап торды да, кулы белән ишарәләп, мине үз янына чакырды. Үзе утырган урындыкның булмаган тузанын сыпырып алгандай итте дә кырына утырырга куша. Үзбәкчәләп минем кем булуымны, кайдан килүемне сорый. Исем-шәрифләремне әйтәм. Билгеле инде, үзбәкчә сөйләшә белмим, шулай да аңлыйм бераз. Шуңа да, әби дә мине аңлар дип, татарча сөйлим. Әбием ялт иттереп миңа карап алды да, ниндидер ят акцент белән, әмма бик дөрес итеп:

– Син, улым, татар милләтле адәм буласыңмы? – ди. Мин баш кагып:

– Әйе, – дим.

– Син Казан татарымы? – ди әбием, аптырап. Мин әйтер идем, әби ниндидер иске, үзе кебек картайган сүзләр белән сөйли.

– Юк, мин Башкортстан татарымын, – дим. Әбием тагын сүзсез калды да бераздан:

– Белмим, ишеткәнем дә юк, ул кай тирәдә, нинди җирләр? Пенза яклары түгелме? – ди. Мин инде бөтенләй аптырыйм. Ничек инде Башкортстан чаклы Башкортстанны белмиләр дип уйлыйм. Һәм «Уфа, Эстәрлетамак якларыннан мин» дип, тирә-яктагы шәһәрләрне санап киттем.

– Шулай язмыш, – дип авыр сулап куйды да әбием: – Бәләбәй еракмы? –ди. Мин инде шатланып:

– Ул кадәр түгел, барсаң, бер сәгатьлек юл булыр, – дим. Ә үзем «юк, бу үзбәк карчыгы булырга тиеш түгелдер, безнең якларны яхшы белә. Татар әбиседер», – дип уйлый башладым.

– Тирә-ягыңда нинди елга-сулар ага? – дип, әби һаман төпченә. Мин санап киттем:

– Дим, Ашкадар, Эстәрле, – дигән булам.

– Авылыңның исемен әйт, исемен, – ди әбием, учын колагына куеп,

бөтенләй минем якка авышып. Аның бик ишетеп бетермәгәнен бая ук чамалап, тавышымны күтәреп сөйли башлагач, үзе үк колагын читкәрәк алды. Мин авылның исемен әйткәч, күзенә чыккан яшьләрен яулыгының очы белән сөрткәләп, кинәт кенә:

– Өршәк хәзер кипкәнмени, олан? – диде. Мин бераз гаҗәпләнеп һәм кыенсына биреп:

– Юк, – дим.

Әбием минем белән сөйләшүдән туктады да Сәгыйдә апага үзләренчә нәрсәдер әйтеп куйды. Апаның йөзендә аптырау да, кызыксыну да, хәтта берникадәр курку да бар иде.

Әби тагын минем якка колагын куеп сораша да сораша. Мин аның һәр соравына тулы итеп җавап бирергә тырышам. Бераздан Сәгыйдә апа барыбызны да өйгә чәй эчәргә чакырды. Бергәләшеп өйгә кердек. Безне бик бай табын каршы алды. Бу якларда табын түр якта идәндә әзерләнә. Элек бездә дә шулайрак иде анысы. Йә сәкедә, йә идәндә була торган иде. Күп тә үтми, мине коткарган ир – Сәгыйдә апаның олы улы да килеп керде. Табында ирләрдән без аның белән икәүбез. Миңа да тынычрак. Тик Рәхимә генә алгы бүлмәгә чыгып китте. Әби минем бу якларга ничек килеп чыгуым турында сораша. Машинадан торып калдым, дип алдаштырам. Миңа тимер юл стансасына, фәлән-фәлән поездга чыгарга кирәк, бер дә булмаса, якындагы автотрассага, дим. Берәрсе олы юлга чаклы чыгарса, әйбәт булыр иде, югыйсә менә бит, барска дип корган капкынга эләктем дип, җәрәхәтләнгән аякны күрсәтәм. Әбием, минем ак чүпрәк белән бәйләнгән аякка карап:

– Ходай насыйп итсә, төзәлер, балам, төзәлер, – диде дә нык кына көрсенеп дәвам итте: – Улым, бу сезнең илегез түгел, бу Әфганстан иле, – ди. Минем зиһенемә аның әйткәннәре барып җитми тора. Ул шуны чамалапмы, әллә үз-үзенәме: – Шулай, балам, бу – безнең ил түгел, бу чит Әфган иле, – дип кабатлап, тагын көрсенеп куйды.

Минем өскә бер чиләк бозлы су койдыларммыни! Үзем дә сизмәстән котым очып:

– Ничек? Хәзер ни эшләргә? Ничек итеп кире кайтырга? – дип кычкырып җибәрдем.

Әбием:

– Курыкма, балам, курыкма, монда да әйбәт кешеләр яши. Озатып куярлар. Тик кайткач кына Себергә сөрмәсәләр үзеңне? – дип, шик белдереп, мине куркытып куйды.

Мин – комсомолец, колхозда иң алдынгы шоферларның берсемен. Кышка партиягә керергә исәпләп йөри идем. Партком секретаре Рилаф абзый да: «Көзге эшләр бетүгә сине кандидат итеп алабыз. Тырышып кына эшлә, кара аны, мине хурлап, йөзгә кызыллык китермә», – дип кисәтеп куйган иде. Ә мин капиталистлар, басмачлар арасында яшәп ятам икән. Партиягә кандидат итеп алганда, анкеталарны ничек тутырырмын да, гомумән, кайтып булырмы әле, әбием әйткәнчә, кайткан көе төрмәгә ябып куймасалар. Минем баштан берсеннән-берсе шөбһәле, берсеннән-берсе ямьсезрәк уйлар йөгерешә.

Ничек бу бәладән исән-сау котылырга? Минем үз кайгым көчле, ә әбием үзе турында сөйли. Бәләбәйнең үзеннән булып чыкты. Революциягә кадәр үк сәүдәгәр этисе бу яклардан кызыл тауар ташыган. Әбинең дә этисенә ияреп, Кәшмиргә барганы булгалаган. Илдә гражданнар сугышы башлангач, монда торып калганнар. Бераз тынычлык урнашсын, тәртип булдырылгач, кире

кайтырбыз әле, дип уйлаганнар. Менә шуннан бирле кайчан тәртип булыр икән дә, кайчан большевиклар бетәрләр икән, дип көтеп ятканнар. Эчтән генә: «Вәт буржуй-басмач, сволочьлар!» – дип уйлап куйдым.

Әбинең сөйләве буенча, Сәгыйдә апаларның әти-әниләре бөтенләй безнең күрше авылдан булып чыкты. Мин моңа шатланмыйм. Бүтән чак булса, кызыксынып, ничек алай да, ничек болай дип, сорашып туймас идем. Күрше генә авылдан булгач, нишләп татарча сөйләшә дә белмиләр? Хәтта безнеңчә аңламыйлар да... Сәгыйдә апаның әтисе авыл мулласы булган. Утызынчы елны, төрле маҗара-михнәтләр күреп, шушы җәһәннәм читенә килеп урнаша алганнар. Еллар тынычланып, дөньялар иминләнгәч, кире кайтырга исәпләре булса да, хыяллары барып чыкмаган. Чөнки совет властена ышанып, кире кайтканнарны йә атканнар, йә булмаса Себер сөргәннәр.

Әби шулай сөйләде дә сөйләде. Елашып та алалар. Көн шулай тегеләрнең сөйләгәннәрен тыңлап, елаганнарын күреп үтте дисәм дә була. Ә бит минем үз кайгым хәтәр. Эчемдә ут яна. Моннан тизрәк табанны ялтырату ягын карарга кирәк. Тик кайсы якка? Юлны белмим. Географияне хәтерләргә тырышып карыйм. Әфганстан безнең илдән көньякта урнашкан урнашуын. Шулай булгач, миңа төньякка сыпыртырга кирәк. Тик төньякта теге кар чалмалы таубабайларының сыртлары гына ялтырый. Һәм алар миңа мәңге мондый биек таулар күрмәгән кешегә, куркыныч һәм шомлы булып күренә. Әбидән, җаен туры китереп: «Бүген нинди көн?» – дип сорыйм.

– Сәфәр аеның шул-шул көне һәм бүген атнаның чишәмбе көне, – дип җаваплый ул.

Бернәрсә дә аңламый:

– Алай икән, – дип кенә куя алдым.

Мин икенче көнне дә кәефсез идем. Теге кортка бүген дә килде, дөресрәге, Сәгыйдә апа тагы Рәхимәне җибәреп чакыртып алды. Тагы шулай әби белән сөйләшәбез. Ул җайлап-җайлап минем кылларны тартып карый. Гаиләм, балаларым барлыгы, юклыгы турында сораша. Һәм мине чынлап торып монда калырга үгетли үк башлады.

– Син, олан, аптырама аларның безнеңчә белмәүләренә. Туган телләрен белмәсәләр дә, алар – татарлар. Аларның татарлыклары каннарында, йөрәкләрендә. Рәхимәне үзеңә кәләш итеп әйттерербез. Аларны татарчага өйрәтерсең. Мондагы татар балаларын үзебезчә укытырсың. Татарлар бар әле ул, күрше кышлакта да хәтсез генә. Бутирәдәге татарлар барысы да хәлле, җитеш яшиләр, – дип, мине кодалапмы кодалый. Күңелгә коткы сала, басмачлар коткысы. Кайда ул, миндә тик моннан тизрәк исән чакта таярга кирәк дигән уй гына. Комсомолец илен сатмый, кайтам, и бетте! Минем бөтен уем – тик әни, сеңелкәш, ага-туганнарда һәм моннан җаен туры китереп качу гына. Күрәсең, моны сизеп, әбием үкенечле тавыш белән:

– Ярар, олан, дөрес уйлыйсың. Туган илдән, туган җирдән аерылып яшәүдән дә зур кайгы, олы бәхетсезлек юк. Яхшы булса да торган җир, сагындыра туган ил, дип әйтмәсләр иде, балакай. Иртәгеләргә сине чик буена кадәр озатып куярлар. Хафаланма, улым, – дип тынычландыргач кына, миңа әзрәк хәл керде. Күңелем тынычланып, йөрәк үз урынына утырды шикелле. Югыйсә, әбиемнең кичә үгетләвеннән төнлә йоклый да алмадым.

Чынлап та, берничә көннән мине чик буена алып килделәр. Билгеле инде, ат белән. Мине озатучыларның берсе Рәхимәнең олы агасы булып, икенче юлдашым – күрше авылдан, үзебезчә вата-җимерә, үзбәкчә кушып сөйләшкән

яшь кенә бер татар егете иде. Юл тузанына сызгалап, кай җирдәнрәк һәм ничегрәк үзебезнең якка чыгарга өйрәтәләр.

– Без бүтән бармыйбыз, хәзер үзең дә кайтып җитә аласың. Чөнки безнең чик буенда йөргәнне күрсәләр, үзеңә авырга туры киләчәк. Тотып алулары ихтимал, – дип аңлаталар. Теге үсмер татар егете миннән барысын да сораша, белергә тырыша. Кешеләрнең ничек киенгәннәреннән алып, нәрсә ашаганнарына чаклы төпченә. Мин аңлатам, җентекле җавап бирергә тырышам.

Көн кичкә авышты. Елгага кадәр байтак кына атларга туры килде. Елга шактый киң һәм ургып ага икән. Тегеләр биргән кәҗә тиресенә тәүдә өреп тын тутырдым. Аны кайсылай тунап, ничек шулай тын чыкмаслык итеп ясаганнардыр инде, аптырарсың бу көнчыгыш халыкларына. Менә шул кәҗә тиресенә киемнәремне бәйләп һәм шуңа тотынып хәл ала-ала, йөзеп-агып дигәндәй, көчкә үзебезнең якка чыктым.

Чәнечкеле тимерчыбыкның исеме генә. Кайбер урыннарда астан өзелгән. Иң курыкканым шул: тимер чыбыкка электр тогы җибәрмәгән булсалар ярар иде. Юк, ток сукмады. Тәүдә юеш камыш белән төртеп карадым, алай-болай дерелдәтмиме дип. Сизелмәде. Шуннан гына батырчылык иттем. Алда тип-тигез итеп сөрелгән җир арасы ята. Аны инде үзем дә белəм ничек үтәргә. Әрем, дөя чәнечкеләрен учмага җыйдым да шуның белән себереп, эземне тигезләп бардым. Моның белән генә бетмәгән икән әле, алда тагы бер кат чәнечкеле тимерчыбык сузылган. Монысында тишек-тилем юк. Ярый әле тегеләр биргән чапан бар, шул чапанны тегенең өстенә ябып чыктым. Югыйсә, барча киемем ертылып, теткәләнеп бетә иде.

Чыгуын чыктым, тик хәзер кайсы якка барырга? Әкияттәге кебек. Уңгамы, сулгамы, әллә булмаса турыгамы, дигәндәй. Иң яхшысы – тизрәк чик буеннан ераккарак сыптырырга кирәк инде, һәм мин туп-туры алга киттем.

Әйтәм бит, анда караңгы тиз төшә дип. Төн. Күзгә төртсәң дә, бернәрсә күрмәссең. Сәрмәнеп, аяк астын чак шәйләп барам. Күпмедер баргач, бөтенләй буталдым. Дөресрәге, адаштым шикелле. Теге чәнечкеле тимерчыбыкка киләм дә чыгам, киләм дә чыгам. Шәфәкъ кызарып, таулар күзгә чалына башлагач кына, көнчыгышны чамалап, төньякка юл алдым. Ике көн шулай тау-таш арасында адашып йөргәч, ниһаять, тимер юл тасмасына килеп чыктым. Ни булса шул булыр дип киттем тимер юл буйлап. Теге якка да, мин бара торган якка табан да поездлар үткәләде үткәләвен. Машина түгел шул, кул күтәреп кенә туктатып утырып китәргә. Озак бардым. Юлга алган көлчә-түгәрәк ипиләр, итләр күптән бетте. Су да калмады. Ниһаять, арып-талып, инде бүтән барырга хәлем дә, теләгем дә калмаганда, еракта, таулар итәгендә көтү йөргәнне күреп алдым. Таулар ул турыга караганда гына якын төсле. Бара-бара һушларым алынды. Мин көтүгә таба барам, ә көтү җайлап кына алга үрмәли. Кич җитүгә көтүчеләр янына чак барып җиттем. Ике яшь кенә үсмер, унике-унөч яшьләрдә булырлар, көтү көтеп йөриләр. Күреп торам: миннән шикләнәләр болар. Тегеләрдән су сорыйм, су китереп бирделәр. Мине юньләп аңламыйлар. Уфа кайда дип сорыйм, баш кына чайкыйлар. Белмиләр. Москва кайда, дим. Алар төньяк-көнбатышка күрсәтәләр. Мин җиргә төртеп күрсәтәм. Русияме, дим. Болар тагын:

– Юк, – дип баш селкиләр. Минем тагын кот очты. Тагын адашып, кире теге якка, Әфганстанга чыгып киттем микәнни инде дип уйлыйм. Һәм курка калып тегеләрдән:

– Әфганстанмы? – дим. Юк, имеш. Башка бөтенләй шик төште, җаным

табанга китте дисәм дә, дөрес булыр. Әллә, мин әйтәм, Иран җиренә барып чыктыммы икән дип уйлый башлаган идем. Теге үсмерләрнең олырагы: «Үзбәкстон бу. Үзбәкстон җире» дип аңлатырга керешкәч, шатлыктан көлеп үк җибәрдем. Күзләремә яшь эленде. Ниһаять, мин үзебезнең илдә. Теге көтүчеләргә ияреп киттем. Алар сарыкларын төнлеккә туплауга ябалар икән. Төнне көтүче малайлар белән үткәрдем. Мине тәмле яшел чәй һәм эремчек белән сыйладылар. Бик туклыклы һәм тәмле нәрсә икән.

Икенче көнне иртән көтүче малайлар янына ишәккә атланып, үзбәк бабае килде. Ул малайларга ризык, чәй-шикәр китереп китә икән. Күрәм, бабай да миңа шикләнеп карый. Кем булуымны, кайдан килүемне сораштыра. Ә мин үз чиратымда теге мин барасы стансаның кайда икәнлеген белешәм. Бабай:

– Һай, олан, ул әллә кайда, ерак, – дип, бөтенләй икенче якны күрсәтә.

Бабайга ияреп, ул торган кышлакка киттем. Юлдашым юл буена юньләп сөйләшмәде дә. Бабай атланган ишәк артыннан йөгерә-атлый чак өлгереп ияреп барам. Ишәк болай җитез хайван икән, лерт-лерт йөгертә генә.

Кышлакта бабай мине биек, юан-юан чинар агачларына ышыкланып утырган кәнсәләр йортына алып килде. Буйлы-буйлы чапаннар кигән берничә үзбәк басып тора. Бездәге кебек инде, берсе килә, берсе китә дигәндәй. Кәнсәләр кырыннан гына аккан арык читендә берничә ир-ат тәмәке көйрәтәләр, насвай чәйнәгәннәре дә бар. Үзара кычкырып-кычкырып бәхәсләшәләр. Бабай ишәгеннән төшүгә, безне сәламләп, тынып калдылар. Барысы да миңа текәлгәннәр. Мине энә күзеннән үткәрәләр. Бабай:

– Стансага машина барырга тиеш, мин белеп чыгыйм, – дип, кәнсәләргә кереп китте.

Ә мин, теге тәмәке көйрәтүчеләрне күрү белән, ишарә белән генә тартырга сорыйм. Берсе шикләнеп кенә булса да миңа тәмәке, шырпы суза. «Прима» иде, әле дә яхшы хәтерлим. Шулай да поезддагы теге хәл яңадан кабатланмасмы дип куркам. Үзбәкнең биргән тәмәкесен иснәп, кулда әйләндереп-әйләндереп карыйм. Юк, таныш исе килә. Түзмәдем, кабызып, төтен суырам. О, егетләр, нинди бәхет, нинди ләззәт... Ә бит тәмәке тартмаганга өч атнамы, артыгракмы вакыт узгандыр. Башларым әйләнеп китте. Мин анысыннан да бигрәк, теге хәл кабатланудан куркып, тәмәкене сүндердем. Уйлыйм: «Юк, дим, тартуны ташларга кирәк, булмый болай». Ул да түгел, кәнсәләр тәрәзәсе ачылып, берничә баш мине кызыксынып күзәтә башладылар. Менә бабай килеп чыкты да бик җитди итеп:

– Хәзер, олан, стансага машина бара. Юллама һәм башка кәгазьләр алырга барыбер монда, кәнсәләргә килә, – ди. – Чак кына көт, бер ун-унбиш минут, – диде дә яныма ук килеп утырды. Кәнсәләрдән тагы берничә таза-таза үзбәк чыгып, минем алга килеп басты. Хәл-әхвәл сорашалар. Алар үзбәкчә, мин татарча. Ничауа гына аңлашабыз шунда. Аңлашылмаган җирдә урысча да сүзләр кушылып китә. Тик урысча алар бик начар аңлыйлар. Урысча минеке дә бик шәп түгел түгеллеген. Ярый инде шунда, безнең кебек авыл кешеләренә.

Табигать, һава торышы турында, уратып-уратып булса да, кайда, кем булып эшләвемне, кайсы якта яшәгәнемне сораштыралар. Мин сөйлим, тегеләр тыңлый. Көлешеп тә алабыз. Дусларча әңгәмә инде. Тик мин сизенәм, малай, боларда нindидер яшерен киеренкелек тоела. Миңа ышанмыйлар. «Әйдә, әйдә, чарла телеңне, әйләндер сүз тегермәнен», дип уйлаганнары сизелеп тора.

Чынлап та, бер унбиш минут та үтмәгәндер, борылыштан бөркәүле «алтмыш алтылы ГАЗ» күренде. Аның артыннан «УАЗ» машинасы да җилдерә.

Кызу киләләр болар. Берәрсен таптамасалар ярар иде, дип уйлап та өлгермәдем, картым теге үзбәк ирләренә нәрсәдер әйтүе булды – шалт-ялт, дөмдер-дөмбер мине теге әзмәвердәй таза үзбәкләр җиргә сугып та ектылар, бөгәрләп тә салдылар. Кая, нәрсә уйларга да өлгермәдем, егетләр. Һич ялгансыз, малай, берничәсе өскә үк менеп атланды. Аяк-кулларны үзләренең буйлы-буйлы билбаулары белән шакарып, суярга салынган сарык шикелле бәйләп тә куйдылар. Теге машиналардан бер көтү солдат автоматларын шалтыратып килеп тә төштеләр, уратып та алдылар. Ялтырап торган хром итек кигән капитан «УАЗ» машинасыннан үз бәһасен белеп кенә төште. Мин моны үземне уратып алган үзбәкләр, солдатларның аяклары арасыннан карап ятам. Ул минем янга килү белән аяклар, капитанга юл биреп, ике якка тезелеп басты. Теге офицер, бик тә катгый калын тавыш белән:

– Кто такой? – ди.

Мин үземнең кем икәнемне әйтергә маташам. Тел әйләнми. Шунда гына чамаладым – кайсыдыр үзенең тирдән каешланып беткән сасы түбәтәен дыңгычлап авызга тыккан. Кычкырып карыйм, кайда ул, чак тын алып ятам. Чөнки ару гына биргәләгәннәр, ахры, борын да каный икән әле, җитмәсә. Шунда офицер:

– Аңлашыла, – диде. – Связать!

Мин һаман үземнең гадилек белән уйлыйм: «кая бәйлисең инде моннан да артыгын. Чорнап ташлаган йомгактан да болайрак бәйләделәр бит». Ә алай түгел икән шул. Янда гына торган солдат чалбар кесәсеннән кап-кара чүпрәк чыгарды да минем күзләрне бәйләп тә куйды. Күзләрем сытылып чыга дип торам. Аннан кулларымны артка каерып, богау салдылар. Шуннан китте шау-шу. Кем ничек сугып еккан да, кем ничек аяк чалган – берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә мактанышырга тотындылар. Бер үзбәкчә, бер вата-сындыра урысча. Ишетеп ятам: бабай белән офицер кәнсәләргә кереп киттеләр. Күрәсең, бабайдан сорау алыргадыр. Бераздан кире чыктылар, бабайны олылап, рәхмәтләр әйтәләр. Тирә-яктагы үзбәкләргә дә рәхмәтләр әйтелде. Капитан дәвам итеп:

– Хөрмәтле дехканнар! Чик бозучы дошманны, империалистлар лазутчигын, куркыныч шпионны тотуда ярдәм күрсәткәнегез өчен сезгә чик сакчылары зур рәхмәт белдерә. Без бу диверсант-шпионны инде ничәнче тәүлек эзәрлеклибез. Ниһаять, ул безнең кулда. Җәзасын алыр, явыз. Империалистлар белеп торсын. Аларның СССРга каршы оештырылган һәрбер явыз провокациясе лаеклы җәзасын алыр. Мөгезләрен сындырырбыз.

Иптәшләр! Яшәсен халыклар дуслыгы! Яшәсен дехканнар белән чик сакчыларының бердәмлеге! Урра, иптәшләр! – дип, кыска гына нотык тотты. Солдатларга кушылып, үзбәкләр дә «урра» кычкырдылар.

Шулай итеп, мине, хәзер шпион, империалистлар лазутчигын, машина әрҗәсенә салып, каядыр алып китеп баралар. Машина даңгыр-доңгыр сикерә. Аның саен минем баш тимер идәнгә бәрелә. Мин түзәм. Үземне тынычландырырга тырышам. Тикшерерләр, белешмәләр алырлар. Кем икәнлегемне ачыкларлар да җибәрерләр. Машина идәненнән тузан күтәрелә, борынга тузан керә. Ярый әле авыздагы түбәтәйне алганнар, бөтенләй тончыгырга калыр иде. Тын алулары авыр. Җитмәсә, кысып бәйләүдән күз алмалары шартлар чиккә җитеп башны авырттыра да, түзеп торгысыз булып, миемнең әллә нинди бер ноктасына килеп бәрелә. Юньләп уйлый да, селкенә дә алмыйм. Кайчан бетә инде бу тәмуг? Кайчан бетә инде бу сызланулар?

Машина шып туктады. Мине капчык кебек алып, җиргә очырдылар. Якадан тартып, аякка бастырдылар да каядыр алып кереп киттеләр. Коридор иде шикелле, күздәге тукыманы чиштеләр. Атларга кушалар. Тик мин бернәрсә дә күрмим. Сукырайдым дип котларым алынды. Җитмәсә:

– Әйдә, атла, – дип, урысча каты гына сүгенеп, җилкә тамырыма ямап та алдылар. Мин абына-сөртенә атлап киттем.

– Ул якка түгел, уңга борыл! – дип җикеренде берсе. Шунда нәрсәгәдер абынып егылдым. Кемдер эчкә китереп типте:

– Кара син аны, сволочь. Чикне бозып чыкканда, бер дә егылмаган, әле килеп кыланып яткан була!

Ничек җитте – шулай торырга чамалыйм. Ишек ачылып китте, мине этеп бер бүлмәгә кертеп җибәрделәр. Алдымда торган урындыкка абынып егылдым. Көчле куллар мине тагы тартып торгыздылар, маңгайга пистолет китереп терәделәр. Бөтенләй таныш булмаган тавыш:

– Ничәү идегез? Кайда калганнарыгыз? – ди.

– Мин берүзем. Адашып китеп шулай булды. Күп эчелгән, – дип, баштан үткән маҗараларны аракыга сылтый башладым.

Минем сүзләрне тыңлаучы да юк. Теге, пистолеты белән авызга ук кереп китеп, авызны каера. Пистолет икәнен чамаладым инде. Мылтык мае солдат хезмәтеннән үк таныш. Этеп-төртеп, ниндидер бер бүлмәгә кертеп яптылар. Камера иде, ахры. Артка каерылган кулларны алга богауладылар. Күзләр ару гына шәйләп, әйберләрне аера башлады. Әйбер диюем стенага йозаклап куелган карават. Шуннан башка нәрсә юк. Тып-тын. Утырыр идең, теге тимер нәрсәкәй стенага йозаклы. Аптырап, почмакка барып чүгәләдем. Тимер рәшәткәле бәләкәй генә тәрәзә, аның бер өлгесе кителеп төшкән, тыштагы чыпчыклар чыркылдашканы да гүелдәп, машина-мазар үткәне генә ишетелеп куя. Камера эче суык. Миләрне куырырлык эсседән соң тәнгә рәхәт булып тора.

Озакламый бер солдат белән милиционер килеп, мине каядыр алып киттеләр. Иң түрдә бер бүлмәгә кертеп юынырга куштылар. Куллар богаулы килеш кенә краннан су агызып юынам. Хәл кереп китте. Рәхәтләнеп су эчеп алдым. Чүпрәк белән битне сөрттерделәр. Өстемнән пычрак-тузаннарны каккалагач, бинаның өске катына алып менеп киттеләр. Ишегенә «Тикшерүче» дип язылган, зур тәрәзәләре шулай ук рәшәткәле якты бүлмәгә алып керделәр. Өстәлдән шактый ерак кына арага идәнгә ныклап беркетелгән урындыкка утырттылар. Чәчләренә көмеш йөгергән олы гына яшьтәге бер абзый утыра өстәл артында. Колхозның баш бухгалтеры Гыймади абзыйга охшабрак торган бер бәндә инде. Кергән көе урысча исәнләшәм. Сизеп торам: минем алдагы язмышым шушы абзый кулында. Бу нәрсәдер яза да яза. Миңа күзлегенең өстеннән генә карап алды да тагын язарга тотынды. Күрәсең, исәнләшүе шулай. Мине алып кергәннәргә күтәрелеп карамыйча гына кулы белән ишарәләп чыгарга кушты. Тагы бераз язышкач, бик игътибарлап, ике кулына тотып, ручкасын карарга кереште. Бармаклары арасында әйләндерепме әйләндерә, әйтерсең дә яңа гына күргән. Һәм миңа карамый гына:

– Тәк, шулай итеп, без русча да сукалыйбызмы? – ди. Мин кыюсыз гына:

– Әзрәк, – дим. Шуннан гына теге миңа карап:

– Йә, сөйләгез, нишләп чик бозып, безнең якка чыктыгыз? Нинди күрсәтмәләр белән, нәрсәләр алып чыктыгыз? Кем күрсәтмәсе белән йөрисез? Гомумән, сез кем? Сөйләгез! Чын күңелдән сөйләп, безгә ярдәм итсәгез, яхшырак булыр. Ул очракта җәзасы да ул кадәр каты булмас, – ди.

Мин тотлыга-тотлыга, каушавымнан һәм нык дулкынлануымнан ниндидер үземә таныш булмаган чит тавыш белән, урысчаны ватып-җимереп сөйләп киттем. Үземнең кем булуым, кайдан килүем, җизнинең вафаты турында телеграмма алуым, өчәүләп юлга чыгуыбыз, ничек тамбурда бер үзбәк белән аракы эчүебез, тәмәке сатып алып тартканнан соң, зиһенем томанланып, бернәрсә дә белерлек хәлдә булмыйча поезддан төшеп калуымны һәм адашып, чик буена барып чыгуымны сөйләдем. Барыбер аракыны кыстырдым. Чөнки наркотик кушылган тәмәке тартканнан кешенең ул кадәр үзен-үзе белмәслек хәлгә килеп, ахмакланып миңгерәүләнгәне башыма сыеп бетми иде ул вакытта. Тик Сәгыйдә апа һәм уллары турында ләм-мим. Көтүчеләр янында булдым да тау башыннан егылып төшкәндә, агач ботакларына сыдырылдым дип сөйләдем. Әзрәк арулангач, көтүчеләр үзләренең киемнәрен кидереп, шул якка бар, синең торган-яшәгән җирең шул якта, шул якка таба юл тот дип җибәрделәр, дидем. Алдадым. Чөнки чын күңелдән ярдәм итеп тәрбияләп терелткән милләттәшләремә минем аркада авырлык килүеннән курыктым.

Тикшерүче мине бик дикъкать белән тыңлады, бүлдермәде. Мин сөйләп бетергәч, кәгазь-каләм китереп тоттырды да, бер як читтә торган тәгәрмәчле авыр гына тумбочканы минем алга этәреп:

– Яз! Миңа нәрсәләр дип алдадың, барысын да түкми-чәчми яз. Бик ятышлы килеп чыга әкиятең. Карап карарбыз. Иртәгә нәрсә дип су коярсың икән? Теге яктан да, бу яктан да сине күреп белүчеләрне алдыңа китереп бастырсак, – диде дә өстәлдә яткан бер кочак гәзит-журналларны укырга тотынды.

Мине шулай көн саен тикшерүчегә йөртәләр. Кайчакны икешәр-өчәр тапкыр. Куркытып та алалар, әрләп тә ташлыйлар. Юхалап-юхалап, төрле нәрсәләр вәгъдә иткән булалар. Шулай ун көнләп җәфаладылар. Әйтүе генә җиңел. Андагы кичерешләр, андагы куркулар! Иң курыкканым «кире Әфганстанга чыгарып ташлыйбыз» дигәч булды. Ләкин барыбер «ныклап тикшерерләр, барысын да ачыкларлар һәм азат итәрләр» дигән уем беркайчан да башымнан чыкмады.

Азактан гына белдем: минем кем икәнемне ачыклар өчен тәүдә Мәскәүгә сорау җибәргәннәр. Ә Мәскәү – Уфага. Уфа, билгеле инде, безнең силсәүит Хаҗи абзыйга һәм колхоз рәисе Кунафин Габделхак абзыйга. Ярый әле алар: «Дөрес, фәлән фәләнов җизнәсе үлде дип, телеграмма алды. Ул шунда китте. Һаман юк әле», – дип язып җибәргәннәр. «Ышанычлы комсомолец, алдынгы колхозчы» дип өстәргә дә онытмаганнар. Ул гына да түгел, апа белән мәрхүм җизни яшәгән кышлакка барып, әни белән сеңелкәштән һәм ападан да сорау алганнар. Төрле маҗаралар белән бу мәхшәрдән чак котылдым, туганнар. Әллә ничә урынга, кайда булганымны сөйләп йөрмәскә сүз бирдертеп, гомумән, телемне теш артында тотарга тиешлегем турында имзамны куйдырттылар.

Җизнинең кырыгына гына барып кердем апаларга. Ә әниләр инде мине тере килеш күрүдән бөтенләй ваз кичкән булганнар. Әнинең чигә чәчләренә чаклы агарып чыккан, ябыгып, бәләкәйләнеп калган. Шул тәмәке тартырга яратуым аркасында нинди михнәт-маҗараларга талып, якын туганнарыма, бигрәк тә әниемә күпме авырлыклар, кайгылар китердем бит. Юньсезлек инде, юньсезлек. Шуннан бирле авызга тәмәке алганым юк. Төпчеген күрсәм дә, йөрәкләрем әллә нишләп китә. Менә, туган, ул тәмәке тарту нәрсәләргә җиткерде мине, – дип, Яшка абзый Ришатка үзенең моңсу да, бер үк вакытта ничектер шелтәле дә карашын төбәде. Без шулай әсәрләнеп, Яшка абзыйның башыннан үткәннәрен, һәркем үзенчә күз алдына китереп, уйланып, дәшми

генә утырабыз. Көн кызуы сүрелсә дә, беребез дә эшкә кузгалырга теләк белдерми. Яшерен генә ышаныч белән, абзый бу бик мавыктыргыч хикәясен дәвам итсә ярар иде дип көтәбез. Ләкин Яшка абзый дәшми. Шулай хәтсез генә утыргач, ул тамак кырып куйды да:

– Әйдәгез, эшкә, егетләр. Җәүдәт абзыегызның башыннан үткәннәрен тагы бер ай тыңласагыз да бетми, – дип, безне эшкә өнди башлады. Без дәшми генә утыра бирәбез. Мин инде үзем, шабашниклар бригадасының җитәкчесе буларак:

– Ярар, абзый, булмаса, бүгенгә эш торып торыр. Бүре түгел, урманга качмас. Барыбер иртәгә кирпеч белән цемент вәгъдә итмиләр. Булмаса, калган өлешен дә сөйләп бетер инде, – диюне кулай күрдем. Барысы да миннән шушы сүзләрне көткәннәр, ахры, җиңел сулап куйдылар. Һәм барыбыз берьюлы, биш пар күз, «йә абзый, көттермә инде, дәвамы ничек? Ә аннан соң нәрсә булды?» дигән сораулы карашларыбызны абзыйга төбәдек. Аның иреннәрендә нindidер көлемсерәү чалымнары чагылып китте, уң кулын чебен-черки кугандагы кебек селтәп, ярар инде, дигән кебегрәк:

– Әййй... – дип сузыбрак куйды. Безнең карашлардан бөрешебрәк киткән кебек булды. Ялангач аякларына карап алды да «ярар, сөйләсәм сөйлим инде» дигән кебек кулын тагы болгап алды һәм салмак кына итеп: – Күрәсең, минем шулай бер ай югалып торуым әнигә нык тәэсир иткәндер инде. Бер-ике көннән бөтенләй түшәккә ятты. Ничек кенә кыен булса да, әнине апа янында калдырып, авылга сеңелкәш белән генә кайтып кердек. Мин яңадан үз эшемдә эшли башладым. Хаҗи абзый белән Габделхак абзый гына бер көнне идарәгә чакыртып:

– Нәрсәләр җимердең? Нәрсәләр кырдың? Уфадан кеше килеп синең турыда монда бик нык төпченеп сорашып йөрде. Характеристикалар яздырдылар. Әйдә, сөйлә, монда чит кеше юк бит инде, – дип, бик нык кыстагач, Әфганстанда булганны кыстырмый гына сөйләп бирдем. Икесе дә көләләр, миннән кайбер маҗараларны кабат-кабат сөйләтеп, берчә аптырап, берчә бот чабып көләләр. Габделхак абзый үзе дә шундыйрак холыклы, кызык кеше бит. Түрә булса да, гади кешеләр белән һәрвакыт ачык итеп, чын күңелдән сөйләшә.

Шулай эшләп йөргән булам колхозда. Әни тегендә, апаларда бит инде. Без монда. Эш эш түгел, аш аш түгел. Беркөнне сеңелкәш белән кияүләргә барып сөйләштем, киңәшләштем дә әни янына яңадан барырга булдым. Мин бит бердәнбер малай. Әни өчен, үзегез беләсез, без җаваплы. Әти-әнине уллары карарга, тәрбияләргә тиеш, ул безнең мөселманда язылмаган закон. Ир балалар булмаган очракта, йә бүтән сәбәпләр аркасында гына бу бурыч кызларга йөкләтелә. Ә урыс халкында картайган әни-әтине карау бөтенләй юк нәрсә. Анда карт-коры, киресенчә, ашын ашамый, йокысын йокламый балаларын, оныкларын карыйлар.

Кыскасы, өйне бикләп, мал-туарны сеңелкәшләргә куып керттем дә, ял алып, киттем Урта Азиягә әни янына. Язмыш-тәкъдир тарткандыр инде мине.

Бу юлы исән-имин генә, бер маҗарасыз барып җиттем. Тик әни генә бертуктаусыз авырый икән. Кан басымы күтәрелгән, тегесе-монысы дигән булалар. Юлда йөрү хәвефле икәнен дә кисәтеп куйдылар табиблар. Әни инде үз чиратында:

– Ак сөякләрем шушы чит-ят җирләрдә генә ятып калмаса ярар иде. Чит төяк ул – үлгәч тә чит инде. Үзеңнең авыл зиратында, әти-әни, ага-туган кырында ятуга ни җитә дип, көне-төне безнең кәефне кыра. Шулай да мин

килгәч, күңеле күтәрелеп, кәефе шактый яхшырды. Мине күргәч, елап ук җибәрде бит:

– Әй улым, сине көтүләрем, тыным белән тартып алырдай булып ятам. Үземнең очып кына кайтырга юк бит канатларым, – дип, такмаклап елый.

Мин өйдән үзебездә үскән җиләк-җимешләрдән тәмле-тәмле кайнатмалар алып килгән идем. Каен себеркесе белән тау әремен дә онытмадым. Әллә савыгыр вакыты җиткән, әллә минем килүем белән күчтәнәчләр сәбәпче булды – әни күзгә күренеп арулана башлады. Хастаханәдән дә алып чыктык. Шәфкать туташы көн аралаш килеп укол ясарга тиеш иде. Мин апаның йорт-ихатасын төзәтәсен төзәтеп, җыештырасын җыештырып йөрим. Безнең якларда күптән кара көз инде, бәрәңгеләр әллә кайчан базларга салып куелган. Ә монда бездәге җәй азаклары кебек җылы. Барча халык мамык басуында. Урындагы түрәләр төрле оешма, дәваханә халыкларын бернигә карамый мамык җыярга куалар. Шуңа да әнигә укол кадап йөрүче шәфкать туташы бүген килмәде. Бер унбиш көнләп булмый, диделәр. Белгән кешеләр медучилищеның соңгы курс студентларына мөрәҗәгать итеп карарга киңәш иттеләр. Киттем медучилищены эзләп.

Ул бер килмәсә килми икән, студентлар, дәресләре бетеп, әле генә өйләренә таралышкан булып чыкты. Бер кәефсез уйларыма батып кайтып киләм. Юл кырындагы кибеттән бик матур һәм зәвык белән киенгән бер туташ килеп чыкты. Ничектер, чәч толымының атлаган саен әле бер, әле икенче янбашына күчеп тибрәлүе миңа кинәт кенә таулар итәгендә калган Рәхимәне хәтерләтеп җибәрде. Уянып киткән кебек булдым. Башыма мәңге чынга алмас хыялый уй килеп, алдымнан гына Рәхимә китеп барса, нинди шәп булыр иде, дип уйлыйм. Әлбәттә инде бу чибәр үзбәкчә киенгән. Килешле күлмәгенең озын итәге астыннан күренгәләп киткән ялтыр бизәкле чалбар балагы аны тагы да серлерәк итеп күрсәтә. Ә инде нәфис аягындагы ак түфлиенең асфальтта текелдәве үзе бер көй булып колакны кытыклап, йөрәкне җилкендерә. Мин, ирексездән, Рәхимә турындагы хатирәләргә бирелеп, алдымнан гына барган хыялый сыннан күземне ала алмыйм.

Хатын-кыз ир-атның күз карашын йөз адымнан да сизә дип ишеткәнем бар. Бу илаһи зат әллә минем күзәтеп барганны сизде, әллә бүтән сәбәп белән, адымын әкренәйтте. Кызның йөзенә карамый гына узып китәргә булдым. Нигәдер, йөзе гәүдәсе кебек матур булмас кебек тоелды. Гадәттә, күп вакыт шулай була бит. Юк, булдыра алмадым, күземнең кырые белән генә тегенең йөзенә сирпелеп үтәм. Йа Ходаа, бу нәрсә?! Алдымда төннәр буе исемнән чыкмаган Рәхимәм басып тора! Рәхимә шул! Хәтта ирененең өске уң як читенә урнашкан бәләкәй генә миңе дә урынында! Тик киемнәре генә матур һәм кыйммәтлеләр. Мин борылып карауга ул да бераз аптырап китте, бер өздереп тутырып карап, ирен читләре белән генә елмаеп алды да карашын тиз үк читкә борды. Ул да мине күзәтеп килгән икән. Ә мин исәр, танымыйча, игътибар да итмичә үтеп барам. Шулкадәр уңайсыз булып китте.

– Рәхимә, әссәламегаләйкем, – дигән булам. Борылып та карамый, ичмаса. Мин адымымны шәбәйтә биреп, куып җитәргә чамалыйм. Кая ул, туташым бер тыкрыкка борылып кереп тә китте, хәзер инде бөтенләй йөгерә үк башлады. Мин дә йөгерергә тотындым һәм:

– Рәхимә, Рәхимә! Бер генә минутка туктагыз әле! – дим. – Мин бит сезне теге күргәннән бирле һич онытканым юк. Синең хакта кабат-кабат уйлап ничәмә төннәр йокысыз үткәрдем! – дим. Ул борылып та карамый, элдерә генә.

Инде куып җиттем дигәндә, зур тимер капкалы йортның бәләкәй капкасын җәһәт кенә ачып, шунда кереп китте. Мин капка тоткасына килеп тотынуга, эчтән эләктереп бикләп тә куйды. Сизеп торам: үзе теге якта, өйләренә кереп китмәде. Мин җай гына шакып ялынам:

– Рәхимә, ачыгыз әле. Мин бит сиңа начарлык эшләргә уйламыйм. Үземне үлем тырнагыннан коткарган кешеләргә ничек алай эшли алыйм, ди.

Ә Рәхимәм капканың теге ягында мине тыңлап басып тора. Мин хәтта аның еш-еш тын алуына кадәр ишетәм. Дулкынланудан үземнең йөрәк тубырдан тибә, тамаклар кипте. Тагын сүземне дәвам итеп:

– Рәхимә, белергә генә телим, Сәгыйдә апа – әниең ни хәлдә? Абзыйларың ничек? Үзең кайсылай итеп монда килеп чыктың? Син бит теге якта торып калган идең? – дидем дә туктап калдым. Чөнки аның безнеңчә, татарча сөйләшә белмәгәне исемә килеп төште. Вәт ахмак мин. Шулай да, бер сүземне аңламаса, берәрсен аңлар әле дип, дәвам итәм: – Сизеп торам, син татарча бик аңлап бетермисең инде, ичмаса, үзегезчә берәр сүз әйт, – дим тегеңә. Мин шулай аның исемен кабатлыйм да кабатлыйм, һәр җөмлә, һәр сүзгә кушам. Бу исемне шулай кычкырып әйтү миңа шулкадәр рәхәт бер ләззәт инде. Менә бит ул, егетләр, ничек. Моннан берничә ай элек миңа бу исем гади генә булып ишетелсә, әлеге минутта ул дөньядагы бөтен исемнәрдән дә кадерлерәк, якынрак. Тик ул миңа җавап кына бирсен дә, елмаеп тагын бер карасын.

Капка җайлап кына, бармак калынлыгында гына ачылды. Мине серле күзләр кызыксынып кына күзәтәләр.

– Бу мин, Җәүдәт, танымыйсыңмыни? Ышанмасаң, менә кара, капкынга эләккән аякны, – дип, уң аякның балагын өскә күтәреп, яра эзен күрсәтәм. Рәхимә зур кара күзләрен түгәрәкләндереп, хәзер инде капканы киңрәк ача. Мөгаен, минем татарча сөйләгәннәрне аңламый инде дип уйлыйм. Аңлата алмавыма, ә аның мине аңлый алмавына ачуым килеп, үкенечле тавыш белән: – Нишләп һаман аңламыйсың, исеңә төшер. Ничек мин сине татарча сөйләшергә өйрәткәнне, – дим. – Соң, сезнең фамилиягез шулай бит. Әниең Сәгыйдә апа әтисе, ягъни картәтиең белән безнең күрше авылдан чыгып киткәннәр,– дип, хәтта авылның исемен дә әйтәм тегеңә. Юк, аптырап, күзләрен челт-мелт китереп, мине беренче тапкыр күргән кеше кебек карап тик тора.

Йә бөтенләй оныткан бу, йә булмаса, танырга теләми мине. Ә бит теге вакытта әнисе аны миңа кияүгә бирергә дә риза иде. Үзе теге вакыттагыга караганда да матурланып, чибәрләнебрәк киткән. Торганы бер фәрештә. Әгәр дә дөньяның бөтен чибәрләренең чибәрлеген бер кешегә бирсәң дә, барыбер Рәхимәнең матурлыгына җитмәс төсле.

Мин шулай йотлыгып, үземне-үзем белештермичә онытылып, күзләрем белән аны ашыйм, аңа карап торам. Кинәт ул кыюсыз гына, ишетелер-ишетелмәс кенә, әмма саф татарча итеп:

– Гафу итегез, Җәүдәт. Беренчедән, мин сезне белмим һәм тәүге тапкыр күрәм. Икенчедән, мин Рәхимә түгел, – димәсенме! Минем өскә бозлы су койдылармыни! Судан чыгарып ташлаган балык кебек, авызымны бер ачам, бер ябам. Ниһаять, авыз эченнән нәрсәдер мыгырдыйм. Ә ул мине тагы да ныграк аптыратып һәм бөтенләй бутап: – Рәхимә – минем әнием ул, – диде дә, капканы ябып та куйды. Һәм ихаталарына җәелгән ташларга теге миңа таныш көйне текелдәтеп өйләренә кереп китте.

Капка төбендә бераз басып тордым да чәйханәгә юнәлдем. Үзбәкстанда шунысы шәп, урамның теләсә кай почмагында, теләсә нинди борылышында

чинар агачлары, уралып-уралып үскән йөзем куаклары күләгәсендә исәпсез чәйханәләр. Безнең як авыл-шәһәрләренә алар – ят нәрсә. Ә монда алар урамтыкрыкларга бер матурлык өстәп, көнчыгышның кабатланмас бер бизәге кебек. Кайсы гына чәйханәгә керсәң дә: теләсәң, безнең яктагыча өстәл артына рәхим ит; теләсәң, калын-калын паласлар җәелгән, бизәкләп эшләнгән сәкегә аякларыңны бөкләп менеп утыр.

Һәм менә мин шундый чәйханәләрнең берсенә килеп кердем. Баягы хәлләрдән соң аны тыныч кына үтеп китү мөмкин түгел иде. Килеп кердем дип әйтү шартлы гына инде. Ишеге дә, ихатасы да юк. Аяк киемемне салып, асфальтка җәелгән палас буйлап сәкегә таба үтәм. Тезелеп торган ап-ак тешләрен елтыратып, чәйханә хуҗасы мине җитәкләп диярлек каршы ала.

Өстәл артына утырасым килмәде. Сәкенең бер як кырына килеп бастым да, үзбәкләрнең күңеле булсын, мин дә «әссәламегаләйкем»не белэм бит әле дип, кычкырып сәламләп, уң кулымны күкрәккә куеп, башымны иеп, сәкенең аргы башындагы өч-дүрт аксакалны сәламләдем. Моңа аларның чын-чынлап күңеле булып:

– Вай, үзебезнең ул, үзебезнең олан, – диештеләр. Шуннан мин аякларымны бөкләп, ашъяулык читенә утырам. Болай итеп Көнчыгыш халыклары һәм мөселманнар гына утыра ала. Килештергәч килештерергә инде, бабайларга карап, картинәй өйрәткәнчә «Әлхәм» догасын укып, әппәр итәм. Бабайларым миңа ияреп битләрен сыпыралар. Болай кылануымны чын-чынлап ошатып, мине үз табыннарына кыстап-кыстап чакырырга тотындылар. Шунда, Галәветдиннең сихерле лампасыннан чыккан дию пәриедәй, минем һәр ишарәне үтәргә әзер торган чәйханә хуҗасы, колагыма иелеп:

– Олан, аксакаллар чакыргач килешмәс, үпкәләтерсең, – ди. Килешеп башымны кагам һәм аксакаллар кырына күчеп утырам. Картлар бик тә канәгать булып, үзләренең сырланып, кан тамырлары калкып торган ябык кулларын сузып, чиратлашып мине сәламлиләр. Араларыннан иң олысы фатиха укып амин тота. Без аңа иярәбез.

Чәйханәдә көннәр буе гәп сатып, кышлактагы соңгы яңалыкларны энәсеннән җебенә кадәр тикшереп, яшь чакларын искә төшереп утырган картлар бер-берсен бүлдерми, дәрәҗәләрен белеп кенә миңа үзләренең сорауларын бирәләр. Алар татарча, мин үзбәкчә белмим, шулай да бер-беребезне бик мәслихәт аңлашабыз. Менә симез сарык итеннән пешерелгән бик тәмле шулпа китерделәр. Сораулар җәйге яңгыр шикелле бетте дә китте. Картлар да үзләренең алдына килгән эссе пылауны сыпырта башладылар.

Чәйгә дә чират җитте. Ә чәй эчү ул инде ашау түгел. Чәй эчкәндә, Көнчыгышта һәрвакыт җанлы әңгәмә-гәп корыла. Һәм без шушы кагыйдәгадәтне бозмыйча җай гына сөйләшеп утырабыз. Мин үземнең хәлемне, дәрәҗәмне аңлап, аксакалларның сорауларына басынкы гына җавап бирәм. Картлар минем апаны да, мәрхүм җизнине дә яхшы беләләр булып чыкты. Чөнки җизни шушы якларда үскән, әтисе – үзбәк, әнисе – татар иде. Минем нинди хәлләр, нинди хәсрәтләр белән йөрүемне сорашалар. Әниемә ярдәм итәрдәй шәфкать туташы эзләвемне белгәч:

– Бәй, олан, әнә әле үзең чыккан тыкрыкта, шул мәхәлләдә тора да инде бик ипле шәфкать туташы. Әнисе дә элек дәваханәдә эшләде. Хәзер кызлары да шуңарга укый. Яшь булса да бик ипле, акыллы бала, – дип, миңа йорт санын, урамын әйткәч, аптырап куйдым. Чөнки аксакаллар Рәхимә кереп киткән йортны әйтәләр.

Бик җылы саубуллашып, тагын бер очрашырга, аларча әйтсәк, гәпләшеп утырырга вәгъдә биреп, аксакаллар белән аерылышам. Һәм, тимерне кызуында сук дигәнне исемә төшереп, чыгу белән урам буйлап бераз бардым да, чәйханә күздән югалгач, бөтенләй икенче якка борылып киттем. Рәхимәләр тыкрыгына төрле урамнар аша урый-урый яңадан килеп чыкканчы хәтсез генә вакыт үтте. Капкаларын кыюсыз гына бер-ике шакып алдым, ачучы юк. Тукта әле, мин әйтәм, керереңнән алда чыгарыңны уйла. Ул бит бу якларда йорт-кура бер ныгытма-крепость кебек. Койманы балчык белән таш кушып, биек итеп өеп эшләгәннәр. Бездәге кебек җәһәт кенә сикереп керермен, димә. Капка төбеннән аккан арык читендә юан-юан чинар, груша агачлары. Алар күптән утыртылган, төрле якка авышып, ихата-йортларга ятышып ук үскәннәр. Тирә-якка карыйм, урамда кеше-мазар күренми. Мин күп уйлап тормый, авыл малае бит, йортка бөтенләй ятып үскән бер юан гына чинар агачына песи кебек үрмәләп менеп тә киттем.

Өстән барысы да күренеп тора. Ботаклар арасына урнашып алдым да йортны күзәтәм. Рәхимәм күзгә чалынса, аны бер күреп калсам иде дип телим, өметләнәм. Боларның ихата эче, тирә-яктагы ихаталар кебек – урын-җир кысык булганга һәрнәрсә бер-берсенә терәтеп төзелгән. Йорт алдында капкага терәлеп үк җиңел машина тора. Йортка таба таш түшәлгән киң генә сукмак сузылган. Буш урыннарга җимеш агачлары, йөзем куаклары утыртылган. Ишек төбеннән берничә адым читтәрәк тандырдан сыек кына төтен күтәрелә. Мин менеп урнашкан ботак ихата эченә үк бөгелеп төшеп үскән. Ботак астында шифер белән ябылган ниндидер корылма да бар. Түрдәрәк – җәйге сәке-беседка.

Көн кичкә авышты һәм кинәт кенә караңгы төште. Әйтүемчә, ул якларда гел шулай инде. Кояш офык артына яшерендеме, бетте. Кинәт кенә караңгы төшә дә төн була. Өйдә ут алдылар. Тәрәзәләргә челтәр корылган. Шулай да Рәхимә сынына охшаган берәү берничә тапкыр күземә чалынып калды. Менә тандыр кырына бер апа чыгып, пешкән ризыкларны коштабакка салып, өйгә алып кереп китте. Тирә-якка тәмле ис таралды. Үземнең шактый ачыкканлыгымны сиздем. Бу апа, күрәсең, Рәхимәнең әнисе иде. Сыны таныш тоелса да, танырлык түгел. Ачык ишектән төшкән ут яктысы тәмам куерган караңгылыкны җиңә алмый. Мин монсына да канәгать булып, агач башыннан төштем дә өйгә кайтып киттем.

Апа эштән кайткан, үзләре белән бергә мамык җыярга җибәрелгән бер шәфкать туташын үгетләп алып килеп, әнигә укол ясаткан булып чыкты. Әнинең дә хәле шактый гына яхшырган. Безнең белән кичке чәйне эчте. Чәй эчкәндә апа уратып-уратып кына минем алдагы көннәргә уй-фикерләремне белергә тели. Сораштыра:

– Кайчан гаилә корырга уйлыйсың? – ди.

Мин, шаяртып:

– Бу бишьеллык планында әлегә каралмаган, – дигән булам.

Апа:

– Соңга калып кайттың, таныштыра идем үзеңне бик матур басынкы бер хатын белән, – ди.

– Юк. Миңа кызлар да бетмәгән, – дим.

Сизеп торам, апа мине өйләндереп, Үзбәкстанда үзе янында калдырырга тели. Сукмаса да күсәк дигәндәй, һаман да ярдәмче, терәк. Ул үзе генә дүрт баланы аякка бастыра алырмы? Җизнинең туганнары бар да ул, тик алар

үзләре барысы да ишле, һәрберсендә җидешәр дә сигезәр бала. Ә апа һаман шул бер якка каера.

– Монда тормыш җиңел, – ди, – кышның да кыш дисәң хәтере калыр. Кар төшеп, су кәгазь калынлык туңган кышлар бик сирәк. Лычкылдатып кар катыш яңгыр явып, бер-ике атна торса, бик хуп. Февраль аенда ук чәчү чәчәргә, бакча утыртырга керешәләр.

Апа сөйли, ә мин ишетмим. Бер колагымнан керә, икенчесеннән чыга. Башымда, күңелемдә тик Рәхимә генә. Апа, кабыргага төртеп, мине фани дөньяга тартып төшерде дә үпкәләп үк дигәндәй:

– Соң, син мине тыңламыйсың да бит, – ди.

Мин:

– Ишетеп торам, тыңлыйм да инде, – дим.

– Тыңласаң, белеп тор. Монда безнең як түгел. Кызлар аяк астында уралып ятмый. Өйләнер өчен калым түләргә кирәк. Ә ул бик кыйммәт, – ди. – Синең нәрсәң бар? Болай йөрмә, өйләнергә күптән вакыт. Әйтәм бит, менә әле бездә эшләгән хатынның ире былтыр авариягә эләгеп һәлак булды. Бик ипле хатын. Бер баласы бар инде анысы. Яше дә синең чамаларда. Һөнәре дә бик яхшы. Шәфкать туташы. Пермь татары. Үзбәкләр әллә ничә кат яучы җибәргәннәр. Тик үзбәккә кияүгә чыгарга теләми. Гомергә монда каласым юк, – ди. Ял алгач та, йорт-җирләрен сатып, үз ягыма кайтып китәм, дип әйтә. Берәр юньле татар кешесе булса, кияүгә чыгар идем, ди. Аңардан да бигрәк, үзбәкләр, калым түләргә рәтләре булмаса, хатын-кызларны урлап алып китәләр. Шуңардан курка. Таулар арасына алып китсәләр, мәңгегә туган якларыңны күрермен, димә. – Апам сөйли, шулай итеп, теге таныш хатынына өйләнергә кодалый. Апаны үпкәләтмим дип, кырт кисми генә:

– Әле якын араларда гына исәбем юк өйләнергә. Бик кирәк була калса, үзебезнең яктан берәр кәләш алырмын әле, – дим.

– Әйе, теге Шәйбәк кызын әйтәсеңме? Син аларның нәсел-нәсәбен белмисең бит. Алар нәселеннән бөтен хатыннар кияүгә чыккан көе «уф эчем, уф башым» дип, өйдән дә чыкмый эч-башларын бәйләп, мич артында яталар да ирләре йончып үлеп киткәч, терелеп китәләр. Шуннан типтереп яши башлыйлар. Кайдан белгән минем Зәбирәне берничә тапкыр, эш юктан эш булсын дип кенә озата барганны?

Апаның бу турыда туктамый нотык сөйләве туйдыра башлады. Минем тизрәк ялгыз калып, Рәхимә турындагы уй-хыялларга чумасым килә. Һәм мин өйләнергә җыенмавым турында кырт кистереп әйтәм дә бүлмәмә кереп йокларга ятам. Апа барыбер үпкәләде шикелле. Ә минем күзгә йокы керми, уемда бары тик Рәхимә генә. Күрәсең, мәхәббәт дигән нәрсә шушы буладыр инде. Әлегә кадәр авылда күпме генә кызларны озаткалап, билләреннән кочаклап йөрсәм дә, берсе турында да бу кадәр уйлаганым булмады. Зәбирәне әйтеп тә тормыйм инде. Бүген шуны ачыкладым: мин, чынлап та, теге чик аръягында күргән көе үк гел Рәхимәне генә уйлап йөргәнмен ләбаса. Ә аны яңадан очраткач, тагын да көчлерәк, тагын да тирәнрәк хисләр суырып алды. Әйтерсең лә, су әйләнчеге, давыл өермәсе, таудан төшкән кар ташкыны булып, мине күмеп китте.

Йокым йокы түгел, ашым – аш. Кигән күлмәк-чалбарларының, ябынган яулыкларының бизәкләренә чаклы күз алдымда. Тек-тек басып атлаган аяк тавышлары әле дә колагымда бер моң булып яңгырый. Ә тавышы соң, тавышы! Капка ярыгыннан йөрәгемне өттереп карап, мине шаяртырга уйлап, «мин

Рәхимә түгел», ди бит әле. Хәзер бу сүзләр минем күңелдә: «Әйе, мин Рәхимә булам, онытмаган өчен рәхмәт», – дигән кебек яңгырап тора.

Аны очратырга, яңадан чиксез тирән күзләренә карарга хыялланып, турларыннан кабат-кабат үтәм. Капка төпләрен саклап, урамның икенче ягындагы чинар агачын терәп, әллә күпме сакта торам. Гашыйк булып, тәмам акылдан язар хәлгә җитеп, җир белән күк арасында очам. Мин – юләр, мин – мәҗнүн.

Шулай, үземә үзем урын табалмый, кичләтеп кенә тагы теге тыкрыктан урамга килеп чыктым. Шулчакныниләр кичергәнне белсәгез икән, егетләр! Рәхимәм тыкрыкның теге башыннан үзләренең урамнарына таба атлый. Өстендә шул ук күлмәк, яулыгы гына икенче. Өйләренә җитеп килә, икебезнең ара шактый. Урам тутырып кычкырып та булмый, кешеләр бар. Кычкырырга да булыр иде, ләкин мин оялам. Өйрәнелмәгән дә. Безнең якта урамда кычкыру тәрбиясезлеккә керә бит. Ә монда алай түгел. Кышлакның бер очында яшәгән үзбәк, кемгәдер берәр хәбәр әйтергә булса, яки кунакка чакырса, урамда күренгән кешегә әйтә: фәлән-фәләнгә шул-шул хәбәрне әйт, безгә кунакка килсен ди. Тегесе үз чиратында икенче кешегә кычкыра. Шулай итеп, хәбәр ике-өч минутта ун-унбиш кеше ярдәмендә бөтен кышлакны урап, тиешле кешесенә барып җитә. Менә шундый үзенә күрә чыбыксыз телефон. Моңа бер кеше дә гаҗәпләнми. Ә мин тордым да йөгердем. Рәхимә кереп киткәнче бер-ике сүз әйтергә исәп, һич югы хет бер тутырып, күзләренә карап алырга иде. Юк, өлгерә алмадым, никадәр тырышсам да, булмады. Минем йөгергәнне Рәхимә шәйләп алды да адымнарын тизләтеп, кереп тә югалды. Мин, тыным бетеп, капканы этәреп карыйм – бикле. Сак кына шакыйм – җавап юк. Сизеп торам, капка артында ул да басып тора, мине тыңлый. Мин тагын әкрен генә:

– Рәхимә, нигә бу кадәр миннән качасың? Сиңа һичнинди начарлык кылырга теләмим. Бу мин – Җәүдәт, – дим. Һәм, бөтен кыюлыгымны җыеп, тегеңә ап-ачык итеп: – Курыкма, тегендә булганны син беләсең дә мин беләм. Шикләнмә, бу турыда һичкем белмәс, – дим.

Бернинди дә җавап юк. Капка тоткасын тагы бер-ике тартып карадым да, теге көнне менгән агачка үрмәләдем. Күз кырые белән булса да, күреп каласым килә үзен. Рәхимә, чынлап та, капкага арты белән сөялгән дә урамда нәрсә булганын тыңлый. Мин аны иркенләбрәк күрү теләге белән, йортка сузылып үскән ботак буйлап алга үрмәлим. Мине Рәхимә дә күреп калды. Берчә аптырап, берчә куркып, капкадан читкәрәк китеп басты да ярым пышылдап:

– Хәзер үк кире төш! Кеше-мазар күрсә – оят! Әниләр сизсә, нәрсә әйтерләр? Күршеләр алдында хурлык! Хәзер үк төшеп кит! Югыйсә, абыйны чакырып чыгарам. Кирәгеңне бирер. Мине оятка калдырма берүк! – дип, ике битен каплап, еларга ук кереште. Минем, әлбәттә, кадерле кешемә кыенлык китерәсем килми. Кире борылып төшәргә чамалыйм. Өй тәрәзәсеннән дә мине күреп калдылар шикелле, ашыга башладым. Саксызрак кыландыммы, аягым ычкынып китеп чак аска очмадым. Гәүдәм белән асылынып калуын калдым да ул, тик ботак кына минем мондый кискен хәрәкәттән шартлап сынды. Шифер ябылган каралты түбәсенә дөбер-шатыр барып төштем. Шиферлар шарт-шорт сынып, эчкә үк мәтәлдем. Тавык абзары икән. Китте тавыш, китте тавык-әтәчләрнең чыркылдап-кытаклавы – бөтен дөнья яңгырый. Шул чагында аңладым: тавык кытаклавыннан да ямьсез тавыш юктыр бу дөньяда.

Рәхимәм өйләренә кереп югалды. Ул да түгел, ике таза ир кулларына таяк тотып, тавык абзарының ишеген ачарга чамалыйлар. Абзар дип, абзар да

түгел инде, тимерчыбыктан үреп эшләнгән челтәр. Арттарак басып торган абзый, Рәхимәнең әтиседерме, үзбәкчә нәрсәдер сөйли, мине әрли. Хәлләр мөшкел. Шүрләп, нәрсәдер мыгырданып абзыйга дәшәм. Алар мине ишетми, күзләрендә ачулы утлар елтырый. Болардан миһербан көтмә. Ниһаять, кетәк ишеге ачылып китте, тегеләр миңа чыгарга куша. Куркып карышам һәм чыкмыйм. Чак телгә килеп:

– Абзый, әкә, – дим, үзбәкчәне исемә төшереп. – Әкә, мин явызлык белән түгел, ялгыш егылып төштем, – дим. Шунда өйдән бер хатын-кыз чыгып, бусагадан кул болгап кычкыра:

– Татар кешесе, ахры? Сезне аңлыймыни ул, – ди. Шунда гына теге ирләр бераз сүрелә биреп, шулай да, таякларын уйнатып, хәзер инде татарча:

– Чык, чык, карак! – диләр.

Минем батырчылыгым җитми. Аптырап өскә карыйм. Әһә, бу тавык кетәге өстенә менеп алсам, койма аша сикереп урамга чыгып качарга була, дип уйлыйм. Минем уемны аңлап, ирләрнең яшьрәге яныма керергә чамалый. Күп уйлап тормый, абзар түбәсенә үрмәләп менә башладым. Теге җәһәт кенә абзарга килеп керде дә аяктан тартып төшерде, сыртка бер-икене тамызып та алды. Ярый әле көч белән кизәнеп суга алмый, абзар тар һәм тәбәнәк.

Ихатада шау-шу кинәләр. Бер-бер артлы эреле-ваклы балалар тезелешеп чыкты. Бер әби дә күренде. Картаеп беткән бер кортка инде, таягына таянып, кояш булмаса да, кулын маңгаена куеп, безнең якка карап нәрсәдер кычкыра:

– Нәрсә булды, балалар? Нигә шау-шу киләсез?

Теге абзый:

– Менә бер угры тавык абзарына килеп кергән, шуны эләктердек.

Ул арада өйдән Сәгыйдә апа килеп чыкты. Аны шунда ук танып алдым. Апа килеп, ирнең колагына нәрсәдер пышылдый. Яшь ир мине җилтерәтеп, алар алдына китереп бастырды да, усал гына итеп:

– Бу каракны нишләтәбез? – диде.

Теге абзый, минем иелгән башны күтәреп, күзләремә карап, татарча дәште:

– Йә, егет, сөйлә, син кем? Кайдан килдең?

– Мин шәфкать туташы диебрәк килгән идем. Әни авырый, аңарга укол ясарга иде. Бөтен табиблар мамык җыярга басуга киткәннәр.

Абзыем көлемсерәп тирә-якка карап алды да:

– Шәфкать туташлары агач башында буламы да, тавыклар яба торган шушы читлек эчендә буламы? – ди. – Югыйсә кыйнап ташласалар да, бер сүз әйтә алмыйсың. Милиция чакырсалар, тагын да яманрак булачак. Аннан исбатла үзеңнең дөя түгеллегеңне.

– Чәйханәдәге картлар шушы йортта шәфкать туташы яши, дигәннәр иде. Мин капка шакыдым. Әнә кызыгыз капканы ачып карады да мине тыңлап та тормыйча элеп куйды. Аптырагач, агач башына менгән идем шул. – Тавык йонына баткан чалбар балакларымны сыпыргалаган булам. Сәгыйдә апам кыюсыз гына тавыш белән:

– Ә нигә соң ул шәфкать туташы кирәк булды? – ди. Мин Сәгыйдә апаның мине тануына тәмам шигем калмыйча, шулай да тотлыга-тотлыга, апаның күзләренә туры карарга тырышып:

– Мин сездә дәваланып ятканда, әни минем өчен бик борчылып авырып киткән. Хәзер бераз аруланды арулануын, әмма көнаралаш уколлар ясап торырга куштылар, – дим. Ул:

– Сез, туганым, нәрсәдер бутыйсыз. Безнең хастаханәдә беркайчан да

дәваланмадыгыз. Нишләптер хәтерләмим дә, – ди. – Дөрес, минем ялга киткәнемә дә хәзер өч ел булды инде, – ди.

Мин чынлап торып болар теге якта яшәгәннәрен яшерәләр, дип уйладым да сүзне бүтән якка борып:

– Шул хастаханәдә инде, сезгә бик тә охшаган апа бар иде, – дип куйдым. Ә зиһенемне «теге чакта апа карарак, олырак күренә иде, битләрендәге җыерчыклары да тирәнрәк һәм күбрәк төсле иде шикелле» дигән уй бораулый.

Тавыклар бераз басылдылар. Миңа карап шашып өргән бияләй зурлык кына эт тә тынычланды. Абзыем исә миннән чын-чынлап сорау алу оештырды. Кем мин? Кайдан, кемнәргә килгәнмен? Кем булып эшләвемә кадәр сораша. Мин эшнең болай зурга китми генә басыла баруына шатланып, алдашмый гына җавап бирәм.

Бу якларда безнең халык, ягъни татарлар укмашып бергә яшиләр. Бер-берен беләләр, бер-берсе белән кунакларга йөрешәләр. Үзара ярдәмләшеп, тату яшиләр. Шуларны уйлап, күңелемне бераз тынычландырырга тырышам. Җитмәсә, мәрхүм җизнәм бу абзый белән кайчандыр бергә эшләгәннәр дә булып чыкты. Шунысы бик тә гаҗәп тоелды: бусагада кулларын маңгаена куеп, безне тыңлап торган теге кортка:

– Кем, кем буласың? Кайсы авылныкы, дисең? – дип, кат-кат сораша. Һәм күрше авылдагы берничә карт әбине, мин бәләкәй чакта ук үлеп, мәрхүм булган бабайларны да белә булып чыкты. Әбием, таягына таяна-таяна җитез генә бусагадан төшеп, безнең янга килде дә битендәге җыерчыклары эченә кереп яшеренә язган кап-кара үткер күзләре белән мине тишеп-тишеп карарга кереште. Үзе: – Алай, алай, кхым-кыхым, алай икән, – дип кабатлап-кабатлап алды да кинәт кенә: – Үзебезнең кеше шикелле, шуңа охшаган, алдамаса. Чәйгә чакырыгыз, – ди.

Минем һәр кыймылдавымны дикъкать белән карап, кискен хәрәкәт эшли калсам, сугып егарга торган ирләр аптырап калды. Алар минем урыным капканың теге ягындагы арыкта икәнен әбигә аңлатырга тырышалар. Әби үз сүзендә нык тора:

– Капка аша керә белмәсә дә, кунак бит, – ди. – Әйдәгез, оланнар, чәйләп алырга вакыт. Әйдә, кызым, әйдә, кунакны да алып кер өйгә, – ди.

Нинди хикмәт, нинди могҗиза! Шулай итеп, Сәгыйдә апа белән Вахит абзыйлар өендә, уңайсызлыктан кызарына-бүртенә, чәйләп утырам. Безгә чәй ясап эчергән Сәгыйдә апа Рәхимәгә әйләнгән. Ә кызның исеме Сәгыйдә булып чыкты. Кыскасы, болар исемнәрен алышканнар. Бу хәл мине үтә аптыратса да, сер бирмим. Табындагы нигъмәтләрдән авыз иткәлим. Үзем күз кырые белән генә теге якны күзәтәм. Эреле-ваклы балалар апа белән абзыйның оныклары икән. Ә теге ир аларның олы уллары булып чыкты. Карт әби, апаның әнисе булып, алар бер-берсенә бик охшаганнар. Һәм әбием бертуктаусыз сораша. Тирә-яктагы урман-таулар, басу-чокырларның барысы турында да хәбәрдар. Әллә кемнәрне, әллә кемнәрне белеп, барысын да төпченә. Сер бирмәсәм дә, дулкынланудан кул-бармаклар сизелер-сизелмәс калтыранып алалар. Үч иткән кебек, чәй чайпалып китә, йә калак, чынаякка бәрелеп, яман нык яңгырый. Бер дә булмаса, кулга тоткан йөзем-хөрмәләр бармак араларыннан ашъяулыкка коела. Шулай да, тырыша торгач, ике касә чәйне яна-көя чак эчә алдым. Ә үзем бертуктаусыз аларда үзем хакында уңай фикер калдырырга тырышам. Бу – үзе бер әйтеп бетермәслек җәза.

Рәхмәтләр әйтеп һәм юкка комачаулаганым өчен гафу итүләрен кабат-кабат

үтенеп, кайтырга кузгалам. Тышта күптән караңгы төшкән. Абзый белән апа озата чыктылар. Тик Рәхимә генә башкача күренмәде. Күзләрем белән күпме генә эзләсәм дә, ул юк. Йөрәкне алдап булмый, сизәм, ул да мине кайдандыр күзәтә. Кайдан, кай төштән? Соңгы тапкыр тәрәзәләргә күз йөртеп алам. Анда да күренми, тик бер тәрәзәдә генә ут яктысы юк. Минем шигем калмады, ул мине шуннан карап тора дип уйлыйм. Мине озата. Шулай булсын иде дип, ышанасым килә һәм мин шулай уйлыйм да.

Болай соңлап кайтуыма апа ачуланып алды:

– Монда кешеләр югалгалап тора, энем. Син чамалап йөре. Беркемең дә юк. Тауларга алып китеп, сарык көтәргә илтеп салырлар, йә булмаса, калган гомереңне арыктан су ташып үткәрерсең. Алай соңга калып йөрмә бүтән, мине куркытып, – дип, күңелгә шом салып куйды.

Шулай ике көн үтеп киттеме-юкмы, ял көне иде. Мин мондагы гадәт буенча базарга чыгып әйләндем дә ниндидер эшкә тотындым. Апа, эшне бүлдереп, мине табынга чакыра. Килеп керсәм, табын артында Рәхимәнең әнисе утыра. Эсселе-суыклы булып киттем. Миннән адресны кабат-кабат юкка гына сорамаган икән. Үзе белән төрле-төрле дару-уколлар алып килгән. Күп еллар хастаханәдә эшләгәч, барысын да белә. Әнине күреп, сөйләшеп, менә чәй эчеп утыралар икән. Чәйләр эчелеп, дару-уколларны ничек кулланырга икәнен тагын бер кабатлагач, апа кайтырга кузгалды. Мине сискәндереп, кинәт үземә аерып кына:

– Булмаса, Җәүдәт туганым, мине әзрәк озатып куйсаң, әйбәт булыр иде. Үзеңә генә әйтәсе сүзләрем дә бар, – ди.

Мин инде шатланып риза. Үземчә уйлыйм: тиккә генә түгел. Кызларыннан берәр хәбәр бардыр.

Апа белән тын гына барабыз. Ниһаять, апам арык күләгәсендәге урындыкка утырырга тәкъдим ясый. Тамагын кыргандай итеп:

– Җәүдәт туганым, син мине аңларсың дип уйлыйм. Бер дә акылсыз кешегә охшамагансың, – дип сүзен башлады. Шунда ук апаның ни әйтәчәген сиземләп, шөбһәләнеп киттем. Йөрәгем күкрәк читлеген сындырырдай булып, иреккә чыгарга теләгән ат кебек тарсылдап тибәргә тотынды.

– Син, Җәүдәт улым, Сәгыйдәне бимазалама. Иң яхшысы, оныт син аны. Кыз баланың күңеленә откы салып йөрмә. Миңа инде, әни кешегә, болай итеп йөрү килешеп тә бетми. Сәгыйдәнең ярәшкән егете бар. Калымы яртылаш түләнгән. Үтенеп сорыйм, туганым. Укыган җиренә дә барып йөрмә. Бу Урта Азия бит, Рәсәй түгел. Кыз баланың бер даны чыкса, яхшы түгел. Синең белән улларым һәм ирем сөйләшергә теләгәннәр иде дә, үзем тыйдым. Туганым, син ипле, яхшы егетсең, күреп торам. Шулай булгач, үзеңә тиясе, үзеңә охшаган кызларны табарсың әле, – дип әйтеп салмасынмы! Башыма күсәк белән китереп тондырдылармыни! Мин зиһенемне җыйганчы безнең янга яшел «Жигули» килеп туктады. Апа җәһәт кенә машинага кереп утырды. Руль артында Вахит абзый иде.

Мин инде:

– Теге вакытта Әфганстанда чакта кызыгызны миңа бишкуллап бирергә риза идегез. Бу якка чыккач нигә карышасыз? – димәкче булып ачылган авызымны да ябарга өлгермәдем, машина күздән югалды.

Менә шулай хәлләр... Озак утырдым ул көнне арык буенда.

Төне буе уйланып, барысын да исемә төшереп яттым. Кызны беренче тапкыр күрүем, яңадан очрашуыбыз, урам чатында кача-поса артыннан күзәтеп

баруларым – һәммәсе дә кабаттан күзалдыма килеп басты. Тик шунысы аңлаешсыз: ничек алар бу кышлакка килеп урнашканнар да, нишләп Рәхимә белән Сәгыйдә апаның исемнәре алышынды? Теге тәмәкене тартканнан соң зиһенем чуалып, үзем бутадыммы әллә, дип тә уйлап бетердем. Бер сер иде бу. Аңлый да, чишә дә алмаслык олы сер иде.

Ә йөрәк яна, малайлар. Минем газап, минем кичерешләремне үзе яратып караган кеше генә белә. Мәхәббәт дигән нәрсә ул шул кадәр татлы, шул кадәр газаплы, шул кадәр әче, шул кадәр буй җитмәслек биек һәм шулкадәр алдаткыч бер хыялый нәрсә... Менә-менә аның асыл сере ачылыр, менә-менә тәмен татып карармын дип көтәсең, тилмерәсең. Ул сине ымсындырып алдыңда гына тора. Кулыңны суз да ал. Ә юк, булмый. Чүлдә сусызлыктан үлеп барганда офыкта күренгән рәшә кебек алдап, синнән ерагая да ерагая. Ул ерагайган саен синең йөрәк уты көчәйгәннән көчәя. Сине көйдергәннән көйдерә.

Апам миңа эш тә тапты. Кышлактан ерак та түгел мамык фабрикасына шофёрлар кирәк икән. Шунда урнашырга кодалый. Барып карадым, киләсе атнага гына килергә куштылар. Дөресрәге, бер юан гына үзбәк – гараж түрәсе – минем татар икәнемне белгәч, ачыктан-ачык әйтте:

– Сез, татарлар, күп беләсез һәм бик буйсынып бармыйсыз. Миңа – буйсынып баш игән кешеләр кулайрак. Киләсе атнага кеше таба алмасам, килеп карарсың. Тик миңа берсүзсез буйсынсаң гына эшкә алам. Тәүге эш хакың минеке, – диде.

Шул көнне үк эшкә алмаганнарына шатландым гына. Бер айлык эш хакын да үзбәккә бик бирәсем килеп тормый әле. Шуннан, тагын бер тапкыр Рәхимәне күреп, үзе белән сөйләшеп карау теләгем дә бар. Йөрәгем сизә: ул да каршы килмәс кебек. Әзрәк шикләндерә дә. Ни дисәң дә чит як, чит җир.

Аны барыбер училище капка төбендә туры китердем. Очрашырга өметләнеп йөрсәм дә, кинәт кенә алдыма килеп баскач, югалып калдым. Күзләренә туп-туры тутырып карап тик торам. Ә күзләр соң, күзләр... ох... сөйләп аңлатырлык түгел. Ул дәшми, мин сүз таба алмый җәфаланам. Аның оялудан бит алмалары кызарып чыкты. Чү, алсу иреннәрен дерелдәтеп-селкетеп нидер пышылдый түгелме? Ирене өстендәге миңенең селкенүеннән генә аңлап алдым. Тик озакка бармады бу татлы мизгелләр. Яныбызга кара шәүлә булып абзасы килеп басты, сеңлесенә ымлап кына китәргә кушты. Рәхимә башын иеп, шәп-шәп атлап китеп барды. Ә абзасы, минем якадан эләктереп алып дер селкетте дә, ысылдап, ачу белән:

– Нәрсә, якташ, аңламадыңмы һаман? Әллә аңларга теләмисеңме?! Сиңа әйтмәделәрмени? Оныт Сәгыйдәне! – дип, китереп торып эчкә берне ямады, малай. Ярый әле шундый киеренке чакларда эч-корсак мускулларын катырып тота торган гадәтем бар. Сугуы да күкрәк авызына туры килмәде. Йодрыгы ару гына. Алай да, сугыша-нитә калсак, бирешерлек түгелмен. Әзрәк чамасын беләбез. Каршы сукмадым. Яңакка бер-икене эләктергәндә дә түздем. Ул хаклы. Чөнки ул сеңлесенең намусын яклый, аның исеменә тап төшермәс өчен тырыша. Шулай бер-икене суккалап, кирәге беткән әйбер кебек, күкрәктән этәреп җибәрде дә: – Кыскасы, бүтән минем күзгә чалынма! Аңладыңмы? Килмешәк... – ди. Барысына да түздем, ә менә килмешәк дигәненә түзмәдем. Ачу белән:

– Монда син үзең кем? Шуны беләсеңме? – дим.

– Ә мин шушында туып үскәнмен, – диде дә сөйләнә-сөйләнә машинасына таба атлады. Ә мин артыннан:

– Алайса син икеләтә ахмак! – дим.

Кире борылып килергә исәбе бар иде дә, тик сеңлесе җиңенә ябышып туктатты. Алар машинага утырып китеп тә бардылар. Борылып килсә, Рәхимәнең абыйсы дип тормый идем. Билләһи дип әйтәм, сугыша идем үзе белән. Ныклап, канга тузганчы.

Алар китте. Ә минем гарьлектән күзләремнән яшь бәреп чыкты. Мине Рәхимәм алдында шулай мыскыллап, кимсетеп китсеннәр инде. Кем-кем, абзасы бит әле. Йодрыклар һәм тешләр, үзләреннән-үзләре кысылып, чатыр-чотыр, шатыр-шотыр киләләр.

Белмим, холкым шулаймы, әллә мине шулай итеп тәрбияләгәннәрме, каршылык, киртәләр очраса, аннан да бигрәк, берәрсе юлыма, эшемә каршы төшеп булашса, үҗәтләнәм дә китәм, шул эшне җиренә җиткереп бетергәнче эшләргә тырышам, бөтен сәләтемне, бөтен белем-осталыгымны шуңа багышлыйм. Бөтен дошман-кара көчләргә үч итеп тырышам. Теге, кем әйтмешли, җәймә булып җәелергә, чакматаш булып очкынланырга да ризамын үз дигәнемә ирешер өчен. Мондый чакта көчем артып, икенче сулышым ачыла, һәм зиһенем, теләгемә ирешер өчен, алдыма чиксез күп төрле юллар ачып сала. Монда да шулай булып чыкты. Рәхимәне болай саклап йөртә башлагач, мин яңадан кабынып киттем. Мәхәббәтемнең уты тагын да ныграк, тагын да ләззәтлерәк итеп яндыра башлады. Мәхәббәтемнең күзгә күренеп бәһасе артты. Мине әйтерсең дә күзгә күренмәс ниндидер бер илаһи көч сөйгәнем өчен көрәшергә чакырып, биектән, җиһаннан күзәтеп, юл күрсәтеп, үзе идарә итә төсле тоелды.

Төн йокыларымны йокламый төрле уй-планнар корам. Аның белән булачак очрашуымны кат-кат күз алдыма китереп, аның белән сөйләшәм. Нинди сүзләр әйтергә, кулларын ничек тотарга, күңелемнән кабат-кабат күнекмәләр ясыйм. Хәзер инде таң яктысыннан ук аларның өй тирәсен күзәтәм. Укырга киткәндә туры китерергә чамалыйм. Юк, очратып сөйләшергә һич форсат табылмый, мөмкин түгел. Иртән абыйсы машина белән укырга илтеп куя һәм төштән соң укыган җиреннән барып ала.

Мәхәббәт дигән нәрсә без, ирләрне, бөтенләй җүләрләндерә бит ул. Ул тыкрыкта мин менеп утырмаган чинар агачлары калмагандыр инде. Әле уйлап карыйм да оят булып китә. Егерме өч яшьлек җиткән егет агач башында утырсын инде.

Менә бүген дә җәһәт кенә бер агач ботагына менеп урнаштым да тегеләрнең йортларын күзәтәм. Исәп – ничек тә Рәхимәне күреп, аның игътибарын җәлеп итәргә. Кесәдә язган хат та бар. Янәсе дә, ул ихаталарында күренсә, сызгырып, йә дәшеп игътибарын җәлеп итәм һәм бәләкәй генә ташка бәйләнгән хатны аңа очырам. Юк бит, күренми генә әй. Әтисе белән әнисе машиналарына утырып каядыр чыгып киттеләр. Бераздан матур-матур бизәкле шәлъяулык ябынып, картәниләре дә, таягын тукылдатып, алпан-тилпән атлап, урам ягына атлады. Ә мин, тиле, кунакчага кунган әтәч кебек утыра бирәм, аяклар, ботлар әрни башлады, арыдым. Тегеләй дә болай да боргаланып карыйм. Юк, егетләр, түзәр әмәл калмады. Тыкрыкта кеше-мазар, бала-чага юклыгыннан файдаланып, җиргә сикереп төштем дә капка төбендәге урындыкка утырдым. Ул да булмый, тыкрыкның теге башыннан Рәхимәнең картәнисе килеп чыкты, сырлап эшләнгән матур таягын тукылдатып килеп тә җитте. Мине танып туктап калды. Күптәнге танышын күргән кебек ике кулын сузып исәнләште һәм кинәт кенә, тавышын үзгәртми генә:

– Сәгыйдәне көтәсеңме? – дип сорап куймасынмы? Мин, көтелмәгән сораудан аптырап, берчә каушап, телемне чак әйләндереп:

– Әйе, – дип әйтә алдым.

– Әй... тормыш. Безнең дә яшь чаклар бар иде, – әбием дә яшь чагын искә төшереп уфтанып алды. Һәм җай гына баягы сөйләшкән көйгә дәвам итте: – Син, олан, юкка Сәгыйдәне бимазалап йөрисең. Үзең ипле генә кешенең баласы күренәсең. Уйлап кара әле, торырга урының да юк бит, балам. Тәүдә шуны хәстәрләр идең. Апаңның да берсеннән-берсе кечерәк дүрт бала. Аларны да карап үстерешергә, ярдәм итәргә кирәк. Юк уй белән, балам, юк уй белән йөрисең. Ни эшлисең бит, язмышка буйсынырга кирәк, ничек кенә газаплы, ничек кенә кыен булса да, – дип, әбием җайлап кына тезә дә тезә. Әллә миңа сөйли, әллә үзалдына сөйләнә. – Бер мәхәббәт белән генә яшәп булмый бит. Ул, өйләнешкәч, олан, ябынырга юрганы да кирәк, ашарга ашың булса, аны ашар өчен кашык-тәлинкәсенә кадәр кирәк. Ә синең нәрсәң бар? – дип, шундый җай гына, үзәккә үтәрлек тавыш белән суза бит бу. Мин дә, җаен туры китереп, әбием тын алган арада, аның көенә чамалабрак:

– Авылда әле өем бар, торырлык. Мал-туар да бар. Үзем колхозда эшлим. Акчасы да ару гына төшә. Яңа карагай өй дә салырга исәп бар, – дигән булам.

– Анысы, өең булуы әйбәт. Йорт-җиһазсыз булмый тормыш көткәндә. Тик, улым, без бердәнбер кызыбызны андый еракка җибәрмибез. Ул шушы кышлакның аргы төбәгендә яшәгән бик ипле кешеләрнең улларына ярәшелгән. Үзебезнең татарлар. Укып бетергәнен генә көтәбез. Иншалла, киләсе язга укып бетерә кызыбыз.

Шулай әби белән сөйләшеп утырабыз. Әби үз фикерләрен, өй эчендәге хәбәрләрне сөйли. Мин дә үземнең лаеклы кияү икәнлегемне исбатларга чамалыйм. Тик әбинең кире каккысыз дәлилләренә очрап, минем исбатлауларым пыяла кебек челпәрәмә килеп ватыла торалар. Мине бик акыллы-акыллы итеп үз урыныма утырта да куя. Шуңа да җен ачуларым килә.

– Яратуың әйбәт. Анысы синең файдага. Тик менә синең бит нәсел-нәсәбеңне, туган-тумачаңны белмибез, балам. Синең бит монда апаңнан башка кемең бар? Беркемең юк, ә монда туган-тумачасыз яшәве бик авыр. Бигрәк тә синең кебек яңа килгән кешегә. Укуың да чамалы. Әнә, безнең гаиләдә Вахит кияү дә укыган, Рәхимә кызым да, Аллага шөкер, вакытында укыды. Менә Сәгыйдә оныгым да укып чыга, Аллаһы боерса, – дип әйтеп ташламасынмы.

Мин кайныйм. Бигрәк тә карчыкның Рәхимәмне Сәгыйдә диюенә. Болар барысы да сүз куешканнар дип уйлыйм. Минем йомшак җирем – укуыма кагылуы – монысы инде чиктән ашкан нәрсә. Әйе, уку ягыннан безнең чамалырак анысы. Бу сүзләре боларның кызларын укыту өчен исемнәрен алыштырып Әфганстан хәтле Әфганстаннан монда – Үзбәкстанга чыгуларын исемә төшереп җибәрде. Безнең нәсел укудан бик алдыра алмаса да, эш ягыннан укыганнарны биш тапкыр бөкләп салабыз. Һәм укыганнардан бер дә ким яшәмибез. Эш ягыннан безнең фамилия җен белән бер, ару-талуны белмибез һәм башлаган эшне ярты юлда калдырган юк. Әбинең уку турында төрттереп алуы минем йөрәккә ук булып кадалды. «Беткән баш беткән, кызларын барыбер миңа бирмәячәкләр. Булмаса, куркытып, нервыларын какшатып булса да алыйм әле!» дигән ниндидер бер кыргый, явыз уй килде. Аннан да бигрәк, күңелемнең иң тирән, иң караңгы почмагында «әллә шулай итсәм, боларны сындырып булмасмы» дигән бик бәләкәй генә ышаныч та ята бит әле, шайтан алгыры. Тоттым да:

– Әйе, әби, бик матур сөйләдегез. Ә бит теге якта, ягъни Әфганстанда сез анда юк идегез, анысы дөрес. Кызыгыз – Сәгыйдә, ә оныгыгыз Рәхимә исемле иде. Нинди матур итеп, татарчаны күптән оныткан булып кыландылар алар, – дип, әбинең үзе кебек сузып, әкрен генә сөйләп алып киттем. – Ә бит Рәхимәнең исемен Сәгыйдә апаның мәрхүмә булган сеңлесе хөрмәтенә кушканнар. Әле килеп, нинди матур итеп алдашып утырасыз. Әби кешегә килешми, бер дә килешми. Җитмәсә, Коръән аятьләре, догалар укыган булып, амин тотып, бит сыпырасыз. Мине белми, дисезме? Барысын да беләм. Рәхимә белән Сәгыйдә апа гына мине оныткан булып кыланалар. Беләсегез килсә, әбием, аларның теге яктагы фамилияләре Ибраһимовлар, ә бабайның исеме Закирҗан булган, – дигән булам. – Монда чыгып, фамилия үзгәртеп, исем алыштыру белән кеше белмәс, дидегезме? – дим, үзем астан гына тегене күзәтәм. Белми бу бала дип уйламасыннар. Ишеткәнем бар, чик буенда яшәүчеләрнең туганнары теге якта да була. Шушы хәлләр искә төшкәч, боларның Әфганстан ягыннан чыгып йөрүләренә һичнинди шигем калмады. Һәм мин дәвам итәм: – Закир бабай күптән түгел генә мәрхүм булган. Оныгыгыз Рәхимә белән каберенә барып дога кылган идек. Бабайның рухы сиңа сәлам әйтте, – дип, тавышыма серле төсләр биргән булам. Тагын да нәрсәләрдер әйтергә авызымны ача гына башлаган идем, әбием бөтен гәүдәсе белән борылды да, тәүге тапкыр күргәндәй, миңа текәлде.

– Кем, кем дисең, улым?

Бераз шикләнеп һәм икеләнебрәк:

– Ибраһимов Закирҗан бабай рухы сәлам әйтте, – дим.

Шушы сүзләрдән соң әби бер аклы-күкле булып, бер бурлаттай кызарып китте дә урындыкка бөтенләй сузылып ук төште. Сизеп торам, арттырыбрак җибәрдем шикелле. Әбием күм-күк иреннәрен берчә ачып нәрсәдер әйтергә әйтә, берчә тирән-тирән итеп тын алырга чамалый.

Коелып төштем, чөнки әбием күгәренеп катып бара. Нишләргә дә белмим, күз алдымда җан биреп ята түгелме? Аптырап, арыктагы су бик таза булмаса да, учлап алып, битенә сибәм. Ниһаять, күзләрен ачып җибәрде. Мине танымый, танымый гына түгел, мине күрми дә, ишетми дә. Чак башыма барып җитте: «ашыгыч ярдәм» чакырырга кирәк. Бүтән чакны урам тутырып миңа комачаулап чым-чыкыр йөргән бала-чагалар да әллә кая кереп беткән. Урамда берәрсе күренсә, ичмаса. Таныш капканы шакырга, дөбердәтергә тотындым. Юк, ачмыйлар. Ниһаять, көттереп кенә Рәхимә капка төбенә килде:

– Кем анда? Нигә шулкадәр капка ватардай итеп дөбердисез?

Мин тотлыга-тотлыга:

– Рәхимә, ач капканы. Әбинең хәле харап! Ярдәм күрсәтмәсең, үләргә мөмкин! – дим.

Рәхимә капканы чак кына ача бирде.

– Инде нәрсә уйлап таптың? Әйттеләр бит сиңа, башкача килеп йөрмә дип! – Һәм чиксез тирән сихри күзләре белән усал итеп яндырып бер карады да капканы шап ябып та куйды. Тагы дөбердәтәм, бикләп куймасын дип, капканы этәрәм, Рәхимә капкадан башын тыгып карады да картәнисен күреп, йөгерә-атлый безнең янга килеп җитте. Агарынып, каушап китте.

– Тизрәк, тизрәк өйгә алып керергә, тыныч урынга яткырырга кирәк, – ди. Күп уйлап тормадым, кибеп, бала-чага авырлыгында гына калган әбине җиңел генә күтәреп алдым да өйгә атладым. Рәхимә минем янәшәдән, әбинең башы

салынып төшмәсен дип, ярдәмләшеп бара. Рәхимәнең тән җылысын сизеп, аның чәчләренең битемне кытыклавы ләззәтенә күмеләм.

Әбине өйнең бер бүлмәсендәге агач караватка салабыз. Рәхимә тиз-тиз генә кан тамырына укол салды. Йөрәген тыңлап, кан басымын үлчәде. Мине әби янында калдырып, күршеләргә кереп «ашыгыч ярдәм»гә шалтыратырга да өлгерде.

Ул үзе елый, үзе, ярым пышылдап: «Картәнием, берүк үлә күрмә инде, безне ташлап китмә!» – дип кабатлый. Калакта ниндидер таблеткалар изеп, салкын чәй белән әбигә йоттырырга чамалыйбыз. Әби чәчәп җибәрде. Шуннан соң гына аның йөзләренә җайлап кызыллык йөгерә башлады, кипкән иреннәрен ялап куйды. Мин барып тәрәзәне ачтым. Саф һава керсен. Башта берсеннән-берсе буталчык уйлар... Әбинең тын алулары тигезләшкәч, мин дә тынычландым. Йоклый, ахры.

Мин Рәхимәнең чәчләренең исен, ул чәчләрнең битемне иркәләвен исемә төшереп, хисләремә исереп, каршыда утырган кызны күзләрем белән йотлыгып эчәм. Әйтерсең дә кайнар чүлдә адашып, сусызлыктан үлеп барганда бик тәмле, саф, салкын суга юлыккан мосафирмын. Тыела алмыйм, күзләремне аңардан аерып алырга ихтыярым җитми. Һәм мин карашымны аңардан алырга теләмим дә. Рәхимә дә моны сизде шикелле, утырган урыныннан торып ук китте, юк нәрсәгә абына. Әби тирәли әле монысын, әле тегесен эшләп йөргән була. Түземе беттеме, янымнан үтешли борылып, өздереп тутырып карап, кызарына-кызарына:

– Кешегә бу кадәр үтәли карау – тәрбиясезлек билгесе, – диде һәм, озын керфекләрен җилпеп, карашын идәнгә төбәп, икенче бүлмәгә чыгып китте. Аның шулай тутырып каравыннан йөрәгем җилкенеп, еш-еш тибә. Башыма шаулап кан йөгерә. Текәлеп карамаска тырышсам да, үзем яшертен-яшертен генә аны күзәтәм. Ул минем һаман күзәткәнне сизеп, усал-усал, шелтәле карашларын миңа аткалый. Болай ул тагын да ымсындыргыч, тагын да серле, матур.

Менә самавыр да кайнап чыкты. Рәхимә чәй әзерләде, әбигә калаклап яңадан чәй каптырабыз. Авыруыбыз, күзен ачмый гына, ярты касә куе чәй эчеп куйды. Бераздан без тыныбыз белән тартып алырдай зарыгып көткән «ашыгыч ярдәм» машинасы да килеп җитте. Олы яшьтәге бер апа килеп керде. Үзбәкчә сөйләшәләр болар. Апам миңа карап нәрсәдер сораштыра. Шуннан Рәхимә:

– Татар ул, татар, – дигәч, доктор иске сүзләр кушып татарча сөйләп алып китте. Менә сиңә мә. Бу апа да үзебезнең кеше булып чыкты. Аның сөйләве буенча, без бик дөрес ярдәм күрсәткәнбез икән. Табибәбез безне мактап та алды:

– Хәзер әбигә тик тынычлык кына кирәк. Менә шушы-шушы уколларны кич кадарсың. Менә шушы даруларны аптекадан сатып алырсыз, – дип, берничә рецепт та язып бирде. Рәхимә аңа чәй тәкъдим итсә дә, ул тагы чакырулар булуына сылтап, ашыга-ашыга чыгып китте.

Без, сәкедә тыныч кына тын алып яткан әбине исәпләмәсәң, тагы икәү генә торып калдык. Рәхимә мине чәй эчеп алырга чакыра. Мин шатланып, мең тапкыр риза. Их, егетләр, сөйгәнең ясап эчергән чәйдән дә тәмле чәйләр бармы икән?.. Ул, ояла-ояла, миңа карамаска тырышып, кызарына-кызарына чәй ясый. Үзем дә каушыйм, үзем дә кызарынам. Их, шулай гомер бакый икәү бергә утырып чәйләр эчәргә иде дә дип хыялланам. Минем бу бәхетле минутларның кадерен белеп кенә, чәйләр эчеп тын гына бик озаклап утырасым

килсә дә, әбинең ыңгырашып алуы бозды татлы минутларны. Икебез дә тиз үк торып әби янына киләбез. Алай-болай шикле үзгәрешләр юк кебек. Күрәсең, саташып алгандыр.

Шунда Рәхимә ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Ярар, Җәүдәт, сезгә рәхмәт инде ярдәм иткәнегез өчен. Сез булмасагыз, берүзем ни эшләр идем? Әти-әниләр кайтса, уңайсыз булыр, барыгыз, булмаса, кайтыгыз инде, – ди. Мин инде аңа каршы:

– Нинди уңайсыз булсын, картәниегезне үлемнән коткардык. Алар да аңлар әле, – дим.

– Юк, шулай да алар алдында уңайсыз. Әти дә бик усал, катгый кеше, – дигән була. Мин инде бик кыстатып тормыйм, мине вөҗдан газабы кимерә. Чөнки әбине шушы хәлгә төшерүче мин бит. Әби, һушына килеп, сөйли калса, мине бу йорттан себерке белән себереп чыгарып түгәчәкләр. Аның белән генә бетсә әле.

– Ярар инде, – дигән булам. Ә үземнең «Рәхимә, мин бит сине яратам. Теге чакны Әфганстанда беренче күргән чагымда ук йөрәгемә кереп калдың», – дип әйтәсем килә. Юк, әйтә алмыйм. Оялудан телем көрмәлә. Каушыйм. Аннан да бигрәк, «ә мин бүтән кешене яратам. Башкача монда килеп йөрмә», – дип кырт кисүеннән куркам. Шул сүзләрне ишетмәс өчен, әйтер сүземне дә әйтә алмыйм. Ул мине сүзсез генә капка төбенә чаклы озата чыкты. Минем белән хушлаша. Мин үземне үзем тыя алмый аның нәфис кулларын үрелеп тотып алдым да саубуллашам. Ә ул тагы да әкренрәк:

– Кул биреп саубуллашырга кушмыйлар бит. Саубуллашучы кешеләр яңадан күрешә алмаска мөмкиннәр, – ди.

Мин бу сүзләргә куанып:

– Рәхимә, без, әлбәттә, күрешербез, күрешәчәкбез,  – дим һәм алдан язып әзерләп куйган, кесәдә яткан хатны аңа тапшырам.

Капка ябылды, хат Рәхимә кулында калды. Мин шат, мин бәхет болытларына утырып йөзәм. Ниһаять, үземнең аңа булган хис-тойгыларымны хат аша булса да белдерергә батырчылыгым җитүенә куанам. Менә шул мизгелдә капка әкрен генә ачылды да Рәхимә миңа карамый гына, пышылдап:

– Ә бит барыбер мин Рәхимә түгел, – диде дә, капканы ялт ябып, тук-тук басып өйләренә үк кереп китте.

Менә сиңә мә, һаман шуны кабатлыйлар. Ярар, әтием әйтмешли, «яшәрбез, күрербез, вакыт күрсәтер әле кемнең кем икәнен». Нәкъ шул минутта, минем бу уйларымны җөпләп, җилкәмнән берәү «шап» иттереп тә элэктерде. Күрәм – Рәхимә-Сәгыйдәнең мине тавык кетәгендә таяк белән «сыйлаган» абзасы. Усал итеп, тешләрен кысып:

– Син нәрсә, йолкыш? Эт ялкавы. Безнең капка төбен сакларга ялландың мәллә? Әйттеләр бит сиңа, бүтән эзең булмасын монда! – дип, берне «ямап» җибәрде. Мин каршы сугышмыйм. Әмма борын белән күзгә эләккәч, мин дә ычкынып киттем. Баш белән берне җилле генә тондырдым да, теге ис алырга өлгергәнче, сыптырдым бу тирәдән.

Ә шулай да мин бик тә бәхетле. Һе, йодрык кына нәрсә ул. Мин бит бүген Рәхимә-Сәгыйдәнең йомшак кулларын-бармакларын тотып карау бәхетенә ирештем.

Урам чатында торган колонкада юындым да очып дигәндәй, өйгә елмаеп кайтып кердем. Борын гына шешеп, бәрәңге рәвешен алды, сул күз төбендә – «фонарь». Әни белән апа никадәр сораштырсалар да, дөресен әйтмәдем.

– Әй, базарда бер исерек ялгыш бүтән кеше белән бутаган. Азактан гафу да үтенде әле, – дидем дә куйдым.

Хәзер Рәхимә-Сәгыйдәләр йортын ерактан гына күзәтәм. Юк, егетләр, һич туры китереп булмый. Дәрескә элеккечә абзасы машина белән йөртә. Бер атна-ун көннән артык вакыт үтте. Карыйм, бер көнне Рәхимә-Сәгыйдә училищеларыннан бүтән кызларга ияреп кайтып китте. Агасы күренми. Мин урамның икенче ягыннан барам. Менә кызлар берәм-берәм таралышып беттеләр. Менә тыкрыкларына да җиттек. Мин һаман урамның теге ягына чыгарга шикләнеп барам. Көтмәгәндә абзасы килеп чыгуыннан шүрлим. Аннан да бигрәк, күздәге «фонарь» хәзер әллә ничек яшәреп, саргаеп, әллә нинди төсләргә керде. Борын инде үз урынына утырды утыруын.

Рәхимә-Сәгыйдә адымнарын әкренәйтте. Өй турыларына җиткәч туктады да минем якка карап тора. Ни булса шул була, урам аша йөгереп чыктым. Исәнләштек. Бу минем «фонарь»га ишарәләп:

– Авыртамы? – ди.

Мин уңайсызланып баш чайкыйм:

– Юк, хәзер авыртмый.

Ул инде бөтенләй елмаеп:

– Хәзер төнен дә күрәсеңдер әле, – ди. – Чинар башына менсәң, төнен безнең йорт алды тагы да яктырак булыр иде, – дип, агач башына күрсәтә. Шигем калмады, минем агач башында утырганнарымны күргән бит бу! Ык-мык киләм, сөйләшергә уңайлы сүз таба алмыйм.

Өйгә кайтып кердем. Апа:

– Бер таза гына бәндә сине сорап килде, озак кына капка төбендә дә көтеп утырды. Бик җитди кылана, үзе бертуктаусыз сәгатенә карый. Син кайтмагач, китте, –ди. Әни дә аңа өстәп:

– Әйтергә онытып торам, ул бәндә элекке көннәрне дә сине сорап килгән иде. Өйдә берүзем генә булгач, капкадан кертмәдем, – дип куйды. Бу хәбәрләр минем шик учагына бензин сипкән кебек булды. Монда куркып гомер кичергәнче, үз илеңә кайтып үлгәнең артык. Шуны уйлап, өйдәгеләргә әйтеп салдым.

– Ярар, әни, җитте. Иртәгә үк юлга чыгабыз. Кайтып китәбез. Ошамый миңа монда, – дим. Апа коелып төште. Елый ук башлады.

– Мин нишлим инде берүзем дүрт бала белән? Аларны ничек кеше итәм? Берсеннән-берсе бәләкәйләр бит әле, – дип, сузыпмы-суза, малайлар, кире калырга үгетли мине. – Яңа эш тә белешеп беттем, фәлән-фәсмәтән, – дип, елапмы-елый. Әни дә аның ягын каера. Имеш, хәзер бездә кыш. Яланөс ничек кайтып кермәк кирәк. Утын да әзерләнмәгән, салам да китерелмәгән. Китте болар, малай, икәүләп балавыз сыга-сыга миңа басым ясыйлар. Мин үземнең сүземдә нык тора торган кеше.

– Син, әни, кайтмасаң кайтмассың, ә мин туйдым. Тормышның фәтүәсе юк монда. Үзебездә, ичмасам, күрше күршесенең ихатасында ниләр барын күреп, ишетеп тора. Ә монда халык сукыр тычкан кебек, биек койма эчендә көн күрә. Юк, булмый, бүген үк билет ягын хәстәрләргә кирәк, – дидем дә, барлы-юклы акчаларны санарга керештем. Кырып-себереп дигәндәй җыйгач, ике билетлык булды.

Эшне тиз тотып, тимер юл вокзалына барырга әзерләнәм. Үзем белән барырга апаның олы улы Нариманны да үгетләдем. Ул сигезенче сыйныфта укый. Ни дисәң дә иптәш, таяныч. Хәзер инде тегеләрнең мине күзәтеп торып,

берәр аулак урында чүкеп китәргә әзерләнгәннәренә һич шигем калмады. Нинди генә планнар корып, нишләтсәләр дә, кырымда шаһит булачак. Бер кешене җыештырып куюга караганда икәүне юк итү ул инде, минем уемча, кыенрак булачак дип беләм.

Без Нариман туганым белән килеп чыгып, ун адым да атлый алмадык, куркыныч шигемне дөресләп, Рәхимә-Сәгыйдәнең теге башкисәр абзасы машинасы белән чажлап килеп туктамасынмы! Йөрәгем кысылып, дарсылдап тибәргә тотынды. Тирә-якка каранам. Урам буш дияргә була. Иң теге очта гына бер көтү бала чага чым-чыкыр килә. Ә башымда – уйлар. Әйе, мавыгып йөри торгач, бу кызыйга чынлап торып гашыйк булганмын булуын. Нәтиҗәсе нәрсә? Хәзер менә берничә ир килеп төшәрләр дә машинага утыртып алып та китәрләр. Һәм Аллаһы әкбәр. Яклаучым бармы монда? Минем беркемем юк. Җизни – мәрхүм. Апа белән әни нәрсә, алар – хатын-кыз.

Атлыйсы адымны атламый бөтенләй туктап калдым.

Торып йөгерер идең – барыбер куып җитәчәкләр. Иң яхшысы – кире борылырга. Ә янымдагы туганым җиңнән тарта:

– Йә, әйдә, нәрсә туктап калдың? – ди. Мин авыз эченнән мыгырданам:

– Әллә акча торып калган инде, – дим. Үзем күземне машинадан ала алмыйм. Куркыныч чакта секундлар сәгатьтән озынрак була башлый. Менә мин җай гына капкага борылам. Капкадан кереп китеп өлгерә алмадым, апа үзенең яңгыравыклы матур тавышы белән:

– Җәүдәт, Җәүдәт туганым, тукта әле, – дип дәшә түгелме? Аңыма барып җитми тора. Әйтерсең лә миңа түгел, ә башка кешегә дәшәләр. Нариман туганым җиңемнән тотып туктатырга чамалый. Теләр-теләмәс кенә борылам. Апа белән абзый тиз-тиз үк килеп җиттеләр. Куркудан, рульдә теге уллары дип уйлаган булам тагын. Алай-болай усал ниятләре юк шикелле. Үзләре авыз тутырып елмаялар. Вахит абзый, тамагын кыргалап, гәүдәсенә туры килеп торган калын тавышы белән:

– Безгә берәр сәгатьтән чәйгә килегез. Барча туганнарыңны да алып килергә онытма. Әниең, апаңны һәм аның балаларын да, – ди.

Шулай итеп, без өчәүләшеп, Рәхимә-Сәгыйдәләргә кунакка килдек.

Идәндәге кыска аяклы өстәлдә бик шәпләп пылау ашыйбыз. Әбине дә алып чыгып утырттылар. Бернәрсә дә булмагандай, элеккеге бик якын танышлар кебек, бик матур утырабыз шулай.

Чәйләп алгач та безнең кайтырга ашыкмавыбызны үтенәләр. «Хәзер шулпа пешеп чыга, гомумән, якташларны сыйлап, кунак итеп, бөтенләй дуслашырга телибез», дигәч, апа белән әни хуҗабикәгә ияреп, йорт-бүлмәләр белән танышырга чыгып киттеләр. Әбине бик сак кына үз бүлмәсенә кертеп урнаштырдылар. Мин инде Заһитның балалары белән танышып, алар белән юк-бар сөйләшәм. Ә Заһит, миңа күз кысып, кулын күкрәгенә куеп, гаеплемен дигәнне аңлатып, сүзсез генә миннән гафу үтенә. Мин дә, күптән онытттым инде дигәнне аңлатып, кул селтим. Шулай балаларны шаяртып, күңелләрен ачып утырганда, Рәхимә-Сәгыйдә шым гына килеп, колакка:

– Сине картәни чакыра, – дигәч, сискәнеп киттем. Ә ул кулымнан үзенең нәфис бармаклары белән тотып тартып торгыза һәм җитәкләп әби бүлмәсенә алып керә. Әби теге матур агач караватта олы мендәргә ипле генә ярым сөялеп, ярым утырып тора. Теге көнне күземә чалынмаганмы, әллә чаршау корылган булганмы – идәннән түшәмгә чаклы сузылган киштәдә – китап. Калын-калын, саргаеп беткән иске китаплар. Урыс телендәгеләре дә, татарчалары да, латин

һәм гарәп хәрефләре белән исемләнгәннәре дә байтак. Гарәп хәрефлеләре, мөгаен, Коръән йә дога китапларыдыр.

Әбием дәшми генә янындагы кәнәфигә утырырга ишарәләде. Миңа текәлеп-текәлеп үтә карый. Мин, аның сынаулы карашын күтәрә алмый, күземне өстәлгә күчерәм. Анда төрле-төрле дарулар исемнәрен укырга чамалыйм, юк булмый, зиһенем миңа буйсынмый.

Әбием исә әкрен генә кеткелдәп көлеп алды. Янындагы келәмне кулы белән сыпырып, булмаган сырларын тигезләп, йомшак кына тавыш белән:

– Ә бит, улым, мин сине көттем. Ничәмә ел көттем, – дип әйтеп салмасынмы, авыр көрсенеп. – Ии... язмыш... – дип, нәрсәдер әйтергә чамалаган иде, күңеле тулыпмы, туктап калды. Күзләреннән яшь чыкты. Җиң очыннан бик матур чигелгән кульяулык алып, яшьләрен сөртә-сөртә: – Кызым, даруны бир әле, – дип, безне дәшми генә тыңлаган Рәхимәгә дәште. Дару эчкәннән соң ул бераз дәшми торды да: – Кырык елдан артык көттем! – дип өстәп куйды.

Мин һичнәрсә аңламыйм. Нәрсә әйтергә тели бу карчык? Зиһене ычкынып, түбәсе кыйшайгандыр моның дип уйлый башладым. Карт кешеләрдә очраштыргалый бит шундый чирләр. Миңа бит чак егерме өч тулды, ә ул ничек мине кырык ел көткән булып чыга?

– Аптырама, олан, «бу хәбәрне өстән, биектән төшкән кеше әйтер. Шул хәбәр дөрес булыр», дип әйтелгән иде китапта. Менә, дөресләнде. Синең бит, олан, безнең йортка беренче аяк басуың капка аша кереп булмады, син күктән, ягъни агач башыннан, биектән килеп төштең. Үәт, аңладыңмы хәзер? – ди. Бернәрсә дә аңламыйча, аптырап, Рәхимә-Сәгыйдәгә күз салам.

– Кызым, китапны алып бир әле, – ди әби. Рәхимә-Сәгыйдә караватның башында торган, шулай ук бизәкләп, сырлап эшләнгән сандыкны ачып, аннан күн тышлы бик иске бер китап алып әбигә тоттырды. Әби зур калын пыялалы күзлеген алып киде дә китапны ачып, аңа карамый гына:

– Китапта син сөйләгәннәр дөрес булыр, дип язылган, балам. Сөйлә, улым, сөйлә. Дөресен сөйлә. Закирҗан бабаңны кайдан беләсең? – дип, туп-туры итеп, күзлеге аша миңа карап тора башлады.

Менә эш нәрсәдә икән! Әбием миннән Әфганстандагы маҗараларымны белергә тели түгелме соң? Шулай шул. Көтелмәгән хәлдән бераз югалып калдым. Ни сөйләргә дә, нидән башларга да белмим. Әбием яңадан китапка карап алды да минем сөйләгәнемне көтә. Һәм ишетелер-ишетелмәс кенә, бик тә моңсу итеп, ничектер, өзелеп-өзелеп:

– Аллаһ хакы өчен, үтенеп сорыйм, балам, – дип тә өстәп куйды.

Ничек кенә кыскача сөйләргә теләсәм дә, әбием минем белән булган маҗаралы хәлләрнең төбенә тоз коя, төпченә-төпченә тыңлый. Бигрәк тә тозактан кемнәр коткарганын тәфсилләп сораша. Мин инде Сәгыйдә апаны шунда күрүемне, Рәхимә белән ничек танышуымны сөйләдем. Татарча аңламаган булып кыдануларына чаклы әйттем. Тылмач итеп, Бәләбәйдә үскән татар әбисен алып килүләрен сөйләдем. Тылмач әбинең Бәләбәй шәһәрен «Бала би» дип атавын да онытмадым. Имеш, бик бай би, улым туса, шушы төбәкне аның хөрмәтенә атармын дип нәзер әйткән, имеш. Улы тугач, бала хөрмәтенә ул җирне «бала би» дип атаганнар. Тора-бара «бала би» Бәләбәйгә әйләнгән. Тик әбине болар кызыксындырмый. Аңа тегендәге Сәгыйдә апаларның ничегрәк яшәүләре кирәк.

– Ә менә Рәхимәнең һәм дә Сәгыйдә апаның бу кышлакта мине күргәч танымаган булып кылануларына, мине бутар өчен исемнәрен алыштырып

йөрүләренә хәтерем калды, – дим. – Тик нигә шул кадәр миннән яшерергә? Мин бит барысын да беләм, әби. Мин белгәннәрне кызыгыз да, оныгыгыз да белә. Шушы ук хәлләрне сезгә алар да сөйли ала иде, – дим. Тик мин боларны беркемгә дә, әни кадәр әнигә дә сөйләмәдем. Ә менә сезгә сөйләдем, әби. Курыкмагыз, бүтән ләм-мим, сөйләү юк, – дим һәм кызарына-бүртенә өстәп куйдым: – Ә бит Рәхимәне тәүге күрүдә үк ошаттым. Тик сез миңа оныгыгыз белән очрашып, сөйләшеп йөрергә генә рөхсәт итегез. Һәм үз чиратымда телемне теш артында тотармын. Бу сер үзем белән кабергә кергәнче калыр!

Әби үзенең түшәгенә сөялеп мине дикъкать белән тыңлады һәм бераз тын гына утыргач:

– Сәгыйдәне чакыр әле, улым, – диде. Мин торып ишекне ачарга да өлгермәдем, бүлмәгә кояштай балкып минемчә, Рәхимә, аларча Сәгыйдә килеп керде. Ишек артында гына торган икән. Оныгына карап, әбием:

– Укол вакыты җитте, балам, ясарга кирәк булыр, – ди. Мин бүлмәдән чыгарга әзерләнеп, торып бастым. Әбием мине бармагы белән чакырып үзе янына утырырга куша. Һәм:

– Рәхмәт, балам, яхшы хәбәрең өчен. Кызларга үпкәләмә, балам, исемнәрен алыштырган өчен. Син белмәгән серләр җитәрлек әле, улым. Мин белмәгәннәре дә байтак. Иртәгә иртәрәк кил, улым. Сәгыйдә дә өйдә булачак. Бергәләп чәйләр эчәрбез, иншалла. Әле безнең сөйләшеп сүзләр бетмәде. Килерсең бит улым, әйеме? – дип, минем вәгъдәмне алырга тырыша. Эшнең әкренләп җайга салынуына, бигрәк тә иртәгә Сәгыйдә белән бергә булачагыма шатланып:

– Әлбәттә, әби, киләчәкмен. Тик Сәгыйдә нәрсә әйтә бит әле, – дим елмаеп һәм Сәгыйдәгә күз төшерәм. Ул да битләре алсуланып, «мин риза» дигәнне аңлатып, башын кага.

Табыннан соң хушлашып, рәхмәтләр әйтеп кайтырга кузгалышабыз. Абзый безне ничек килеп алган булса, шулай олылап, машинасы белән өебезгә чаклы озатып куйды. Вакыт шактый соң инде. Без кайтканда, сәгать төнге уникенче булып киткән.

Мин иртән иртүк инде аларга чыгып йөгерергә әзер идем. Апа белән әни генә тыйдылар:

– Таң тишеге белән кая ашыгасың? – диләр. – Кунакка болай иртә бару тәрбиясезлек була. Кояш әзрәк күтәрелә бирсен. Син нәрсә? Кеше йокыдан тормас борын барып утыралармы? Килешмәгәнне...

Үзем дә аңлыйм алай ярамаганын. Тик бер төн эчендә Сәгыйдәне шулкадәр сагындым, әйтерсең лә унлап ел күрмәгәнмен. Чак түзеп тордым кояш өскәрәк күтәрелгәнче.

Рәхимә апа мине бусагада ук, елмаеп-көлеп каршы алды. Сәгыйдә дә чыгып басты. Апаның әйтүенә караганда, Вахит абзый эшкә киткән, ә әби мине иртә таңнан ук көтеп утыра икән. Әби бүлмәсенә кердек. Аңа, күрәсең, әле генә дарулар эчереп, укол кадаганнар, бүлмәдә сизелер-сизелмәс дару исе аңкый. Мине күрүгә әбиебез балаларча шатланып, исәнләшергә дип кулларын суза. Рәхимә апага:

– Кызым, чәеңне яңарт әле. Әнә кунакның да тамагы кибеп киткәндер, – ди.

Мин урынымнан тора биреп:

– Юк, юк. Мин әле генә табын яныннан торып килдем, – дигән булам. Әбием, гадәтенчә, кире урыныма утырырга кушып, кулы белән ишарәләп:

– Йоласы шулай, улым, йоласы. Безнең халыкта килгән кешегә һәрчак ризык тәкъдим иткәннәр. Син, балам, һич карышма. – Һәм әбием, мине аптыратып,

кинәт кенә: – Шулай итеп, Сәгыйдә апаң мәрхүмә туганы хөрмәтенә кызына Рәхимә дип исем кушкан диденме әле, балам? – дип куйды.

Әбинең минем кичә сөйләгәннәрне энәсеннән-җебенә чаклы хәтерендә калдыруына шаккатып:

– Әйе, шулай шул. Миңа Рәхимә үзе сөйләп аңлатты теге тылмач әби аркылы. Аннан инде без бер-беребезне болай да аңлый башлаган идек. Әйтәм бит, татарча белмәгән булып кына кыландылар, – дим.

Сәгыйдә шулчак әби белән безнең арадагы сөйләшүне ишетеп түзмәде:

– Кемнәрне әйтәсез ул? – дип сорап куйды. Әбием көлеп кенә:

– Күп белгән тиз картайган, үзем җайлап сөйләрмен әле, – ди.

Аның хәле кичәгегә караганда күпкә яхшырган, кәефе күтәренке. Өстәлдән кичәге китапны алды да:

– Улым, синең хакта күп нәрсәләр беләм бит, – диде, серле итеп.

– Беләсездер, кәнишне, кичә генә барысын да сөйләп бирдем бит, – дим.

Безне зур кызыксыну белән тыңлап, күзәтеп торган оныгына да ипләп кенә эш кушты:

– Бар, кызым, син әниеңә табын әзерләш. – Сәгыйдәне чыгарып җибәрүен үземчәрәк аңлыйм.

Егетләр алдында кукраеп басып торма, дип ишарәләведер, дим. Юк икән шул. Әби сөйли башлагач кына аңладым. Ул минем кайчан туганны, елын, көнен-аен сорашты да, теге китапны ачты. Әле бер битен, әле икенче битеннән укып, бәләкәй чагымда суга батып үлә язганымны да, шофёр булып эшләгәндә, авариягә эләгеп, чак исән калуымны да әйтеп бирде. Шуннан кинәт кенә күзлеген салды да, миңа туп-туры карап, хәйләкәр итеп:

– Сәгыйдәне чынлап торып яратасыңмы, улым? – ди.

Мин көтелмәгән бу сораудан югалып калам һәм әкрен генә:

– Шулай, ахры, – дим.

– Ахрысы булырга тиеш түгел. Яратасыңмы, юкмы?

Мин кып-кызыл булып кызарам һәм телемне чак әйләндереп:

– Яратам! – дим, кулларымны кая куярга белмичә урындык почмагына ышкыштырып, өстәлгә җәелгән чигүле җәймәне карашым белән сөзеп.

– Тыңла алайса, улым. Сөйгән кешең белән яшәячәксең. Дүрт балагыз була, илле яшеңдә нindидер зур авыр кайгы кичерәчәксең. Шуны җиңеп чыксаң, тагын да рәхәт, озын гомер кичерәчәксез. Яраткан кешең янында булып, балалар игелеген күреп яшәячәксез. Берничә тапкыр өеңне, яшәгән урыныңны алыштырачаксың. – Әбием тагы китапка карап алды: – Монда дүртенче балаң бик ачык күренми. Әмма карт көнегездә ул бала сезнең кояшыгыз астында җылына...

* * *

Хикәясенең шул җирендә Җәүдәт абзый туктап тынып калды. Көн сүрелеп килә. Шулай да кызган һава-җир тиз генә суынырга теләми. Абзыебыз тагы үрелеп алып теге кымыз кебек әчегән әйрән белән тамагын чылатты һәм безгә дә суза. Эчегез, янәсе. Без, абзыйның сөйләвен туктатмас өчен, барыбыз да сүзсез генә баш чайкап, аның тәкъдимен кире кактык. Һәм аның сөйли башлаганын көтәбез. Яшка абзыебыз, «әле бу кояш һаман баемыймыни» дигән кебек, кояшка карап алды да:

– Ә бит әби әзрәк ялгышты. Сәгыйдәнең авырып кинәт кенә мәрхүмә буласын белмәгән. Әллә белеп тә әйтмәде, – дип туктап калды. – Юк, белгән

булса, әйтер иде, билләһи, әйткән булыр иде, – дип, күзенә эленгән яшь тамчысын тиз генә җилпеп ташлады.

Ул арада чәй өлгерде. Рәхимә апа бик тәмле итеп сумса пешергән һәм безне табынга чакыра. Без Сәгыйдә белән икәүләп әбине җитәкләп-күтәреп дигәндәй теге якка алып чыгабыз һәм өстәл артына мендәрләргә сөяп утыртабыз.

Табын артында әбием миңа үзләре турында сөйләп алып китте.

– Ихтилал булып, мулла-мәзиннәрне эзәрлекли башладылар. Бер төнне картәтиегезнең элекке бер шәкерте килеп хәбәр салды: «Закирҗан ага, иртәгә авылдан чыгып китмәсәң, үзеңне кулга алалар, гаиләңне Себер сөрәләр», – дип. Бабагыз, ягъни әтиең, – әби Рәхимә апага карап алды, – бабаң бик сизгер кеше булды. Өченче көн генә Уфадан кайтып, коточкыч хәлләр турында сөйләп кенә туктаган иде. Шушы хәбәрне ишеткәч, ике арбага мичәүләп атлар җиктек тә, сала алган йорт-җиһазны төядек. Калган барча дәүләтне күрше Гыйльмулла абзыйларга тапшырып, шул ук төнне Ырымбурга чыгып качтык. Җитмәсә, кулда игезәк имчәк балаларым Сәгыйдә белән Рәхимә. Кәшшәфетдин белән Заһитым инде кул арасына кереп баралар. Безнең белән авыру каенанам да бар. Ул бик тә укымышлы карчык иде. Михнәт-авырлыклар күрә-күрә, шулай качып барабыз. Ә сәүит хөкүмәте безне бастырып эзәрлекләп килә. Үзе килә, үзе гел укымышлы зыялыларны бетереп, җыештыра бара. Казакъ далаларына чыгып киттек. Бабагыз кышын балалар укытты. Шулай тамак туйдырабыз. Бушрак вакытымда үзем дә аңа ярдәм иттем. Яз җитү белән юлга чыгабыз. Атларны кышын берәм-берәм суеп ашап бетердек. Каенанамны тәүге кышны ук казакъ далаларында, чит җирләрдә җирләргә туры килде. И... и... балалар, ул этләнүләр, ул кышкы салкыннарда туңулар – барысын да сөйләсәң, кеше ышанмаслык хәлләр...

Әбием үзе сөйли, үзе елаштырып ала. Күргән михнәтләрен исенә төшерү аңа шактый авыр, күрәсең.

– Соңгы атыбызны буранда казакъ ярлылары урлап алып китеп суйдылар. Бик акыллы хайван иде. Баулары киселгән тирмәбез дә, буранда авып, тәгәрәп китте. Тирә-якта бернәрсә күренми, карлы буран. Далада җил-буран бигрәк көчле була бит. Яшь балалар хакынадыр инде, буран әзрәк басыла төште. Шунда миһербанлы бер карт очрап, бер ат һәм олы гына киез калдырып китте. Югыйсә шыкырдашып туңып үлә идек далада. Их балалар, ул сәүит власының начар яклары бик күп булды инде. Яхшылыгы да бар, әлбәттә, анысын да инкарь итеп булмый.

Үзбәкстанга килеп, ару гына тормыш корып яши башлаган идек, Закирҗан бабаңны кулга алдылар. Имеш, балаларны мулла укытырга тиеш түгел. Атарга дип алып барганда, җаен туры китереп качкан. Икенче көнне Фрунзе кул астындагы дашнаклар дигән, сакал басып беткән ямьсез кешеләр килеп, Сәгыйдә белән Кәшшәфетдинне чырылдатып алып киттеләр. Рәхимә белән Заһидулланы йомыш белән күршеләргә кертеп җибәргән идем. Дашнакларны күргәч, күршеләрем балаларны чыгармаганнар, рәхмәт яугырлары. Алар шулай исән калдылар. Теге ерткычлар, шулай итеп, ике баламны алып киттеләр. Үземне дә бетерәләр иде. Ярый күрше-күлән коткарып алып калды. Сәнәк-кәтмәннәр күтәреп чыккан халык. Балалар хакына Аллаһы Тәгалә саклагандыр инде. Дашнакларның юлбашчысы шундук әйтте: «Йә ирең, йә балаларың белән үзең, – ди. Иреңнең кайда икәнен әйтсәң, балаларыңны җибәрәбез. Әйтмәсәң, аларны терелəй күмәбез», – дип яныйлар. Бүтәнен хәтерләмим дә инде, шунда егылганмын. Икенче көнне бер дашнак ат өстеннән генә Кәшшәфетдинемнең

үле гәүдәсен капка төбенә калдырып киткән. Кеше, адәми заттан булса, этне дә алай ташлап китми. Бахыр баланың, елганы кичеп чыкканда, аркасына атканнар икән. Мин шул егылудан бер ел аяксыз, сөйләшә алмый яттым. Үзбәкләр бик миһербанлы халык, ничек итсә иттеләр, үләргә ирек бирмәделәр. Гомерем булгач, терелдем, аякка бастым. Ә Заһитым фашист илбасарларына каршы сугышта һәлак булды. Командир иде. Танк йөртте. Бик акыллы, тимер-томырга бик әвәс иде балам. Гомере генә кыска булды улымның.

Теге тәүге качканында Закирҗан бабаң тауларда яшеренгән булган. Кемдер балаларыңны да зинданга яптылар дип хәбәр иткән. Шуннан бу, төнлә сакчыны үтереп, балаларны алып кача. Таңга таба артыннан куа төшәләр. «Ирең Әфган чиген чыкканда, ике баласы белән суга батты», дип килеп әйттеләр миңа. Тик Кәшшәфетдин улымның гына гәүдәсен тапканнар. Шул гаип булудан менә әлеге көнгә кадәр бер хәбәр дә юк иде. Ходай насыйп иткәч, хәбәрне син китердең, балам, – дип, әбием элеккедән дә ныграк, лышык-лышык елап җибәрде. Кулларын күкрәгенә куеп, рәхмәтләр әйтеп башын ия. Әбигә кызлары да кушыла. Чәй мәшәкатьләре күптән онытылган, чәй-сумсалар күптән суынган. Мин дә, сиздермәскә тырышып, читкә борылам. Әбине җәлләп, күземнән яшьләр тәгәри. Каһәрең, кульяулыгым юк икән. Оят булса да, күлмәгемнең җиңе белән күземне сөртәм. Шулчак Сәгыйдә, әниләренә сиздермәскә тырышып, минем кулга бик матур кульяулык тоттырды. Татар кызлары гына болай бизәкләп чигә кульяулыкны. Язгы ләйсән яңгыры кебек яшь коеп алгач, әбием тынычлана төште. Һәм мине борчыган, мин бирергә әзерләнгән сорауга үзе җавап биреп куйды:

– Ә дашнаклар дигәннәре кемнәр, дисеңме? Шушы кышлакта күпме хатын-кызларны мәсхәрәләделәр, күпме яшь ир балаларны көчләделәр алар. Шуңа да Закирҗан бабаң кеше хәтле кеше үтерергә мәҗбүр булган. Аларны кеше дип әйтүе дә авыр. Бер иблис токымын үтерде ирем. Бабаң рухына багышлап, күпме Коръән чыктым, күпме догалар укыдым. Аллаһтан ярлыкау сорадым. Бабаңа бер сүзем юк. Ичмаса, бер иблиснең башына чыгып, балаларны хурлыктан коткарды. Аңа мең-мең рәхмәтләр. Ходайның рәхмәте белән, балам, син алардан да хәбәр алып килдең. Теге яктагы Сәгыйдә апаң ул – шушы Рәхимә апаңның игезәк сыңары инде, улым. Үзең әйттең бит, кызларына Рәхимә дип исем кушканнар. Менә без дә бу якта шул Сәгыйдә апаң хөрмәтенә кызыбызга Сәгыйдә исемен куштык дип, оныгының аркасыннан сөеп-яратып алды.

Рәхимә апа белән Сәгыйдә әле барысын да аңлап җиткермиләр иде шикелле. Күрәсең, шуңа да әбием:

– Җәүдәт улым, булмаса, апаңа да сөйлә инде. Алар да ишетсен, теге яктагы Рәхимә оныгым белән Сәгыйдә кызымның хәбәрен, – диде дә миңа күзләрен мөлдерәмә тутырып карап тора башлады. – Сөйлә, улым, сөйлә. Һич тартынма, тутырып сөйлә.

Төш авышуга мин инде, әйтерсең лә, бик зур батырлык эшләгән кеше кебек идем. Сәгыйдәнең миңа сокланып каравы күңелемә каймак, йөрәгемә баллы бер наз. Элек миннән читләшсә, бүген үзе янымда бөтерелә. Әбием һаман да яшь күрсәткәләп алса да, хәзер бу тик шатлык яшьләре генә инде. Өй бәйрәм төсен алды.

Рәхимә апа сый-нигъмәтләр алырга базарга йөгерде, ә безгә теге хикмәтле тандыр дигән мичкә ут куярга кушты. Әбине үз бүлмәсенә кертеп, дарулар эчереп, тынычландырып яткырдык.

Нәрсә булса шул булыр дип, сөйгәнемне утынлыкта туры китереп, суырып-суырып, бер кысып кочаклап үптем, егетләр. Беләсегез килсә, иреннәренең тәме әле дә тел очында тора кебек. Ул бик карышмаса да, кочагымнан шуып чыкты да, кып-кызыл булып:

– Кит инде, кеше-мазар күрсә, ояты ни тора. Син бигрәк азгынсың. Йә көтмәгәндә кочаклыйсың, йә булмаса, тавык абзарын җимерәсең, – дип челтерәп көлде дә утынлыктан чыгып йөгерде.

Ничек кенә хәйләләп тагы бер кочакларга ниятем булса да, барып чыкмады. Мич матур гына кызып, ялкынланып яна. Утка карап утырабыз. Мин аңа елышыргарак тырышып карыйм, тик ул урыныннан тора да китә. Бераздан апа белән абзый да күтәренеп кайтып керделәр. Абзыем минем якка канәгатьсез, шикле карашларын аткалап-аткалап алса да, минем шатлыкны, минем күктә очкан хыялларымны җиргә, кире фани дөньяга кайтарырлык хәлдә түгел иде.

Чәйләп, сыйланып алгач, килгән кунакның вакытында киткәне яхшырак, дигәнне исемдә тотып, кайтырга кузгалам. Латыйфа әби белән дә саубуллашып чыгуны кирәксенеп, ишектән башымны гына тыгып хушлашырга уйлаган идем дә, барып чыкмады. Ул, мут елмаеп, янына чакырып алды да, иелергә кушып, колагыма пышылдый:

– Иртәгә җомга көн. Уең булса, иртәгә төштән соң Сәгыйдәгә яучы җибәр. Иң кулай көн. Китапта шулай язылган, – дип, өстәлдә яткан теге сер тулы китапка күрсәтә. Һәм «исән-сау йөр, улым» дигән кебек, кулбашымнан кагып, аркамнан сыпырып куйды. Мин күкнең иң биек, җиденче катында очып дигәндәй кайттым өйгә. Һәм иртәгесенә нәкъ әби әйткәнчә эшләдем дә.

Җәүдәт абзыебыз:

– Их... – дип бер тирән итеп тын алды да торып басты. Елга аръягына, офыкка, баеп барган кояшка карап бераз тын торды һәм ниндидер бер сагышлы тавыш белән: – Менә шулай кулга төшердем мин үземнең иң зур, иң тәүге һәм иң соңгы мәхәббәтемне – Сәгыйдә апагызны, беләсегез килсә, егетләр. Тик гомеркәйләре генә кыска булды. Үсеп җиткән балаларыбызның игелеген күреп, шатлыкларын гына уртаклаша алмады, – дип, бик нык итеп көрсенеп куйды. – Әй язмыш... тәкъдир-күрәчәк дигәннәре шушы буладыр инде ул, маңгаеңа нәрсә язылган, шуны күрәсең, – диде дә, җай гына атлап, елгага таба китте. Без кымшанырга да кыймый тып-тын утырабыз. Мин инде Җәүдәт абыйның бүтән берни дә сөйләмәячәген чамалап, егетләргә әкрен генә:

– Шабаш, егетләр. Бүгенгә җитәр. Җыештырыгыз эш коралларын! Кайтырга вакыт, – дим.

Егетләр теләр-теләмәс кенә торып, дәшми генә җыештырына башладылар. Барысы да бик җитди. Без барыбыз да Җәүдәт абзый алдында ничектер бәләкәйләнеп, мескенләнеп калдык.

Эчебездән генә уйлый идек шикелле: «Рәмиләләребезгә, Фатыйма-Зиләләребезгә барыбыз да шулай яратып өйләндекме? Шулчаклы яратышып, бер-беребезне ихтирам итешеп торабызмы хатыннарыбыз белән?!» Егетләргә таралышырга кушам. Эшкә җәяү йөрибез, чөнки без кышкылыкка әзерләгән ферма авыл янында гына.

Үзем абзый киткән сукмактан елга буена төшәм. Ул инде салкын суда юынып-чайканып алган. Яр буенда ике тезен кочаклап агымсуга карап уйланып утыра. Уйларын бүлдерергә базнат итмим. Тик ул, минем килгәнне шәйләп, торып басты да:

– Үз әкиятем белән бүген эшләргә дә ирек бирмәдем, – дип, моңсу гына, гаепле кеше кебек елмаеп куйды.

Аны тынычландырырга ашыгам:

– Зарар юк, Җәүдәт абзый. Батырга да ял кирәк. Бик матур да, бик фәһемле дә тарих сөйләдегез. Рәхмәт сезгә!

Ул сүзләремә игътибар да итми:

– Ни бит әле, кара әле, туган... Кыен булса да әйтим инде. Мин бүтән эшкә килә алмыйм. Урыныма берәрсен табарсың. Әнә теге очтан «Пытыр» малае Миңнулла эшсез ята түгелме? Әйтсәң, килә ул. Минем олы малайдан хат килде. Үз янына чакыра. «Дөньямны ташлап китеп буламы», дип уйлаган идем дә менә бүген «барам» дигән катгый фикергә килдем.

Безнең калымчылар бригадасына Җәүдәт абзыйсыз кыен булачак. Анысы көн кебек ачык. Белмәгән һөнәре, эшләмәгән эше юк. Чын-чынлап алтын куллы кеше. Ләкин мин аны калырга үгетләп тә, кыстап та булашмадым.

– Ярар, Җәүдәт абзый, җан биргәнгә юнь бирер әле Ходай. Әйдә, кайтабыз, – дию белән генә чикләндем.


Авыл урамына килеп кердек. Сөйләшмибез. Авыл көтүе күптән кайткан. Көтүдән соңгы ыгы-зыгы, сыер савулар, мал ябулар тынган. Өйләрдә ут ала башлаган мәл. Мин абзыйны үзебезгә кичке ашка чакырам. Ул ризалашмый, бик тә төшенке, моңсу тавыш белән:

– Аның, туган, дөньяда иң кыены – бикле, буш, караңгы өйгә кайтып керүе. Сине көтеп, елмаеп каршы алырдай тормыш иптәшең булмагач, яшәүнең бер яме-мәгънәсе юк. Өйгә кайттың ни дә, кабергә кереп яттың ни, – дип, бик тә күңелсез итеп әйтеп куйды. Мин инде аны тагын да ныграк кызганып, үзебезгә алып бармакчы булам.

– Сөйләшеп утырырбыз, – дим. – Дус-туганнар килсә, дип әчетеп куйган җимеш суы да бар. Кичә генә тәмләп карадым. Хөкүмәтнеке бер якта торсын,– дип, тегенең иң йомшак җирен сыпырам.

Җәүдәт абзый:

– Юк, туган. Әйтүең өчен рәхмәт. Ул Яшка эчә, Яшка алкашка әйләнгән, диләр дә ул. Дөрес түгел. Эчеп карадым бит инде. Онытылмасмы дип уйларым, сүнмәсме дип кайгыларым. Юк, малай, аракы гына баса алмый икән йөрәк сызлауларын. Шуңа да улым янына барып карыйм. Өй салырга җир биргәннәр аңа. Үзем салып бирәм өйне. Менә дигәнен. Хан сарае кебекне. Гаепләмә, гомер булса, бер күрешербез әле, Ходай насыйп итсә. Хуш, туган, – диде дә кырт борылып китеп барды. Караңгылыкка кереп югалды. Әйтерсең лә, укып чыккан бик кызык, мавыктыргыч китап ябылды...



Эльверт
Хәмәтшин

# ЕЛЛАРДАН МАЯК КУЯМ…

## Каләмем

Минем каләм матурлыкны сөя,
Изгелекне генә үз итә.
Кәгазь битләренә эзләр салып,
Тормыш йомгагымны ул сүтә,

Каләм яза минем күргәннәрне,
Үткәннәрне шигъри юл итә,
Шигырь җене тигән минем җанга.
Язып торса каләм – шул җитә.

Кемдер әйтер: «Каләм – корал!» – дияр,
Ә минем ул – якын сердәшем.
Тормышыма бәхет нуры сибә,
Йөрәк белән бик еш серләшеп.

Каләмемне җил-давылдан саклыйм,
Салкыннарда тотам учымда,
Мин яраткан камил шигъри дөнья
Яши шушы каләм очында.

* * *

Коллык китми илдән, коллык китми,
Яши белә төрле сыйфатта.
Шул коллыкта халкым яши бирә,
Карамый да уйлап бу хакта.

Бер коллыктан икенчегә илтә
Өерелеп барган юллары:
Элек халык язмыш колы булган,
Хәзер күпләр акча коллары.

---

Эльверт ХӘМӘТШИН (1951) – *шагыйрь; «Каеннарым мине көтәләр», «Гомер эзләрем», «Син – сагышым кояшы» исемле китаплар авторы. Башкортстан республикасының Авыргазы районы Степановка авылында яши.*

## Җир – изге ул...

*Ни генә булса да, бу җир*
*Тудырган шагыйрь улын.*
*Шагыйрь туган көннән алып*
*Ул инде изге урын.*
Р. Миңнуллин.

Җир турында төрле фикер йөри:
Изге, диләр, шагыйрь туганга.
Җир-Ана ул изге булып кала
Анда кеше туып торганда.
Без барыбыз җирдән яралганнар,
Җир – кешенең изге Анасы.
Изге анасына мәрхәмәтсез
Була кайчак адәм баласы.
Бер гомергә җиргә кемнәр килгән,
Кызганмыйлар аны, ваталар.
Байлык эзләп, көн-төн казыналар,
Шартлаталар, туптан аталар.
Җир-Анабыз үз тәнендә саклый
Сугышларның күпме ярасын?
Ул һаман да хәстәрлекле Ана –
Ул туйдыра адәм баласын.
Җир турында шундый фикер йөри:
Изге, имеш, шагыйрь туганга.
Җир ул безгә изгеләрдән-изге
Туган төбәгебез булганга!
Газиз җир ул мәңгелектән килгән
Изгеләрдән-изге төшенчә.
Изгелеге аның бәйле бары
Кеше күңеленә, минемчә...

## Ил һәм шагыйрьләр

*Хәерче илдә шагыйрьләр күп була.*
Зөлфәт Хәким

Шагыйрь булу – хәерчеләр эше,
Байларның бит уе башкада.
Ил турында шагыйрь генә уйлый,
Муенына элмәк асса да.

Туган илем, газиз туган илем!
Яраталар сине фәкыйрьләр!
Тән азыгы түгел, җан азыгы
Таба синдә фәкыйрь шагыйрьләр.

Синдә туган бөек шагыйрьләр бит
Таң калдыра бөтен дөньясын,
Ә син үзең туры сүзе өчен
Кайберләрен читкә куасың.

Рәнҗетсәң дә син аларны куып,
Сөюләрен барыбер җуймыйлар.
Җәфа чигеп, үлем көткәндә дә
Мәдхияләр сиңа укыйлар.

Күрәсең дә кебек, үзең һаман
Үзгәрмисең, нидер көтәсең.
Газиз илем! Син бит үз халкыңны
Кыйный-кыйный шагыйрь итәсең!

## Алга атлыйм

Алга атлыйм, барган юлда
Еллардан маяк куям.
Шушы юлдан берчак кабат
Кире кайтырмын сыман.

Гомер уза, миннән артта
Маяклар – еллар кала.
Шул елларның һәрберсе
Маңгайга эзләр сала.

Алга атлыйм, гомер бит ул
Атлата алга гына.
«Бәхет сине көтә», – диеп,
Бары алдата гына.

Туктый алмыйм, алга атлыйм
Язмышым сызган юлдан.
Бәхет тапсам, шушы юлдан
Кире кайтырмын сыман.

* * *

Халкымны мин үлеп яратамын,
Чын йөрәктән, артык сүзләрсез.
Сөюемә ачык дәлилләрне
Тормыш юлларымнан эзләрсез.

Халкымны мин үлеп яратамын,
Сөю хисе таша җанымнан.
«Халкым белән генә бәхетле мин»,
Дигән фикер чыкмый аңымнан.

Халкымны мин үлеп яратамын,
Тумыштан ук сөю бирелгән.
Тик халкымнан яшәү көче алам
Һәм яраткан туган җиремнән.

Халкымны мин шулай яратамын:
Яңарырмын, үлсәм, гөл булып.
Ул чакта да халкым назлар мине
Талгын искән җылы җил булып.

## Кыйнады дөнья

Кыйнады дөнья, кыйнады,
Ләкин мин бирешмәдем.
Гаделсезлек белән җирдә
Беркайчан килешмәдем.

Бирмәде дөнья, бирмәде:
Затлы кием кимәдем.
Байлык өчен горур башым
Һич кенә дә имәдем.

Куды дөнья, куды мине
Ачы җилләр истереп.
Җанымны төрде сагышка
Меӊ тапкырлар үтереп.

Интектерде мине дөнья
Бирми хәләл ашымны.
Кулым сузып яшәмәдем,
Горур тоттым башымны.

Кыйнады дөнья, ләкин мин
Яшәдем – бирешмәдем.
Җан өшеткеч җилләрендә
Төз тордым, бөрешмәдем.

Үзем беләм: бетәр бер көн
Язган ризык-ашым да.
Башым кебек горур торыр
Җирдә кабер ташым да.

## Авыл җире

Яздан алып көзгә кадәр,
Баш имичә җилләргә,
Үсә бары чүп үләне
Уӊдырышлы җирләрдә.

Мул уӊышлы диӊгез-кырлар
Керә хәзер төшләргә.
Чөнки кырга чыгучы юк
Иген игеп эшләргә.

Карашлар да үзгәрделәр
Иген игү эшенә:
Тир түкмичә рәхәт яшәү
Кирәк хәзер кешегә.

Ташландыкка әверелде
Инде күпме авыллар!
Авылларны җимерерлек
Илдә дәһшәт-давыл бар...

Буран ясин укый сыман
Кышкы авыл җиренә.
Авыллар да ак кәфенгә
Төренгәндәй күренә.

## Каендай саргаермын

Күӊелемә ялгыз каен
Булды никтер ятышлы.
Әллә шуӊамы тормышым
Ифрат та сагышлы.

Синсез мин бит ялгыз каен
Иркен җиһан-яланда.
Өзгәли җил ялгыз җанны
Сагыш-яӊгыр яуганда.

Синсез салкын җәйге яӊгыр,
Яуганда да челләдә.
Ялгыз җаннар өшидер ул
Кызу комлы чүлдә дә.

Сине көтәм, өметләнәм,
(Ялган өмет яшәтә).
Сагышларны баллап бирә,
Күӊелне дә яшәртә.

Мин каенга охшаш булгач,
Каендай саргаермын.
Гомеремдә сине генә
Сагынып картаермын.



Айгиз
Баймөхәммәтов

# УРАМ БАЛАЛАРЫ

ПОВЕСТЬ

I

Тезләрен кочаклап, көчек шикелле бөгәрләнеп яткан малай дер калтырап уянды. Тышта караңгы төшеп тә өлгергән икән. Бая ике кат свитер киеп, юрганга төренеп яткан иде дә. Суык барыбер үзенекен итте, тәне калтырый, тешләре тешкә тими.

Караватта ятып түзмәде малай, өйнең икенче ягына чыгып, өстәл янына килде. Ике стакан белән буш шешәдән башка бернәрсә дә юк. Ул киштәләрне, тартмаларны ачып карады. Ичмасам, ярма йә бер-ике бөртек бәрәңге табылсачы...

Ачыккан, калтырануыннан тынычлана алмаган малай аптырап утыра бирде дә җан ачуыннан:

– Әни тагы эчәргә киткән! – дип кычкырып елап җибәрде.

Кала читендәге шушы агач йорттан кеше өзелми. Әнисенең шешәдәш дуслары өчен монда ишек һәрчак шар ачык. Ике ел элек Данилның әтисе үлгән иде. Кеше коткарам дип, күлдә баткан... Әллә кайгысыннан, әллә ялгызлыктан әнисе эчүгә сабышты. Берзаман әллә нинди ят ирне өйгә алып кайтты да бергә яши башладылар.

Әтисе дөнья куйганнан бирле Данил тыныч тормышны онытты. Тәмле аш авыз иткәне, җылы өйдә йоклаганы, яхшы кием күргәне булмады. Әйтерсең лә, әтисе үзе белән бөтен котны алып китте. Туганнары да юк бу калада. Әтисе үләр алдыннан Үзбәкстаннан күчеп кайткannar иде алар. Бөтен якын кешеләре шул якта торып калды.

– Болай булмый, – дип, үзалдына сөйләнде Данил. – Ничек тә өйне җылытырга кирәк...

Шул ният белән ул тышка чыкты. Ихатаның теге, бу ягына барып карады. Утын түгел, чыра да юк. Шушы март ае тиз генә үтеп китми, дип сукранды

---

Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ (1988) – *язучы, журналист; татар, рус, башкорт, казакъ телләрендә чыккан «Калдырма, әнкәй!», «Урам балалары», «Кызык бу тормыш...» кебек китаплар авторы. Шәехзадә Бабич исемендәге Башкортстан Дәүләт республика яшьләр премиясе лауреаты. Уфада яши.*

ул үзалдына. Җир кардан арынса, көннәр дә аязыр, өйдә дә ул тиклем салкын булмас иде.

Ихатада бернәрсә дә тапмагач, Данил бакчага чыкты.

– Таптым, – дип куанды ул, бакча уртасында үсеп утырган чыршыны күреп. Тиз генә агачның корыган ботакларын сындырып алды да өйгә йөгерде.

Шуннан ылыслы ботакларны ваклап, ипләп кенә мич эченә өйде. Шырпы сызып, ылыска якынайтуы булды – анысы шытырдап янып та китте. И, куанды малай, и, сөенде! Ялкынга учын якынайта биреп, җылынырга утырды. Тик бу шатлыгы озакка бармады. Ылыслар тиз арада көлгә әйләнеп өлгерде, ә ботаклары тырпаеп калды. Ут сүнде...

Кәгазь салырга кирәк булган, дип уйлады малай. Өй буйлап кәгазь эзләргә тотынды. Саргаеп беткән гәзит тапты. Өстәл астында тузып яткан чүпрәк-чапракны да мичкә тыкты.

Кәгазь янып китте. Ялкын чүпрәкләргә күчте.

– Сүнмә инде, ут, сүнмә! – Данил, өшеп беткән бармакларын җылытырга маташып, янә ялкынга кулын якынайтты. Учак бер дә дөрләргә ашыкмады. Иске-москы пыскып, өйгә төтен таралды.

Шулчак тышта кемнеңдер йөткергәне, берәүләрнең шаркылдап көлгән тавышы ишетелде. Ишек шар ачылып китте дә кичке кунакларның йөзе күренде. Бусагада әнисе, үги әтисе һәм тагы ике ир пәйда булды.

– Нәрсә өйне төтенгә тутырып утырасың?! – Мич алдындагы Данилны күргәч тә, хуҗабикә тамагы ярылырдай итеп кычкырып җибәрде. – Кулыңнан бер эш килми, маңка! Ашарга таптырудан башка бернәрсә дә белмисең!

Малаена җикеренә-җикеренә, пимасын салып тормыйча, әнисе түргә үтте, кесәсеннән шешә чыгарып, шап иттереп өстәлгә куйды.

– Йә, нәрсә карап торасыз, исемләп чакырганны көтәсезме?! – диде ул әшнәләренә.

Бу мәҗлеснең ничек бетәсен Данил яхшы белә. Талаш-сугыш, барлы-юклы стаканнарны вату, елаш-сыкташ булачагы көн кебек ачык.

– Әни, эчмә инде!

Ләззәтләнеп аракы коя башлаган хатынны бу ачуландырды гына. Урыныннан сикереп торды да улының якасына ябышты.

– Син генә, корыгыр, миңа акыл өйрәтмәсәң инде! – Әнисенең пычранып, көрәккә әйләнгән куллары малайны шул тиклем кысып алды, җибәрергә дә уйламый. – Синең өчен генә күпме сүз ишеттем, беләсеңме?! Мәктәпкә йөрмәсәң дә, мин гаепле, пычрак киенеп барсаң да – мин. Өйгә бирелгән эшеңне эшләмәсәң дә – мин. Егет булып беткәнсең – һаман минем җилкәмне кимерәсең. Син туганчы, мал туса, ичмасам, бер файда булыр иде. Башкача өнең чыкмасын, көчек, җанымны көйдерсәң, йә сугып үтерермен! – Шулай төкереген чәчә-чәчә, әнисе Данилны җилтерәтә бирде, малай аның кулларыннан ычкынмакчы булып, тартышып маташты:

– Җибәр мине, җибәр!..

Данилның бу гамәле үги әтисенә җитә калды.

– Җибәр әле шул маңканы! – дип кычкырып әйтте ир. Әнисе, калтыранып, тынычлана алмыйча өстәл янына барып утырды.

– Нәрсә, кеше булдыңмы, ә?! – Куе мыеклы, тәбәнәк буйлы, аракы исе аңкып торган ир елан кебек ысылдап, малайга якынайды. – Һаман борыныңны тыгасыңмы? Теге чакта да эшне син боздың, сволочь!

– Нинди эшне?

– Үзең беләсең. Исәргә салышма.

Усал караштан Данилның буыннары җебеде. Аның күзенә карамаска тырышып, башын читкә борырга да өлгермәде, чигәсенә шап иттеләр. Күз алдында очкыннар чәчрәп китте. Башы әйләнеп, идәнгә тәгәрәде.

Янына килеп юатыр, гафу үтенер дип, Данил, яшьле күзләрен мөлдерәтеп, әнисенә карады. Дөньядагы иң якын кешесе моңа игътибар да бирмәде:

– Ярый, җаным. Кызма! – дип, иргә әйтте дә аны өстәл янына чакырды.

Үги әти тынычланырга уйламады.

– Нәрсә бичәләр кебек мышнап ятасың, ну-ка, тор! – Каты куллары белән Данилның терсәгеннән эләктереп, аягына бастырырга маташты, гыжылдап җикеренә бирде.

– Кайчан безгә яшәргә хут бирәсең, хөрәсән?! Әниеңә тагы бер сүз әйтеп кара – сугам да егам. – Шулчак үте сытылырдай чиккә җиткән үги атасы өйгә тулган төтеннән чәчәп йөткерергә кереште. Бераздан: – Өйне нигә төтен белән тутырдың, инәңне! – дип, Данилны җан ачуыннан төртеп җибәрде. Болай да юньле ризык күрмәгәнлектән ябыгып, хәлсезләнеп беткән малай очып барып төште. Борыныннан чәчрәп кан чыкты.

Ирнең бу тиклем шашынуын күреп, әнисе тынычландырырга тырышты.

– Ярый, җитте, җитте! Иртәгә үзем иманын укытырмын әле, – дип, ирнең аркасыннан сөеп алды. – Утыр инде, утыр!

– Ух, маңка! Мин сине тегенең өчен никогда не прощу!.. – дип сөйләнә бирде аракыдан шашынган ир. – Бигрәк өйне төтенгә тутырган. Бернәрсә дә күренми! Ут куйма! Тавык кебек күшексен әйдә. Без үлмәбез. Менә бу бөҗәк иртәгә үк катачак!

– Нинди зыяным тиде сезгә? – дип ишетелер-ишетелмәс пышылдады малай. – Мин бит җылынырга гына теләдем!

Эчкечеләрнең шаркылдашып көлүе, бер-берсе белән ярыша-ярыша бәхәсләшүе, Данилны мыскыллап телгә алулары бергә буталып, малайның башында кайнады. Өйдә суык, төтен дә таралмый. Тешләре тешкә тими, дер калтырап, идәндә ята бирде ул.

Түзә алмады Данил. Караватка түшәк урынына җәелгән курткасын киде дә урамга чыкты.

Ишегалдына чыккач, шешкән иреннәренең сызлавын киметер өчен, карны учына йомарлап, авырткан урынына басты. Тәне тоташтан сызлый.

Данил бәләкәй чактан йолдызларны күзәтергә яратты. Аларның исемен дә, ничек урнашканнарын да яхшы белә. Боларны әтисе өйрәтте. Әле дә, үзен тынычландырырга теләгәндәй, күккә бакты. Ләкин анда бер йолдыз да күренми. Күк гөмбәзен кап-кара, куе болытлар каплап алган. Алар, өйдәге төтендәй, һич беркайчан таралмас сыман тоелды аңа.

– Әллә тоташ дөньяның миче төтенли инде?! – Бу уй малайның башына үзеннән-үзе килде.

Данил ихатадан чыкты да күпкатлы йортлар ягына юнәлде. Әнисенең аны җан көченә җилтерәтүе, үги әтисенең таштай каты куллары белән дөмбәсләве һаман да күз алдыннан китмәде. Шул авыр минутларны исенә төшереп, сыктый-сыктый атлый бирде ул.

Караңгы төндә кая, кемгә барырга? Бу сорауга ул җавап таба алмады әле.

## II

Данил төне буе йоклый алмады. Моңа тиклем аңа урамда кунарга туры килмәгән иде әле. Нихәл итәсең – башка чара юк. Өеннән чыгып киткәч тә, биш катлы йорт подъездына килде. Иң югары катка күтәрелеп, туңып беткән

кулларын батареяга терәп җылытып алды. Сөякләргә бераз җылылык йөгергәч, кәефе күтәрелгәндәй булды. Тышта бер адәм заты күренми. Башына, әллә кире кайтыргамы, дигән икеле уй килде. Теге эчкечеләр янынамы? Юк! Ач тамагым – тыныч колагым. Нәрсәгәдер үз итми аны үги әтисе.

Теге көнне соң... Әнисе исерде дә бернәрсә белми йоклап китте. Ә үги әтисе Данилга йокы бирмәде. Малай инде черем итә башлаган гына иде, алҗыган ир аны көчләп дигәндәй караватыннан торгызды. «Әйдә, сине сугышырга өйрәтәм!», – диде ул исе дә китми. Данил ничек кенә каршы торып карамасын, теге барыбер үзенекен итте. Имеш, боксёр итмәкче була малайны. Йодрыкларын төйнәп, берничә тапкыр мичкә сугып алды. Шуннан кабатларга кушты.

– Кул авырта, ошамый миңа бу бокс, – дип карышты малай.

– Әгәр куркак икәнсең, хәзер үзеңә сугып карыйм! – дип янады ир. Исерек кешенең башында нинди уйлар барлыгын белеп булмый, шуңа шүрләде Данил. Аның кушуын үтәмичә чара калмады. Мичкә кат-кат суга торгач, бармаклары канап бетте. Ә «әти» олы куаныч белән сөйләнә бирде:

– Мин барда өйрәнеп кал! Азак үзең бөтенесен дә тукмарсың.

Икенче көнне дә шул хәл кабатланды. Бармаклары сыдырылып, күгәреп беткән иде Данилның.

Исерек ир тагы күнекмә эшләтергә булгач, малай каршы торды:

– Нигә мин исәр сыман мичне тукмарга тиеш? Кулларым сызлый, башка алай итмим!

Бу сүзләр «йорт хуҗасын» ачуландырды гына. Күп уйлап тормый малайның җиңеннән җилтерәтеп тотып алды да яланаяк көенә тышка куып чыгарды.

– Каршы сүз әйтеп маташа, көчек! Әнә, тор тышта. Акылга утыргач керерсең.

Кышның салкын төне иде. Данил күпме шулай тышта киемсез торгандыр – хәтерләми. Бәлки, ун минут чамасыдыр. Ләкин шул ара аңа мәңгелек булып тоелды. Чарасыздан түзә алмый бер аягыннан икенчесенә сикеренгәләде. Аякларын тоймый башлагач, учы белән аларны уып та маташты. Тик әнисе генә күрмәде улының болай изалануын. Ул күптән исереп йоклый иде. Күпмедер вакыт үткәч, үги әтисе ишекне ачты.

Арыды Данил мондый мыскыллаулардан. Әгәр өенә кайтса, теге исерек ир аның башыннан сыйпап торырмыни?..

...Малай батареяга сыенып, оеп кына киткән иде, подъезд ишегенең шапылдап ябылуына дертләп уянды. Өскә күтәрелгән тавыш ишетелде. Урта яшьләрдәге апа икән.

– Бә-әй, бу кем баласы? – диде ул, малайны күреп. – Кемгә килгән идең?

– Беркемгә дә түгел, – диде калтыранган тавыш белән Данил. – Җылынырга дип кенә кердем.

– Алай икән... Ярый, подъездны пычрата күрмә. Югыйсә, бүтән аягыңны бастырмабыз! – Хатын бу малайның сукбай булуына төшенде шикелле. Югыйсә төн уртасында нинди әни баласын урамга чыгарып җибәрсен, ди. Уртача буйлы, кап-кара күзле, озын керфекле, сөйкемле генә күренгән бу малайны ханым жәлләп куйды. – Әллә ачыккансың инде?

Бу сүзләрне ишеткәч, Данилның авызына әчкелтем сыекча йөгерде.

– Иртән ашаган идем дә ул, – дигән булды малай. Күптән яхшы аш күрмәсә дә, таныш түгел апага дөресен әйтергә оялды.

– Хәзер, көтеп тор чак кына...

Апа май ягылган ике телем икмәк чыгарды. Хатынның фатирына кереп

киткәнен дә көтеп тормады ул, тансык ризыкны кабалана-кабалана ашарга тотынды. Икмәк сыныгы эләккәч, бу апага рәхмәт әйтергә дә онытты.

Ике телемне Данил «эһ!» дигәнче ашап куйды. Идәнгә коелган валчыкларны да чүпләп капты. Эчтән генә теге мәрхәмәтле апага кат-кат рәхмәт укыды. Тик тамагы туймады. Тагын да ныграк ашыйсы килде. Бәлки, тагы берәрсе өенә соңлап кайтыр, шул кешедән сорармын дип уйлаган иде дә, бүтән подъездга керүче булмады.

Таң аткач, малайның ашау теләге арткannan-арта барды. Башы әйләнә, эче чәнчеп-чәнчеп куя. Күзен йомса, аның алдында зур күмәч яткан кебек. Ахырда кичәге икмәк биргән апаның ишеген шакыды.

– Бәй, син һаман мондамыни?.. – диде малайны күреп, эшкә кабаланып йөргән хатын.

– Апа, берәр телем икмәгегез булмасмы?

– Әй, Ходай! Ни булды бу дөньясына?! Кая карама – ятимнәр. Берәүнең беркемдә эше юк! – Хуҗабикә башын селекте дә кереп китте. Иртән генә пешергән ике йомырканы тәлинкәгә салды, икмәк телеп, май якты.

Ишек төбендә күзләрен мөлдерәтеп торган малайга сыен бирәм дип, подъездга чыккан иде, күршесенә тап булды. Ул алама киенгән малайны, ризык тоткан күршесен күреп, котырынды да китте.

– Гомер бакый теләсә кемне подъездга ияләштерәсең, – диде ул Данилның кичәге танышына. – Шул сукбайларның монда кереп эчү, пычратулары җитмәгән, тагы ашатып маташасың!

– Син баланы эчкечеләр белән бутама, яме. Аның сиңа ни зыяны тигән?

– Яклашма шуларны. Әнә, почта тартмасына хат салыр әмәл юк, ут төртәләр дә китәләр, ут төртәләр дә китәләр. Идәнне көнбагыш кабыгы белән кем тутыра дисең?

– Куй, күрше, син кеше хәленә керә белмисең...

– Җитәр! Подъезд буенча мин җаваплы! – диде теге хатын, авызын очлайтып, шуннан Данилга якыная төшеп, аны куарга тотынды. – Хәзер үк эзең булмасын! Югыйсә иремне чакырам. Бар-бар, торма монда теләнеп!..

Ризыкны кулына да алып өлгермичә, Данил усал апаның әрләвеннән куркып, чыгып сыпыртты.

Йорттан чыккач та кая барырга икән, дип аптырап торды. Беркемгә дә кирәкмәгән, дөньяда бөтенесенә дә комачаулаган көчек кебек хис итте үзен. Шушы уйларга бирелеп, авыр тын алды да каршыдагы йортка таба атлады.

Малай бүтән якка китәргә җыенганда гына, күзенә катыргы тартма чалынды. Игътибар итмәслек тә түгел: теге нәрсә йә алга, йә артка таба хәрәкәт итә. Бу нәрсә икән дип гаҗәпләнде Данил. Бәлки, җилгә шулай? Алайса бер якка гына шуар иде. Әнә бит, уң якка борылды, тагы алга шуа башлады. Менә сиңа мә!

Малай түзмәде. Танавын каплады да янына барды. Тартманы күтәреп җибәргән иде, дерт итеп калды! Аның алдында чем-кара төстәге матур гына көчек уйный башлады. Күрәсең, шушында ризык эзләп йөргәндә, ялгыш тартма каплаган да куйган. Күзләре соры, үзе кап-кара, бәләкәч кенә койрыгын уңга-сулга селтәгән була. Данил көчекне кулына алды. Аның маңгаенда йолдыз кебек ап-ак билгесе бар. Малай аны яратып сыйпап алгач, көчек иркәләнде дә китте.

– Сине дә әниең ташлап киттеме, бахыркай? – дип эндәште Данил, көчекнең хәленә кергәндәй. – Курыкма, бәләкәчем, мин сине үземә дус итеп алам. Мин Данил булам. Ә синең исемең ничек? Нигә шул тиклем аптырап карыйсың? Белмисеңме исемеңне? Алайса, сиңа Йолдыз дип исем кушам.

Ишеттеңме, Йолдыз! Әнә маңгаеңда нинди матур йолдызың бар. – Малайның шулай сөйләнә-сөйләнә, йомшак кына сыйпавыннан көчек күзләрен йомып, рәхәтләнеп иркәләнә бирде. Шулчак зур гына этнең ырылдап туп-туры аңа таба килүен күрде. Малайны тешләргә тырышып, ажгырып килә. Данил, коты очып, көчекне кулыннан ычкындырганын сизми дә калды. Ә Йолдыз бернәрсә булмагандай теге эткә барып сарылды. Анысы һаман тынычланырга уйламый. Данил читкә качкач кына басыла төште. Шуннан эт, көчеген иркәләп, ялап алды.

Данил яңа гына танышып өлгергән «дусты»ннан һич кенә дә аерылырга теләмәде.

Читтән генә күзәтә бирде. Сокланып, ничектер көнләшеп карады ул көчек белән эткә. Әнисе янында булгач, Йолдыз йә аунап ала, йә аның аягын тешләп маташа. Ә әнисе яратып кына колагыннан тешли, аркасыннан ялый. Читтән генә карап утырып түзмәде Данил. Көчекне үзенә ияләштермәкче булып, шым гына чакыра башлады:

– Йолдыз, Йолдыз, кил, кил!

Малайның бу кыланышын күреп, эт сагая төште, колакларын тырпайтты. Ә Данил һаман үзенекен кабатлады:

– Йолдыз, Йолдыз, кил, кил!

Малайның иркәләп назлавы ошап калган, күрәсең, көчек әнисе алдында уралды-уралды да туп-туры Данилга таба йөгерде.

– Кил инде, кил! – дип аны дәртләндерде малай. Йолдыз уйнаклап, шатлыгын яшерә алмый, бәләкәй генә телен чыгарып килеп тә җитте. Кешенең үзен болай тотуына аптырап куйды әнисе. Шулай да көчегеннән калмады. Аңардан өч адымда гына туктап, күзәтеп торды. Кешенең көчеккә карата ихласлыгы, изге нияте йөзенә чыккан иде.

Көнләшүен яшерә алмаган эт ырылдап куйды. Ә көчеге моңа игътибар итми дә, малайның аягы арасында бутала, аңа өреп маташкан була. Бу кешенең бер зыяны тимәячәген сизеп, эт тынычланды.

– Ачуланма инде миңа! – диде Данил, кап-кара эткә карап. – Мин бит аны ялгыз дип уйладым. Ә син миңа ташландың. – Малайның үпкәләгәндәй тыныч кына сөйләгәннәрен эт башын йә уңга, йә сулга борып тыңлады. – Телисеңме, икегезне дә үземә дус итеп алам. Көчегеңә Йолдыз дигән исем дә куштым. Ә син, әйтимме, кем буласың? – Бераз уйлана бирде дә шатланып, яңа исемне әйтте. – Юлдаш!

Шулай җайлап кына эткә якынлашты Данил. Яңа гына исем алган Юлдаш карышмады. Малай курка-курка гына кулын этнең аркасына салды, иплəп кенә сыйпап алды.

– Хәзер ялгызым түгелмен, – дип шатланып сөйләнде малай. – Мин бәхетле: бер көн эчендә Йолдызлы да, Юлдашлы да булдым!

Шатлыгыннан ул контейнерлар янына нәрсә өчен килгәнен дә онытты. Бераз шулай яңа юлдашлары белән уйный торгач, корсагы туктаусыз бгырдый башлагач, ач икәнлеге исенә төште. Кичә үги әтисе сугудан ярылган иреннәрен ялап куйды.

– Сез миңа үпкәләмәгез, зинһар, – диде Данил, – берәр телем икмәгем булса, өчебезгә дә уртак бүлеп ашар идек. Юк шул... – Ышанмыйсызмы, менә карагыз дигәндәй, кесәсен әйләндергән иде, аннан икмәк валчыгы җиргә сибелде.

Эт сискәнеп китте. Бая җилеп килгән ягына чапты. Бертиклем баргач, авызына нәрсәдер эләктереп, кире болар ягына йөгерде. Данил этнең авызында

нәрсә икәнен күргәч, аптырап калды. Юлдаш бер бөтен икмәк кабып алган! Эт икмәкне малайның алдына салды да, берничә адым артка чигенеп, җиргә ятты.

Бу хәтле дә ап-ак зур икмәкне кулына алгач, Данилның эченә җылы йөгерде. Ул икмәкне сындырып, бер өлешен көчеккә бирде дә, кабалана-кабалана, зур кисәкне ашый башлады.

– Ах, тәмле!.. Ух, тәмле!

Юлдаш, олы канәгатьлек хисе кичергәндәй киерелеп, кеше белән көчекнең тәмләп, икмәк ашаганын күзәтте.

***

Данилның күптән инде туйганчы уйнаганы юк иде. Ике яңа дусты белән рәхәтләнеп йорт тирәли йөгереп кинәнделәр. Эт тә көчегенә ияреп, сабыйларча куанып, малай тирәсендә бөтерелде, туры килгәндә, аның битен дә ялап алды.

Биек йорт алдындагы мәйданчыкта тиргә батып куыша торгач, Данилның тамагы кипте, су эчәсе килде. Тик аны кайдан алырга? Кибеттә берәү дә бушка бирмәс. Әгәр берәр фатирга ишек шакып караса?! Шул ният белән малай Юлдашны, Йолдызны ияртеп, беренче подъездга таба атлады. Йорт эченә керергәме-юкмы дип икеләнде ул, ишек янына килеп җиткәч. Бүген иртән генә теге йорттан ничек куылуын исенә төшергәч, авыр ютәлләде.

Подъездның ишегенә үрелгән иде, каршысына ниндидер кыз йөгереп килеп чыкты да ялгыш малайга бәрелде.

– Ай, гафу итегез! – диде сылукай, уңайсызланып. Сезнең бернинди дә гаебегез юк дигәндәй, Данил ихлас елмайды.

Чибәркәйнең төс-башына шунда ук игътибар итте малай. Гүзәл чәчкә кебек күренде аңа бу кыз.

Кыз ишек төбендәге көчеккә сокланып, аңа омтылды. Йолдыз алдына чүкте дә аны сыйпарга тотынды.

– Кара әле, нинди матур! – Кыз куанычын яшермәде. – Бу синең көчегеңме?

– Әйе! – Данилның җавабында ниндидер горурлык бар иде. – Исеме Йолдыз аның!

– Ул чынлап та Йолдыз! Шундый сөйкемле! – Кызыкай көчекне җылы сүзләр белән назлады. Шуннан малайга борылды да:

– Көчегең белән таныштырдың, ә үзең белән юк, – диде көләмсерәп.

– Данил булам! Ә син?

– Ләйсән!

– Сиңа ничә яшь? Миңа – унөч.

– Кызларның яшен сорарга ярамый! – Ләйсән көлеп җибәрде. – Ярый әйтим, миңа да унөч.

Шулай көтмәгәндә, ишек төбендә таныштылар. Яңа очраткан кызга нинди сорау бирергә дә белмәде Данил. Моңа тиклем кызлар белән танышканы юк иде, югалып калды. Ләйсән көчекне шул тиклем үз итте. Җибәрергә дә уйламый, уйнатуын белә. Ә Йолдыз сикергәли, нәзек тавышы белән өреп маташа.

– Син аңа якынрак иел әле, – дигән булды Данил, акыл өйрәтеп, – ул синең битеңне ялаячак. Теле йомшак, бәбәйләрнеке кебек.

Ләйсән көчек белән уйный бирде, ә Данил кызны сиздерми генә күзәтте. Ниндидер яңа хисләр аны чолгап алганын үзе дә аңлап җиткермәде. Ничектер йөрәк тирәсен рәхәт җылылык кытыклаган кебек.

– Көчекнең ашыйсы киләдер, – диде Ләйсән, хәстәрлек күрсәтеп. Данил шулвакыт су сорарга ниятләде.

– Юк, рәхмәт, без ашап алдык та ул, – диде оялчан гына. – Менә су булса, эчәр идек. Мин дә, этем дә, көчегем дә сусады. Ә өебезгә тиклем әле атларга да атларга...

Ләйсән йөгереп кереп китте. Күп тә үтмәде, су алып чыкты. Тәүдә үзе белән алган тәлинкәгә коеп, Йолдызның алдына куйды. Көчекнең кинәнеп, су ялаганын күреп, койрыгын болгап, Юлдаш килеп җитте. Банканың яртысында калганын кыз малайга бирде.

Ләйсәннең көчеккә карап шул тиклем күзе кызды. Хәзер үк үзенең фатирына алып кайтырга риза иде. Тик хуҗасы бар шул. Ахырда кыз сорамыйча булдыра алмады:

– Данил, синең бер этең бар бит. Әллә көчегеңне миңа бирәсеңме?

Бу сүзләрне ишеткәч, малайның төсе үзгәреп китте:

– Юк, юк, юк! Ул – минеке, берәүгә дә бирмим!

Кыз үзе дә әрсезлегенә уңайсызлангандай итте.

– Борчылма, – дип юатты малай. – Мин шушы тирәдә еш булам. Теләсәң, Йолдыз белән бергәләп уйнарбыз.

Ләйсән куанып, елмаеп җибәрде. Шулай озак кына ишегалдында тордылар. Көчектән аерыласы килмәде кызның...

Данил, Ләйсән белән хушлашкач, базар ягына юнәлде. Андагы рәтләр янынннан кат-кат үтте. Бигрәк тә икмәк, төрле җиләк-җимеш сатылган урыннарда озак торды. Эт белән көчек тә «әйдә, шул тәм-томнарны алып ашыйк» дигәндәй, янында уралдылар. Их, беркем дә хәленә керми шул малайның! Шушы калачларга, конфет-печеньеларга караганда, авызына су җыелганын, ичмасам, берәрсе сизсә иде!

Тегеләй-болай йөри торгач, кич тә якынлашты. Тирә-якны караңгылык баса башлады.

Данил бәләкәй чактан караңгыдан курка. Ниндидер шайтаннар, җен-пәриләр кич ауга чыга, имеш, дип ишеткәне бар. «Бүген төнлә кайда йоклармын икән? Суыкта урамда туңмасам ярар иде», дигән уй башында урала. Йоклар урынның булмавы аны бөтен шайтаннардан да ныграк куркыта.

– Бүген икенче йортның подъездына кереп карыйбыз, – дип эндәште ул янында торган дүрт аяклы дусларына. Бераз уйланып торгач, биек йортлар янына юнәлде. Ә Йолдыз белән Юлдаш аннан бер адым да калмады.

Караңгы тыкрыктан китеп барганда, артыннан ике кеше ияргәнен сизеп калды Данил. Күздән яздырмакчы булып, уңга да борылып карады. Әмма тегеләр бер дә калырга уйламый. Куркуыннан малайның йөрәге дөпелдәп тибәргә кереште. Егерме метрлар чамасы ераклыкта ике малай ияреп килә. Данил адымнарын шәбәйтсә, алар да тизрәк атлый. Куркуыннан тиргә батты. Йөрәге атылырдай булып тибә.

Качарга! Тиз генә көчекне кулына алды да җан-фәрман йөгерергә тотынды. Юлдаш та аны узып китеп алга чапты.

– Тукта, дидем, тукта!

– Хәзер аягыңны сындырам!

Куучыларның сүзләрен ишеткәч, Данил тагын да кызурак йөгерә башлады. Ә тегеләр туктарга уйламый да, җилдерә генә!

– Тукта! Тукта!

Ах, каһәрең! Шушы якларны начар белә шул Данил. Бернәрсәгә дә карамый алга йөгереп, капкага килеп төртелермен дип уйламаган иде дә. Ике яктан биек йорт, ә алда – койма. Малайның буыннары калтырый. Куркуыннан елар чиккә җитте. Теге эзәрлекләүчеләр шунда ук куып тотты. Үзләре алама киемдә, өс-башлары сәләмә. Берсе куып җиткәч тә, туктап та тормыйча, җан ачуыннан

Данилга сукты. Малай тәгәрәп барып төште, көчек тә чыелдап тәгәрәп китте. Бәләкәченең елавын күреп, кара эт ырылдап, тегеләргә ташланды.

Икенчесе, тәбәнәге, кулына таяк тоткан икән. Эттән куркып, аны таягы белән куып маташты.

– Этеңне тый, этеңне! – диде озынрагы, ялваргандай итеп.

– Ал, дидем, кәнтәеңне!!!

Данил Юлдашны тынычландырырга тотынды.

– Җитәр, Юлдаш! Юлдаш, җитте, җитте, тынычлан!

Зур батырлык күрсәткәндәй, Юлдаш өрде-өрде дә, бераздан тынып, Данил янына ук килеп басты.

– Мин сезгә нәрсә эшләдем? – диде Данил, аптырап.

– Ә нигә без әйткәндә туктамадың? – Озыны малай ягына якыная бирде.

– Әллә...

Сүзгә таяк тоткан тәбәнәге дә кушылды:

– Син нәрсә эшләп йөрисең безнең территориядә?

Данил ни дип җавап бирергә дә белмәде.

– Йә, ярый, шүрләмә, әйт, нәрсә өчен монда килеп чыктың?

– Өйдән чыгып киттем дә... – диде ул, кулын селтәп.

Бу сүзләрне ишеткәч, озын малай куанычын яшерә алмады:

– Болай булгач, үзебезнең пацан булып чыгасың бит...

– Нигә күптән әйтмәдең аны, димәк, дус булыйк, – тәбәнәге исәнләшер өчен кулын сузды. – Без сине берәр «добыча» дип уйласак...

Данил икесе белән дә кул биреште. Сүзне озыны дәвам итте:

– Әйдә, танышыйк! Мин Цыган булам. Унбиш яшь.

– Ә мин – Орех! Уникe яшь, – дип кушылды тәбәнәге. – Ә синең кушаматың бармы?

– Исемем – Данил. Унөч яшьтәмен. Ә нигә исемегез шул тиклем кызык ул?

– Сөйләсәң, озын хәбәр инде. Курыкма, сиңа да кушамат табарбыз, – диде үзен Цыган дип таныштырганы. – Син теплицадан качкансың инде...

«Аңламадым» дигәндәй, баш какты Данил.

– Теплица, димәк, ул − өй! – Якыная биреп, Орех төшендерергә тырышты. – Теплицада кыяр, помидор кебекләрне үстерәләр бит. Өйдә дә шулай, андагы малай-кызлар әзергә яши. Ә без үз тамагыбызны үзебез туйдырабыз.

– Син, Данька, хәзер кая барырга уйлыйсың?

– Әллә...

– Караңгыда ялгыз йөрүе куркыныч. Киттек. – Безгә ияр дигәнне ишарәләп, Цыган алга ымлады.

– Беләсеңме, безнең нинди әйбәт урыныбыз бар? – диде Орех. – Күпләр шунда яшәргә хыяллана! Беркем дә сиңа шулай ит, болай ит дип, акыл өйрәтмәс. Мәктәпкә бар диюче юк, күпме телисең – шул хәтле йоклыйсың. Җылы, беркем дә борчымый.

Шушы караңгы дөньяда тагын кая барасың, дип уйлады да Данил малайларга иярде...

## III

Әллә ни ерак китәргә туры килмәде. Бер-ике биек йортны үттеләр дә биш катлы йорт алдына килеп бастылар, Цыган тирә-ягына каранды. Күрәсең, кемдер күреп калмасын өчен шулай сак кылана.

– Бу турыда беркемгә дә сөйләргә тиеш түгелсең! Секретный объект, – дип җитди генә эндәште Данилга.

– Ярый.

– Әгәр берәрсенә әйтсәң, үзеңә үпкәлә. – Орех дигәне сүзгә кушылды.

Подъезд янында подвалга төшә торган урын бар. Цыган аны ипләп кенә ачты да эчкә үтте. Малайлар да, көчеге белән эт тә аның артыннан иярде.

Үзенең өен Данил ничектер котсыз, пычрак итеп күрә иде. Юк, ул ялгышкан икән. Менә бу, ичмасам, шайтан оясы. Кайда карама – чүп-чар, шешә савытлары, чүпрәк-чапрак тузып ята.

– Шушы була инде безнең өй. – Цыган елмаеп, яшәгән урыны белән таныштыра башлады. Ничек атарга бу урынны? Бүлмә дисәң, бүлмә түгел, келәт дисәң, аңа да охшамаган. Гади генә күпкатлы йортның ташландык подвалы. Монда кешеләр кереп йөрми. Сантехниклар берәр авария була калса гына төшәләр. Монда Цыган белән Орех хуҗа. Күрәсең, алар инде монда бүген генә килмәгәннәр. «Өйне» үзенчә баетып та өлгергәннәр. Таш идәндә саргаеп беткән ике матрас ята. Ятар урыннары шушыдыр, дип уйлады Данил. Кайдандыр җимерелгән шифоньерның ишеген дә алып килгәннәр. Астына кирпеч салып, аңардан өстәл ясаганнар. Агач тартма да бар. Анда, күрәсең, ризык саклыйлар. Өстәлдә торган буш банкалар савыт хезмәтен үтиләрдер. Ничек кенә ямьсез, куркыныч күренмәсен, иң мөһиме − монда җылы. Уты да бар. Якты, җылы. Тагын нәрсә кирәк? Урам суыгында күшегеп йөргәнче, монда утыруың мең артык, дип уйлады Данил. Хәер, шул ук уй Цыган белән Орехны да монда алып килгәндер.

Баш очында әллә күпме торбалар тырпаеп тора, шунысы гына бераз теңкәгә тия. Канализация торбалары. Җитмәсә, вакыт-вакыт аның эчендә су шаптыр-шоптыр итеп ала. Теге икәү моңа игътибар итмәгәндәй, Данил да күнегер...

– Запасны чыгар әле! – Цыган эре генә боерды. – Кунак күрсен ничек шәп яшәгәнебезне.

Орех аның әйткәннәрен үтәргә генә тора. Агач тартманың эченнән пакет чыгарды. Ул пакет сыйлы гына булып чыкты. Өстәлгә икмәк, балык консервасы, колбаса кунаклады. Аларны бүлеп чыккач, Орех ашарга чакырды.

– Да-а, болар ничек яхшы яши, – дип уйлап куйды Данил. Мондый сыйны әле кайчан күргәне бар?

– Болар кайдан?

Шул сорауны гына көткәндәй, Орех йотлыга-йотлыга сөйләргә тотынды.

– Кичә кичен урамда йөреп ятабыз. Ниндидер исерек ир китеп бара. Бахыр аягында да тора алмый. Кулында – зур пакет. Теге чак кына бара да егыла, бара да егыла. Тайгак.

Аны бүлдереп, Цыган дәвам итте:

– Тегенең артыннан калмаска булдык. Тик урамда кешеләр күп. Шуңа артык якын барасы килмәде. Бер заман теге исерек караңгы урамга борылды. Тиз генә кулыннан әйберләрен тартып алдык та – сыпырттык. Бу әле пүчтәк. Анда тагы шоколад, кәнфитләр бар иде. Ашап бетердек.

Цыган бу төркемдә «башлык» икән. Беренчедән, ул – иң өлкәне. Икенчедән, яшәүнең рәтен-чиратын бүтәннәрдән яхшырак белә. Ни дисәң дә, өйдән бүген генә чыгып киткән кеше түгел. Аларның «гаиләсенә» килеп кушылуы Данилның күңелен күтәреп җибәрде. Күмәк – яу кайтарган, диләр бит. Бергә булгач, күңелле дә, җиңелрәк тә булыр. Тик этләрне генә ошатмады Цыган. Ярар, көчеге кирәк, ди. Ә зур эт нәрсәгә? Артык тамак. Ул бит һава сулап кына тук булмый. Тагы бер сәбәп бар: Цыган этләрне яратып бетерми. Беренче класста укып йөргәндә, урамда эт талаган. Күршеләрнең эте тиктомалдан

ябышып, аягының итен умырып алган, озак кына йөри алмый азапланган. Шуннан соң Цыган этләрне күрә алмас булган.

– Ә теге нәрсәне чыгармыйсыңмы? – диде ул Орехка.

– Үзең әйтмәдең бит. Хәзер без аны... – Орех янә тартмага үрелде. Күпмедер чокынгач, ялтыр шешә китереп чыгарды. Аны олы куаныч белән бер кулыннан икенчесенә сикертеп, малайлар алдына куйды:

– Тышта өшеп кителде. Әйдә, җылынып алыйк.

Аракыны күргәч тә, Данилны нәрсәдер чеметеп алгандай булды. Күп күрде инде ул шундый шешәне. Хисапсыз бәла, кайгы китерде инде ул йортларына. Әле килеп, яңа танышлары шуны эчәргә үгетли.

– Юк, малайлар, мин эчмим, – Данил кырт кисте. Цыган аптырап карап куйды:

– Кит, юкны сөйләмә. Әллә бер дә эчкәнең юкмы?

– Юк! Эчмәдем дә, эчәсем дә килми. Аны эчкән кеше акылын югалта. Күргәнем бар инде...

Орех та үгетләргә тотынды.

– Ул сиңа шулай күренә генә, Данил. Мин дә тәүдә шулай дип уйлый торган идем.

Данил күпме генә карышса да, тегеләр барыбер күндерде. «Берне генә йотып кара», «Аның начарлыгы юк», «Күңелең күтәрелеп китәр» дигән сүзләр белән кыстадылар малайны.

– Шул сасы суны кеше нәрсәгә эчәдер? Мин булдыра алмыйм.

– Сасы булса, борыныңны йомып эч!

– Әйе, әмма аракыны авызыңда тотма. Йот та куй.

Тәүге тапкыр эчү күңелне болгандырып җибәрде. Әче су авызын яндырып төшеп китте. Җирдәге иң тәмсез әйберне авыз иткәндәй, чирканып, җиргә төкерде. Бүтән эчмим дисә дә, тегеләр үзенекен талкыды:

– Тәүге тапкыр шулай була инде. Менә икенчесен эчсәң...

Утыра биргәч, егетләрнең кәефе тагын күтәрелеп китте. Аларның бигрәк тә Данил хакында күбрәк беләсе килә. Ул ничек бар, шулай сөйли бирде. Башка вакыт булса, бәлки, оялып дөресен әйтмәс иде. Аракы эчкәч, әллә кыюланды, әллә теле ачылып китте. Бу малайлар да яхшы тормыштан качып, подвалга килеп кермәгәннәр икән. Аларның да үз хәсрәте, үз сызланулары бар. Һәркемнең үз тарихы...

– Ә мин детдомнан качтым. – Орех авыр көрсенеп куйды. – Айдан артык чыгып киткәнемә. Әле һаман таба алмыйлар.

– Нигә качарга булдың соң? – дип төпченде Данил.

– Өлкән малайлар тукмый...

Орехның сөйләвенчә, анда ул кадәр үк начар да түгел. Ашаталар, киендерәләр, җылыда йоклыйсың. Тик күңел тынычлыгы гына юк. Ә анысы – һәр кеше өчен иң мөһиме.

Орех детдомга бер ел элек барып эләккән. Әтисез үскән малай. Әнисен төрмәгә утыртканнар. «Орех» дигән кушаматны өлкән малайлар аңа шунда ук уйлап тапкан. Башы зур аның. Өлкәнрәкләр аны күрә алмый. Яныннан үткән саен башына сугалар.

– Түз, син бит орех! – дип мыскыллыйлар.

Еш кына берәр нәрсә урларга кушалар. Орех юашрак булгач, аңа төрле «задание» бирелә. Әйткәннәрен үтәмәсәң, билгеле, башына эләгә.

Орехкәтлитне үлеп ярата. Хәер, аны яратмаган кеше бармы икән?! Шул ризыкны

биргән көннәрен түземсезләнеп көтеп ала балалар. Орех та. Тик аны ашау бәхете һәркемгә дә тими. Өлкәнрәкләр тартып ала. Ашамлыкны үз кулларың белән тотып, «башлыкка» алып барырга кушалар. Бары аның тәмле исе генә учыңда кала...

Бер көнне Орех мәктәптән барысыннан да алдарак кайта. Караса, тәрбияче һәр өстәлгә ашамлыкны бүлеп салган. Кәтлит тә бар. Бу юлы түзәрлек хәле калмаган. Азак тукмалачагын белсә дә, кәтлитне ашарга тотына. Эх, аның тәмлелеге! Ите авызда эреп кенә тора. Ә суты соң? Үзенекен ашап бетергәч тә туймый Орех. Ахырда кыер-кыймас кына күршесенең кәтлитенә үрелә. Анысын да «әһ» дигәнче ашап куя. Ә күз теге кәтлитләргә һаман кызыга. Туктар әмәл юк. Малай тагын берәүнекенә омтыла. Тагын, тагын, тагын... Шулай ун кешенең өлешен! Хәтта онытылып китеп «башлыкныкын» да! Ашап бетергәч, ашханәдән чыгарлык хәле калмый. Эче туп сыман була! Көч-хәлгә, ял итеп торыйм әле дип, өстәл астына төшеп ята һәм шунда ук йокыга китә. Малайлар аны өстәл астыннан сөйрәп чыгаралар.

– Всё, Орех! Хәзер зур башыңны гына түгел, корсагыңны да ярабыз, – дип сырып ала аны төркемдәшләре.

Нык эләгә Орехка! Күмәкләшеп тукмыйлар. Кем таяк белән суга, кем тәпечкә белән... Һәркем башына эләктерергә тырыша. Ул минутларны искә төшерсә, әле дә дертләп куя малай. Тукмалудан башы күгәреп, шешенеп бетә. Детдомда аңа көн юк. Бердәнбер котылу юлы – качу.

Цыган... Аның чын исеме – Тимур. Тик аны малай сирәк куллана. Кушаматы үзенә дә ошый. Ниндидер горурлык белән йөртә. Тимур – күп балалы гаиләдән. Биш бала арасыннан иң өлкәне. Әнисе белән генә яши. Үзенең әтисен хәтерләми. Шулай да әнисенең ялгыз яшәгәне булмаган. Бер-бер артлы ирләр аларда тукталып торган. Яңа «әти» килгән саен сеңлесе, энеләре арткан. Бу җәһәттән Данил белән язмышлары охшаш. Тимурның да әнисе эчәргә ярата, өйдән кунак өзелми, туганнары юньле карау күрми. Ә Цыган дигән кушамат бирүләре...

Тимур мәктәптә үзенә шөгыль табып ала: бәләкәй малайлардан акча талый. Күпләре куркып, үзләре китереп бирә. Кайсыбер укучылар мәктәптән кайтып килсә, тегеләрне стенага тери дә кесәләрен капшый. Нәрсә таба, үзенә ала. Шуңа классташлары аны «Цыган» дип атый башлый. Тышкы кыяфәте белән дә аларга охшаган. Бөдрә чәчле, коңгырт йөзле, күзләре уйнап тора.

Озак котырырга туры килмәде Цыганга. Кемнеңдер әнисе милициягә язып биргән. Китте шау-шу. Әллә ничә көн йөрттеләр Тимурны. Зыян күргән бөтен укучылардан аңлатма алдылар.

– Котырып туйдың, малай! Инде балалар колониясенә җибәрәбез сине, – ди мәктәп директоры. Тимур нишләргә белми. Башына төрле уйлар килә. Хәтта күпердән сикерергә дә ниятли. Әнисенә әйттең ни дә, әйтмәдең ни... Аның үз хәсрәте, үзенең авызына үзе хуҗа була алмый, белгәне – эчү. Цыган, балалар арасында ничек кенә эре булып кыланмасын, директорның әйткәненнән шүрли. Шуңа беркем дә тапмасын дип, бүтән калага качарга була.

Менә инде подвалда өч үсмер. Өчесенең дә үз тарихы. Авыр язмыш, гаилә фаҗигасе берләштерде, дуслаштырды аларны.

– Әйдә, тагы кой, Орех! – Бите кызарган Цыган дустын ашыктырды. – Сөйли башласаң, сүзең бетмәс синең...

Малайлар тагы күтәрде. Бер-берсен бүлдереп сөйләргә ашыкты. Алар берчә шаркылдап көлде, берчә сулкылдап елады. Тагын берәрне күтәргәч, Данилга кинәт кыен булып китте. Аяк астындагы җир чайкалгандай тоелды. Баш әйләнә, күз алдында томан. Эчендәге булган барнәрсәсе, укшытып, тышка чыгып

килә. Малайларның йөзе дә икешәр булып күренә. Нидер әйтәсе килә, тик теле әйләнми. Нәрсә булды соң? Әллә үлү дигәннәре шушы инде дип курыкты Данил. Читкә китеп, хаҗәтен үтәргә теләгән иде, тик аяклары тыңламады. Урынында утыра бирде дә матраска ауды...

Исерүнең нәрсә икәнен белми иде әле ул. Әгәр, иртәгәсен ничек кыен булачагын белсә, бәлки, тотмас та иде аракыны. Башы чатнардай булып авыртып, хәлсез тора алмый яту, үләр чиккә җитеп авыру көтә иде аны иртәгесен.

### IV

Бергәләшеп яшәүгә ике ай да үтеп китте. Салкын көннәр артта кала бара. Алда – матур җәй. Тик гел бер кием белән йөрү оят. Өйгә кайтып, алыштырырга кирәк. Данил бу хакта күптән уйлап йөри иде. Менә, ниһаять, тәвәккәлләргә булды. Өметсез – шайтан гына, диләр. Бәлки, әнисе акылына килеп, яхшы итеп яши башлагандыр? Бәлки, Данилны эзләп арыгандыр. Дөресен әйткәндә, мондый тормыш малайның үзен дә ялыктырды. Подвалда яшәү – яшәүмени? Юньле ашау юк, һәрчак хәвеф... Иртәгәсе көнең караңгы...

Туган йортына якынлашкан саен, йөрәге дөпелдәде. Юк, кабат әйләнеп бармас ул теге дусларына. Ике ай урамда йөрде – җиткән. Кешечә яши башларга кирәк. Мәктәптә укуын да дәвам итәр. Аның бит хыялы бар. Әтисе шулай тели торган иде.

Их, әтисе исән булса... «Минем улым төзүче булачак! Менә күрерсез, калабызда биек-биек йортлар салып куяр әле!» – дип кабатларга ярата иде ул. Әйе, әтисе нигәдер улының нәкъ төзүче булуын нык теләде. Хәзер барысы да җитәкче булам дип тырыша, ә эш эшләргә кешеләр калмады, дигән сүзләрен дә яхшы хәтерли. Бу һөнәр Данилның үзенә дә бик ошый. Тик болай укымыйча, урам буйлап йөрсә, хыялы ничек тормышка ашсын?! Шушы турыда уйланып, әтисенең рухы алдында оялып куйды ул.

...Өйләре каршында кызыл машина күргәч, авызы ерылды. Еракта яшәгән берәр туганнары килгәнме әллә? Өй дә танымаслык булып үзгәргән. Агач капкалар тимергә алыштырылган, тәрәзәләрнең рамы матур итеп буялган. Хуҗа кулы тигәне беленә, өй әллә кайдан балкып тора. Тик капканы болай гына ачармын, димә. Кыңгырау да эшләп куйганнар. Данил төймәгә басты. Якын кешесе белән күрешүгә әзерләнеп, өстендәге киемен ипләп куйды, тырпайган чәчен тигезләп маташты.

– Сезгә кем кирәк? – Алдында дәү гәүдәле, бөтенләй ят ирне күргәч, малай аптырап калды.

– Мин үз өемә килдем. Әнием кайда? – Данил эчкә үтәм дип үрелгән иде дә, теге ир кулын аркылы куйды.

– Бу йортны без сатып алдык. Алар күчеп китте.

Көтелмәгән хәбәрдән малайның буыннары йомшарды.

– Кем сатты? Ул бит безнең өй.

– Белмим. Элекке хуҗалары ниндидер ташландык авылга күчеп киттеләр.

– Алдашма! Бу әтиемнең өе! – Елар чиккә җиткән малай җан көченә ирне этеп, эчкә үтәргә маташты. Теге үз урынында каты торды. Нықыш малайны җиңелчә генә селтәп җибәрде.

– Башка килеп йөрмә. Монда хәзер мин хуҗа! – Алдында ишек шап итеп ябылды.

Инде Данил барысын да аңлады. Менә ни өчен үги әтисе аны күрә алмаган.

Монда килеп әнисе белән яши башлагач та, өйне сатыйк, дип аптыратты. Әнисе ризалашкан иде дә, бөтен планнарын Данил бозды. Җан-фәрманга кала хакимиятенең опека бүлегенә йөгерде. Ничек бар, түкми-чәчми сөйләп бирде. Ул вакытны йортны сатарга ирек бирмәделәр. Закон Данил ягында булып чыкты. Балигъ булмаган бала барда, мондый эшкә рөхсәт булмады. Опека бүлеге мәсьәләне үз күзәтүенә алды. Менә шуның өчен үги әтисе нык ачуланды, малайга көн күрсәтмәде: «Теге этлегең өчен не прощу!»– диде. Инде төшенде Данил. Бәләкәй чактан ук таныш урыннан болай гына китәргә ашыкмады үсмер. Күршеләренә сугылырга булды. Аңа бер генә сорау тынычлык бирми: әнисе ничек итеп йортны сата алган? Данилга 18 яшь тулмыйча аны эшли алмыйлар бит. Теге оятсыз ирнең эшедер...

– Бәй, син монда нәрсә эшләп йөрисең? Авылга күчтегез түгелме? – дип аптырады күршесе.

– Юк, күчмәдек. Менә бит, алдыгызда басып торам.

Күршесе чәйгә чакырды. Сөйләшеп утыргач, эшнең ничек килеп чыгуын Данил яңа аңлады. Имеш, малай астма белән авырый, калада тыны буыла дип, табибтан ялган белешмә алганнар. Баланың саулыгын саклау өчен, һавасы чистарак берәр авылга күчәргә киңәш язган булганнар анда.

Менә шул белешмә буенча опека йортны сатарга рөхсәт биргән. Янәсе, Данилның саулыгы өчен борчылганнар. Шулай итеп, каладагы өйне сатканнар. Аның акчасын нәрсә эшләткәннәрдер – билгесез. Күз буяу өчен, бәлки, ташландык авылдан берәр тавык кетәгедәй йорт алганнардыр. Ә калган акчасын, билгеле инде, эчүгә... Юк, әнисенең башына мондый хәйлә килмәс иде. Теге ирнең генә хөсетлеге бу. Тәү күрүдән үк үз итмәде Данил шул ирне. Кулы тулы «наколка» иде, төрмәдә утырган икән. Шул йортны «очыру» өчен генә ияләшкәндер. Әнисен нык җәлләп куйды малай. Тозакка эләккән куян сыман тойды ул иң якын кешесен. «Юк, әнисе өйне сатмаган! Алданган!» дип үзалдына сөйләнде. Данилның кәефе кырылды. Күрәсең, үз нигезенә кайтырга язмаган. Алга таба да подвалда яшәргә туры киләчәк.

Малайлар «оясында» бәйрәм гөрли иде. Аракы алганнар.

– Син кайда югалып йөрдең? – диде Цыган.

– Өемә кайтып килгән идем...

– Ә безнең менә нәрсәбез бар... – Орех гадәттәгечә мактануын белде. – Үзем уйлап таптым...

Карасаң, малайлар тик утырмаган. Өске катта яшәгән әбидән Орех кәстрүл сорап торган. «Без яңа күршегез. Беренче катта торабыз. Әле тулысынча күченеп бетмәдек», – дип алдаган ул карчыкны. Теге ышанып, кәстрүлен биргән. Малайларга шул җитә калган. Тиз генә сатып алыр кешесен дә тапканнар. Очсызракка җибәргәннәр, әлбәттә. Мәгәр бер утырып алырлык булган.

## V

Көн саен нindидер хәйлә корырга, тамак туйдыру чарасын табарга нужа үзе куша. Әле Орехның кесәсендә бер сум акчасы бар. Аңа гына нәрсә аласың? Иң күбендә – бер кап шырпы. Шул бер сумны ничек арттырып була икән, дип озак уйланып ятты ул. Кинәт башына бер уй килде. Ул урыныннан сикереп торды:

– Малайлар, бер шәп идеям бар. Әгәр мин әйткәнчә эшләсәк, бүген байыйбыз. – Цыган да, Данил да аңа сәерсенеп карап куйды. Мөгаен, берәр кемнең янчыгын чәлдерергә кушадыр, дип уйладылар. Хәер, кеше әйберенә аю мае сөртүдән башкасын белмиләр дә алар.

– Моның өчен миңа бер бит кәгазь, ручка кирәк, – дип сүзен дәвам итте Орех. – Сездән шул әйберләр, калганы – миннән.

– Нәрсә, акча ясарга булдыңмы әллә? – диде Цыган, көлемсерәп.

– Күрерсез... Мин кушканны алып килсәгез.

Кәгазьне дә, ручканы да табу кыен булмады. Малайлар моны «әһ» дигәнче эшләде. Урамда уйнап йөргән малайдан сорадылар. Ул барысын да чыгарып бирде. Бу кирәкле әйберләрне алдына китереп салгач, Орех шатлыгыннан учын учка уды:

– Акча сурәтен төшерергә талантым юк, тик башка нәрсәгә башым эшли. Хәзер күрерсез...

Орех җитдилек белән эшкә тотынды. Тәүдә кәгазьне бәләкәй кисәкләргә бүлгәләде дә, һәрберсенә «50 тиен» дип язып чыкты. Барлык кәгазьдә дә бер үк язма. Шуннан аларны язу күренмәслек итеп бөгәрләп, кәпәченең эченә салды.

– Киттек минем арттан. Лотерея уйнатабыз! – дип боерды ул дусларына.

Тегеләр аның артыннан иярде. Кесәсендә яткан бер сумлык тәңкәгә Орех кат-кат карап алды. «Менә ул минем байлыгым», дип сөенде. Юл уңае бер кибеткә кереп чыкты, бер сумлыгын ваклатып, иллешәр тиенлек ике тәңкә алды.

– Нинди лотерея тагын, әйт безгә? – Данил Орехның бу аңлашылмас кыланышыннан ярсыды. – Без нигә синең арттан сарык сыман ияреп йөрибез?

Аны Цыган да җөпләп куйды:

– Нигә эндәшмисең? Кая алып киттең безне?

– Сабырлык, тагы бер кат сабырлык. Хәзер күрерсез.

Орехка ияреп бара торгач, бөтенләй икенче урамга килеп чыктылар. Бу якта аларның күптән булганы юк. Биек йортлар арасындагы зур мәйданчыкта балалар туп-тулы. Мәктәп яшендәге балалар чыр-чу килә. Берәүләр турникта төрле күнекмәләр ясый, икенчеләре туп тибә, өченчеләре куышлы уйный.

Орех малайлар күпләп җыелган җиргә барып басты. Тегеләрне үзенә якынрак чакырып алды да кинәяләп сөйләргә тотынды.

– Дуслар, кем лотерея уйнарга тели? – Барысы да ишетсен дип, тавышын көчәйтте. – Алдан әйтәм – берәү дә оттырмаячак.

Мондый хәбәргә бүтәннәрнең колагы тырпаеп калды. Орехны тирә-яктан балалар уратып алды.

– Мин уйныйм!

– Мин дә...

Күпләрнең кызыксынуын күреп, Орехның эченә җылы йөгерде. Эшләр болай уңай барса, чынлап, акча керәчәк.

– Шартлары гади, – диде ул. – Уйнауның хакы бер сум тора. Түләгез дә шушы кәпәч эченнән кәгазь кисәген чыгарыгыз. Анда бүләкнең күпме икәне язылган.

– Ә күпме отарга була?

– Кемгә ничек туры килә. Ун сум, илле сум, хәтта күбрәк тә. Әнә, күрше урамда бер малай йөз сумны эләктерде!

Балалар җанланып китте. Кемдер кесәсеннән булган акчасын чыгарырга ашыкты, икенчеләре әнисеннән сорарга дип, өенә йөгерде. Уен кызу башланып китте. Шунда ук ике кеше лотерея алып, бәхетен сынап карарга булды. Ә Цыган белән Данил бер сүзсез эшне читтән күзәтеп торды. Балалар кәпәчтәге кәгазьне алып язманы күргәч, авызлары салынды:

– 50 тиен генә!

– Минем дә шулай...

Мондый очракта үзеңне ничек тотарга икәнен Орех яхшы белә. Иң мөһиме: югалып калмаска. Кесәсендәге ике илле тиенлек тәңкәне чыгарып, тегеләрнең учына салды:

– Лотерея булгач – шулай була инде. Барысына да зур акча тәтесә, кызыгы бетә. Кайсыгыз иң бәхетле кеше икән бүген? Илле сум әле менә шушы кәпәчтә ята. Йә, кемгә кирәк ул акча?

Һәркем үз бәхетен сынап карарга тели. Берсеннән-берсе кызып, лотерея алалар. Кайберләре хәтта бишәрне алды. Ару гына чират җыелып китте. Бу күренешкә Орехның да, дусларының да күңеле бермә-бер күтәрелде.

Кәпәчтәге кырыкка якын кәгазь кисәге юк булды. Аны сатып алган һәркем бары бер язуны күрде: «50 тиен». Алдан вәгъдә ителгән ун, илле сум да күренмәде. Цыган дустына пышылдады:

– Тизрәк таярга кирәк!

Алар шулай итте дә. «Хәзер киләбез» дип алдашып, табаннарын ялтыратты. Алданганнарын аңлаган балалар үзара сукранып калдылар.

Малайлар Орехны мактады:

– Менә, ичмасам, синдә баш. Каян уйлап таптың аны?

– Әйтмә дә. Юкка гына Орех димәгәннәр сине. Төп башына утырттың маңкаларны.

Бу акчага нәрсә алачакларын малайлар яхшы белә. Клей! Шул нәрсәне озак иснәми торсаң, теләк артканнан-арта. Аның белән булышканда, бөтен дөньяң онытыла, ашыйсы да килми. Ике көн элек кенә туйганчы иснәгәннәр иде аны. Кичә дә шуны ничек табарга дип баш ваттылар, тик бернәрсә дә килеп чыкмады. И ачулары килде шуңа! Хәтта үзара талашып беттеләр. Ә бүген ничек уңай килеп чыкты!

– Бүген әйдә сарысын алмыйк әле, – диде Цыган. – Аның күк тышлысы әйбәтрәк. Исе дә яхшы. Ә сарысын иснәсәң, баш ныграк авырта, җитмәсә тамак төбе әчетеп этләтә.

Орех аны куәтләп куйды:

– Әйе, мин дә шуны әйтергә тора идем.

Клей белән ничек эш итү юлын малайлар хәзер яхшы белә. Остардылар. Беренче кагыйдә: полиэтилен капчык белән клейны бер кибеттән алырга ярамый! Сатучылар шунда ук аларның токсикоман икәнен аңлап, бернәрсә дә бирми куып чыгарачак. Милиционер чакыруы да бар. Ә болай нәрсә өчен аны аласың дип сорасалар, «әтиемнең туфлиенең табаны аерылды», – дип алдаячаклар. Ә капчыкны инде бүтән кибеттән алачаклар. Әнә шулай хәйләкәррәк булсаң, барысы да килеп чыга. Бүген дә малайлар шулай итте. Бер тюбик клей, өч полиэтилен капчыкны бер бәласез алдылар.

Юлда килгәндә, Орех сәер итеп сүз башлады:

– Егетләр, мин үземә наколка эшләтергә телим әле.

Көтелмәгән хәбәргә дуслары аптырап куйды:

– Анысы сиңа нәрсәгә кирәк?

– Кулыма «13» санын эшләтәм. Ул – бәхетсезлек билгесе, – дип дәвам итте Орех. – Үземне белгәннән бирле гел бәхетсез мин. Ник берәр яхшы кешенең баласы булып тумадым икән? Бәләкәй чактан бирле изаланам.

– Куй, юкны сөйләмә әле! – Данил аны тынычландырырга маташты. – Барысы да алда бит. Мин, мәсәлән, андый саннарга ышанмыйм...

– Ә мин ышанам, – Орех үзенең сүзендә нык торды. – Менә кайсы бер илләрдә биек йортларда 13 нче кат юк. Фатирларга да андый сан бирелми.

– Ничек инде алай?

– Ә менә шулай. 12 нчедән соң, 14 нче кат башлана. Бәхетсезлектән курыкканга шулай итәләр. Ә мин курыкмыйм. Өйрәндем инде. Шуңа наколка эшләтәм.

Подвалга кергәч, малайлар ишекне нык итеп бикләде. Янәсе бүтәннәр үтә алмасын. Һәркем үз урынын алды. Орех һәрберсенең полиэтилен капчыгына сыек клей салып чыкты. Берсеннән-берсе узып иснәргә тотындылар.

Тәүдә сәер, ят күренсә дә, Данил да җайлап күнде бу шөгыльгә. Менә әле дә бер тутырып сулавы булды, шунда ук тәне буйлап эсселек йөгерде. Аяклары җебеде, күз алдында әллә нинди төрле чәчкәләр күренде. Тәүдә ул ракета сыман җирдән аерылды да өскә очты. Җир аңардан ераклашып, бәләкәй нокта булып калды. Шул тиклем җиңел һәм рәхәт аңа! Менә ул йолдызлар яныннан очып үтә. Аста кешеләр нигә мәшәкатьләнеп яши икән? Эх, белсәләр иде... мондый тормыш барын... Кешеләр меңәр ел буе чишә алмаган серләрне дә төшенде ул хәзер. Әллә нинди ачышлар башка үзеннән-үзе килә. Ә аны аңлар өчен шундый биеклеккә күтәрелергә кирәк – йолдызлар янына...

...Калтыранып, дертләп уянып китте Данил. Бу халәттән элеккеге тормышка кайту яман авыр икән шул. Күпме шулай таш идәндә яткандыр, белми. Башы шаулый, тамагы кипкән. Җитмәсә, Йолдыз үзенә урын таба алмый, чәбәләнә. Нигә алай кылана икән? Ачуны китереп, үзәкләр өзәрдәй итеп улавын әйт әле.

Данил тирә-ягына каранды. Цыган да капчыгын тоткан килеш йоклап киткән. Данил аның битенә сугып, уятырга тотынды.

– Ә-ә, по-шё-ё-ёл! – дип, аңлаешсыз гына итеп сөйләнде тегесе.

Ахырда Орехны уятырга булды. Ул да күп иснәгән, күрәсең, комсызланып башын капчык эченә тыккан да шул килеш йоклап киткән. Чәчләре клейга ябышып өлгергән, шуңа авырга туры килде.

– Эй, Орех, уян! – Ләкин дусты бер сүз дә эндәшмәде. Йөзе күм-күк булган. Данил аны җилтерәтеп карады. Тагы битенә суккалады. Тик Орех бер өн дә чыгармады.

– Орех, җитәр, кыланма! Тор! – дип кабатлады Данил.

Җавап булмады. Аптырагач, аның күзләрен бармагы белән ачты. Орехның күзләре өскә таба тәгәрәгән иде. Нык йоклый, күрәсең. Битен тотып карады, суынган. Җитмәсә, этнең улавы күңелгә шом өсти. Бәлки, шулай каты йоклыйдыр! Колагын куеп йөрәген тыңлады – типми...

Данилның коты очты. Башына эссе капты. Йөзе кәгазь сыман ап-акка әйләнде. Кычкырам, дисә, тавышы чыкмый.

– Кот-ка-ры-гыз! Орех үлгә-ә-ән! – дип җан көченә сөрәнләде. Күз аллары томаланды. Нәрсә эшләргә белми, урамга йөгереп чыкты. Ничек табиблар, милиционерлар килеп җиткәнен дә ачык хәтерләми. Алары малайлардан җентекләп кат-кат сораштылар.

– Передоз, – диде ак халатлы хатын.

Орехның гәүдәсен алып китәргә булдылар. Данил соңгы тапкыр аның йөзенә карыйм дип үрелгән иде, дерт итеп калды. Мәетнең битен ниндидер вак бөҗәкләр сырып алган. Алар шул тиклем күп, кара яу булып артканнан-арта бара.

– Бу нәрсә? Кайдан ул? – дип аптырады Данил.

– Күрмисеңме, бетләгән бит, – диде Цыган. – Элек ишеткәнем бар иде. Димәк, шул сөйләгәннәре дөрес инде. Кеше үлсә, тәнендәге бетләр өскә калкып чыга, ди...

– Ярар, житте! Тоже нашлись тут учёные!

Милиционер сукранып, мәетнең өстен япма белән каплады. Орехны моргка, ә Цыган белән Данилны милиция бүлегенә алып киттеләр. Малайларны аннан тиз генә җибәрергә ашыкмадылар. Әллә күпме аңлатма алдылар да бикләп куйдылар. Иртәгәсе көнне генә чыгардылар.

Данил хәзер үзенә урын таба алмый. Бигрәк жәл шул Орех. «Үземә наколка эшләтәм. 13 санын», дигән соңгы сүзен исенә төшерсә, тыела алмый – күзләреннән яшьләр ага.

Цыганның да күңелендә тыныч түгел. Ул өйрәтте бит Орехны клей иснәргә. Әгәр өйрәтмәгән булса... Әйе, рәхәт кебек иде иң башта. Ә хәзер нәрсә белән бетте бу шаяру?!

Тәртип сакчысы каты сөйләште:

– Детдом белән бәйләнешкә керербез. Күмүне алар кайгыртыр. – Шуннан малайларның яшәү урынын язып алды. Әниләренең исемен дә белеште. – Көтегез. Сезне тагын чакыртачакбыз. Доигрались!

Кире теге подвалга кереп булмады. Ишеккә инде ача алмаслык итеп зур йозак элгәннәр. Ул йортны караган сантехникларга да эләккәндер әле. Алга табан нәрсә эшләргә, нәрсәдер уйлап чыгарырга Орех та юк. Үз өйләренә кайтырга ярамый. Милиционерлар килеп теңкәгә тиячәк. Бәхетләренә күрә, ярый әле җәй башланып тора. Автовокзалдан ерак түгел зират бар. Ул борынгы. Күптән инде анда җирләмиләр. Соңгы тапкыр сугыш чорында госпитальдә ярадан үлгән солдатларны күмгәннәр. Ә хәзер калада ул ташландык урын. Шунда куыш корып яшәп торырга булдылар. Данил тәүдә ризалашмый, карыша бирде. Тик Цыган барыбер күндерде:

– Үзең кара. Өеңә кайтсаң, милиция килеп, колониягә алып китәчәк. Ә монда тыныч. Беркем йөрми, үлгәннән түгел, тередән куркырга кирәк...

Тирә-яктан иске калайлар, такталар җыеп үзләренә урын әтмәлләделәр. Тәүдә куркынычрак тоелса да, атна үткәч, өйрәнделәр. Монда аларны кем тапсын? Зират эчендә эзләп йөрергә милиционерларның җиде ятып бер төшенә кермидер әле.

Малайлар бер-берсе белән озак сөйләшми йөрде. «Әйе» яки «юк» дип кенә аңлаштылар. Юк, дошманлашмады алар. Якын дусның көтелмәгән үлеменнән һушларын гына җыя алмадылар. Бар табигать яшеллеккә күмелә башлаганда, үлеп ят әле...

Икесе дә үзенә гомерлек сабак алды: бүтән клей дип авыз ачмаска. Нинди шаян, елгыр малайны сузып салып куйды! Цыганның да, Данилның да әле яшиселәре килә. Ни тиклем кыен булса да...

## VI

Бүрене аягы туйдыра, дип юкка әйтмиләр. Үз көнен үзе күреп яшәгән малайлар бу кагыйдәне яхшы аңлый. Яшәгәч, төрле хәлләргә каласың.

Теләнә белер өчен дә зур осталык кирәк, хәтта талант дияргә дә ярый! Данил да шул нечкәлекне яхшы үзләштерде. Йөргән таш шомара инде. Ишек алдында кулыңны сузып торып кына кесәгә акча тулмый. Хәйләкәр, шәп психолог булырга кирәк. Иң тәүдә бик кайгылы йөз ясыйсың. Күзләреңдә хәсрәттән менә-менә яшь тамарга әзер тора. Мондый кыяфәткә керү серен Данил яхшы белә, ул тормышындагы иң кайгылы мәлне исенә төшерә – әтисенең үлемен. Бу фаҗига әле генә булган дип үзен эчтән ышандыра.

– Зинһар өчен, ярдәм итегез! Минем шул тиклем ашыйсым килә!

Иң мөһиме: сөйләүдән туктамаска.

– Ике көн бернәрсә дә ашамадым. Апа, зинһар өчен...

Хатын-кызлар җәлли беләә. Ирләр акча чыгарып бирми. Моны Данил күптән сынады инде.

Бүген көн уңышлы башланып китте. Цыган анда нәрсә кыландырадыр, ә Данилның эшләре көйле. Бер сәгать эчендә йөз сум чамасы җыеп алды. Мул табыш! Бәйрәм бу! Тик бер ябык кына ирнең читтән аңа текәлеп карап торуы сагайтты. Бу абый еш йөри ул автовокзал янында.

Абый автовокзалга бер керде, бер чыкты. Платформага, халык күбрәк булган якка төшеп китте. Беразга югалды да янә күренде. Ят ир Данилны читтән генә күзәтә. Шулай да озак түзмәде: туп-туры кулын сузып торган егеткә килде.

– О-о-о, сәлам, брат! Хәлләрең ничек? – Ул әллә кайчангы таныш сыман Данилны кочаклап алды.

– Ә сез кем? – көтелмәгән очрашуга егет сагаеп калды.

Теге ир күптәнге дустын очраткандай, сары тешләрен күрсәтеп елмайды:

– Нигә, танымыйсыңмы мине?

– Юк, бер дә исемә төшерә алмыйм.

Данил ничек кенә уйланмасын, барыбер бу кешенең кем икәнлеген хәтерли алмады. Куе кара мыеклы, үзе ябык, озын гәүдәле ир... Өстенә уңып беткән күлмәк кигән, үтүкләнмәгән чалбар. Лупага охшаган зур, йомры күзлек. Юк, кемлеген белми Данил бу кешенең.

– Бәлки, кем беләндер бутыйсыңдыр мине? – диде ул, котылырга тырышып.

Ир барысын да әйтеп салырга ашыкмады. Кесәсеннән «Прима» тәмәкесе чыгарды.

– Дай в зубы, чтобы дым пошёл!

– Нәрсә? – Ят кешенең нәрсә сораганын малай тиз генә төшенмәде.

– Шырпың бармы?

– Зажигалкам гына, – диде Данил.

– Булсын...

Данил кесәсенә кулын тыкты. Зажигалкасы юк. Сул кесәсен капшап карады. Анда да юк. Башка кесәләрен дә караштырды. Ярый, җыелган акчаларын эчке кесәсенә яшергән иде. Үзе дә аптыраашта калды.

– Бая гына кесәмдә ята иде...

Теге ир шаркылдап көлеп җибәрде. Шуннан үзенең кесәсеннән кызыл зажигалка китереп чыгарды.

– Шушы нәрсә сиңа танышмы?

Данил үз әйберенең, әле генә килгән кешенең кесәсенә ничек барып эләккәненә аптырап калды.

– Ул минеке бит! «Д» дип уелган язуы бар, – дип әйтүдән башка чара тапмады. – Ә ул сиңа ничек барып эләкте?

– Фокус-мокус! – Ир тәмәкесен кабызды.

Могҗиза бу! Данил исәр түгел бит. Биш минут элек кенә зажигалка аның кесәсендә ята иде. Һәм менә сиңа мә: ниндидер көч белән башка кешенең кесәсенә килеп кергән. Вәт, ичмасам, фокус! Бу абый алайса, гади кеше түгел. Берәр гыйлләсе бардыр.

– Абый, сереңне ач әле. Ничек эшләдең? – Данил тынычлана алмады. Барысын да тиз генә беләсе, аңлыйсы килде. Алдында ниндидер шарлатан түгел, ә фокусник тора бит!

– Әйдә соң. Зажигалкаңны кире кесәңә сал. – Данил янә әйберен әйләндереп

карады да чалбарының уң кесәсенә салды. Кесәсе тишек түгел икәнлеген тикшерде. Кабаттан капшап карады: зажигалка үз урынында ята.

– Инде күрсәт, – дип елмаеп эндәште.

Ир тәмәкесен ыргытты да читкә китте. Бер биш адым үткәч, кире борылды. Малайны тәүге күргәндәй, кочагын җәеп исәнләшергә тотынды.

– О-о-о, сәлам, брат! – Данилны кочаклап, аркасынан сөеп алды. – Хәлләрең ничек?

Малай ирнең бу кыланышына сәерсенеп карап куйды:

– Ә зажигалканы ничек алырга уйлыйсың соң? – диде көлемсерәп.

– Кесәңне кара! – Мыеклы абый мут елмайды.

Данил кесәсенә үрелде. Уң ягын карады, сул ягын... Зажигалка юк иде...

– Ничек инде?! – Малай авызын ачып, сүзсез калды. Абый тагын көлеп җибәрде:

– Фокус, дидем бит! Фокус-мокус!..

Шулчак Цыган килеп чыкты. Бернәрсә дә эләктерә алмаган, күрәсең. Йөзе боек. Данил, әле генәниләр күргәнен сөйләргә тотынды.

– Мин сезне күптән күзәтеп йөрим. – Ир тагын тәмәкесен кабызды. Малайларга да берәрне сузды. – Болай елгыр малайларга охшагансыз. Шуңа килеп танышырга булдым. Исемегез ничек?

Цыган, өлкән кеше буларак, таныштыруны үз өстенә алды:

– Мин – Цыган булам. Ә ул – Данька! Без күптәнге дуслар. Ә сез кем?

– Косой, диләр. Погонялам шулай. Чын исемем – Илдар. Тик исемем белән берәү дә эндәшми. – Дус булыйк дигәндәй, Косой егетләрнең кулын кысты.

– Тагын бер фокус күрсәтәсеңме? – Данил һаман бая күргәннәреннән тынычлана алмады.

– Күрсәтермен. Теләсәң, өйрәтермен дә.

– Чынмы? Алдамыйсыңмы?

– Алдамыйм.

Малайлар яңа танышуга шат иде. Шулай булмыйча. Нинди кызык кеше бит. Җитмәсә, өйрәтәм, ди. Абый артык сөйләнеп бармый. Җитди кешегә охшаган. Ә шулай да һәр сүзен игътибар белән тыңлыйсы килә.

– Сез кайда яшисез? Фатирдамы? – дип төпченде Косой.

– Фатирда түгел. Шушы тирәдә йоклап йөргән урыныбыз бар. – Данил башын игән килеш җаваплады.

– Аңлашылды.

## VII

Өй эче аптырарлык түгел. Яңа җиһаз да, затлы әйберләр дә юк. Нух заманындагы чаршаулар эленгән. Идән чиста итеп юылган, урын-җир пөхтә җыештырылган. Стенада борынгы фотолар эленеп тора. Зур сәгать тә туктап калган. Бар байлык: ике тимер карават та бер өстәл. Ә абый яңа гына килеп, дөньяны үзенчә матурларга тырышкан. Күрәсең, йортта күптән кеше яшәмәгән. Тик шулай да монда яхшырак. Һәрхәлдә зират эчендәге куышка тиңләп булмый инде. Моңарчы алар яшәгән подвал белән дә чагыштырырлык түгел. Баш астына салырга – мендәр, ябынырга юрган бар. Монысы яхшы.

Илдар – кырык яшьтән узган ир. Гомеренең яртысын диярлек төрмәләрдә үткәргән. Сәбәбе бер – кулы озын. Менә әле дә иреккә чыкканына куанып йөри. Хәер, куанамы соң? Чыкканда, үзе шулай уйлый иде дә бит. Кайткач, күргәненнән күңеле кайтты. Әти йорты ялгызлыктан чүккән. Күрше-тирә аның

холкын белгәнгә күрә, аралашмый. Бер-ике урынга эшкә барып караган иде, утырып чыкканын белгәч, ипләп кенә баш тарттылар. Ә бит ашарга кирәк. Һава сулап кына тук булмассың. Телиме-теләмиме, теге сәләтен эшкә җигәргә туры килә. Тик әлегә ул сак кылана. Төрмәнең караңгы камераларыннан да бераз ял итеп алырга кирәк. Тагын Илдарның эчен пошырганы – ялгызлык. Эчендәгесен сөйләр өчен, хәтта янына утырып чәй эчәрлек кешесе булмавы җанын көйдерә. Төрмәдә үзенең дус-ишләрен, фикердәшләрен табып беткән иде. Әле дә автовокзалда шушы ике егет белән танышу бераз кәефен күтәреп җибәрде. Беренчедән, өчәү өчәү инде, күңелсез булмас. Икенчедән, бу егетләрнең аңа ярдәме дә тиячәк. Илдар планнар да корып куйды. Егетләр җитез, аннан-моннан куркып тормыйлар. Үзләренә 18 яшь тә тулмаган бит әле. Әллә нинди эш кылсалар да, хөкем каты түгел. Моны Илдар яхшы белә. Барысы да ул уйлаганча килеп чыкса... Әйе, зур өметләр баглый аларга Косой-Илдар...

Табын кызганнан-кызды. «Өч таган аумый – өчәү итик», дип күтәрделәр. Шуннан «арбаның дүрт тәгәрмәче әйләнгәндә генә, ул яхшы бара» дип, дүртәү иттеләр... Кызмача булган малайлар кайда яшәүләре, монда нинди җилләрнең илтүен сөйләп бирделәр.

Илдар да ачылып китте. Кәрт чыгарып, әллә нинди фокуслар күрсәтергә тотынды. Малайлар авыз ачып күзәтте.

## VIII

Малайларның яңа урында яши башлавына атнадан артык вакыт үтте.

Тәүге көннән үк Илдар үз шартын куйды. Малайлар телиме-теләмиме, чәчләрен кырып ташларга! Данил белән Цыганның бертуктаусыз кашынганнарын күреп, шулай эшләргә булды. Тегеләр тәүдә киреләнеп маташты. Бигрәк тә Цыган бөдрә чәчләре белән хушлашырга теләмәде. Косой каты торды:

– Минем өйдә вшивым не место!

Хәзер икесенең дә таз башлары ялтырап тора. Бетләргә каршы көрәш моның белән генә бетмәде. Тимер чиләктә су кайнатып, киемнәрен дә пешекләп алды Илдар.

– Чистота – мать порядка! – дип, үзалдына сөйләнә бирде. Бу сүзләрне еш кабатларга ярата Косой. Төрмәдә шушы кагыйдәне миенә ныклап сеңдергәннәр. Үз өстен карамаган, шапшак йөргән адәмнәргә анда да караш бүтән, ди. Шуңа да төрмәдән кайткан көнне үк өен ышкып, юып, тазартып алды. Эчтән йорт ярлы күренсә дә, яткан урыны таза. Кызык малайларга мондагы тормыш. Илдар абый тиз генә үз кешегә әверелде. Эче тулы мәзәк! Инде беттеме икән дисәң, тагын әллә нинди этнәкәсен китереп чыгара. Яңадан-яңа фокуслар өйрәтә. Укытучыбыздан уңдык, дип сөенә егетләр.

Тәүге «дәресе» бигрәк сәер булды. Илдар һәрберсенең уң кулын жгут белән бәйләде. Нык итеп, кан тамырларын кысканчы.

– Инде ике бармак белән бәбкә үләнен йолкыгыз! – диде ул. Һәм үзе йолкып та күрсәтте.

– Көлмә шул тиклем! Әллә без казга охшаганбызмы? – Сәер шөгыльгә егетләр ризасызлык белдерде.

– Сез үзегез миннән үтендегез! Приказ не обсуждается! – дип боерды «укытучы».

Цыган белән Данил бармаклары талганчы үлән йолыкты.

– Шәбрәк, шәбрәк! Туктамагыз! – Игътибар белән күзәтеп утырган Илдар

боларны кабаландырды гына. Билгеле, кан тамырлары кысылгач, кул ойый, бармаклар да начар эшли. Мондый хәлдә үлән йолку түгел, бармакларны хәрәкәтләндерү дә авырга туры килә. Ә «остаз» тизләтә! Тыңламый кая барасың. «Шәкертләр» кулындагы тамырлары бүртеп чыкканчы, бармаклары күгәрә башлаганчы шул үлән йолку белән булышты.

– Бүгенгә җиткән! – Илдар канәгать елмаеп, жгутларны чишәргә ярдәмләште. – Бу иң беренче күнекмә булды. Атна буена шуны кабатлаячаксыз.

Җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй, егетләр җиңел сулап куйды. Кулдан жгутны чишкәч, кан да йөгерде, бармакларга рәхәт җылы таралды.

Атна буена шул дәрес дәвам итте. Бармак очлары сөялләнеп бетте. Бу сәер дәрес тә аларны ялкытты. «Нәрсә өчен кирәк икәнлеген азак әйтермен. Бу бик мөһим дәрес», – дип, Илдар ымсындыра торды.

Бактың исә, төрмәдәге дусты Косойга шушындый киңәш биргән икән. Урлашуга әзерлек өчен бик яхшы тәҗрибә. Кешенең кесәсеннән нәрсәнедер җиңел генә китереп чыгарыр өчен оста бармаклар кирәк. Гармунда, йә гитарада уйнарга өйрәнгән сыман. Кулның тамырын юкка гына кысмыйлар. Андый чакта бармаклар таш сымак ката, тыңламый. Әнә шундый кыен шартларда шәп эшләтә алсаң, башка вакытта бармакларың йөгереккә әйләнә. Берәр кемнең сумкасына тиз генә кереп киткәнеңне хуҗасы гына түгел, үзең дә сизми калачаксың.

– Алда өйрәтәсе приёмнарым күп әле. Бу зур эшнең башы гына, – дип дәртләндерде аларны Остаз.

**IX**

Данил озак йоклый алмый ятты. Бар уе әнисе, әтисе турында. Әнисе хәзер кайларда йөри икән? Бәлки, ул Данилны әлеге мәлдә эзлидер! Әгәр күрсә, нык итеп кочаклар иде әнисен. Очрашуның татлы минутларын күз алдына китереп, үзен көндәлек мәшәкатьтән арындырырга тырышты. Данил әнисе белән күрешеп, матур яши башлауларына ышана. Чак кына түзәргә кирәк дип тынычландыра үзен.

Әти йорты да күз алдыннан китми. Юк, сатмаганнар аны. Теге абзыйлар, мөгаен, вакытлыча кереп торгандыр да шулай дип, малайны алдаштырып маташалардыр...

«Тиздән икенче катын төзербез», дип сөйли иде әтисе. Әгәр үлеп китмәсә... Аның үлгәненә дә Данилның ышанасы килми. Базарда йөреп ятканда, әтисен очратыр кебек.

Әтиең белән әниең янында яшәү нинди олы бәхет икән! Шул мәлне үлеп сагына Данил. Бигрәк тә авыр мәлләрдә якыннары, йорты турындагы истәлекләр аның күңелен җылыта. Хәтта өйдәге юрганның җылысы да хәтереннән чыкканы юк. Татлы истәлекләргә бирелеп, малай йоклап китте...

***

Эх, шул Ләйсән. Кояштай елмайган кызны тәүге тапкыр күргәненә күпме вакыт үтте. Гел очрашып та тормадылар. Данил өчен ул мөмкин дә түгел. Ә шулай да ул кызны бер көнгә дә онытканы булмады. Ничектер истә, йөрәк түрендә йөрткән сыман. Бүген күрешсәләр, нәрсә дип әйтер икән? Шунысы кызык: көннән-көн шул кыз ешрак исенә төшә. Менә әле дә аяклар теге йортлар ягына үзеннән-үзе алып китте. Тик буш кул белән бару уңайсыз. Ләйсәнне нәрсә беләндер куандырасы иде. Шул уй белән зур кибеткә керде.

Акчасы булган кешедәй киштәләр яныннан тегеләй-болай үтте. Шулчак күзе йомры көзгегә төште! Нинди матур әйбер! Кесәдә йөртер өчен бигрәк уңайлы. Вәт ичмасам Ләйсән куаначак. Күп уйлап тормый, Данил аны өске кесәсенә тыкты да чыгу ягын карады. Бу урлашуын берәү дә сизмәде.

Биек йортлар арасына кереп, эзен яздыргач, Данил эскәмиягә утырды. Олы куаныч белән теге көзгене кесәсеннән чыгарды.

– Мату-у-ур! – дип куйды канәгатьлек белән. Җитмәсә, япмалы бит әле. Ләйсән куаныр инде...

Көзгедә үзен күргәч, бераз кәефе кырылды. Күптән юынмагач, муены пычрак, ачуны китереп, кара җеп сыман күренеп тора бит әле. Колак эчен дә тазартырга кирәк. Болай шайтан сыман кыяфәттә сылу янына ничек гарьләнми барсын инде? Оятка калдырса? Бүтән күрешмәстәй булса?

Үзеннән-үзе оялып, елга ягына табан атлады Данил. Бу зур булмаган каланың уртасыннан елга ага. Аңа барып җитү әллә ни ерак түгел. Ичмасам, муенын, битен, колагын юып алыр. Кеше алдына чыкса, һәркем матуррак күренергә тырыша, ә кыз янына барганда, бу теләк икеләтә арта. Рәхәтләнеп, су чәчрәтеп юынды ул. Моннан соң шундый рәхәт булып калды. Кәеф тә күтәрелде. Бер уңайдан киеменең пычранган урыннарын сулап, сөртеп алды. Хәзер очрашуга барырга мөмкин.

Көзгене янә кулына алды ла Данил уйга калды. Кем соң ул теге кыз алдында? Ләйсән аны акыллы, тәртипле малай дип белә. Ә Данил?! Бар белгәне – урлашу... Әле дә кызга бүләк дип көзге алды. Әйе, мондый бүләккә сылу куаныр. Тик нинди юл белән табылган соң ул бүләк? Шушы икеләнү аңа тынгы бирмәде. Ләйсәнне ул күпләргә өлге итеп күз алдына китерә. Аның белән аралашкан кеше алдашмаска, урлашмаска тиеш. Ләйсән – сафлык. Ә сафлыкны пычратып, урлаган әйберне ничек бирергә мөмкин! Гарьлек Данилны эчтән ялмап алды. «Оят! Оят! Оят» – дип үзалдына кабатлады. Әгәр кыз аның карак икәнлеген белеп алса? Нигә шушы турыда Данил алдан уйламады икән? Төшенә этисенең керүе юктан түгел бит. Әллә урлашып йөрүенә шулай әрнүен белдерәме? Башында мең төрле уйлар чуалып, томалады.

– Чукынып китсен бу көзгесе! – Малай бар көченә ялтыр бүләкне суга атты. Инде нәрсә эшләргә? Елга ярындагы тугайда үскән төрле-төрле чәчкәләргә күзе төште аның. Тапты! Күп тә үтми, чәчкә гөлләмәсе аның кулында иде. Кешегә шатлык бүләк итәр өчен мотлак урлашырга димәгән. Шушы уеннан малайның кәефе күтәрелде. Ул ышанычлы адымнар белән күптән таныш йорт ягына атлады.

***

Подъезд алдында Данил ярты сәгать чамасы утырды. Кызның фатиры кайда икәнен дә белә. Тик уңайсыз. Әгәр ул ишектәге кыңгырауга басса, Ләйсән урынына әнисе килеп чыкса? Ул чакта нәрсә дияр? Оялта. Шуңа тәүдә подъезд алдындагы эскәмиядә көтеп утырырга булды. Тагын биш минут кына көтәм дә, әгәр чыкмаса, үзем күтәреләм, дип, үзен тынычландырды.

– Саумы, Данил? – Таныш тавышка малай башын күтәрде дә өнсез калды. Аның каршысында Ләйсән басып тора иде. Ике кулына сумка тоткан. Чәчкәле күлмәк кигән. Озын, куе чәчләре биленә тиклем төшеп тора. Ә елмаюы...

– Сәл-а-ам! – Күптән көткән кешесе белән күрешүдән Данил югалып калды. Тотлыга-тотлыга исәнләште. – Ә син кайдан киләсең?

– Кибеткә барган идем. Әнием囗 эштә. Ул кайтуга берәр нәрсә пешереп куярга

кирәк, – диде Ләйсән, елмаеп. Әйберләрен җиргә куйды. Данил шатлыгыннан чәчкәләре турында да онытты. Анысын эскәмиягә куеп торган иде. Арытабан сүзне нәрсә турында дәвам итәргә белми торганда, күзе теге гөлләмәгә төште.

– Ә-ә-ә, онытып торам. Ләйсән, бу сиңа! – Болай да якты йөзле кыз балкып китте. Аның күзләреннән шатлык нуры бөркелә. Мондый да кыюлыкны көтмәгәндер Данилдан. Дөресен әйткәндә, тәү күрүдән үк ошатты бу малайны Ләйсән. Гадилеге, ихласлыгы белән үзенә каратты. Мәктәптә дә малайлар җитәрлек. Тик Данил алардан күпкә матуррак. Тешләрен күрсәтеп, бер елмаюы ни тора! Ә үзен ничек ирләрчә тота бит әле. Куанычы эченә сыймады кызның, үзе дә аңламастан егетне кочаклап алды:

– Рәхмә-әт! – диде ул гөлләмәне иснәп. – Миңа беркайчан да чәчкә бүләк иткәннәре юк иде.

Шатлыгыннан кыз менә-менә очып китәрдәй тоелды. Шушы мәлдә егетне аңлата алмаслык хисләр чолгап алды. Бигрәк тә Ләйсәннең кочаклавы нык тәэсир итте. Хәтта башына эссе йөгерде, үзе оялып, кызарып китте. Мондый мизгелләрне беркайчан кичергәне юк иде әле.

Йолдыз да кайдадыр югалып торган җиреннән килеп чыкты. Күптән күрешмәгәч, ул да Ләйсәнне сагынган, күрәсең. Койрыгын болгап, үрле-кырлы сикереп, кызга сарылды. Ләйсән дә аны иркәләп алды.

– Ничек зураеп киткән. Үскән бит әле... – Эт йомшак кулларны тоеп иркәләнә бирде. – Әйдә, тышта тормагыз. Керик!

Егет бу тәкъдимнән аптырап калды. Тышта озак торып булмый бит инде. Ләйсәнгә аш пешерергә кирәк. Данилның аның янында озаграк буласы килә дә бит. Сөйләшмәсәләр дә, күзләренә генә карап торырга риза. Ничектер рәхәт аның янында, бөтен мәшәкатьләреңне онытасың. Икенче яктан, Данил фатирга керергә тартына, чөнки носкилары тишек. Шуны кыз күреп калса, бетте баш!

Ахырда:

– Юк, рәхмәт. Кереп тормамдыр, уңайсыз, – дип баш тартты. Ләкин Ләйсән үзе генә өенә керергә ашыкмады:

– Әйдә, әйдә. Үземә генә барыбер күңелсез. Чәй эчеп алырбыз.

Фатирга керергә Данил ризалашмас та иде. Теге ике авыр сумканы күреп, егетлеге алга чыкты.

– Үзем күтәрәм, – дип, йөкне кулына алды.

Йолдыз да калышмады. Ул белә: шушы кыз белән күрешсәләр, аңа һәрчак нәрсәдер эләгә. Теге тапкыр зур сөяк эләкте, колбаса белән дә сыйларга мөмкиннәр аны. Әле дә күпне өмет итә эт. Шул нияте аңа егет белән кыздан бер адымга да артта калырга ирек бирми. Фатирга кергәч тә, Йолдыз әрсезләнеп түргә үтмәде. Ишек төбенә ятып, ризык китерүләрен көтте.

Данил рөхсәт сорап, тиз генә юыну бүлмәсенә кереп бикләнде. Оятка калмыйм дип, теге тишек носкиларын салып, аякларын сабынлап юды. Инде кеше күзенә күренергә дә була.

Ләйсән аш бүлмәсендә мәш килде. Кәстрүлгә ит салды да бәрәңге, кишер чистартырга кереште. Күңелсезләнеп утырмасын дип, Данилга фотоальбомын тоттырды.

– Мин кеше фотоларын карарга яратам, – дигән булды Данил. – Бигрәк тә балачактагысын. Ул вакытта кешеләр кызык була.

– Ярар. Тик көлмә минекеләрдән...

Фотоальбомны гына карап утырмады Данил, Ләйсән эш белән мәшгуль вакытта сиздермичә күзәтте. Шулай була икән. Күзне дә алырлык түгел.

Нәрсәсе беләндер тартып тик тора. «Уңган кыз. Кулына күз иярми», – дип үзенчә нәтиҗә ясап куйды.

– Ләйсән, ә син ничә төрле аш пешерә беләсең?

– О-о-о, күп инде алар! Әнием бәләкәйдән өйрәтте.

– Ә нәрсәне ешрак әзерлисең?

– Вакытка карап инде. Әгәр ашыксам, табада йомырка кыздырам. Өч минутта әзер була. Ә инде вакытым күбрәк булса, итле ризык әзерлим. Ә син нәрсә яратасың?

Бу сораудан Данил өнсез калды. Соңгы мәртәбә нәрсә ашады соң? Бәрәңге йә борчак боткасы, йә макарон дип әйтсә, уңайсыз. Бу бигрәк фәкыйрь икән дип уйлар Ләйсән. Курыкты. Ахырда, бик күптән ашаган затлы ризыкны исенә төшерде.

– Бишбармак йә каз ите белән салма, – дип әйтә алгач, иңеннән олы йөк төшкәндәй тоелды.

– Менә син тәмлетамак икәнсең. Ярар, анысын да берәр пешерербез...

Икәүләшеп, капма-каршы утырып аш ашадылар. Монда бөтен нәрсә дә пөхтә. Савыт-сабалар ялтырап тора. Кая карама – тәртип. Ә ашның тәмлелеге... Кайчан мондый сыйны күрде соң Данил? Ничек кенә тырышмасын, барыбер исенә төшерә алмады. Йолдыз да өлешсез калмады. Итне турагач та, эре-эре сөякләр аңа бирелде. Бүген эткә дә, Данилга да бәйрәм.

Ашаганда, Данил үзен иплерәк тотарга тырышты. Ничек кенә тиз ашап бетерергә теләсә дә, үзен тыйды: калаклары белән җайлырак эш итте. Комсызланып, шәп-шәп йотарга ашыкмады. Әнә, Ләйсән ничек оялчан утыра. Үзен Данил алдында тагын да итагатьлерәк итеп тотасы килә. Егет тә шушы нияттән азат түгел.

Ләйсәндә ничек кенә рәхәт булмасын, кайтырга кирәк. Данил сәгатькә карап алды. Әнисе эштән кайтып керсә... Алтыдан да соңга калырга ярамый. Әгәр ул берүзе генә яшәсә, бәлки, чыкмас та иде. Икесенә шундый күңелле бит. Вакыт үткәне дә сизелми. Эх, гел шулай бергә булсалар...

Данил кайтырга җыенгач, Ләйсәннең йөзе үзгәрде. Күренеп тора, аның да хушлашасы килми. Тик бүтән чара юк.

– Ә син тагын кайчан безнең якка киләсең? – диде Ләйсән.

– Борчылма, – Данил кызны тынычландырырга тырышты. – Инде озакка югалмам. Килермен шушы елларда. Бергә шәһәр буйлап йөрербез.

– Алдашмыйсыңмы? Килерсеңме? – дип кабатлап сорады кыз.

– Килермен.

– Ярар. – Ләйсән тагын елмайды. – Дөресен әйткәндә, син озак югалып йөргәч, мин борчыла башладым. Бүтән килмәссең дип уйлаган идем. Әллә үпкәләттемме, дип тә борчылдым.

– Сүз бирәм. Башка югалмам! – Егет чыгып китим генә дигән иде, кинәт кире борылып карады. Күзләр очрашты да, сүзсез генә тордылар. Данил бу мәлдә шул тиклем бәхетле итеп тойды үзен. Кызның кулына кагылмыйча чыга алмады.

– Ләйсән, колагыңа бер әйбер әйтимме? – дигән булды. Кыз, ниндидер мөһим хәбәр ишетәм дип, аңа үрелде. Шулчак Данил аның битеннән үбеп алды. Бу тиклем кыюлыгына үзе дә аптырады. Бу уй кайсы арада башына килгәндер. Шундый көтелмәгәнчә килеп чыкты! Ләйсән оялып читкә борылды...

Подъездан чыккач, Данил йөгерә-атлый Илдарның йортына юнәлде. Ул шул тиклем шат иде шушы минутта. Күңелдә – тантана! Тирә-як тагын да

ямьләнеп киткән! «Мин – бәхетле!» дип, урам тутырып кычкырасы килде. Юлда очраган һәр кеше дә аның кебек бәхетле кебек тоелды. Әйе, бу дөньяда яшәү олы шатлык икән! Нигә элек шуны сизмәде соң? Бөтен хикмәт Ләйсәндә. Эх, аның уйнап торган күзләре! Оялчан карашы... Ташны эретерлек итеп елмаюы... Ә инде колакны иркәләгән тавышы...

Юк, атлап түгел, очып баргандай булды Данил. Әйтерсең лә, канатлар үсеп чыкты. Элек мәктәптә укыганда, шигырь ятларга ярата иде. Ә хәзер үзенең шигырь язасы килеп китте. Ләйсәнгә атап...

## X

Хәзер базарга йөрү хәвефле була башлады. Аларны бу бәләкәй калада сатучылар йөзгә белә диярлек. Бүтән чара уйлап тапмасалар...

Илдар төне буена йоклый алмый чыкты. Бер уй башында уралды. Барыргамы, бармаскамы? Юк, ул үзе анда йөрмәс. Ә менә ике малай... Ничек итәргә икән?..

Черновны бу калада белмәгән кеше юктыр. Череп баеган адәм. Кайсы бер кешеләргә уңыш елмаеп кына тора. Әнә шул зур корсаклы ир халык өчен нәрсә эшләгән?! Ул хакимият тирәсендә урала. Шунда ниндидер вазифа били. Моннан тыш, гаиләсенең бизнесы да бар. Каладагы аракы, сыра саткан иң зур кибетләр Черновларныкы. Аларга каршы сүз әйткән, эшләрен тикшергән адәм юк. Ай үсәсен – көн үсеп, баеп яшиләр. Каланың иң матур урамында ике катлы балкып торган йорт – аларныкы.

Илдар күптән күз салып куйды шул кызыл кирпечле йортка. Ә инде аның хуҗасы турында риваятьләр авыздан-авызга күчеп йөри. Имеш, Черновның бер пар туфлие генә дә – укытучының бер еллык эш хакына тора. Ул адәм банкта акча сакламый дигәнен дә кемнәндер ишетте. Акчаларын өйдә тота, банкка ышанычым юк, дип әйтә икән. Ремонт эшләгән егетләргә шкафтан төргәге белән акча чыгарган да күз алдында чутлап биргән! Өйдәге җиһазларның кыйммәтлеге, күплеге турында әйтеп торасы да түгел. Ничек моңа ышанмыйсың! Хәзер кешеләрнең берсеннән-берсе узып, байлык туплый торган заман башланды. Намус та, мәрхәмәтлек тә арткы планга күчте. Мондый мал колларына хәзер халык та күнегеп бетте. Фәләннең өендәге әбрәкәйнең ишеге алтыннан дисәләр, икеләнми ышаначаклар.

Әле отпуск чоры. Күпләр бу вакытта йә диңгездә, йә чит илдә ял итә. Чернов ял итмәслек кешеме? Ул да бит эшли. Илдар шул йорт ягыннан көн дә үтеп йөри. Йортның һәр өлешенә игътибар итә. Капка эчтән бикле, тәрәзәләр ябык, чаршаулар эленеп тора... Тик бер урында форточка гына ачык калган. Инде бер атна күзәтеп йөрде: кичен анда ут янганын күрмәде. Форточканы да ябучы юк. Үзенең танышы аша да белеште. Чынлап та, хуҗалар ялга киткән...

Данил белән Цыган – үткер егетләр. Илдарга аларның җитезлеге, зирәклеге ошый. Моңарчы җиңелрәк «эштә» аларны күп сынады. Афәрин, сер бирмәделәр. Кайдадыр тотылып, артык мәшәкать тудырмадылар. Уңды, бик уңды Илдар шушы йолкышлардан. Тамак та тук, баш та тыныч. Әгәр алар булмаса, хәзер иректә йөрер идеме? Яшьләр өчен Илдар борчылмый. Эләксәләр, алардан ни җавап? Унсигезләре тулмаган. Димәк, өлкәннәр сымак җаваплылык та юк. Илдар судан коры чыгачак. Аларга да бит бу шөгыль ошый. Цыган дигәне «һайт» дигәнгә «тайт» дип тора. Ләззәт белән башкара һәр кушканны.

Болар белән разведкага барырга була, дип сөенеп куйды Илдар. Вакытны югалтырга ярамый. Тәвәккәлләргә кирәк.

***

– Әгәр килеп чыкмаса? – Цыган чәен читкә этеп, торып китте.

– Карга сыман каркылдап торма! – Хуҗаның җавабы каты иде. – Барысын да белештем. Өй буш. Хуҗалары ял итәргә киткән...

Сүзгә Данил да кушылды:

– Башкача тәкъдим юкмы? Нигә шул өйгә төшәргә дигән?

– Кесәләр буйлап йөрү ялкытты. Бу – бала-чагалар эше. Это не наш уровень. – Косой үзенекен талкыды.

Малайлар сүзсез калды. Ни дисәң дә, шүрләтә. Моңа кадәр андый адымга барганнары юк бит. «Эшнең» дә ниндие әле?! Йорт басарга! Җитмәсә, хуҗасы кем! Илдар күндерә белә. Мондый мәлдә ничек сөйләргә кирәклеген аңа өйрәтәсе юк. Иң мөһиме – тынып калмаска! Нәрсә булса да сөйләргә. Нәкъ шушы икеләнгән мәлендә, әгәр тегеләр үзенекен сүз итсә, эш барып чыкмас. Мондый вакытта берәүнең генә сүзе сүз булырга тиеш. Ничек тә ышандырырга кирәк.

– Сез миңа ышаныгыз. – Мич алдына утырып, Илдар тәмәкесен кабызды. Тегеләрне дә янына чакырып алды. – Эшне ничек үтәргә кирәклеген күптән уйладым. Всё чисто. Бер нәрсәдән дә куркырга ярамый. Барысы да җип-җиңел. Кердең, алдың, чыктың...

Данил бу тәкъдимнән чигенү ягын карады:

– Моңарчы базарга йөрдек. Кесәләрне чистарттык. Ачтан үлмәдек бит...

Косой аңа кырын карап куйды:

– Ул вакытны онытыгыз. Анда өйрәнү өчен генә йөрдек. Хәзер сезнең тормышта бүтән этап башлана. Целовать – так королеву, брать – так банк!

– Барыбер шүрләтә бит әле, Илдар абый! Ул тиклем зур җинаять өчен әллә нәрсә эшләтерләр...

– Ха-ха... – хуҗа боларның беркатлылыгыннан көлеп җибәрде. – Шул да булдымы зур җинаять? Зурның ни икәнен сез әле белмисез. Матур галстук, костюм киеп йөргән кайсыбер түрәләр миллионлап, миллиардлап урлый! Тоташ ил халкына диелгән мөлкәт берәүнең корсагына кереп ята. Ә ул ыжламый да. Аны тотучы, җавапка тарттыручы кеше дә юк. Мин нигә шундый юлны сайлады дип уйлыйсыз? Үч итеп урлыйм, чөнки безнең илдә урлашмыйча яшәп булмый...

Илдар кинәт кызып киткәч, малайлар аны бүлдерергә кыймады. Күрәсең, бу төер күптән аның эчендә яткан. Әле шуңа ниндидер гаделлекне юллагандай, ярсып сөйли бирде.

– Ә син зур җинаять, дисең? Бүтәнчә алай көлдермә, яме, Данил. Яши-яши шуңа инандым: кем йә тавык, йә магнитофон урлый – төрмәгә ябалар. Ә кем завод йә урманны урлый – иректә яши. Кайда гаделлек?! Шуңа гомер буена бер үкенечем бар: күп итеп урлашырлык урында эшләмим. Әллә нинди эшләр кылып, баеп яшәр идем.

Тышта дөм караңгы. Тирә-якта тыныч. Бер адәм тавышы ишетелми. Йорт та ялгызы тора. Иң мөһиме – этләре юк. Тик менә коймалары гына биек. Җитмәсә, кирпечтән салганнар бит әле. Кирмән, диярсең. Илдар кушканча эшләргә кирәк. Данил ике кулын тезенә куеп, «баскыч» ясады һәм Цыган, шуңа басып, өскә үрмәләде. «Һоп» итеп эчкә дә төште. Данилның эше башка. Ул тирә-якны сагалап торырга тиеш.

– Тәрәзәдән керү ничек җиңел. Ичмасам, форточкасын япмаганнар, исәрләр,

– дип уйлап өлгерде Цыган. Ә аның кебек ябык кешегә ул форточка нәрсә инде?! Баш кына керсен, ул чакта бөтен тәнең сыячак. Бу кагыйдәне малай яхшы белә. Эчтә бик сак булырга кирәк. Ут яндырырга ярамый, моның өчен шырпы җитә. Эз калдырмас өчен юка перчаткалар да киде. Белгән догаларын укыды да тәрәзәгә үрмәләде. Тәүдә башын, ике кулын тыкты, шуннан рамына тотынып, эчкә төште. Шәп килеп чыкты.

Шул мәл коточкыч сирена тавышына Данил дертләп китте. Йорт эчендә йөрәкне ярырлык итеп сигнализация улый башлады! Йөрәк табанга төшкәндәй булды! Ах, чукынчык байлар! Үз мөлкәтен ничек сакларга беләләр.

– Цыган, тайдык! – дип кычкырды ул җан көченә. Мондый очракта бердәнбер чара – табан ялтырату. Димәк, өйне сак астына куйганнар. Алары озак көттермәс, хәзер үк килеп җитәрләр.

Цыган калтырана-калтырана чыгу ягына үрелде. Форточкага атылып дигәндәй чумды. Бите, куллары сыдырылды. Тик ул авыртуны тоймый иде. Бар уе – тизрәк чыгып качу!

– Шәбрәк! Шәбрәк! – Данил кабаландыра торды.

Цыган тәрәзәдән чыкса да, коймага үзе генә сикереп менә алмады. Капканы да эчтән тарткалап карады, ул йозакка бикле булып чыкты. Тегеләй дә, болай да йөгереп карады. Ул камауда! Баскыч сыман әйберләре юк. Ә теге сирена һич туктарга уйламый, ярсып акыра да акыра!

– Чё тормозишь? Чык тизрәк!

– Чыга алмыйм! Койма биек...

Якында гына машина тавышы ишетелде. Анысы зур тизлек белән килә. Йорт сакчылары. Бетте баш.

– Син яшерен шунда, – бүтәнчә уй килмәде Данилның башына. Үзе дә котылу ягын карап, каршы йорттагы бакчага сикерде. Кеше күрмәсен өчен куаклар арасына качты.

Машина нәкъ шул ике катлы йорт алдында туктады. Эченнән әзмәвердәй дүрт ир йөгереп чыкты. Һәрберсенең кулында – күсәк. Фаралар яктысында Данил моны яхшы күрде. Берсе шыгырдатып капканы ачты да бергәләп эчкә үттеләр. Ә сигнализация, корып киткере, туктамый акыра.

Цыганны тапмасалар ярар иде, дип теләде Данил. Элек белгән догаларын исенә төшерергә тырышты. Цыган елгыр егет, берәр җиргә яшеренеп калыр ул, дип ышанды. Менә сигнализация тынды. Ә йөрәк дөпелди. Нәрсә булып бетәр икән? Шушы мәлдә Илдарны каһәрләде малай. Аңа, җылы өйдә яткач, рәхәт. Әгәр шушы хәлдән исән-сау чыксалармы, табар Косойга нәрсә әйтерен. Мондый мәлдә минутлар сәгатьтән дә озынрак тоела. Эчне пошырып, теге сакчылар да ихатадан чыгарга ашыкмый. Нәрсәдер эзлиләр, тентиләр чукынчыклар.

– Ах, вот он где лежит, тварь! – дип сөрән салды эчтә кемдер.

– Попался, ворюга!

– Это же беспризорник. Знакомое лицо!

Данил ике кулы белән башын тотты да катып калды. Могҗизага ышанса да, ул теләгәнчә килеп чыкмады. Тегеләрнең ярсып-ярсып тукмаганы ишетелде: «А-а-а, кулымны сындырасыз. Кирәкми!..» Малайның ычкынырга теләп карышуы ирләрнең ачуын арттырды гына, күрәсең.

– Мы тебе все руки и ноги переломаем!

– Будешь знать – куда лезть.

– Тимәгез миңа! Ән-иииииии! – Цыган болар жәлләр дип, елап ялварды. Кан

күргән бүре кебек, күсәк тоткан әзмәверләр шашканнан-шашынды. «Шак-шок» иткән колакны ертырдай тавыш тирә-якка ишетелеп торды. Ә ирләр бер җәлләү белми, башын да, кабыргасын, аяк-кулларына да агач күсәк белән төйделәр генә. Цыганның авызыннан да, колагыннан да кан китте.

Андый тукмауның шаһиты булу – үзе коточкыч хәл. Шуңа Данил чарасыздан колагын каплады. Күзеннән бертуктаусыз яшь акты. Ярдәм итә алмый шул дустына – шунысы үкенечле. Чыкса, үзен дә шул ук язмыш көтә. Тоташ дөнья ишелгәндәй тоелды шушы мәлдә. Үзенең җир йөзенә туганына үкенде Данил.

– Кот-ка-ры-гы-ыз! – Берәрсе ишетер, ярдәмгә килерләр дип, бар көченә кычкырды Цыган. Ләкин аны коткаручы булмады. Ирләр узыша-узыша типкәләвен дәвам итте.

Хәлсез, канга баткан Цыганны урамга чыгарып ыргыттылар да, машинага утырып, күздән юк булдылар.

***

Данил тукмалган дустын ничек тә Косойның өенә алып барып җиткерергә ашыкты. Тик аның тырышуы бушка булды. Йөз метр араны да әллә бер сәгать үттеләр. Цыган туктаусыз уфылдый, берничә адым бара да туктый.

– Данька, тукта-а, – дип телгә килде Цыган. – Миңа кыен, башка бара алмыйм, ятып торасым килә...

– Түз инде чак кына, түз... – Данил адымнарын киметми, дустын юатырга маташты. – Хәзер кайтып җитәбез.

– Юу-ук. Тукта... Башкача чыдап булмый, – дип, ул елап җибәрде. – Эчемдә нәрсәдер чәнчә, башым әйләнә. Ишетәсеңме мине, зинһа-а-а-р! – Бу сүзләрне олы ялвару белән Цыган бар көченә кычкырып әйтте. Әмма кешене бу хәлендә урам уртасында калдырып булмый бит. Цыган бертуктаусыз кан түкерә... Авыртуын киметергә тырышкандай, бөгәрләнеп, эчен уып маташты. Аның шул тиклем дә куркыныч хәлен күреп, Данил нәрсә эшләргә белми аптырап торды.

– Йә, сиңа нәрсә эшлим? «Скорый» чакыртсам, ничек булыр икән?

Цыган туктаусыз чәчәвеннән арына алмый, көчкә телгә килде.

– Хәлләрем хөрти, Данька, – диде ул ыңгыраша-ыңгыраша. – Бөтен тәнем авырта. Эчемдә утлы тимер яткан сымак. Сөякләрем чатный. Җитмәсә, сул кулым сынган шикелле.

– Тик син күзеңне йомма, яме? Ишетәсеңме мине – йомма! – Данил шулай диде дә дустын куаклыкта калдырып, җан-фәрманга урамга йөгереп чыкты. Мондый мәлдә һәр минут кадерле икәнлеген яхшы аңлый иде.

Цыганның янына йөгереп килеп җиткәндә, ул һушын югалтыр хәлдә, җирдә бөгәрләнеп ята иде. Йөзе шешенгән, күзләре төпкә баткан. Ул Данилны күргәч тә, соңгы өмет белән дустына карады.

– Скорый киләме?

Данил аны тынычландырырга маташты:

– Әйе, хәзер килә.

Шулчак «ыһ» дип авыр сулады Цыган. Эчендә нәрсәдер чәнечкәнгә һәр тарафка ишетелерлек итеп ыңгырашып алды. Көченең минут саен кимүен тоеп, әйтер сүзен тәмамлап куярга ашыкты:

– Ходай мине дөньяның бөтен кыенлыкларын татыр өчен җибәргәндер ул. Бер рәхәттә яшәп булмады, дус, шунысы үкенечле.

– Бәхетле көннәребез алда әле...

– Юк, Данька. Синең этең дә безгә караганда күпкә бәхетлерәк. Аны,

ичмасам, урамда кешеләр жәлләп, сөяк йә икмәк биреп китә. Ә безне жәлләгәннәре булдымы? – Цыганның һәр сүзе кыенлык белән генә чыга иде.

Акланырдай сүз тапмады Данил. Аның белән килешми мөмкин түгел иде.

– Мин аякларымны да, кулымны да тоймыйм. Әллә кая очып китәрмен кебек. Күземне йомарга да куркам...

– Түз, түз! Хәзер «скорый» килә...

Цыганны шунда ук алып киттеләр. Тик ул ак халатлы кешеләр килгәндә, һушын югалткан иде инде. Данил да алар белән барырга теләде, әмма аны алмадылар.

...Төштән соң Данил үзе дәваханәгә барды. Ул кала читендә урнашкан. Тәүдә кабул итү бүлегенә кереп, дустының кайсы бүлектә ятканын сорашты. Исем-фамилиясен төгәл белмәгәч, табуы кыенрак булды.

– Сез кемгә? – диде актан киенгән олы яшьтәге ир.

– Тимур... Ул бүген сезнең бүлеккә эләкте. 16 яшьтә.

Тыныч кына утырган табиб урыныннан торды да Данилга якынрак килде.

– Ә сез аңа кем буласыз?

– Энесе.

Палатага кертмәсләр, дип курыкты малай. Шуңа якын туганы дип, алдап әйтте. Табиб беразга тынып калды. Шуннан нәрсәдер әйтергә теләп, кулы белән ишарәләп маташты.

– Сезгә ничек әйтергә дә белмим... Ул күп кан югалткан. Давлениесе нык төшкән иде.

Табибка әйтеп бетерергә дә ирек бирми, Данил сорауларын яудырды:

– Ә хәзер хәле яхшырдымы? Аны кереп карасам буламы?

– Реанимация дә ярдәм итмәде. Без аны коткара алмадык...

Данилның аяк астында җир убылгандай тоелды. Буыннары тотмый, шунда ук чүгәләде...

## XIII

Цыган үлгәч, бер атна тирәсе Данил аңын җыялмый йөрде. Берәүне дә күрәсе, берәү белән дә сөйләшәсе килмәде. Илдарның йортына аягы тартмады. Бөтен бәладә, дустының үлемендә тик аны гына гаепләде. Көченнән килсә, бүген үк буып ташлар иде. Кайгыга баткан егет үзенә урын таба алмыйча, каланың йә теге, йә бу очында үзенә йокларга урын эзләде. Адашып йөри торгач, ташландык гаражга килеп юлыкты. Хәер, көннәр җылы тора, түзәрлек.

Атна үткәч, Данил «остазы» Косойның өенә барып килергә булды. Анда яшәргә теләге юк. Бәла китергән ирнең күзенә карап, нәрсә уйлаганын түкми-чәчми ярып салырга! Егеттә кан кайный, Цыганның үлеме өчен нәфрәте ташый. Икенчедән, эте анда калды бит. Үзенең тугры дустын ничек шул адәм кулына калдырсын? Этен алып, уйлаганнарын әйтеп, битенә төкереп чыгып китәргә исәбе.

Капканы озак шакыса да, чыгып ачучы булмады. Косой куркып яшеренгәндер әле дигән уй килде. Шуңа бакчага кереп, тәрәзә аша өй эчен карады. Ут сүнгән, берәү дә күренми. Ярый, Илдар өйдә юк, ди, ә эт кайда соң? Мөгаен, йорт тирәсендә йөридер.

– Йолдыз, Йолдыз! Кил, кил! – Данил этен чакырырга тотынды.

Тавышка күрше йорттан олы яшьтәге хатын килеп чыкты. Данил элек тә аны күргәли иде. Тик бер дә сүз кушып, сөйләшкәннәре булмады. Дөресрәге, Илдар аралашырга кушмады. Косой шул тиклем күрә алмады ул күршесен.

Гел исемләп түгел, ә «старая карга», «ведьма», «стукачка», «маразматик» дип кенә телгә ала иде.

– Сезгә кем кирәк? – Хатын егетне яхшырак күрергә теләпме, якынрак килде.

– Кос... М-м-м. Илдар кирәк иде.

– Кызганычкамы, бәхеткәме дигәндәй... Аны якын арада гына күрә алмассың.

– Ә нәрсә булды?

– Ике көн элек милиция килеп, кулларын бәйләп, алып киттеләр. – Хатын биек өйләр ягына кулы белән күрсәтте. – Әнә шундагы бер киоскны талаган булган, мәхлук. Хәзер биш елдан соң гына килерсең инде абыеңны күрергә. Котылдык. Колак тынып калды.

Данил ишеткәненә ышанмый, күзләрен акайтты. Шул кирәк аңа, дип, эчтән куанып та куйды. Аны шушы мәлдә Косойның алдагы язмышы түгел, ә этенең кайда булуы ныграк борчый иде.

– Ә этне күрмәдегезме? Аны монда калдырып торган идем.

– Шул бурны алып киткән көндә үк югалды ул.

**XI**

Инде нәрсә эшләячәген Данил яхшы белә. Бу турыда төне буе уйланып чыкты. Бер генә юл калды. Җитте! Арыды ул тормыштан! Ялгызлык, ачлык, беркемгә дә кирәкмәвең... Артык җан итеп тоя ул үзен дөньяда. Шуннан да куркынычрак берәр нәрсә бармы? Беркемгә дә кирәкмисең. Әйе, сукбай тормышын башлавына елдан артык вакыт үтте. Тәүдә барыбер яхшырак иде. Орех, Цыган... Алар бер-берсен аңлап, бер табактан ашыйлар иде. Ә хәзер... Яраткан эте дә калмады. Ничек алай килеп чыкты соң? Шул тиклем якын иде бит аңа Йолдыз! Елдан артык гомерне бергә үткәрделәр. Алар очрашканда, Йолдыз әле көчек кенә иде. Аннан соң күпме көннәр үтте... Ә кышын аны үлемнән кем коткарды?! Әгәр шунда дүрт аяклы дусты ярдәмгә килмәсә...

Нәрсә көтә аны? Орех та, Цыган да теге дөньяда, Илдар – төрмәдә. Данилны да шушы ике юлның берсе көтә. Исән калса, тагын тамак хакына урлашу, җинаять кылу. Юк, мондый тормышны теләми Данил. Кешеләргә зыян китерүдән арыды. Әтисен оятка калдырып, адәм көлдереп йөргәнче, җир йөзендә яшәмәвең хәерле.

Данилның эчендә – ялкын. Нәфрәт тә, тормышка үпкәсе дә, үкенечләре дә кушылып, тышка кайнап чыгар төсле. Йөрәге ничек түзәдер?! Кирәкми, кирәкми ул шушы дөньяга. Шундый нәтиҗәгә килде ул. Мәңгелеккә китәр өчен барысы да әзер. Барлык кылган гөнаһлары өчен Аллаһтан ярлыкау сорады. Инде була. Һәр хәрәкәтен алдан чамалады: унга тиклем саный да, аяк астындагы утыргычны тибеп җибәрә. «Бер, ике, өч...» Кешенең соңгы минутында иң кадерле кешеләре исенә төшә, диләр. Әнисе... Кирәкме соң аңа Данил? Өйне сатып эчте, ят иргә ышанып, бердәнбер баласыннан баш тартты. «Алты, җиде...» Әтисенең ихлас йөзе күз алдына килде. Эх, ул исән булса! Бүген мондый хәлгә калыр идеме Данил? Әтисе нык яратты аны, Данил да аны. Тик әтисенең өметен генә акламады. Шунысы кызганыч. Ярый, тегендә очрашырлар әле. «Сигез, тугыз...» Ләйсән! Шул кызны кинәт күз алдына китергәч, ул сискәнеп куйды. Соңгы очрашулары исенә төште. Ничек ягымлы итеп сөйләште кыз, ә күз карашлары...

– Алдашмыйсыңмы? Килерсеңме?

– Килермен!

Үз сүзләре кайтаваз булып колагында кат-кат яңгырады.

Нигә аны онытып җибәрде соң егет? Тормыш мәшәкате бастымы? Теге көнне алардан очып дигәндәй кайткан иде. Тукта әле... Аңа әйтми, эчендә сер итеп саклаган сүзе дә бар бит. Аның белән хушлашмый китү дөрес булмастыр... Данил муенынннан бауны чиште дә, сикереп җиргә төште. «Теге дөньяга ашыгырга иртәрәк. Ләйсәнне күрәсе бар», – дип үзалдына сөйләнде...

Ләйсән яшәгән йорт янында Данил бер хатынны очратты. Авыр сумка тоткан, шуны көчкә-көчкә өстерәп китеп бара. Җәлләде ул хатынны.

– Апа, әйдәгез алып барышам.

– Куй, кирәкми. Үзем... – Әллә кешене мәшәкатьләп торасы килмәде, хатын тәкъдимнән баш тартты. Шулай да арыганы күренә. Уфылдап, подъезд алдындагы эскәмиягә утырды. – Өемә килеп җиттем, дисәң дә була. Күп калмады.

Данил үз юлы белән китәргә иткән иде, нәрсәдер аны туктаткандай итте. Бу хатынның йөзе таныш сыман. Кайда күрештеләр соң? Хәтерләгән кебек тә бит...

– Улым, йөзеңне әйтәм, бигрәк таныш... – хатынның эндәшүе Данилның ялгышмавын раслады.

– Мин дә сезне таныдым. – Шулай дисә дә, Данил төгәл хәтерли алмады. Апа үзе исенә төшерер, дип өметләнде. Ә-һә! Хәтерләде. Өеннән чыгып киткән көнне бер подъездда кунган иде Данил. Шунда ач малайның тамагын туйдырды бит бу апа. Әйе, нәкъ үзе! Күз төбендәге миңен дә яхшы хәтерли Данил.

– Сез мине ашаткан идегез, – диде малай, уңайсызланып.

– Әй, хәтер дигәннәре... Шулай шул. Хәтерлим, хәтерлим, балакаем, – хатынның тавышы калтыранып китте. Күз яшьләрен сөртеп алды. – Тик мин ул вакыттагы бәхетле апа түгел инде. Зур кайгы төште бит башыма. Яшәвемнең яме калмады...

Тынычлана төшкәч, апа Данилны өенә чакырды. Чәй эчеп алырбыз, диде. Данил икеләнми ризалашты. Сумканы тотып, аның фатирына юнәлделәр. Данил үзенең хәл-әхвәле турында сөйләп өлгерде. Тик бөтен дөреслекне түгел. «Өйдә яшәмим. Әни эчә. Дусларымда йөрим», – диде.

Хатынның исеме Сәлия икән. Соңгы күрешүдән соң, апа бик үзгәргән. Былтыр март аенда күргәндә, бөтенләй икенче иде. Ак чәчләре күбәйгән, күзе дә моңсуланып, төпкә баткан. Хәлсезлеге йөзенә чыккан. Әллә авыру, әллә кайгы бөккән, чак кына алга бөкрәя биреп атлый. Үзе карт та түгел бит әле. Алтмышын яңа тутырган.

Сәлия апа ике бүлмәле фатирда ялгызы яши икән. Ярты ел элек зур кайгы кичергән. Бердәнбер улы фаҗигале рәвештә авариядә һәлак булган. Кабул итми ана кеше улының үлемен: бүлмәсендә бөтен әйберләре дә үз урынында тора.

– Яшьли генә әрәм булды колынчагым, – дип, Сәлия апа улының фотосын күкрәгенә кысты да елап җибәрде. – Аның өчен генә яшәдем бит, аның өчен генә. Бик соңлап таптым аны. Ялгызым үстердем. 25 яшь кенә иде. Әле яшәргә дә, яшәргә. Кәләш тә алып өлгермәде. Ичмасам, оныкларым калыр иде. Ә хәзер беркемем юк.

Данил апаны тынычландырырлык сүзләр таба алмады. Бигрәк авыр икән шул хәле. Кайгы шулай бетерә икән кешене. Кояштай балкып торган йөзен кара күмергә әйләндергән. Ярдәм итә алмый шул Данил Сәлия апага, шунысы үкенечле.

Язмыш, тәкъдир, яшәеш хакында соңгы арада күп уйлана Сәлия. Нигә күп нәрсә шулай дөньяда гаделсез бүленә? Хәтта җәза да. Менә шушы малай

нинди матур, ягымлы булса да, берәүгә дә кирәкми. Үз әнисе аңардан баш тартып, аракыга алыштырган. Данил бәхетсез булса да, шушы җирдә йөри бирә. Ә Сәлиянең улы? Әтисез үсте. Тик әнисе моны сиздермәскә тырышты. Бүтән балалардан ким-хур күренмәсен өчен ике урында эшләде. Яратып, сөеп үстерде. Аның иң зур бәхете иде ул. Ә бер көн килеп бөтен дөньясы чәлпәрәмә килде. Нигә алай? Ходай шушы кайгыны нигә нәкъ Сәлиягә бирде? Бүтән кешеләр юкмыни дөньяда? Әнә, урам тулы эчеп йөргән хатыннарга җил дә, яңгыр да тими. Сәлиянең нинди гөнаһы булды икән?

Чәй эчеп алгач, Данил ванна керде. Апа аның өс-башының пычрак икәнен күреп, коенып чыгарга кушты. Сөйләшеп утыра торгач, караңгы да төшә башлады. Данил китәргә җыенды.

– Рәхмәт, апа! Сез шундый изге кеше. Миңа кайтырга кирәк.

Сукбай малайның «кайтам» диюен ишеткәч, Сәлия шикләнеп куйды.

– Соң бит. Караңгыда кая барасың?

– Әй, берәр дусларыма керермен әле. – Данил шулай алдаса да, кая барасы билгесез иде. Үзен мескен хәлдә генә күрсәтәсе килмәде.

– Кит, юк белән булма, – Сәлия апа малай өчен борчылып эндәште. – Кал йокларга. Улымның бүлмәсе барыбер буш тора...

***

Кала урамы буйлап егет белән кыз кулга-кул тотынышып китеп бара. Кыз иркәләнеп, егетнең колагына нидер пышылдаган иде, икесе дә көләргә тотынды. Аларның мондый кәефен күреп, бүтәннәр дә үзеннән-үзе елмаеп куя. Шатлык шулай як-якка сибелә. Ә ничек пөхтә киенгәннәр! Соклангыч пар!.. Бәхет дигәннәре шушындый кыяфәттә буладыр. Ләйлә белән Мәҗнүн, Йосыф белән Зөләйха... Андый гашыйклар турында борын-борыннан риваятьләр телдән-телгә күчә килгән. Яшь йөрәкләрнең тугрылыгына, эчкерсез сөюенә күпләр сокланган. Андый кешеләр дөньяны ямьли, диләр. Ерактан балкып килгән Данил белән Ләйсән гөрләтеп туй үткәреп, мәхәббәттән исерү мәлен кичерәләр.

Бик нык үзгәрде хәзер Данилның тормышы. Теге күрешкәннән соң, Сәлия апа аны уллыкка алды. Бик җиңелдән килеп чыкмады, әлбәттә. Бихисап документлар юлларга, бер түрәдән икенче түрәгә йөгерергә туры килде апага. Җитмәсә, эчкече әнисен ана хокукыннан мәхрүм итәргә кирәк иде. Аны районда эзләделәр, кермәгән авыл калмады, барыбер таба алмадылар. Тик Сәлия ханым үз сүзендә нык торды. «Малайны әҗәлгә бирәсем юк», – дип, каты әйтте опека хезмәткәрләренә. Ходай аның теләген ишеткән, күрәсең, барыбер ерып чыктылар. Малай шулай йортлы булды. Өс-башы бөтен, тамагы тук. Ялгызлыктан котылгач, Сәлиянең дә яшәргә дәрте уянды, элекке яралары онытыла бирде.

Данилның укымый йөрүе генә бераз бәкәлгә сукты. Ручка тотарга да оныта башлаган иде. Ә бит алда нindидер һөнәр алырга кирәк. Монда да әмәле табылды. Мәгариф бүлеге белән сөйләшеп, кичен өстәмә укуга йөрде. Бер ел эчендә ике классның программасын үзләштерергә туры килде. Ярый әле янда гына Ләйсән яши. Аңардан ярдәм сорап, көн дә өйләрендә булды.

Әле менә һөнәрчелек училищесында ташчыга укып йөри. Тугызынчы классны бетергәч, кая барырга дип озак уйланмады. Әтисе аның төзүче булуын теләгән иде бит! Үткәннәрен исенә төшерәсе килми Данилның. Куркыныч төш сыман хәтер төбендә саклана ул көннәр.

Яшьләр парк ягына борылды. Анда фонтан да бар. Шуның янында утырып алырга иде ниятләре. Шул урынны алар үлеп ярата бу калада.

Парк капкасы төбендә Данил җирдә утырган бер хатынга игътибар итте. Чәчләре тузган, күз төпләре күм-күк, үзе ябык кына, өстендәге киеме сәләмә. Сукбай хатын, дип әрнеп куйды егет. Хатын кулын сузып, акча теләнә. Янында сыра шешәсе, ярты икмәк ята. Күрәсең, бу апа күптән шундый тормыш белән яши. Оялып та, тартынып та тормый.

Кинәт Данилның үзенең үткәне исенә төште. Ул да бит автовокзалда кулын сузып, теләнеп тора иде. Юк, үзе теләп бармады мондый адымга. Нужа чыгарды. Бу хатын да уен өчен чыгып утырмагандыр. Ничек кенә булмасын, сукбай хәлен Данил яхшы аңлый. Ул кесәсенә кулын тыкты да 100 сум акчасын чыгарды. Бер сүз эндәшми аны хатынның алдына салды.

Башын иеп утырган хатын алдында шундый акчаны күргәч, сискәнеп китте. Гадәттә, аңа тәңкәләр салып китәләр. Ә монысы... Мәрхәмәтле кешегә рәхмәт әйтим дип, ул башын күтәрде. Кинәт күзләр очрашты. Данил да, сукбай да катып калды. Берничә мизгел дәвам итте бу тынлык.

– Әйдә инде, Данил! Нәрсә аптырап торасың, – дип кабаландырды хатыны.

Теге хатын бар көчен җыеп, аягына басарга маташты. Ләкин ничек кенә тырышмасын, утырган җиреннән торырга көче җитмәде.

Яшьләр паркка кереп, күздән югалды.

Бу күрешүдән соң Данил тынычлыгын югалтты. Теге хатын аның әнисе түгелме? Күргәненә күңеле белән ышанасы килмәде. Үзгәрсә дә үзгәрер икән кеше. Бите туп кебек, шешенгән, өсте бигрәк пычрак. Сүз кушар иде – Ләйсәне ашыктырды. Хатыны алдында оят. Шушы сукбай – минем әнием дип, ничек әйтә алыр иде? Ә, бәлки, күзенә күренгәндер, аның әнисе түгелдер... Әле шул икеләнү күңелен айкый. Шулмы, түгелме?

Икенче көнне иртүк шул парк ягына юл алды Данил. Башында мең төрле уй кайный. Әгәр әнисе булып чыкса, аны мондый хәлдә ялгызын калдырмас улы. Берәр әмәлен табар. Юындырып, дәвалап алсалар, элекке тормышка кайтыр. Нинди генә булмасын – ул бит үз әнисе!

Парк капкасы алдында ир белән бүтәнчә киенгән хатын теләнеп тора иде. Тик кичә очраткан апа гына күренмәде.

– Ә кичә монда утырган хатын кайда булды? – дип сорады Данил.

– Кто? Ася что ли? – Русчалап җавап кайтарды сукбай.


– Аның исеме Асия булырга тиеш, – дигән булды егет.

– А-а-а. Шытты бит ул, – дип кырт кисте ир кеше.

– Ничек? Аңламадым сезне!

– Богу душу отдала, – диде кычкырып хатын. – Сегодня ночью!

Данилның башына таш белән суктылармыни?! Ни алга, ни артка адым ясый алмый бер урында басып тора бирде.



Хәнәфи
Бәдигый

# АВЫЛДАН КИЛГӘН ЧЫПЧЫК

АЛЛЕГОРИК ПОЭМА

I

Илче итеп җибәрелгәч,
Авылда туган чыпчык,
Шәһәр кибетенә керде
Ачык ишектән очып.
– Күреп-белеп кайт! – диделәр:
– Анда ничек яшиләр?
Нәрсә ашыйлар кешеләр,
Кошлар... безнең ишеләр?
Шул хакта сөйләрсең аннан
Бөртекләп, бәйнә-бәйнә.
Үзеңне дә күрсәтерсең,
Барып кайт әле, әйдә!

– Ил өстендә чыпчык үлми,
Ач булмассың! – диделәр.
– Бер кош чүпләп кенә бетми,
Ашлык күп! – дип көлделәр.
Әйе, чүпләнде кырларда,
Юлыкты амбарларга.
Хәтта тамак ялгап алды
Очып кереп барларга.
Туктап ял иткәләп алды,
Ун-унбиш минут саен.
Шуңа армады, талмады, –
Белә алҗымау җаен!

II

Казанга карап очарга
Маяк булды олы юл.
Машина агымын күреп,
Тәмам хәйран калды ул.
Монда тормыш кайный икән,
Карап торсаң – тамаша.
Утлы язуларны күреп,
Хәтта күзләр камаша.
Барча кибет исемнәре
Гел башка телдә микән?
Күрде: татарның бер сүзе –
«Бәхетле»се бар икән!
Бу – зур ашамлык кибете:
Өч катлы, затлы, иркен.
Җаны теләгәнен ала
Бирегә кергән һәркем.

Була монда ашап-эчеп,
Сыйланып утырырга.
Мөмкин икән кәрҗинеңне
Байларча тутырырга.

Өскә менәләр, төшәләр
Үзйөрешле баскычта.
Җәяүләп атлыйсы да юк,
Алып китә баскач та.
Чыпчык әрле-бирле очып,
Шаккатып карап йөрде.
Ашамлыкларның, җиһазның
Йөзләгән төрен күрде.
Ул авыл кибетенә дә
Кергәләп йөргәләде.
Андагы тәм-томнарның да
Төрлесен күргәләде:

Хәнәфи БӘДИГЫЙ (1941) – *шагыйрь, галим; «Күңел ялкыны», «Яшел чирәм», «Тормыш фасыллары» һ.б. китаплар авторы. ТРның Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Бөртеклеләр, кузаклылар,
Җиләк-җимеш, яшелчә,
Чикләвек, конфет, печенье,
Хәтта чиста яшел чәй!

Шәһәр гипермаркетында
Ниләр генә юк икән.
Күз күрмәгән берәр әйбер
Калды микән, юк микән?

Ит-май, сөт, сыр, тәмләткечнең
Бардыр йөзләгән төре!
Ашап карарга һәрберсен
Җитмәс чыпчык гомере.
Алты кыйтгадан килгәндер
Мондагы азык-төлек.
Андый гаҗәеп җимешләр
Күренми иде элек.
Ахры, без җирнең үзәге –
Ниләр килмәгән кайдан!
Кайберләрен санап-санап
Күрсәтте шул уңайдан.
Күп ризыклар әзерләргә –
Бәрәңге, кабак, помидор,
Кукуруз, арыш, бодайлар
Килгән Америкадан.
Кәбестә, чөгендер, шалкан
Тары, арпа, кишер, суган,
Дөге, чия, карабодай
Таралган Азиядән.
Кыяр, сарымсак ишеләр –
Ерактан – Һиндстаннан.
Алмалар, солы, баланнар
Редискалар – Кытайдан.
Дөрес, ул илләр дә бездән
Бик күп нәрсә алалар.
Аларны да бездәгедәй
Яратадыр балалар.
Менә кайлардан башлана
Чын дуслык бу дөньяда!
Дуслык булган җирдә генә
Яшәү рәхәт кайда да!

## I I I

Ашарга килмәде чыпчык,
Күреп кайтырга гына!
Гел рәхмәт әйтеп яшәде
Туып-үскән ягына!

Кыр чыпчыгы, диләр аны,
Нәселе – Африкадан.
Ул яшәмәгән җирләрне
Табып булмый картадан.
Иярми ул җылы якка
Китә торган кошларга.
Ияләнгән кеше белән
Туган җирдә кышларга.
Кечкенә генә булса да,
Акыллы, күзәтүчән.
Бик яхшы хәтерле, эшчән,
Тырыш һәм хәрәкәтчән.
Атлар, куяннар, тавыклар,
Этләр белән дус яши.
Кеше янәшәсендә дә
Кешегә иялэшми.
Өйрәнгән ул күзәтергә,
Яхшылап, төрле яклап.
Шуңа күрә яши белә,
Үз иминлеген саклап.
Чыркылдыйлар үз ишләре:
«Чик-чирик, зиф-тиф-тен-тен».
Күмәк яшәүне ярата,
Дус-иш итеп бер-берсен.

## IV

Чыпчыкларның да бар икән
Үзләренчә исеме.
Һәркайсының туры килә
Исеменә җисеме.
Хәер, чыпчык малайлары
Исем табарга оста.
Гәрчә эти-әниләре
Кушканы да бар, юкса.
Иптәшләре «Качкын» дигән
Исем таптылар аңа.
Чыпчыкларча: кыска, матур,
Мәгънәле һәм өр-яңа!
Качкын чыннан да бик оста
Кинәт качып очарга.
Мондый сыйфат сакланырга
Бик кирәкле кошларга!
Чая шәһәр чыпчыклары
Урап алмакчы иде.
– Авыл гыйбады! – дип көлеп,
Егып салмакчы иде.
Качкын кинәт читкә очты,
Берсе куркып егылды.

Алар аңына килгәнче,
Күзләреннән юк булды.
Шунысына гаҗәпләнде
«Бәхетле»дә йөргәндә,
Ничек шәһәр чыпчыклары
Таныды дип, күргәндә.
Шәһәрнекеләр таныды
Аксыл коңгырт төсеннән.
Сузылган ак сызыклардан
Канатлары өстеннән.
Бераз кечерәк күренә
Шәһәр-өй чыпчыгыннан.

Танып була ак яңагы,
Карасу томшыгыннан.
Алар эшчән, тырышалар
Җәйләрен һәм кышларын.
Кыр-басуда җимнәр чүпләп,
Эшләп таба ашарын.
Шәһәр чыпчыгы кайнаша
Зур базар тирәсендә.
Анда әзер азык бик күп
Кичен дә, иртәсен дә.
Авыл чыпчыгына эш күп
Басуларда, кырларда.
Тик бу хакта аз сөйлиләр,
Язылмаган җырлар да.
Башкала чыпчыкларыннан
Ишетеп алды Качкын:
Тел кыскартырга боерган
Карга короле Каркин.
Ярты телле калачак, ди
Кардәшләре Каркинның.
Шул исәпкә күбәйтә, ди
Туганнарын Каркинның.
Кимнәр чыркылдасын дигән
Фәкать ояларында.
Аларча «сайрамас», дигән
Хәтта балаларым да.
Кавемем балаларының
Үзләрен үстерергә,
Кирәк дигән башкаларның
Телләрен кистерергә.

Тел бирелгән, – дигән Качкын –
Туйганчы чыркылдарга,
Табигать үзе юл куймас
Тел кыскартып уйнарга.

## V

Кибетләрдән кибетләргә
Ул озак очып йөрде.
Кирәк-ярак, ашамлыкның
Бик күп төрләрен күрде.
Алар бар да төрелгәннәр
Кәгазьләргә, капларга.
Ярый үткен томшыгы бар
Чукырга, тарткаларга.
Язуын да укып булмый:
Урысча, инглизчә.
– Начар! – дип, татар чыпчыгы
Бәяләде үзенчә.

Шәһәр чыпчыклары, ахры
Бу тормышка күнеккән.
Качкынга авылда яшәү
Бәхет, чын оҗмах икән.
Кибетләрдәге әйберләр
Шулкадәр кыйммәт икән.
Дәүләт авылдан алганнан
Биш тапкыр артып киткән.
Киштәдәге гап-гади су
Сөт бәясеннән кыйммәт.
Авыл хисабына шәһәр
Байый икән, әкәмәт.

## VI

Качкын байтак очып йөрде
Шәһәр урамы буйлап.
Кайткач күргәнне сөйләргә
Туры килер, дип уйлап.

Китап кибетләре бик күп
Якты, иркен залларда.
Татар китаплары гына
Берән-сәрән аларда.
Асфальт җәелгән урамнар
Тип-тигез таба кебек.
Машиналар, автобуслар
Чабалар выж-выж килеп.
Әйтерсең тыгыз рәтләре
Киң урамны тарсына.
Әле ярый светофорлар
Юл күрсәтә барсына.
Кызыл, сары, яшел төсне
Бик төгәл күрсәтәләр.
– Кагыйдәне саклагыз! – дип
Алдан ук кисәтәләр.
Ишегалларында юллар


Ишелгән, беткән, тузган.
Төзәтмәгәнгә, ахрысы
Бишбылтыр вакыт узган.
Бәлки, җаваплы кешеләр
Монда бер дә кермидер.
Керсә дә, йөрсә дә, бәлки,
Күңел күзе күрмидер.
Чокыр-чакырлы урамнан
Узып китсә машина,
Пычрак суны җәяүленең
Чәчрәтә өс-башына.
Авыл халкы ишегалдын
Беркайчан онытмады.
Тузган җирен вакытында
Төзәтмичә тотмады.
Ә шәһәрдә стадионнар,
Зур сарайлар төзелә.
Ишегалды урамына
Игътибар юк, сизелә.

**VII**

Чыпчык очып, башкалада
Мәктәпләргә дә керде.
Андагы сәер хәлләрне
Үз күзе белән күрде.
Татар мәктәпләре беткән,
Татар теле киселгән.
Татар баласы илендә
Димәк ки – кимсетелгән!
Туган ил дип утка кергән,
Илгә бар көчен биргән,
Шул туган тел шушы илдә
Күпме җәберләү күргән!
Кибет-урамнарда очып,
Шәһәр тормышын белде.
– Тамак ялгарга кирәк! – дип,
Базарга барып килде.
Монда орлык, җиләк-җимеш
Куелмаган төрелеп.
Шәһәр чыпчыклары йөри
Очынып-бөтерелеп.
Алар шундый җитез җимне
Эләктереп алырга:
Очып төшкәнен сатучы
Мөмкин күрми калырга.
Качкын да кимен куймады,
Бик тиз тамагы туйды.
Болай шәһәрдә яшәргә
Рәхәт, дип уйлап куйды.
Билгеле, ул бу турыда
Уйлады хәзер генә.
Тик күнекмәгән яшәргә
Әзергә бәзер генә.
Очып килмәде бит монда
Шәһәрдә калыр өчен.
Туган ягыннан ала ул
Яшәүнең ямен, көчен.

Качкын әйтә:
– Үзебезчә
Ашыбыз һәм эшебез.
Шөкер, авыл җирлегендә
Иркенәеп яшибез.
– Кем рәхәт, бәхетле яши,
Авылда, шәһәрдәме?
– Шунда! – диде Качкын, – кайда
Ходай, дәүләт ярдәме!

Качкын тәмам карар кылды
Кайткач барын сөйләргә!
Чутламасыннар авылны
Берни белмәс җүләргә!



Әмирҗан
Моталлапов

# ГАИЛӘ*

БӘЯН

...Иртәрәк кузгалдым бугай, дип уйлады Факил капка биген ачып урамга аяк басуга. Болытлы булгангамы, күзгә җиңелчә томан җир өстен каплагангамы, аяк асты рәтләп күренерлек түгел иде. Шулай да багана башындагы лампочкалардан төшкән сүрән яктылык урамдагы хәрәкәтне күпмедер шәйләргә мөмкинлек бирә.

Кем булыр? Авыл аякланырга өлгергәнче бирегә килеп чыгарга бу бәндәне ни йомышы мәҗбүр иткән? Үтеп кенә барышымы, әллә адашуымы?.. Угры түгелдер, билгеле, адымы шикле кыяфәткә тартмаган.

Дымык һавада селкенмичә кагаеп торган карачкыга тартым гәүдә, каккан казык кебек тын торуына карамастан, Факил ягына борылып, сәлам бирде:

– Исәнмесез!

– Бик исән әле, ханым... Кем буласыз, дим? Танымыйм, әллә күргән-белгәнем түгелме? – дип тезеп китте Факил, кызыксынуын яшерә алмыйча.

– Танымассыз. Мин бу тирәнеке түгел. Шушы авылда таныш ханым яшәргә тиеш иде, юл уңаеннан аның хәлен белеп чыкмакчы булдым.

– Кемгә атап килүегез иде?

– Халисә апага.

– Кайсы Халисә?

– Хәсән Халисәсе, диләр иде бугай...

– Ул Халисә күптән юк инде.

– Ничек?

– Вафатына ун ел булмады микән инде.

– Ә кызы?

– Зәлифәме?

– Шулай иде бугай...

---

* Журнал варианты

---

Әмирҗан МОТАЛЛАПОВ (1934) *— прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Яшьлегем кайтавазы», «Бал сатучы Төлке», «Абыну» һ.б. китаплар авторы. Актанышта яши.*

– Үз кызы түгел икән, дигән сүзләр йөрештерә иде, гайбәт кенә булгандыр, менә дигән итеп карап үстерде, укытты, кеше итте...

– Кыз хәзер кайда яши, дисез?

– Төгәлен белмим.

– Ире бу якныкы түгел идеме?

– Әйе. Укыганда ук өйләнешкәннәр, институттан соң шәһәрдә калганнар. Балалары тугач, Халисә апаны үз яннарына алганнар иде, авыл кешесе шәһәргә чыдыймыни? Бер елдан әйләнеп кайтты. Бераздан чиргә сабышты. Зәлифә кайта-китә йөреп, аңа тәрбия күрсәтте. Халисә түти озак ятмады. Аны җирләгәннән соң, Зәлифә авылга аяк басмады, – дип тәфсилләп аңлатты Факил, хатын сорауларына белгән чаклысын сөйләп.

Факил колхоз амбарлары ягына кузгалды. Хатын аңа иярде.

Күпмедер таушала төшкәндәй тоелса да, хатынның кайчандыр нәфис гәүдәле, шактый сөйкемле икәнлеген төсмерләргә була иде.

– Халисә апаның өе дә калмадымы?

– Череп беткән иде, ишелеп төште. Ул ихатага агроном өчен йорт салдылар, – дип җавап кайтарды Факил.

– Алай икән... – диде дә хатын тынып калды.

– Хәзер кая юл тотмакчы буласыз? – дип кызыксынды Факил, хатынның бүтән йомышы юклыгын чамалап.

– Районга китәм инде. Аннан Казанга, – диде хатын, уңышсыз чыккан сәфәре өчен борчылуын сиздереп.

Халисәдән бигрәк, Зәлифәне күрәсе, гафу үтенәсе килгән иде бит аның.

***

Һөнәр мәктәбе курсларын тәмамлагач, Гөлнур тегү фабрикасында эшли башлады. Урта мәктәптән соң, педагогия институтына кермәкче иде – конкурстан узмады. Авылга кире кайтасы килмәде кызның. Үзе кебек үк институтка керү өмете киселгән Фаягөл исемле бер кыз белән бу кышны һөнәр мәктәбендә укып үткәрергә булдылар. Һөнәр мәктәбенең яшәү урыны бар. Фабрикада эшләгәндә дә, шушында торып калырга мөмкин икән.

Тегүче һөнәрен тиз үзләштерделәр. Авыл кызларына хас булганча, алар икесе дә тегү машиналарында бәләкәйдән үк күпмедер күнегү алганнар иде. Шуңа күрә тегү-кисү серләренә төшенү кызлар өчен артык катлаулы булмады.

***

Тулай торакта байтак еллардан бирле Халисә исемле хатын яши иде. Гөлнурдан яшькә шактый олы, тик шулай да кызга түбәнсетеп карамый. Гөлнур белән серләрен дә уртаклаша хәтта. Киңәшләрен дә бирә.

– Үскәнем, институтка кермәвеңә артык борчылма. Сиңа, бәлки, баш ватып укуның кирәге дә юктыр. Диплом алып, рәхәт күрмәгәннәр дә бик күп. Кыз баланың бәхете – ирдән. Ходай Тәгалә сине кимсетмәгән: чибәрлегең хәттин ашкан, кулыңнан эш килә, егетнең менә дигәненә тап булырсың да бәхеткә кинәнеп яшәрсең әле, – дип хатын Гөлнурны юатып, аның хәленә керде.

Халисә апасының сүзләрендә хаклык бар: Гөлнур төшеп калганнардан түгел – табигый матурлыгы, килеш-килбәте, буй-сыны күргәзмәгә куярлык! Үз дәрәҗәсен чамалый кыз. Халисә апасының әйткәннәре белән күңеленнән

ризалаша да... Тик белем ягыннан үз ишләреннән түбән баскычта калуы борчый. Тормыш көтәрдәй, хатын ихтирам итәрдәй егет туры килсә, кавышырга каршы килмәс иде әллә. Шәһәр егете табылса, тагын да кулай. Авылда яшәп, дөнья куам дип, мал лапасы баткагында бата-чума мәш килү – хыял түгел шул...

Имтиханнардан соң, озак та үтми кинәт бәхет елмайгандай тоелды Гөлнурга. Уйламаганда, бер егет белән танышты. Дөньясын онытып мавыгып китте егет белән. Бәхетенә язганы шулдыр сыман тоелды.

Егет шәһәрдә туып үскән бердәнбер малай, фатирлары бар, ата-анасы белән яши. Әгәр өйләнешергә тәкъдим ясаса, берсүзсез ризалашачак Гөлнур.

Күрешүләр көннән-көн кабатланып кына торды: кино, концерт, спектакльләр карадылар, танцыларга йөрделәр. Егет Айдар исемле. Армия хезмәтен үтәп кайткан гына, эшкә урнашу артыннан йөргән чагы. Техникум тәмамлаган, укуын алга таба дәвам итәргә исәбе юк. Бу хакта Гөлнур кызыксынгач, ул:

– Укыган чаклысы җиткән, заводка урнашып, кулга акча кертү хәстәрен күрергә кирәк, – дип кенә җавап бирде. – Ата-ана җилкәсендә яшәргә теләмим, өйләнер чагым да җитеп килә, туй чыгымнарын каплау өчен күпмедер мая тупларга кирәк бит, – дип ачыклык кертте Айдар үз ниятенә.

– Тиз генә өйләнмәссең әле. Шәһәр егетләре гаилә корырга ашыкмый бит.

– Минем озак сайланырга исәбем юк. Күңел тарткан кызга тотам да өйләнәм, – диде егет, кызга елмаюлы караш ташлап.

– Андый кыз тиз генә табылыр микән соң?

– Таптым бугай инде...

– Сер түгелдер бит?

– Нишләп сер булсын!.. Син ул!

Гөлнурга шушы сүзләрне ишетү кирәк иде. Ишетте һәм ихлас ышанды. Бу ышаныч көннән-көн ныгый барды. Кыз үзен Айдарның аерылмас дусты итеп тоя башлады. Егет тә икеләнерлек сәбәп тудырмады – назлы сүзләр белән кызны коендырып кына торды. Гөлнурның мәхәббәт хисләре белән тулы йөрәгенә артык назның кирәге дә юк иде инде. Ул Айдарны сүзсез дә аңлый, аны яратуы да ихлас...

***

...Гөлнур Халисә белән бер бүлмәдә яши. Хатын төскә-биткә чибәр булмаса да, ягымлылыгы, мөлаемлеге, ярдәмчеллеге белән үзенә тартып тора. Юккабарга кызып китеп, каты орыну гадәте юк.

Халисә авылда яшәгәндә үк, яшь килеш кияүгә чыккан. Тату, яратышып торганда, фаҗигагә тарып, иренең гомере өзелә. Ятим үскән Халисә ике ел тормас борын ирсез дә кала. Каенана йортыннан китәргә мәҗбүр була ул. Шәһәргә килеп, тегү фабрикасына урнаша. Биредә яшәвенә дә ун ел вакыт узып бара.

Хәтсездән китүенә карамастан, туган җирен сагынып яши хатын. Җәй айларында авылыннан урап килә, аның саен җирсүе көчәя генә төшә. Авылда бертуган энесе яши иде. Күптән түгел аны да җир куенына салдылар. Ата-анадан калган иске өй хәзер буш килеш моңаеп утыра. Авылга кайтып, калган гомерен шул өйдә үткәрәсе килә Халисәнең. Берьялгызы хикмәт майтара алырына икеләнү генә кузгалуны тоткарлап тора...

Халисәнең авылга чираттагы сәфәре көннәрендә Айдар Гөлнур янына килеп, куна кала башлады. Бу хикмәт тора-бара алар өчен гадәти хәлгә әйләнде.

***

– Байтактан бирле аралашасыз, алышу-барышу турында сүз кузгатышканыгыз бармы? – дип кызыксынды Халисә, Гөлнурның элеккечә кичләрен чыгып китәргә атлыгып тормавын күреп. – Арагыздан кара мәче үтмәде микән?!

– Баштагы мәлне «өйләнәм» сүзен еш кабатлый иде, соңгы вакытта никтер сүрәнләнде, – дип җавап бирде кыз, башын күтәрмичә, иңсәләрен сикертеп.

– Башкага күзе төшмәгәндер бит?

– Ул ягы сизелми... Хәер, егетләрне аңламассың – шәһәрнекеләрне бигрәк тә.

– Бүген очрашырга сүз куешмадыгызмыни?

– Өч көнлек командировкага киттем, диде.

Гөлнурның кичләрен сирәк чыгуы, көннән-көн үз эченә йомыла баруы ике арада барлыкка килгән каршылык нәтиҗәсе икәнлекне Халисә чамалый иде, үзе ачылып китәргә теләми, әллә кыенсына – димәк, тормыш манзараларын күп күргән кеше буларак, төпченеп, хәлнең асылын ачыклау Халисә өстенә төшә.

– Гөлнур үскәнем, яшермичә әйт әле: арагызда берәр хәл бармы? – диде хатын, кызның яшьле күзләрен күреп.

– Бар шул, Халисә апа... Төп башына утыртты, ахрысы, мине Айдар...

– Аңламадым?

– Кавышырга һич теләге юк. Бай кызга күзе төшкән бугай...

– Дөньяда бердәнбер егет Айдар гына түгел ләбаса! Баш ярылып, күз чыкмаган. Бу чибәрлегең белән менә дигән егетләргә тап булырсың әле.

– Халисә апа, авырга уздым мин...

– Айдарга әйттеңме?

– Әйе.

– Нәрсә ди?

– Төшерергә куша. Мин сиңа өйләнмим. Бала белән генә мине үзеңә бәйли алмассың, ялгызың үстерергә калачак, ди.

– Инде нишләргә уйлыйсың?

– Югалтырга исәбем юк.

– Бик дөрес!

– Дөресен дөрес тә, ирсез бала табуымны әти-әни ничек кабул итәр? Алар каршында гына түгел, туган-тумача алдында ояты ни тора! – дип, Гөлнур үксеп еларга кереште.

– Тап! Үзем карап үстерермен. Бала минеке булыр. Ә синең ныклы тормыш корып, яңадан яшәр чагың алда әле... Сугыш елларында да тол аналар әллә ничәшәр бала карап, аякка бастырганнар. Шөкер, хәзер тормыш утырып килә, бала ашату, киендерү – кулдан килми торган нужа түгел, – диде Халисә, әйткән сүзендә тайпылышсыз калуын раслап.

***

Егерме яше дә тулмаган бит әле! Яшьлегенең иң үзәк чагы. Шушы көннән бала анасы булып, тол хатыннар сафына басасы килмәде кызның. Алдагы көннәрендә бәхетле тормыш корып җибәрә алыр, бәлки? Яшәеше тәртипкә кереп, гаиләсе иркенлектә яшәсә, баланы кире кайтару мөмкинлеге дә килеп чыгар?!. Баланы гына түгел, Халисә апасын да үз тәрбиясенә алыр. Аның да башка таянычы юк. Кылган игелеген дә онытырга ярамый...

Сөясе-сөеләсе килә Гөлнурның. Бүтән хилаф сукмакка тайпылмас иде

инде. Бәлки, уку хәстәренә дә ныклап торып керергәдер? Абруйлы белгечкә әйләнә икән, аның белән санлашырлар, парын да, бәхетен дә берьюлы табар...

Алай да соңгы, төпле карарга килгәнче, Гөлнур Айдар белән ныклап сөйләшү ниятенә керде. Фатирларына туры барырга кыенсынды, эшләгән урынында очрата алмады. Кагылган саен: «Айдар бүген килмәде», «Айдар командировкада», – дигән җавапларны ишетте. Очрашудан качып йөрүе җитмәгән, иптәшләрен дә алдашырга өйрәткән бугай...

Эштән кайтышлый гына эзенә төшү мөмкинлеген чамалап, кыз алар яшәгән йорт янына килеп көтәргә булды. Озак торырга туры килмәде.

– Монда сиңа ни калган? – Айдарның беренче соравы шул иде.

– Синең соңгы сүзеңне ишетергә телим.

– Син аны күптән беләсең.

– Мин баланы төшермәячәкмен...

– Вәт, дура!.. Аны ничек карап үстермәкче буласың?

– Үзеңнең кулдан килмәсә, ата-анаң ярдәм итәр. Аларга китереп бирермен, – диде Гөлнур, елый язып. Тыныч кына сөйләшмәкче иде, үзе дә сизмәстән кычкырыбрак әйтте.

Бу мәлдә Айдар да каушады. Тыныч холыклы, иплегә санап йөргән кызның күз алдында кинәт үзгәрүе аны аптыраашта калдырды.

– Мин ярдәмнән баш тартмыйм. Авырыңны төшерергә акча бирәм. Башка чыгымнарыңны да түләрмен, – дип тезеп китте Айдар, хәтәр ярдәмчел бәндә сыман.

– Мондый оятсыз кешедән, ялганчыдан акча алырга хурланам мин. Бала тугач, ярдәм ягын үзең карарсың... Кемлегеңне күрербез, – дип, күз яшьләрен сөртә-сөртә, Гөлнур китеп барды...

***

Илфас гадәттәгедән иртә уянды. Урман кисәргә килүчеләр белән очрашырга тиеш ул бүген.

Барасы юл озын түгел, атын кауламады егет. Килеп җиткәч, малкаен тугарып, арбадагы печәнгә кушты. Иртә иде әле. Көзге куе томан җир өстенә канатын җәеп килә. Вакыты белән күз күреме хәтсез кысыла. Томан тагын да куера калса, юлаучыларның делянканы чамаламыйча узып китүләре дә ихтимал, каршыларына чыгып торуың яхшы.

Аланлык очында егет колагына сәер шытырдау ишетелде. Кыргый җанвар йөрүе түгел бу. Учак тергезергә җыенучы бәндәнең коры ботаклар сындыруына охшаган. Урманчының үткен күзе бер шәүләнең кабалануын шәйләде – ул, чынлап та, коры ботакларны ашык-пошык сындырып, чокырга тыгызлап сала иде. Ул арада, калай савытының бөкесен ача башлагач кына, бензин сибеп ут төртергә чамалавын төшенде Илфас. Учак тергезергә түгел, урманны утка өерергә чамалый бит бу мәхлук!..

– Ни кыланасың син, явыз? Урманны көлгә очырасың бит! – дип җан көченә оран салуын үзе дә сизми калды Илфас.

Якын-тирәдә җан иясе булырын уена да кертмәгән бәндә, кайтаваз таратып яңгыраган көчле тавышны ишетүгә, каушап калды. Тәне калтыраудан кулындагы савыты җиргә тәгәрәде һәм, аваз салучының үзенә таба килүен күреп, олы юлга томырылды, качкынның үзе түгел, эзе дә югалды. Ул утырып киткән машинаның әче төтене генә томанга уралып калды...

...Явызлыктадыр нияте, берәү дә таң тишегеннән урман эченә кереп, учак якмас, дигән шик туды егеттә.

Томан, сыекланып, җиргә утырып килә. Кояш нурлары сөзелеп төшә башлагач, алан өсте шактый яктырды. Агач ботаклары яшь агачлар утырту өчен тирән итеп ярылган буразнага тутырылган иде. Нәрсә яндырырга теләде микән соң ул монда, дигән шик белән урманчы егет ботак-сатакны кузгата башлады. Берничә агачны алып куюга, өем селкенгәндәй булды. Өнме, әллә төшме бу?.. Буразнада хатын-кыз гәүдәсе иде... Күкрәген сытып торган ботаклардан арынгач, тирән сулыш алып, ыңгырашып куйды. Яшь кенә чибәр кыз. Баш чүмеченнән кан саркый. Һәрвакыт үзе белән йөртә торган сумкасыннан бинт алып, кызның башын бәйләде Илфас һәм ашыгыч ярдәм машинасын чакыртты, яралыны хастаханәгә озатты. Кыз һушына килмәгән иде әле...

***

Үзе коткарган кызның хәле һәм язмышы белән кызыксынасы килү теләге көннән-көн көчәя төште Илфаста. «Кем ул? Бу якларга каян килеп чыккан?» кебек сораулар тынгы бирмәде аңа. Хастаханәгә барып, коткаручы буларак, кызның хәлен белешү гөнаһ түгел ләбаса! Бәлкем, әле бу якларда аның танышбелеше дә юктыр, янына да килмиләрдер?..

Кызның йөзендә гаҗәпләнү, каушау билгеләре ярылып ята иде. Аларның аптырауданмы, әллә куркуданмы барлыкка килүен аерырлык түгел. Табиб: «Әйдә, мин сине үзе чибәр, үзе миһербанлы егет белән таныштырам», – дип бүлмәдән алып чыкканда, килүченең кемлеген тәгаен белмәгәч, юлда очраган һәм гомерен чак-чак өзми калган теге шофёр булмагае, дигән икеләнү күңелен биләгән иде.

– Менә бу егет синең коткаручың, – дип, табиб ике арага күпер салгач, шик-шөбһә кинәт юкка чыкты.

– Рәхмәт! – диюдән башка сүз тапмый, тотлыгып торды кыз. Беравык тын торганнан соң, телгә килеп: – Мин бит бернәрсә дә хәтерләмим, – дип, яшь сыгып алды.

– Иң мөһиме: исән калдың.

– Сезнең аркада гына. Югыйсә, фани дөньяда ук тәмуг утында янасы булганмын икән. Сезне бәхилләтергә көчемнән дә килмәс инде...

– Танышмадык та бит әле...

– Гөлнур...

– Матур исем. Ә мин Илфас... Бу якларга каян килеп чыктыгыз соң? – дип кызыксынды Илфас.

– Башта Мәскәүгә, мин уйлаганча килеп чыкса,ераграк та китәргә иде исәп, – дип акланды кыз, сәфәргә чыгуының сәбәбен аңлатып торасы килмичә.

***

Сихәтләнә төшкән авыруларның күпчелеге кичне телевизор каршында үткәрә. Гөлнурның иркенләп карау түгел, телевизор экранына күз салганы да юк иде. Башкаларның мөкиббән китеп утырулары аңа гаҗәбрәк тоелды хәтта. Бүген Илфас белән очрашып танышудан күңеле күтәрелдеме, әллә телевизордан ишетелгән сүзләр аның дикъкатен җәлеп иттеме – тамашачылар янында тукталып калды.

Экранны тутырып утырган бер ир бәхет эзләп, чит илләргә китүче кызларның тоткынлыкка эләгеп, кире кайта алмыйча газап чигүләре, эт типкесенә калып, каңгырап йөрүләре турында сөйли иде. Коллыкка төшкән кызларның фәхишәлектә йөрүләре турында күпмедер тыңлагач, Гөлнур ишеткәннәре белән ризалашасы килмичә, кузгалу ягын карады. Бүлмәгә кереп, ялгыз уйланып яту күпкә хәерлерәк тоелды аңа.

Чит илгә эләгеп, «бәхеткә кинәнгән» кызлар язмышы турында ишетеп кенә түгел, андыйларның үзләрен күреп тә белә Гөлнур...

Чит илгә бардым да кайттым гына түгел, Гөлнурның планнары катлаулырак иде шул. Аның теләге – барган җирендә төпләнеп калу, бай егет белән никахлашып, миллионер хатыны булып яшәү иде.

Үз илендәге язмышыннан канәгать түгел иде ул, тышауланган ат хәлендә яши кебек. Кызы Зәлифәне Халисә апасына калдырганнан соң, сукбайлыкта үткән вакыты да дүрт елдан артып китте. Шушы арада байтак шәһәрләргә барып җитте, төрле һөнәргә кул тыгып карады, әмма үзен таба алмады. Кая килеп чыкса да, күңеле утырмады: акчаны көрәп алырлык хезмәткә дә тарымады, бай егеткә дә юлыкмады...

Илфастан иң кирәклесен сорамый калган бит: буйдакмы ул, әллә өйләнгәнме? Авылда гына төпләнеп яшәмәкчеме, шәһәргә китү нияте юкмы?

Шушы сорауларга җавап эзләп ятканда, бүлмәгә кизү торучы шәфкать туташы керде: «Синең янга килгәннәр», – дип, аны уйларыннан бүлдерде. Килүченең Илфас икәнлегенә шикләнмәде кыз.

Илфас ак күлмәккә кара галстук таккан, өстендә энә-җептән генә төшкән кара костюм... Кыскасы, кыз сорарга килгәндәй ыспай киенгән егет. Гөлнур шундук игътибар итте: бик килешле гәүдәле, мөлаем йөзле егет икән ләбаса аның яңа танышы. «Берәү булса бу чибәрлеге, буй-сыны белән, урман каравылчысы булып ятмас иде, әллә кайчан шәһәргә качар иде», дигән уй йөгереп үтте. Әйтерсең, андыйлар шәһәрдә генә яшәргә тиеш...

– Терелгәч, кая юл тотмакчы инде? – дип кызыксынды Илфас.

– Казанга китәрмен, мөгаен.

– Анда көтеп торучың бармы?

– Кем булсын!.. Җае чыгар. Элек яшәгән, эшләгән урын бит.

Ятимлек йөген ялгыз күтәрүнең яманлыгын аңлый Илфас. Мондый язмыш ачысын үзе татыган кеше ул. Шуңа күрә Гөлнурны ихластан кызганды, ярдәм кулын сузасы килде.

– Ник Казанга китәргә соң? Дөнья кендеге анда гына түгел бит, – диде Илфас, сорау биргәндәй ишарәләп түгел, үзалдына сөйләнгәндәй генә.

– Борын төртердәй башка урыным юк шул!

– Монда кал!..

– Ничек инде?! Күргән-белгән җирем түгел, бер танышым юк...

– Мине беләсеңме?

– Сине беләм дә...

– Шул җиткән. Әүвәл үзебезгә алып кайтам. Бергә яши башларбыз...

– Ничек алай?.. Өйдәгеләрең ни әйтер?

– Мин ялгызым яшим. Үземә үзем хуҗа. Иртәгә үк никахлашабыз. Хатыным булырсың... Менә дигән итеп яшәрбез, – диде Илфас, һәр сүзенә басым ясап....

***

Күп бала анасы булу Гөлнурның яшәү планына кермәгән иде. Яшьлек хыяллары җимерелүдән туган үкенеч, кимсенү тойгыларын күпмедер юу, тәүге мәхәббәттәге хатасы аркасында туган Зәлифәсе өчен тәүбә итү омтылышы да хатынны тормышның чынбарлык кануннарына буйсынырга мәҗбүр итте. Халисә апасының синең менә дигән егет очратып, ныклы тормыш корып, ишле балалар үстерер чагың алда әле, дигән сүзләре юк-юкта аның хәтерен искәртеп тора үзе. Илфасны Халисә апасы юраган егет дип атарга тулы нигез бар. Аның белән тату, ныклы тормыш кордылар, бернинди мохтаҗлык күрсәтмичә... Ләкин чит ана тәрбиясендә үскән Зәлифәсе дә бар бит әле!.. Ничек кенә онытырга теләсә дә, хәтереннән җуеп ташлый алмый ул әниле килеш ятим калган гөнаһсыз кызын... Бәлки, оныта да алмас!.. Хәзерге мәлдә гаилә тормышының бер уңайга агуы гына ерактагы баланы эзләүдән тыеп тора. Бу хакта ир сизенә калса, бүгенге тормышының челпәрәмә килүе бик ихтимал бит...

***

Иренә карата дорфалык күрсәтә, аны санга сукмый, чалымга алмый, дигән сүзләр белән Гөлнурны гаепләргә урын юк, әлбәттә. Илфас кылган яхшылыкка җавап йөзеннән, ихласлык, мөлаемлек күрсәтергә тырыша ул, тик аның күңел төбе барыбер эреп бетми. «Илфас урынында, их, Айдар булса иде!» – дип уфтанган минутлары байтак хатынның. Беренче мәхәббәте белән кавышкан тәкъдирдә урман эчендәге бистәдә генә түгел, япа-ялан даладагы ялгыз шалаш эчендә дә рәхәт яшәрләр иде кебек тоела аңа... Бүген дә Гөлнур Айдарны исенә төшерде. «Кемгә өйләнде икән? Миннән өстен хатын таптымы? Тормышыннан канәгатьме? Үзен сагынамы?» кебек сораулар тезелеп үтте аның уеннан.

Нилектән кайнаша соң мондый фикерләр Гөлнур башында? Илфас белән кавышудан тоташ бәхетсезгә әйләндеме? Кагып-сугып яшәдеме, җәберләдеме аны ире? Кул күтәрдеме, авыр сүз әйтеп, чүбек чәйнәп теңкәсен корыттымы? Юк бит – Гөлнур мондый кимсетүләрнең әчмухасын да татымады. Бала урынына күреп яшәде аны Илфас.

Тик хатынның күңелендәге яшьтән каткан боз барыбер эреп бетмәде. Аның гәүдәсе генә урман эчендәге бистәдә булды, ә күңеле далага – дала уртасындагы калага омтылды. Нининдидер хыялый бәхет эзләп, күз күрмәгән төбәкләргә ашкынып яшәде ул...

***

...Зәлифәне күреп сөйләшергә, ялгыш адымы өчен гафу үтенергә дигән ният белән килгән иде Гөлнур Халисә апасының туган авылына. Кызганыч: ни кызын, ни апасын күрү бәхетенә ирешә алмады. Иң авыр минутларда ярдәмгә килгән Халисә алдында тау чаклы бурычы булуын аңлый хатын. Үз кочагына сыйдыра алмаган баласын карап үстереп, укытуы, кеше итүе өчен Халисә каршына тезләнеп, рәхмәт укырга әзер булып килгән иде югыйсә...

Сәфәре уңмады. Корган планнары гамәлгә ашмады. Игелек өчен түлисе бурычы үз иңендә өелеп калды.

...Гөлнурның шушы хакта уйлавы булды – тәне буйлап кайнар ток үтеп китте. Тик ул тәнне җылытмады, күшектерде, бозландырды гына. Күрәсең, аның җанын иман дигән изге байлык тузан бөртеге чаклы булса да кереп

калган әле. Яшьлегендә кылган ялгышның күпмедер өлешен төзәтү ниятенә керүенең башлангыч билгеседер, бәлки?..

Кызы гафу итәрме соң Гөлнурны? Бу дөньяда син дә бармыни? Моңа кадәр кайда йөрдең, нәрсә уйладың? Чит кеше тәрбиясендә үскән балаңның барлыгы әле генә исеңә төштеме, дип, кул селтәп, куып җибәрмәсме?..

***

Гөлнур кичке поездга утырды. Сәфәре – туры Казанга. Баруын бара, калага аяк баскач, кая борын төртер? Иске таныш-белешләрнең кайсы исән, кайсы – юктыр? Булганнарын да ничек табар? Күпләре аның барлыгын онытканнардыр инде. Онытмаганнары ничек кабул итәр? Бәндәләргә карата авылдагы шикелле ихласлык күрсәтү җитенкерәми шул калада.

Шушы урман арасыннан кайчан башымны алып олагырмын икән дип, гомер буе яшерен уфтанып яшәгән бистәсенә кире кайтып борын төртер чамасы да юк хәзер Гөлнурның. Шыгырдап торган юан нарат бүрәнәдән салынган иркен, якты йорт кына түгел, бербөтен милек – барлык каралты-курасы белән аларныкы түгел инде. Илфас үлеменнән соң сатып, ихатаны төбе-тамыры белән корытты хатын...

Зәлифәсенең эзенә төшенү теләге белән кылган сәфәре дә әлегә уңышсыз тәгәлләнде. Кызының бу мәлдә кайдалыгын белә алмаса да, Казандагы фатирларының адресын кулга төшерде.

Кичә утыртып алып килгән шофёр егет әйткән фатир хуҗалары чыннан да Халисәнең чыбык очлары икән. Адресны шулар бирде. «Үзләре хәзер анда тормасалар да, күршеләре аларның кайдалыгын белергә тиеш. Шулар аша Зәлифәнең эзенә төшә алырсыз», – дип, Гөлнурның ышанычын ныгыттылар.

Поезддан төшү белән шунда юнәлер Гөлнур. Кызын очратмаса да, кайдалыгын белә алыр, телефон номерын алыр, күрешеп сөйләшү хакында хыялланыр. Аннары...

***

Тыкы-тыкы... Тәгәрмәчләрнең бер көйгә туктаусыз тыкылдавына күнегеп бара Гөлнур. Ул икенче тәүлеген юлда. Тагын шул чама вакыт барасы. Самолётта очасы калган, дип үкенеп алган иде әүвәл. Аннары үз-үзен тынычландырды: калган гомер эчендә поездга утырып, ерак араларга сәфәр кылырга туры киләме-юкмы, дөнья күреп, йөреп калсын әле... Купедан урын булмавы гына кызганыч, билетлар сатылып беткән булып чыкты.

Гомуми вагондагы ыгы-зыгыдан башы томалана башлаган Гөлнур, проводник белән килешеп, купега урнашты. Янда тагын бер юлдаш булу да хатын күңеленә хуш килде. Сөйләшеп вакыт үткәрергә кеше бар.

Таныштылар. Икесе бер шәһәргә баралар икән. Ул да татар хатыны булып чыкты. Бу килештән Гөлнурда җәелеп сөйләшү кайгысы юк иде. Поездга утырганнан бирле рәтләп йоклаганы да булмады. Хатын күзләрен йомды.

Гөлнурның бу тиклем онытылып йоклаганы булмагандыр. Ул күзен ачканда, кышкы кояш байтак күтәрелгән иде. Юлдаш хатын иртәнге чәйне эчеп, каршы стенага арка терәп китап укып утыра. Шунысы гаҗәп: проводник хатынның кычкырып, чәй өләшеп йөрүен дә ишетмәгән хәтта Гөлнур.

Ул кичтән күршесенең исеме Әлфинә икәнен белеп, аның кая баруы белән

кызыксынырга өлгергән иде. Юынып, тамак ялгап алгач, ныклабрак танышу исәбенә керде. Соңгы елларда анда кешеләр язмышы белән кызыксыну ихтыяҗы көчәя төште. Бер хәсрәте дә булмаган бәндә юк дөньяда. Кем үзен бәхетле саный? Кайсысы үзен бәхетсезләр рәтенә кертә?.. Шундыйларның фикерләрен ишетәсе килә Гөлнурның. Кайгы-хәсрәт – бәхетсезлекме? Бәхетлеләр тормышына да кайгы-хәсрәт үтеп керәме? Бәхетсезләр арасында хәсрәтсезләр булырга мөмкинме?

– ...Нәкъ шулай.

– Ахыры ничек беткән инде?

– Синекеннән үзгәрәк... Сеңлем шофёр бәйләнә башлагач, җай туры китереп, кулына монтировка эләктергән дә теге мәлгуньнең түбәсенә орган. Качасы гына калган да, үтердем дип уйлап, милициягә хәбәр иткән...

– Шуннан?

– Шуннан... Шуннан ни буласы билгеле инде. Кулга алып, сеңелне ябып куялар. Гаепсезгә санап, бераздан чыгардылар. Теге мөртәт шофёр исән калган. Үзен тикшерә башлаганнар. Байтак хатын-кызны мәсхәрәләвен ачыклаганнар.

– Үзен утыртканнармы?

– Ничек әйтсәң дә ярыйдыр: акылын җуйган ул. Үзенең кемлеген белми башлаган. Диваналар йортына япканнар...

Гөлнур хатынга сорау бирә, ә күңеленнән үзе белән килеп туган вакыйганы күз алдына китерә. Хәйләкәррәк кыланганда, ул да афәттән котыла алыр иде, мөгаен... Ярый, бәхетенә, Илфаскае аның җан тәслим кылырга тиешле урынында пәйда булган.

– Ул хөрәсәннең исеме ничек иде микән? Алай истә-оста калмагандыр инде?

– Ничек калмасын! Хәтергә гомерлеккә сеңде бугай. Сеңелнең котылып калуын көтеп, суд мәрәкәсе артыннан йөргәндә, бәлагә тарытучының кем булуы белән кызыксынмыйча каласыңмыни? Белдек. Хәбиб атлы иде ул. Фамилиясе дә «Х» хәрефенә башлана – Хөрмәтов. Математик буларак, мин атамаларны һөнәрем буенчарак, тамга белән күңелгә сеңдерергә тырышам. Моныкы $X^2$, ягъни икс квадратта.

– Аның явызлыгы квадратта гына бетмәгәндер, – диде Гөлнур, үзалдына сөйләнгәндәй уйланып. Теге чакта кабинага кереп утыргач, шофёр аның кая юл тотуы белән кызыксынды, исемен сорады. Гөлнур үз исемен әйткәч, шофер: «Минеке Хәбиб», – дигән иде. Әллә инде әле искә алган Хәбиб? Әллә адашлар гынамы?

– Мине утырткан шофёр да Хәбиб исемле иде. Битендә элекке яра эзе дә бар иде, – диде Гөлнур, сагаеп.

– Нәкъ үзе бит, малайкаем. Теге Хәбибнең дә бите яралы иде, – дип мөһер сукты Әлфинә.

– Төрмәгә дыңкычлыйсы иде дә аны...

– Сары йорт гомерлек зиндан булыр аңа, мөгаен. Анысы төрмәдән дә яман.

***

Зәлифәләр яшәгән йорт тимер юл вокзалыннан ерак түгел иде, тиз тапты Гөлнур. Икенче катка күтәрелде һәм фатирның ишек кыңгыравына басты. Берничә тапкыр басса да, эчке яктан ишеккә таба килүче аяк тавышы ишетелмәде. Әллә звоноклары эшләмиме дип, Гөлнур ишекне йодрык белән төя башлады. Шундук каршыдагы фатирның ишеге ачылды.

– Кем кирәк?!

– Мин Зәлифәләргә килгән идем, – диде Гөлнур. Хатын төпченә башласа, кияүнең исемен дә, нинди фамилия йөртүләрен дә белми ләбаса! Хәер, күрше болары хакында төпченмәде. Яшькә үз тирәсендәге хатынның йөз-кыяфәте буенча кайсы милләттән икәнлеген чамалап, Гөлнурга якынайды да саф татар телендә:

– Сез Зәлифәнең кеме буласыз? – дип сорап куйды.

– Мин аның анасы белән бертуган апасы... Соңгы вакытта элемтәләр өзелгән иде, – дип үз ялганын тезеп китте Гөлнур.

– Килүегез юкка булган шул. Бер атна элек китеп барды алар.

– Кая?

– Болгариягә. Эшкә түгел, ялга киттеләр. Нәсимне бүләкләп, санаторийга путёвка бирделәр.

Бу җаваптан үзенә кирәкле бер яңалыкны отып калды Гөлнур: Зәлифәнең иренең исеме Нәсим икән.

– Кызганыч! – дип, Гөлнур юл төенчеген күтәрде.

– Алдан хәбәрләшмәгәнсез икән шул...

– Туры килмәде, элемтә өзелеп торды.

– Хәзер кая барасыз инде?

– Вокзалга төшәрмен. Билет алып, киту хәстәрен күрергә кирәк.

– Озын юлдан соң черем итмичә вокзалда төн үткәрү газап булыр, калыгыз бүгенгә. Иртән билетка заказ бирербез. Керегез миңа, – дип, чын күңелдән үгетләде күрше хатын.

– Таныш түгел кешегә мәшәкать тудырып, – дип кыенсынган иде Гөлнур.

– Ничек таныш булмасын? Сәкинә исемле мин, Зәлифәнең туганы – минем туган. Без туганлашып, ярдәмләшеп яшәдек. Мине үз анасы шәенә күрде Зәлифә. Әйдәгез, әйдә, – дип, хатын Гөлнурны җитәкләп үк алды.

Керделәр.

Чәй янындагы әңгәмә Зәлифәгә турыдан-туры бәйле барды.

– Үзенең үткәне турында Зәлифәнең ихластан ачылып сөйләгәне булдымы? – дип кызыксынды Гөлнур, сөйләшер өчен таяну ноктасын эзләп. Бу хатыннан берни яшереп тормаска иде аның исәбе. Дөресен бәян итәр. Кайчандыр бер җанны кыжратып, хәтер төбендә яткан серләрне түгеп, җиңеләеп калырга кирәктер ләбаса!

– Эчкерсез зат ул. Андыйларны «Эчендәге – тышында», диләр. Минем белән тел яшереп сөйләшмәде, – дигән җавап ишетте Гөлнур.

– Ата-анасы хакында да сөйләгәне булгандыр?

– Алар турында нәрсә әйтсен соң? Бер мәлне минем әтине дә, әнине дә күргәнем юк, кем икәннәрен дә белмим, – дип ачынып алган иде, кабат искә төшермәде.

– Күрмәгәч – белмәс шул, – диде Гөлнур, авыр көрсенеп һәм кинәт куырылып алды. Яшьлек хаталарын төзәтү әмәле юк шул инде. Бары тик җан сызлатып үкенергә, эчтән янып сызарга гына кала.

– Сез Зәлифәгә бик нык охшаган да хәтта, – диде хуҗабикә, Гөлнурны еракка җәелә башлаган уйларыннан арындырып.

– Бик якыннар бит, шуңадыр...

– Бертуганнармы?

– Аннан да якынрак, – диде Гөлнур һәм чын дөреслекне яшерерлек көче беткәнне сизеп: – Минем кызым ул Зәлифә!– дип әйтеп салды.

Бүлмә эченә авыр тынлык урнашты. Бәгырьгә тия торган бушлык иде бу.

– Үз-үземне һич гафу итә алмыйм. Мин аннан бернинди ихтирам-шәфкать, матди ярдәм көтмим, бары тик мине гафу итүен, кичерүен генә телим. Алдына тезләнеп, гафу сорарга килгән идем мин монда, – дип, аратирә тамган күз яшьләрен сөртештереп утырган җиреннән үкереп еларга кереште Гөлнур.

Сәкинә сүз катмады. Күңел хафасы күз яше белән җиңеләя төшәр, дип, Гөлнурның тынычланганын көтте...

Чишелде Гөлнур. Казанга укырга килеп институтка керә алмавы, тегү фабрикасында эшләве, тулай торакта Халисә апасы белән бер торакта яшәве, әлбәттә инде, Айдар белән ике арадагы мәхәббәт багланышлары турында тәфсилләп сөйләде. Кызына үзе исем кушып, үз кулы белән Халисә апасына тапшыруын да яшермәде...

– Син кызың белән күрешүдән курыкма. Аңлар ул сине, кичерер. Зиһенле, фәһемле җан иясе ул, акыллылыгы йөзенә чыккан, – дип, хуҗабикә Гөлнурның күңеленә өмет уты салып куйды.

– Картайгач кына мин кирәк булдыммыни, моңарчы кайда йөрдең?! – дип, йөземә төкермәсә ярый инде...

– Зәлифәң – нечкә күңелле хатын. Үзе дә бала анасы. Ә син хәзер оныкларыңның дәү әнисе! Язмыш сукмакларының кемне кая илтеп ташлыйсын кем белгән... Үз анасын күрү аның өчен дә көтелмәгән шатлык булыр әле – менә күрерсең!

***

Иртәнге аштан кузгалу белән Гөлнур киенергә кереште. Аның кабалануын чамалап, Сәкинә каршы төште:

– Иртүк кая җыенасың? Китәргә түгелдер бит?

– Чакырып килгән кунак түгелмен, чаманы белергә кирәк.

– Чакырылмаган кунак тагын да кадерлерәк. Сине җибәрәсем килми әле. Фатир иркен, күңел киң, ашарга ризык бар. Кал син! Кызың ял итеп кайтканчы, бергә көтик. Китсәң, йә тагын югалырсың...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



*Фәридә Хәсәнова 1981 елның 18 июнендә Арча районы Олы Әтнә авылында туган. Әнисе Рәдифә – дөньяга Шиһабетдин Мәрҗанине тудырган Ябынчы авылыннан, әтисе Фәрит – Бактачыдан, Сибгат Хәким, Лена Шагыйрьҗан укып чыккан Күлле Киме мәктәбен тәмамлаган. Фәридә 1998 елда Олы Әтнә урта мәктәбен алтын медальгә тәмамлап, укуын Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясендә дәвам иттерә. Аннан мал табибы белгечлеге алып чыга. Шул вакыттан Г.Тукай исемендәге Әтнә авыл хуҗалыгы техникумында укыта, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары.*

Фәридә
Хәсәнова

# СУРӘТ ЯНСА, ҖАН – МӘҢГЕЛЕК

***

Тукайга да бәсләр кунган
Тойган кебек вазгыятьне.
Ул мәдхия җырлаган тел
Күрмәсме соң кыямәтне?

Тукайга да бәсләр кунган...
И туган тел, бәгырькәем,
Өшетмичә, туңдырмыйча
Саклый алсын сине һәркем.

Тукайга да бәсләр кунган,
Табигать бу, кышкы салкын.
Телең телгә йокмасын, дип,
Телим сиңа газиз халкым.

***

Ә мин китәр идем җир читенә...
Син кайда да ялгыз түгел, сизәм.
Синнән мине аерырга теләп,
Күңелемнән дәрьяларны гизәм.

Көнлек мәшәкатьне оныттырып,
Эш ташлатып искә төшәсең, тик...
Могҗизалар көтми ятим күңел,
алдагысын Ходай белә... көтик.

Җир читенә барып чыксам беркөн,
Мәхәббәткә сәлам әйтимме соң?

Әллә белмәмешкә салышыйммы?
Нишләтермен яңа ярасын.

Син кайда соң? Әйдә, бергә барыйк.
Юк, саташам, кышлар җиткәннәр.
Язны таба алмый интегә, ди,
Җир читендә сөю көткәннәр.

***

Мин сине сагындым... сулышың
җылысын тоялсам – елармын
тавышсыз, тын гына... тузанын
үбәрмен син кайткан юлларның.

Мин сине сагындым... йөрәгем
Син диеп тибүдән туктармы?
Җанымны тырнаган үкенеч
күңелнең төпкелен актарды...

Актарды, айкады, давылы
җимерде өметем утарын...
Мин сине сагындым... чынлыкта,
хыяллар ялганга буталды.

Сагындым... сагынма, дисәң дә,
Хисләрем ташкынын тыймамын!
Якыннан булмаса – ерактан,
үзеңне бер күрү – хыялым!
Мин сине сагындым, сагындым...

***

Бутала, саташа табигый фасыллар
Меңенче йомгагын сүткәндә гасырлар.
Кешелек үз йөзен югалткан бу мәлдә
Бер-ике дистәгә тулырмы асыллар?

Асыллар, Алласын, намусын сатмаган,
Мин, диеп мөнбәрдән күкрәген какмаган.
Иленә, теленә тугрылык саклаган,
Халкының ышаныч, өметен аклаган,

Кайда сез? Мин кем соң? Кыйблага еракмы?
Чегәннәр кирәкми сорарга азакны...
Кем тели – шул бора, без әллә курчакмы?
Телсезләр өере үз итте баткакны.

Меңенче йомгагын сүткәндә гасырлар,
«Үткәнең онытма!» дип дәшә тамырлар.
Рух көчен туплыйк та кыйблага юл алыйк!
Без ханнар нәселе, җиңелми батырлар!

***

Ә мин бүген алтмыш тугыз тапкыр
Казан урамнарын әйләндем.
Күңелемнән генә синең юлны
Үземнеке белән бәйләдем.

Кисешмәдек... бәлки, параллельләр
Булып үткән узган сукмаклар.
Юлдашлардан сорыйм: «Кайда ул?», – дип.
Юк, дәшмиләр, әллә чукраклар.

Казан йоткан сине, яшергәндер,
Авыл мокытлары җитәрлек...
Тик Казанда, белмим, бармы Сиңа
Шигъри юллар бүләк итәрлек.

Ә мин бүген алтмыш тугыз тапкыр...
Иртәгә дә... йомгак сүтәрмен...
Әкият булсын, хыял... тик мин чатта
Юллар кисешүен көтәрмен.

Укып чык та елмай, төн кергәндә
Якты уйлар җаның биләсен.
Аңлап бетермисең син үзең дә
Кайдан ишелеп бәхет киләсен.

Ә мин бүген...

***

Вакыт үткәч, бездән калыр
Бары сурәт ак-каралы.
Карап искә алырлармы?
Искә алып карарлармы?
Әллә утка ягарлармы?
Бик кадерләп сакларлармы?

Йә ул тузанда аунармы?
Кемдер тын гына еламы?
Елмаермы аны күреп,
Киләчәге – билгесезлек...
Безгә булыр ул барыбер,
Сурәт янса, җан – мәңгелек.

***

Август җиткән, дисең, авыр сулап.
Бу бит азак түгел, уфтанма.
Алышына бары декор, бизәк,
Түбә кыегыннан моң тама.

Август кына, дисең, көндәлектә.
Җәйдән хәер өстәп, көз йөри.
Ефәк күлмәк киеп чыктым әле,
Көзне өркетергә, дип, юри.

Август, август... күңел май кичендә,
Шомырт исләренә исерә.
Сары яфрак агачында, беләм,
Соңгы төнен бүген кичерә.

Җылы алмашына салкын белән,
Сөю нәфрәт була кайчакта.
Мәхәббәткә тугры булыйк әле,
Сары яфрак булып янсак та,
Көеп кара көлгә калсак та.

***

Казан! Туңдым, әйдә, каһвә яса,
Сөт өсләре салып вакланма.
Шикәр генә балландырмас, ташла.
Син битараф миңа, акланма,
Вакыт, урын юк дип, җай чыкмый дип.
Миллионнар сыена үзеңә.
Мине генә этәрәсең һаман,
«Нигезеңне сакла, тилермә!»

Килгән саен яңгыр, җилең белән
Бәгыремне меңгә теләсең.
Беркатлылык, гадилегем, җанны
Корбан итүемне телисең?
Синең стандартыңа туры килмим,
Бераз йомшаруың көтәрмен.
Каһвә китер, эчеп җибәрим дә
Иртәгә үк кайтып китәрмен.

# ФӘРИДӘ ХӘСӘНОВА ШИГЫРЬЛӘРЕ

Борынгы заманнарда каләм көченә таянып иҗат итүчеләргә җиңелрәк булгандыр дип шаярта галимнәр – ни әйтсә дә яңа, яңалык. Бүген инде кабатланудан качу мөмкин түгел. Шуңа да XXI гасырда әйтелмәгән сүз яки фраза калмады дигән гомумбилгеле фикер – цитациягә, ягъни башка текстлар белән сөйләшүгә корылган өр-яңа төр әдәбиятның барлыкка килүе өчен нигез дә була. Кабатлану – мәҗбүрият, әмма кабатлаганда да үз сукмагыңны, үз алымыңны, үз язу рәвешеңне табу сорала. Аны бик матур итеп – «йөзем бөртеге» дип тә куялар әле. Изюминка. Фәридә Хәсәнова шигырьләренә бәйле шуның турында сөйләшербез.

Беренче шигырь – «Тукайга да бәсләр кунган». Туган тел хакында шигырь язмаган шагыйрь булмас. Бу очракта да текстта  тел язмышы үзәккә куела. Лирик герой һәр кешенең аны саклавын тели һәм өмет итә. Шигырьдә ике «йөзем бөртеге» бар: беренчесе – *«Тукайга да бәсләр кунган»* фразасы туры мәгънәсендә Тукай һәйкәленең кышкы сурәтен күз алдына бастырса, аннан соңгы тезмәдәге вазгыять сүзе белән янәшә Тукай теленең, мәдәниятенең «бозлыклар» чорына килеп керүенә ишарә ясый. Бу образ яңгырашы яки тәэсир көче белән шигырьне «тотып торырлык» ук булып чыкмаган. Хәтта аны бераз төгәлләштереп, «Тукай һәйкәленә бәсләр кунган» дип үзгәрткән очракта да, бу фраза үзеннән соң ук тагын бер ачыклаучы матур тезмә сорап тора.

Әмма икенче сурәт чын мәгънәсендә әдәби: *«Телең телгә йокмасын, дип, / Телим сиңа, газиз халкым»*. Ул беренче сурәт кебек үк ясалган: туры мәгънәсендә үткен гыйбарәне кабатлау булса (тел телгә йокмау – туктаусыз сөйләп тору), күчерелмә мәгънәдә исә бер тел икенчесенә йокмау, башка чит тел белән кушылмау турында сүз бара. Шушы сурәт беренче текстны шигырь ясаган. Дөрес, сүзләрне яңгыраш ягыннан туры китереп сайлауда осталык җитәрлек булмау үзен нык сиздерә.

Икенче шигырьдә – «Ә мин китәр идем җир читенә...» – мондый «йөзем бөртеге» юк. Хис булса да, сүзләр сайланышындагы хилафлыклар аны шактый аңлаешсыз калдыра. Җавапсыз мәхәббәттән арынырга теләү турындагы матур гына башланган беренче строфадан соң килгән икенче строфада лирик героиняның каршылыклы кичерешләрен янәшә тезмәләрдәге «көтми» һәм «көтик» сүзләрен бергә куллану бөтенләй бутап җибәрә. 3 строфада вәзен бозылу, 4 строфадагы *«әйдә, бергә барыйк»* фразасының уңышсызлыгы (җир читенә китеп җавапсыз сөюдән арынырга өметләнгән героиня инде шунда сөйгәнен чакыра?!) шигырьдәге эмоциональ эчтәлекне, хис-кичерешләрнең эзлекле үсеш-үзгәреш юлын җимереп ташлый.

Өченче шигырь – «Мин сине сагындым... сулышың...» кабат «йөзем бөртеге» турында сүз ачарга мөмкинлек бирә. Бу бик яхшы – димәк, табышлар бар. Беренче табыш матур: *«тузанын үбәрмен син кайткан юлларның»*, ул

мәхәббәтнең көче турында да, героиняның холкы турында да сөйли. Әмма ул гына шигырьне формалаштырып бетерерлек түгел. Дәвам иткәндә, эмоциональ яктан да, эчтәлек ягыннан да артык, кирәксез булган өченче строфадагы өмет «утарының» җимерелүе хакындагы образ тупас килеп чыккан. Чиксез иркенлеккә оча-йөгерә ала торган өметне утарга кертеп биклисе дә, ул утарны җимерүне күз алдына китерәсе дә килми.

Дүртенче шигырь – «Бутала, саташа табигый фасыллар» – 12/12 вәзене белән үк игътибарны җәлеп итә. Милләтнең, кешелекнең асыл затлары, аларның бөек миссиясе хакындагы шигырь, кызганыч, шулай ук буталчык юлга кереп киткән. Беренче ике строфада, пафос һәм сүзләр сайланышы ягыннан башка шагыйрь әсәре хәтергә килсә дә, матур гына гражданлык лирикасы үрнәге күзаллана башлый. Әмма 3 нче строфа кинәт кенә «мин» турында сөйләргә керешә. Әлеге строфаның соңгы тезмәсендәге «телсезләр» һәм «баткак» сүзләренең ничек ярашуы бөтенләй аңлашылмый... Гомуми тексттан бу өченче строфаны бөтенләй алып куясы килә. Дүртенче строфа кабат беренче икесендә табылган эчтәлеккә ярашып китә. Әмма монда да өченче тезмә – ясалма булып, сораулар тудыра.

Тагын бер текст – «Ә мин бүген алтмыш тугыз тапкыр...». Беренче тезмәдәге «йөзем бөртеге» игътибарны җәлеп итә: нишләп 69 тапкыр икән ул? Әмма... бу табышмак җавапсыз кала.

«Вакыт үткәч бездән калыр...» – бәйләмдәге иң уңышлы текстлардан. Дөрес, төсле фотографияләр чорында аклы-каралы сурәт детален куллану сорау уята. Әмма һәр кешенең күңелендәге миннән ни калыр дигән сорау текстны бергә туплый, тиешле дәрәҗәдә сагыш белән дә сугара. Кызганычка каршы, бу шигырьнең соңгы юлы табылмаган. Чөнки биредәге соңгы тезмә – *«Сурәт янса, җан – мәңгелек»* аны йомгакламый, бәлки, дәвам итүне сорый.

«Казан! Туңдым, әйдә, каһвә яса» – шәхсиләштерелгән текст. Уйлап бетерелмәгән юллар бар. Әйтик, *«Синең стандартыңа туры килмим, / Бераз йомшаруың көтәрмен»*. Казан шәһәренең йомшаруын көтеп утыручы героиня – кызык та, кызганыч та.

Гомумиләштергәндә, Фәридә Хәсәнова шигырьләре турында түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин: текстларның аһәңе-көе яки сүзләрне яңгыраш ягыннан туры китереп сайлауны аерып мактап булмас; тема-мотивлар яки лирик геройның дөньяга карашы җәһәтеннән дә гаҗәпләндерерлек яңалык күрмәдем; фикер ачыклыгына килгәндә – монысы да җитәрлек түгел. Бигрәк тә соңгысы – иҗатчы өчен мөһим таләп. Хәтта махсус катлауландырылганда, берничә эчтәлекне бер-беренә урнаштырганда да (бу Ф.Хәсәнова очрагы түгел), аларны укырга ачкыч, юнәлеш сорала.

Шулай да текстларда аларны шигырьгә әйләндерерлек матур гына яңа-үзгә табышлар бар. Максатчан уйланганда-эзләнгәндә, Фәридә Хәсәнова матур әсәрләр иҗат итә алыр кебек. Әмма вәзен, шигырьгә – шигъри сүзләр сайлау өстендә эшләргә, артык детальләштерүдән котылырга кирәклеге дә аермачык.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



*Орхан Вәли Каныk (1914-1950) XX гасыр төрек әдәбиятында яңа юл ярган, төрек шигырен эстетик салоннардан урамга, халык хозурына алып чыккан күренекле әйдаман шагыйрьләрнең берсе. Ул Истанбул шәһәрендә төрек музыканты һәм композиторы Вәли Каныk гаиләсендә туа. Истанбул университетындагы әдәбият факультетының фәлсәфә бүлегендә белем ала. Укуын ташлап, төрле дәүләт оешмаларында, башта Анкарада почта хезмәткәре, соңрак Төркия мәгариф министрлыгында тәрҗемәче булып эшли. «Яфрак» (1940-1950) исемле газета чыгара. Каләмдәш дуслары Октай Рифат һәм Мәлих Җәүдәт белән бергәләп, «Өчаяк» дип исемләнгән яңа әдәби юнәлеш оештыралар. Шагыйрь фикеренчә, сәнгать кешенең хисләреннән бигрәк, аның акылына тәэсир итәргә тиеш. Аның иҗатына француз символистларының йогынтысы зур була. Орхан Вәлинең шигырьләре алман, инглиз, рус, үзбәк телләренә тәрҗемә ителгән. Аның татар галәменә тәүге аваз салуы. Шигырьләр турыдан-туры төрек теленнән тәрҗемә ителүләре белән дә игътибарга лаек.*

Орхан
Вәли

# БАДӘМ АРТЛАРЫННАН КҮТӘРЕЛӘ АК АЙ...

## Истанбулны тыңлыйм

Күзләремне йомып тыңлыйм Истанбулны,
Хозурланмый гына тыңлап булмый аны.
Исеп куя кинәт назлы җиләс җилләр,
Җилдә салмак кына чайкалалар гөлләр.
Ерак-еракларда – дулкын кагышлары,
Су ташучыларның ишетәм тавышларын.
Күзләремне йомып тыңлыйм Истанбулны,
Хозурланмый гына тыңлап булмый аны.
Күктә, бик биектә – чиксезлекләр күрке –
Очып бара чыңлап, кошлар төркем-төркем.
Ятьмәләрдә мыжгый диңгез балыклары,
Бер хатын-кыз ярда чайкый аякларын.
Күзләремне йомып тыңлыйм Истанбулны,
Хозурланмый гына тыңлап булмый аны.
Салкын җиләс һава Капалы Чаршыда[1],
Шаулый-гөрли кайный Мәхмүтпашасы[2] да.
Ишегалларында күгәрченнәр туе,
Чүкеч тавышлары тынмый көннәр буе.

[1] Капалы Чаршы – Истанбулдагы базар исеме.
[2] Мәхмүтпаша – Истанбулдагы базар исеме.

Язлар җирдә, язлар, җилкенә хисләрем,
Алып килә җилләр язның хуш исләрен.
Күзләремне йомып тыңлыйм Истанбулны,
Хозурланмый гына тыңлап булмый аны.
Айный алмый һаман үткәннәрдән бар да,
Шыксыз каекханә[3] черем итә ярда.
Кагыла йөзләремә дулкыннарның тыны,
Күзләремне йомып тыңлыйм Истанбулны,
Юл буеннан атлый бер чибәркәй, каһәр,
Шаярулар, җырлар монда таңга кадәр.
Кулларыннан кинәт төшә җиргә нидер,
Роза гөледер.
Күзләремне йомып тыңлыйм Истанбулны,
Хозурланмый гына тыңлап булмый аны.
Итәгендә, күрәм, талпынадыр бер кош,
Иреннәре  дымлы, йөзләрендә балкыш.
Бадәм артларыннан күтәрелә ак Ай,
Йөрәк тибешен дә мин тоямын бугай.
Истанбулны тыңлыйм...

## Икмәк

Тел очымда тибри исеме бер дустымның,
Күкләр биеклеге иңә җанга тулып.
Җиргә ятып эчәм зәңгәр чиксезлекне,
Онытылган йөзләр ага болыт-болыт.

Хатирәләр тулы көзләр табигатьтә,
Учларымда җылы икмәк рухын тоям.
Әйтерсең лә ап-ак, садә болытлардан
Сабый чакның назлы җыры чыңлый сыман.

## Поезд тавышы

И мосафир,
Бу шәһәрдә синең
Кемең дә юк,
Һичбер таныш йөз.
Ярың да юк кайгың бүлешергә,
Син берьялгыз. Сабыр. Чыда. Түз.

Ишетелсә поезд тавышлары,
Үзәкләрне өзеп кичләрен.
Күзләреңнән ике чишмә кебек
Агып чыгар төсле яшьләрең.

## Башка төрле сагыш

Бу сагышым минем башка сагыш,
Булмый торган барлык адәмнәрдә.
Юк, язлар да китермәде аны,
Шау чәчәккә чумган бадәмнәр дә.

[3] Каекханә – көймәләр саклый торган урын.

Мин ышанмыйм үлем барлыгына,
Кемнәр уйлап чыгаргандыр аны?!
Кояш белән бергә җитәкләшеп
Килгән үлемнән соң куркыргамы?

Апрель җиткән саен мин бер елга
Яшәрәмен. Язлар белән бергә
Арта баргач сөю, гыйшык уты
Үлемнән соң, нигә ул өркергә?

Аһ, дускаем, уйлый күрмә ялгыш,
Бу сагышым башка төрле сагыш...

## Ялгызлык шигыре

Ялгыз яшәмәгәннәр аңламас
Асылын бу гади чынлыкның:
Аһ, никадәр куркыныч икәнен,
Кешегә бу шомлы тынлыкның.

Үз-үзләре белән сөйләшкәнен
Аңлый алмас алар беркайчан.
Көзгеләргә йөгереп килгәннәрен,
Төннәрендә эзләп тере җан.

Ялгыз яшәп карамаганнар
Аңлый алмас...

## Төш

Мин төшемдә әниемне күрдем,
Үлгән килеш күрдем мин аны.
Күз яшемә чыланып уяндым да
Мин яңадан ачтым дөньяны.

Искә төште кинәт сабый чакта,
Иртән бер бәйрәмгә барганым.
Күк йөзенә шарым очырткач мин,
Артларыннан аның елый-елый,
Нәүмизләнеп карап калганым...

## Мәхәббәт парады

Талчыбыктай зифа бер кыз иде,
Хәзер ул – сәүдәгәр хатыны.
Симергәндер, бәлки, мичкә кебек,
Ишетелми – бер дә юк тыны.
Бер күрәсем килә аны кабат,
Барып кына җитеп булмый шул.
Шаяраммы? Түгел. Ни дисәң дә,
Иң беренче ярым иде ул.

Икенчесен – миннән өлкәнрәген –
Мүнәввәрне уйлап җан яна.
Биек койма аша йортларына
Хатлар ташлый идем мин аңа.
Ул хатларны укып, эче катып
Көлә иде җәйге кичләрдә.
Шул чакларны искә аламын да,
Оятымнан белмим нишләргә.

Бер үк мәхәлләдә яшәгәне –
Халидә атлы иде анысы.
Бергә уйнап үстек, диварларга
Исемнәрне яздык акбур белән –
Балачакның матур «йоласы».

Дүртенчесе азгын хатын иде
(Чү, йөрәгем, зинһар, ярсыма!),
Беркөнне ул хәтта шыр ялангач
Килеп басты минем каршыма.

Инде бик күп еллар үтсәләр дә,
Онытa гына алмыйм мин аны.
Еш кына ул төшләремә керә,
Оныттырып бөтен дөньямны.

Бишенчесе... Хәер, ул хакта мин
Теләмим дә хәтта сөйләргә.
Алтынчысы-ы-ы? Менә аның өчен
Риза идем хәтта үләргә.

Әлеге шигырь төгәлләнмичә кала. Аның дәвамын – теш щеткасы төрелгән кәгазь кисәген – вафатыннан соң костюм кесәсеннән табып алалар. Бу – шагыйрьнең соңгы шигыре.

«Нуриннисам!», диеп, яратып кына
Дәшә идем аңа, чын әгәр.
Кара кашым, сылуым, асыл ташым,
Килсә иде синнән бер хәбәр!
Ах, Нуриннисам минем, Нуриннисам,
Язылмыйча калган бер кыйссам!

Җиденчесе, Алия исемлесе,
Бер аксөяк нәселеннән иде.
Затлы мехлар, алмаз алкаларны
Ул миннән дә ныграк, ахры, сөйде.

Йөрәгемне ялкын ялмады,
Әллә нигә ул кыз күңелемә
Беркайчан да якын булмады.

Сигезенчесе дә – шул ук каннан,
Ләкин гаепләрнең барысын да
Гөнаһ булыр иде аңа гына
Сылтап калдыру Ходай каршында.

Кеше хатыныннан сафлык эзләү,
Булган кебек бер мәгънәсез шөгыль,
Авыру кешедән дә сәламәтлек
Таләп итү һич мөмкин эш түгел.

Тик һаман да онытa алмыйм шуны
(Онытa алмам кебек гомергә),
Нигә кирәк иде адым саен
Ялган сүзләр сөйләп йөрергә?..

Тугызынчысы Айтәт атлы иде,
Барда бии иде һәр көнне.
Теләсә кемнең колы иде шунда,
Бардан чыккач, ләкин янына ул
Якын җибәрмәде һәркемне.

Мине ташлап дөрес эшләде ул –
Унынчысы – акыл җимеше.
Әйтерсең лә мәхәббәт тә бары
Җилкуар һәм байлар өлеше.

Ике күңел бергә кушылганда,
Печәнлек тә, хәтта, киң сәйран.
Тән ялангач чакта икеңә дә,
Дөнья гүя олы бер хамам.

Баш-аягы белән эшкә чумган
Хатын иде унберенчесе.
Соң нишләсен? Залим хуҗасының
Колы иде, бер хезмәтчесе.

Лександра ярты төндә килеп,
Кала иде миндә таңгача.
Сәрхушләнә иде коньяк эчеп,
Иртән торып, йөгерә иде эшкә,
Ят күзләрдән ул кача-кача.

Соңгысына килик...
Беркемне дә шулай аның кебек
Якын итә алмадым һичкайчан.
Аны уйлап әле хәзергәчә
Хыял күкләремдә мин очам.

Хатын гына түгел, уйлап баксаң,
Чын кеше дә иде тормышта.
Кирәк түгел иде аңа байлык,
Мал-мөлкәтең хәтта ялгыш та.

«Их, без тигез һәм хөр булсак иде» –
Диеп, һәрчак янды, көйде ул.
Нәкъ тормышның үзен яраткан күк,
Кешеләрне ихлас сөйде ул.

*Төрекчәдән* **Рәмис АЙМӘТ** *тәрҗемәләре*



Фирдәвес
Зариф

# МИН ДӨНЬЯНЫ КҮРӘМ

ХИКӘЯ

**1**

Төнге күктә тулган ай йөзә. Аның көмешсу яктысында, егетләргә тәүге тапкыр баккан кызлар кебек, йолдызлар җемелдәшә.

Менә ай яктысы инеш буендагы талларны, тал ышыгына баскан егет белән кызга төште.

– Беләсеңме, Нәзифә, мин бүген төшемдә урман аланында йөргән ялгыз болан күрдем. Җәй уртасы, тирә-якта яшеллек, тик нигәдер бер куакның яфракларына сары сарган. Шул куакта өзелеп-өзелеп сандугач сайрый. Ә болан, моңсу күзләрен тутырып, зәңгәр күккә карый. Шунда, нишләптер, мин аның күзләрен синең күзләреңә охшаттым, Нәзифә. Беркавым карап торгач, болан акрын гына куак янына килде һәм сары яфракларга үрелде. Инде кабам дигәндә генә, көчле җил чыкты. Ул, куак ботакларын йолыккалап, яфракларын очырта башлады. Ә минем күңелне шом биләде. Кадерле нәрсәмне югалткандай, мин ул яфракларны тота, кочагыма җыя башладым.

– Әллә нинди шомлы төш сөйлисең син, Нәсим. Минем әби, кич җиткәч, төшеңне сөйләмәскә куша. Иртән сөйләгән төшем булсын, диген...

Нәзифә, җиңелчә дерелдәп, Нәсимгә сыенды.

**2**

Җиргә тагын көз килде. Моңсу сарылыгы белән күңелдә сагыш уятса да, табигать быел да кешеләрне кояшлы якты көннәре белән куандырды.

Гомер дигәннәре... Нәзифә белән Нәсим мәктәп елларының соңгы бусагасына аяк бастылар. «Алдагысын Алла гына белә», – диләр. Киләчәккә корган матур хыялларының күпмесе тормышка ашар да, язмыш җилләре аларны кайларга таратыр. Әлегә мәктәп елларыннан, ваемсыз яшьлек хыялларыннан һич тә аерыласы килми.

Көннәр бер-бер артлы үтә торды. Нәсим белән Нәзифә өчен бәхетле, киләчәккә якты өмет вәгъдә иткән матур көннәр булды алар. Хәер, яшьлек үзе үк матурлык, бәхет түгелмени?! Шуңа булса кирәк, декабрь суыкларына ияреп, җанны өшетерлек ачы хәсрәт киләсен сизми-тоймый калдылар...

Нәзифә ул төнне саташып, куркыныч төшләр күреп уздырды. Ә куркынычның иң хәвефлесе аны өндә көткән икән. Инде уянып, күзләрен ачкач та, тирә-ягында шомлы караңгылык күреп, ул куркып китте. Тәнендәге дерелдәү узып, исенә килгәч тә, әллә һаман да төш күрәмме икән, дип, күзләрен угалады. Күз алдындагы шомлы караңгылык чигенмәде, чөнки күзләре... күзләре күрми иде.

– Әнием, әнием бәгърем, күзләрем күрмиләр. Күрмим бит, әнием бәгърем! – дип ачыргаланып кычкыруын сизми дә калды ул.

Мич тирәсендә кайнашкан әнисе башта аңышмый торды. Аннары кызын, кочагына алып, юатырга тотынды:

– Юкны сөйләмә, кызым. Төш күрә торгансыңдыр. Бар, тышка чыгып кер, салкында йокың ачылып китәр. Төш кенә ул, кызым, узар.

Нәзифә торып утырды, киемнәрен табып киде. Аннан соң, кармаланып, мич янына килде һәм итекләрен эзли башлады. Аны күзәтеп торган әнисе агарынып китте, бермәлгә телсез калды, ә икенче мизгелдә, кызын кочагына алып, елап җибәрде.

– Нәзифәм, кызым, син бөтенләй күрмисең икән бит. Йа Аллам, нинди каргышлы көн булды бу!

Юк, ана белән кыз, ике тән генә түгел, бер-берсенең дәвамчысы булган ике җан иңрәп елады ул иртәдә. Күз яшьләре түгел, җанны әрнеткән хәсрәт чишмәләре акты аларның битләре буйлап. Ачы, чиксез ачы иде ул чишмәләрнең суы. Бары ваемсыз җил генә, берни булмагандай, юлларда кар бөртекләре куды.

**3**

Инде кыш та үтеп бара. Ә Нәзифә өчен көннәр бертөрле – күңелсез һәм моңсу. Әле ярый Нәсим килеп йөри, мәктәп хәлләре белән таныштыра.

Классташлары инде һөнәр сайлыйдыр, зур тормыш, бәхет турында хыялланадыр. Нәсим дә тормышта үз урынын, пар канатын табар, Нәзифәнең дөньяда барлыгын да онытыр. Хәер, үпкәләми ул аңа. Сөйгән кешесенә кем начарлык теләсен, ди.

Нәзифәнең уйларын Нәсимнең тавышы бүлде:

– Нәзифәм, бәгърем, мин медицина университетының хирургия факультетына керергә уйлыйм. Әнә, дөньяда нинди катлаулы операцияләр ясыйлар, йөрәк булып йөрәкне күчереп утырталар. Синең дә күзләрең ачылыр. Үзем булдыра алмасам, атаклы хирургларга күрсәтермен.

– Нигә минем өчен киләчәгеңне корбан итәсең, Нәсим? Син, юрист булып, рәнҗетелгән кешеләрне яклау турында хыяллана идең бит.

– Синең якты көнне, табигатьне, кешеләрне күрә алмавың гаделсезлек түгелмени, Нәзифә? Кешеләргә саулык бүләк итү, өйгә кайткач, сөйгәнеңнең ягымлы карашын тою бәхет түгелмени?!

– Шулаен шулай да, Нәсим. Ләкин теләк – бер, чынбарлык – икенче, дигәндәй, ниятең барып чыкмаса?

– Ни генә булса да, мин сине ташламам, Нәзифә. Күзең белән күрә алмасаң, күңелең белән тоярсың. Тик мин язмышның шулай мәрхәмәтсез булуына ышанмыйм, ишетәсеңме, кадерлем, ышанмыйм!

– Юк, юк, Нәсим. Минем бәхетсезлегем сиңа бәхет китермәс бит. Оныт син мине, онытырга тырыш. Син әле үз бәхетеңне табарсың. Ә мин синең бәхетеңә куанып яшәрмен.

– Күңелсез уйларны калдырып торыйк әле, Нәзифә. Әнә, радиодан ял концерты бара.

Нәсим, транзисторны кулына алып, тавышын ачты. Бүлмәгә моң агылды:

«Тәрәзәләр елмаялар,
Тәрәзәләрдә нурлар –
Зәңгәр күкләргә үрелеп,
Зәңгәр күкләргә үрелеп,
Йөрәктә шыта җырлар.
Тәрәзәләр, тәрәзәләр
Киңрәк ачылсын.
Язны сагынган күңелдә
Сагыш басылсын...»

Алар сихри моң агышына кушылып җырлый башлауларын үзләре дә сизми калды.

**4**

Нәзифә язларга гашыйк. Бу яз да аңа якты өметләр, шатлык алып килер кебек иде. Әмма көннәр үткән саен, Нәсим белән аерылышу минутларын уйлап, йөрәге сулкылдап куя. Дөрес, әле Нәсимнең чыгарылыш имтиханнарын тапшырасы бар. Университетка

имтиханны уңышлы тоткан очракта да, сентябрьгә кадәр азмы-күпме вакыт кала. Нәзифә үзе дә, Нәсимнең ярдәме белән чыгарылыш имтиханнарына әзерләнә башлады. Югыйсә, күзләре күрми башлагач, укудан гына түгел, тормыштан да күңеле суына башлаган иде инде. Тик әнисенең үгетләве һәм Нәсимнең түземлелеге, игътибарлылыгы үзенекен итте – Нәзифә, акрынлап кына булса да, яңа темаларны үзләштерә башлады. Авыр, бик авыр иде аңа, чөнки ул сәламәт вакытында төгәл фәннәрне укытучы сөйләве буенча гына түгел, үзе күреп, язып үзләштерергә дә күнеккән иде. Ә инде тарих, әдәбият кебек фәннәр аңа җиңел бирелде. Бәхетсезлеккә юлыкканчы бик яхшы билгеләренә генә укыган кызны кызганып, укытучылар да көнаралаш килеп йөри башладылар.

Өметләр яңарып, үз-үзенә ышаныч туып кына килгәндә, Нәзифәнең тормышын өермә кебек тузгыткан бер вакыйга булды: фермада сыер савучы әнисе кинәт кенә каты авырып китте. Берәр атна өйдә яткач, аны «ашыгыч ярдәм» машинасы белән район хастаханәсенә алып киттеләр. Олы яшьтәге әбисен һәм йорт эшләрен карау үз хәлен үзе генә белгән Нәзифә өстенә калды. Өстәвенә, әнисенең хәле үзәкне өзә. Инде түзәр чамасы калмагач, күрше Миңнеҗамал апаны өйдә күз-колак булырга күндереп, Нәсим белән район үзәгенә киттеләр.

Хастаханәгә алар көн төшкә авышкач кына барып җиттеләр. Әнисе яткан бүлеккә керергә рөхсәт ителмәсә дә, Нәзифәнең хәленә кереп, аның үзен генә эчкә уздырдылар. Палата ишеген ачуга, әнисенең хәлсез тавышын ишетеп, Нәзифә бер мизгелгә зиһенен җыя алмый торды. Икенче мизгелдә ул, егылып китмәс өчен, ике куллап ишек тоткасына ябышты. Нәзифәнең хәләтен күреп, шәфкать туташы аны, җитәкләп, әнисе янына алып килде һәм урындык куеп, янәшә утыртты. Күрмәсә дә, әнисенең сулган сары йөзен, эчкә баткан күзләрен күңел күзе белән тойды ул. Күз яшьләрен авырлык белән генә йотып, әнисенең кулларын учларына алды һәм йөзенә тидерде:

– Әнием, бәгърем, хәлең ничек?

– Әйбәт, кызым, инде аруланып киләм, монда табиблар яхшы карыйлар, – диде ана, кызын борчымаска тырышып. – Син ничек үзең генә ерак юлга чыгасы иттең?

– Мин Нәсим белән килдем, әнием. Тик аны кертмәделәр.

– Әбиең ни хәлдә, кызым, йөриме?

– Шулай өй тирәсендә йөреп тора. Терлек-туарны карарга Нәсим килеп булыша.

– Бик авырга туры килә инде сиңа, кызым. Болай килеп чыгасын кем белгән. Азрак түз инде, озакламый мин дә чыгармын.

– Син безнең өчен борчылма, әнием. Яхшылап дәвалан. Мин ияләштем инде. Аннары Нәсимнең әнисе дә көнаралаш килеп йөри.

– Алланың рәхмәте яусын инде ул игелекле җаннарга. Изгелекләре үзләренә изгелек булып кайтсын.

– Әнием, мин сиңа үзем пешергән кабартма һәм өчпочмаклар алып килгән идем. Аз булса да аша инде, хәл кереп китәр.

Аннары ул шәфкать туташына эндәште:

– Апа җаным, бу тавык шулпасын җылытып бирмәссезме икән?

– Соңрак, кызым, соңрак, – дип бүлдерде аны әнисе. – Син юкка кайгырма, кызым, монда да ашаталар. Сине күргәч, йөрәгем тынычланып, кәефем күтәрелеп китте әле. Бүген үк кайтып китәр идем дә, духтыр җибәрми, бөерләреңнең кай якта икәнлеге онытылырлык булсын, ди.

Палатага төшке аш керттеләр. Нәзифәгә әнисе белән саубуллашып чыгып китәргә туры килде. Ана кызын моңсу күзләре белән озатып калды.

Нәсим Нәзифәне беренче катка төшә торган баскыч янында борчылып көтеп тора иде.

## 5

Июнь ае яңгырлы килде. Әллә быел җәй булмыймы икән, Ходаем, дип тәшвишләнә башлаган картларның борчуын басарга теләгәндәй, күктә яңа ай тугач, көннәр дә аязып, рәтләнеп китте.

Нәзифә белән Нәсимгә йокы аз эләгә – менә-менә чыгарылыш имтиханнары башланырга тора. Нәзифәнең әнисе хастаханәдән чыкса да, күтәрелеп китә алмый. Азрак йөрүгә, башы әйләнеп, кереп ятарга мәҗбүр була. Шуңа күрә йорт эшләре дә

Нәзифә өстендә. Дөрес, терлекләрне Нәсим караша, әмма ике арада йөгереп йөрү аңа торган саен кыенлаша бара. Соңгы көннәрдә ул, сулыгып, коры сөяккә калды. Әнисе Фәүзия апа улының сәламәтлеге өчен курыкса да, каршы дәшми. Ана күңеле аңлаптоеп тора – ярата, бик ярата ул Нәзифәне. Югыйсә халык арасында, нигә сөлек кебек егетнең киләчәген гарип кызга бәйлисең, дип әйтүчеләр дә аз түгел. Юк, алар белән килешә алмый ул, чөнки яшьлегендә аны әнисе, кеше сүзенә карап, сөйгән кешесенә бирмәде. Хәзер менә кушыла алмаган елга ярлары кебек икесе дә бәхетсез. Хәер, алай дип әйтү гөнаһ булыр: ни әйтсәң дә, бәгырь кисәге – улы Нәсим бар...

Вакытның үз кануннары. Аны туктатып та, ашыктырып та булмый. Нәсим белән Нәзифә күпме сузарга тырышсалар да, чыгарылыш имтиханнары килеп җитте.

Юкка кайгырганнар икән, барлык имтиханнар да уңышлы үтте: Нәсимгә – «бишле», Нәзифәгә «дүртле» һәм «бишле» билгеләре куйдылар. Ул көнне дөньяда алардан да бәхетлерәк кеше булмагандыр, Нәзифәнең хәтта күз аллары яктырып киткәндәй булды. Кичке караңгылык иңгәч, җитәкләшеп, чишмә буена төштеләр. Чишмә элеккечә көмеш тавыш чыгарып челтерәп ага, тал яфраклары да әүвәлгечә талгын гына серләшәләр. Адәм балаларының серләрен белергә теләгәндәй, вакыт-вакыт чишмә дә агышын акрынайта, яфраклар да шыбырдашудан туктап торалар кебек тоелды Нәсим белән Нәзифәгә. Хәер, бу беренче минутларда гына шулай булды. Бераздан гашыйклар берберсенең йөрәк тибешен, назлы сүзләрен генә ишетәләр иде.

– Нәзифәм, менә минем беренче теләгем кабул булды – чыгарылыш имтиханнарын уңышлы тапшырдык.

– Икенче теләгең нинди иде, Нәсим?

– Ни генә булса да, гомергә бергә булу.

– Юк, Нәсим, үзеңә гомерлек үкенеч алма. «Яшьлек кайнарлыгы басыла, алда мәшәкатьле тормыш кала», – ди әбием.

– Өченче теләгемне дә әйтим инде, Нәзифәм.

– Әле синең өченче теләгең дә бармыни? – дип сораган булды Нәзифә. Ә үзенең бу хакта бик тә беләсе килә иде.

– Өченче теләгем – синең белән бергә якты көнгә соклану. Мин аны һәр иртәдә Аллаһы Тәгаләдән сорыйм. Фәрештәләр дә «Амин» дип дога кылсалар иде, дим.

– Рәхмәт сиңа, Нәсим. Саф күңелең, изге теләкләрең өчен рәхмәт. Миндә дә бүген өмет яши. «Аллаһы Тәгалә адәм балаларын газап өчен түгел, ә бер-берсен бәхетле итәр өчен яралткан», – дип юата мине әбием.

Аның сүзләрен расларга теләгәндәй, әрәмәдә өздереп-өздереп сандугач сайрый башлады. Чишмә челтерәвенә һәм сандугач моңына өретелеп, офыкта таң сызылып килә иде.

**6**

Ә гомер ага да ага. Аның агышын адәм баласының теләге генә түгел, зилзиләләр дә туктата алмый. Җырдагы кебек: «Ага сулар, айлар ага, еллар ага...»

«Әйе, берәүләр өчен гомер ага. Ә менә аның өчен ул туктап калгандай булды. Әллә язмыш, әллә...» Күңелсез уйларын таратырга теләп, Нәзифә бакчага чыкты, тәрәзә алдында ук үскән шомыртны кочагына алып, кәүсәсенә битен куйды. Кәүсә буйлап тереклек суы агуын тоеп, ул сискәнеп китте.

«Юк, өметеңне өзмә әле син. Яшәргә кирәк, яшәргә..., – дип юата кебек иде аны шомырт. – Әнә, мин ничә еллар инде ялгыз үсәм, тик шулай да өметсезлеккә бирелмим. Ә синең әле Нәсимең бар».

– Әллә исәрләнәм инде,– дип куйды үзалдына Нәзифә һәм өйгә кереп китте. Аннан өстәл янына килеп, Нәсимгә хат язарга утырды. Күрмичә хат язуның авырлыгын шунда гына тойды ул. Дәфтәр битеннән чыгып китмәс өчен, кәгазь читен кат-кат капшарга туры килде аңа. Хат юллары шулай тезелде.

«Нәсим, газизем!

Хатыңны алдым. Мине онытмавың, җылы сүзләрең өчен рәхмәт.

Үземнең хәлләрем әйбәт, әни белән әби бер килеш йөреп торалар.

Фәүзия апа көнаралаш килеп, булышып китә. Аллаһының рәхмәте яусын аңа!

Эшләрне бетергәч, озак кына сөйләшеп утырабыз. Бик сагына ул сине, мин дә юксынам. Кайчан имтиханнарыңны биреп бетерерсең дә, кышкы каникулга кайтырсың икән дип көтәбез. Ә көткәндә, вакыт шундый акрын үтә, көннәрне уздыра алмый интегәм. Төннәрен тагын да авыррак, сискәнеп уянам да сине уйлыйм. Тәрәзә янына утырып, имтиханга әзерләнәсеңдер, рәтле йокы да эләкмидер, дим. Уку белән ашарга әзерләргә дә вакытың калмыйдыр инде, укый-укый күзләрең талгандыр...»

Шунда Нәзифәнең тамагына кайнар төер тыгылды, күз яшьләрен йотып, бермәл тәрәзәгә карап торды. Урамнан аңа караңгылык, төн пәрдәсе генә бага иде. Тик бүлмәдәге якты ут кына күзләренә караңгы-кызгылт шәүлә сирпеде. Нәзифә куллары белән күзләрен каплады, менә-менә учларын ачар да, күзләре яңадан күрә башлар кебек тоелды аңа. Сәламәт вакытта күзләренә көн яктысы түгел, бәхетнең үзе баккан икән бит. Ә ул аны сизмәгән, аңламаган. Их, тормыш, тормыш... Сабырлык биреп, яңадан шул бәхет белән очраштырсаң иде. Җибәрмәс иде ул аны, кадерен белер иде.

Шулай уйланып утыра торгач, күзләренә йокы сарылды. Өстәл янында йокыга талуын сизми дә калды ул.

Нәзифә төшендә дулкын булып чайкалучы яшел иген кырын күрде. Менә ул кыр юлыннан шул дулкыннарга таба йөгерә. Җил дә яшел башакларны аңа таба куа кебек. Алар дулкын булып киләләр дә, авылга керергә кыймый, кире йөгерәләр. Җил тагын аларны алга куа, тик башаклар җил кочагыннан яңадан шуып чыгалар... Ни хикмәттер, Нәзифә дә алар янына килеп җитә алмый. Менә ул, эсселектән сулуы кабып, туктап калды, тез буыннарының хәле китеп, тузанлы юлга тезләнде. Егылып китмәс өчен кулларын сузып, күк йөзенә бакты. Күк йөзе чалт аяз булса да, нишләптер анда... кояш юк иде.

Нәзифә шул мизгелдә сискәнеп уянып китте, үзенең кайда икәнен аңышмый, кузгала алмый торды. Бөтен тәне дерелди, кыл кыймылдатырлык та хәле юк иде. Бераз вакыт узгач, авырлык белән торды да кармаланып караватка барып ятты. Тик күзләрен йокы алмады, йоклап китсә, тагын теге шомлы төшне күрер кебек иде. Нәзифә үзен ялгыз, чиксез ялгыз итеп сизде. Әйтерсең лә караңгы бушлыкта берүзе торып калган. Ул кычкырырга теләде, әмма тавышы чыкмады. Шунда гына Нәзифә тәненең ут булып януын, иреннәре кипшереп, авыз эче чатнавын тойды.

«Су, – дип пышылдады ул, – бер йотым су бирегезче...»

Әнисе дә уянган икән, чынаякка чәй агызып, тәне кызышып яткан кызының иреннәренә тидерде. Йотылып чәй эчкәч, Нәзифә саташулы халәттә йокыга китте.

Ә тышта буран котырына, кар бөртекләре койма буйларында, өй кыекларында сыенып урын эзли, тик җилнең генә аларның хәленә керергә исәбе юк иде.

## 7

Нәзифә атна буе авырып ятты. Үз хәле хәл булса да, әнисе аның яныннан китмәде: мәтрүшкә төнәтмәсе, кура җиләге белән чәй, төрле дарулар эчерде. Инде икенче атнага киткәч, Нәзифә торып йөри һәм тамагына да азрак ашый башлады. Көн саен килеп йөргән Фәүзия апасы аны өй эшләренә, терлек-туар янына якын җибәрмәде: «Өзлегерсең, әлегә чыгып йөрмә, менә ныклап аякка баскач, үзем үк эш куша башлармын», – диде.

Бер-ике көннән, имтиханнарын уңышлы тапшырып, кышкы каникулга Нәсим кайтып төште. Нәзифәгә канатлар үсеп чыккандай булды. Дөньяда аннан да бәхетлерәк кеше юк иде кебек ул көнне: кая басканын, нәрсә әйткәнен дә белмәде. Янында Нәсимнең барлыгын тою, тавышын ишетү аңа көн яктысын кайтаргандай булды.

«Әйе, адәм баласын өмет, башкалар өчен кирәклегеңне тою яшәтә. Ходай Тәгалә кызымны өметтән аермасын, рәхмәтеннән ташламасын иде. Без инде яшисен яшәгән»,– дип уйлады Нәгыймә апа, Нәзифә белән Нәсимгә карап.

Икенче көнне Нәзифә белән Нәсим, кулга-кул тотынышып, тау астындагы чишмәгә төштеләр. Чишмә буен кар каплаган. Бәс һәм кар сарган тал ботаклары очларын түбән игәннәр. Чишмә дә элеккечә ярсып түгел, талгын гына ага. Әйе, табигатьтә тәңгәллек, кешедән башка бөтен тереклек иясе табигать кануннары белән яши. Тик кеше генә, үзен табигатьтән өстен куярга омтылып, шул тигезлекне боза. Югыйсә, кешеләр дә

бәхетле яшәр, җаннар да җәрәхәтләнми, фаҗигаләрнең дә күбесе булмый калыр иде. Кызганыч ки, адәм баласы күп вакытта үзенең асылына каршы килеп яши шул. Тик гомер азагында гына уйлана башлый.

Чишмә буендагы матурлыкны күреп, ирексездән шул турыда уйлады Нәсим. Хәтта беркавым бер-берсенә эндәшергә дә кыймый тордылар.

Кинәт җил исеп куйды. Нәсим белән Нәзифәнең өстенә кар коелды. Шуны гына көткәндәй, тал ботакларыннан пырхылдашып бер төркем кызылтүш очып китте. Чишмә буенда кабат тынлык урнашты.

Нәсим, елмаеп, Нәзифә өстенә коелган карны сак кына каккалый башлады.

– Тимә, Нәсим, бәлки, кар түгел, бәхетнең үзе кунгандыр.

– Алайса, мин аны җибәрмим,– дип, Нәсим Нәзифәне йомшак кына кочаклап алды.

– Янымда булсаң, җибәрмәс идең дә бит. Тик ике атнадан яңадан китеп барасың шул.

– Укып бетергәч, бәхетең һәрчак яныңда булыр, Нәзифәм.

– Их, шулай булсачы. Тик күңелем моңа нигәдер ышанып җитми, Нәсим. Башканы табарсың да онытырсың кебек.

– Җүләрем. Шундый уйлар уйлыйлар, димени. Башкалар башканы эзләсеннәр. Мин бит сине, бары сине генә яратам.

Җиргә төшкән саф кар бөртекләре үзара кавышкандай, иреннәр бер-берсе белән кушылды.

**8**

Табигать язга аяк басты. Яз белән бергә, күңелләрдә яңа өметләр бөреләнде.

Өмет... Адәм баласын тормыш җиз иләктән иләгәндә, ул аның күңелендә чаткы булып кабына да, үз-үзен югалтудан саклап кала. Ә андый мизгелләр кеше тормышында шактый очрый. Гомер агышында, югалту һәм табышлар аша, адәм баласы тормыш тәҗрибәсе туплый, өмете дә ныгый бара. Әмма ул инде яшьлектәге хыял дигән канатын югалткан була. Канатлы булганга, яшьлекнең гомере кыска, һай кыска...

Нәзифә дә, өметен югалта язганда, хыял канатына таяна иде. Ә хәзер шул армас-талмас канатларны җуеп, бары өмет кенә калды. Өмет... Кешене шул яшәтә икән бит! Юк, бүгенгесе ничек кенә авыр тоелмасын, киләчәгендә яктылык булырга тиеш ләбаса. Бәлки әле, Нәсим белән чынлап та бергә булырлар, күзләре дә якты көнне күрер. Ышана алмый аның күңеле тормышның газаптан гына тора алуына. Әнә бит, Нәсим дә җәйге ял вакытында аны тәҗрибәле табибларга күрсәтеп карарга вәгъдә биреп китте. Кем белә, бәхет дигән нәрсәдә, бәлки, аның да өлеше бардыр?!

Шулай дип юатты Нәзифә үзен. Яз сулышын тоеп, йөрәге дә ешрак, өмет белән тибә башлады. Көннәр шулай бер-бер артлы уза торды. Нәсимнән хат килгәндә, кичләр дә көнгә тоташкан кебек була иде.

Ә беркөнне ул күңелендәге хисләрне кәгазьгә төшерергә уйлады. Җан җылысы белән туган хисләр, шигырь юллары булып, дәфтәр битенә күчте:

Күбәләкме гашыйк кеше җаны,
Җирдән ургып чыккан чишмәме?
Давылларны кичәр бер корабмы,
Йолдызмы бер юлсыз кичтәге?!
Бизмән бармы сөю газабына,
Тиңдәш бармы иркә-назына?
Мәхәббәтең җуйсаң, дәва бармы,
Алмаш бармы яшьлек язына?!
Сорау арты сорау туа җанда,
Еллар булып гомер агыла.
Язмышлардай, җаваплар да төрле,
Тормыш юлы шулай языла.

Нәзифә бер мизгел уйланып торды, аннары, кармаланып, ишеккә таба атлады. Тышка чыккач, саф һавадан, башы җиңелчә әйләнеп китте. Нәзифә, коймага тотына-тотына, бакчага юнәлде. Шомырт ботагында булса кирәк, өздереп-өздереп сыерчык

сайрый башлады. Аның тавышына сарай түбәсеннән тамган тамчылар кушылды. Нәзифә, онытылып, күңеле белән гүзәллек дөньясына чумды. Тәненең һәр күзәнәге буйлап җанына талгын бер рәхәтлек, җиңеллек агылды. Чалт аяз күктә апрель кояшы балкый иде.

**9**

Нәсимнең кайтыр көне якынлашкан саен, Нәзифә өчен көтеп алу татлы газапка әйләнде. Сәгатьләрне генә түгел, минутларны да саный иде аның йөрәге. Үзенең кая басканын, нәрсә эшләгәнен дә сизми башлады хәзер Нәзифә. Ә көннәр, үч иткәндәй, айга тиң акрын уза иде. Төшләрендә Нәсимнең имтихан тапшырганын күреп, төннәрен саташып чыга. Имеш, Нәсим имтиханыннан «икеле» алган да, яңадан тапшырырга рөхсәт алып йөри. Андый вакытларда манма тиргә батып уяна иде Нәзифә. Төшен сөйләгәч, әнисе аны: «Бисмилла әйтеп ят, кызым, әбиең өйрәткән догаларны укы. Борчылма, юк-бар төш кенә булган ул», – дип юата иде.

Ә бер төнне Нәзифә гаҗәеп матур төш күрде. Авыл янындагы басу чәчәкләргә күмелгән икән. Чәчәкләр арасыннан тургайлар, күккә күтәрелеп, өздереп-өздереп сайрыйлар. Аларга чикерткәләр хоры кушыла. Чәчәктән чәчәккә очкан күбәләкләр аның ал бизәкле күлмәгенә, чәчләренә куна. Кулларына алыйм дигәндә генә, очып китеп, бер-берсен куыша башлыйлар. Ул да булмый, каяндыр болыт чыгып, җылы яңгыр сибәләп үтте, күк читендә, аллы-гөлле төсләргә манылып, салават күпере чыкты.

Төше шул урында өзелеп, Нәзифә уянып китте. Елмаеп, күзләрен йомды. Әмма инде күздән йокы качкан иде. Күпме теләсәң дә, татлы төшләрнең дәвамы булмый шул.

Нәзифә, акрын гына торып, түр якка чыкты. Әнисе белән әбисе әле уянмаган иде. Аяк очларына гына басып, ул саклык белән генә ишек янына килде. Элгечтән шәльяулык алып, иңенә салды да бакчага чыкты. Дымлы салкынча һавадан, үләннәргә сарылган чык тамчыларыннан өшетеп җибәрсә дә, өйгә керергә ашыкмады.

Якында гына әтәч кычкырды. Димәк, таң атып килә. Бәлки, бүген Нәсим кайтыр. Сөйләшә алдымы икән ул минем хакта, әллә мине өметләндерер өчен генә әйттеме? Юк, юк, Нәсим сүзендә торыр. Насыйп булса, бәлки күзләре дә ачылыр. Дөрес, Нәзифә участок хастаханәсендә дә, район хастаханәсендә дә ятып чыккан иде. Андагы табиблар: «Күз нервларына, челтәр катламга зыян килмәгән. Операция ясау зарурлыгы юк», – дип, республика офтальмология хастаханәсенә юллама бирүне кирәк санамадылар. Ул вакытта район табибларының ваемсызлыгыннан араларлык, югары оешмаларда дөреслек эзләрлек кешесе булмады шул...

Шулай уйга чумып күпме утырган булыр иде, әнисе чыгып дәште. Нәзифә теләр-теләмәс кенә өйгә атлады.

Теләге фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килде, күрәсең, ул көнне Нәсим кайтып керде. Исәнлек-саулык сорашкач, Нәсим:

– Нәгыймә апа, каршы килмәсәгез, мин иртәгә Нәзифәне Казанга алып китәр идем. Ә аннан, юллама алып, Мәскәүгә, – диде.

– Мин каршы түгел түгелен дә, Нәсим улым. Тик көнендә өлгермәсәгез, Мәскәүдә кайда тукталырсыз икән соң?

– Борчылмагыз, Нәгыймә апа, Мәскәүдә эти ягыннан кардәшебез яши. Әгәр Нәзифәне хастаханәгә салсалар, телефоннан булса да хәбәр итәрмен, – диде Нәсим, аны тынычландырырга тырышып һәм Нәзифә белән йөреп керергә рөхсәт сорады.

– Ярый, балалар. Сез кайтканчы, мин Нәзифәгә юл кирәк-яраклары әзерли торырмын, – диде ана, ризалык биреп.

**10**

Нәзифәне Гельмгольц исемендәге институт клиникасына салдылар. Биредә катлаулы медицина җиһазларында җентекле тикшерүләрдән соң, әйтү түгел, хәтта укып чыгуы да авыр булган диагноз куйдылар: «нейроинфекция – арахноидит нәтиҗәсендә килеп чыккан ретробульбар неврит».

– Сеңлем, күрү сәләтен югалтыр алдыннан берәр йогышлы чир белән авырмаган идеңме? – Профессорның Нәзифәгә биргән беренче соравы шул булды.

– Әйе,– дип җавап бирде Нәзифә һәм үзенең грипп белән чирләп китүе, әмма дәресләрне калдырудан куркып, аны аяк өсте уздыруы хакында сөйләде.

– Их, кызым, кызым, – диде профессор, аңа шелтәле һәм бер үк вакытта үз итеп, – сез, яшьләр авыруның нәтиҗәләре хакында уйламыйсыз шул. Йә, ярый, – дип өстәде аннары, Нәзифәне тынычландырырга тырышып. – Әле өмет бар. Әмма савыгу синең үзеңнән дә тора. Икебез дә тырышсак, без авыруны, һичшиксез, җиңәрбез!

Һәм ул Нәзифәгә, үз кызыдай якын итеп, күңелне эретерлек ягымлы бер җылылык белән карады...

Клиникада кызга антибиотик һәм витаминнар белән гомуми дәвалау курсы билгеләделәр. Бер ай үткәч, Нәзифәнең күзләрендәге бәйләвечне салдырып карарга булдылар. Кискен яктылыктан ул күзләрен чытырдатып йомды. Хәлне аңлаган табиб янындагы шәфкать туташына: «Иртәрәк әле», – дип, бәйләвечне яңадан куярга кушты. Нәзифә өчен елларга тиң тоелган тагын бер ай узды. Түземсезләнеп һәм куркып көтте ул бәйләвечне бөтенләйгә алыр көнне. Марляны сүткәндә, тез буыннарына кадәр калтырады. «Курыкма, сеңлем, барысы да әйбәт булыр!» – дип юатты моны тойган шәфкать туташы. Нәзифә әле шуннан соң да чытырдатып йомган күзләрен ачарга кыймый торды. Карт профессор, җилкәсенә йомшак кына кагылып: «Ач күзләреңне, кызым, курыкма, мин синең янда», – дигәч кенә, күзләрен ачарга батырчыл»ык итте. Ап-ак бүлмәдә күрде ул үзен. «Мин төш күрәм ахры»,– дип пышылдады аның хәлсез иреннәре. «Юк, кызым, өндә бу, өндә. – Әлеге сүзләрне әйткәндә күпне күргән профессорның күзләрендә дә мөлдерәмә яшь иде. – Димәк, син күрәсең, күрәсең!» – дип өстәде аннары, Нәзифәне кочагына алып.

Ике айдан соң клиникадан чыкканда, Нәзифә яхшы күрә иде инде.

Нәсим аны беренче каттагы вестибюльдә каршы алды. Өмет һәм ярату күрде Нәзифә аның күз карашында.

– Нәзифәм, бәгърем, – диде ул, кызны кочагына алып. – Хәлең ничек?

– Мин күрәм, Нәсим. Мин кояшны, сине, дөньяны күрәм. Ишетәсеңме, Нәсим?!

– Чынмы, чынмы, кадерлем, чынлап та күрәсеңме?!

Нәсим аны яңадан кочагына алды, энҗедәй яшь бөртекләре җемелдәгән күзләренә карады. Нәзифә, егетнең борчулы карашын тоеп, тынычландырырга ашыкты:

– Шатлыктан ул, Нәсим, шатлыктан. Мин бу көнне озак, бик озак көттем. Төшләремдә дә, караңгы бушлыктан чыгу юлы эзләп, саташып чыга идем. – Нәзифә, бер мизгелгә тын калып, кулъяулык чите белән күз яшьләрен сөртте. – Рәхмәт сиңа, Нәсим. Яратуың, түземлелегең, изге күңеллелегең өчен рәхмәт.

– Ярату өчен рәхмәт әйтәләрмени, кадерлем! – Нәсим кызның күзләренә сөеп карады. – Мин бит сиңа язмышым, бәхетем итеп карыйм. Ә бәхет өчен күп кирәкми. Мин сине теләсә нинди хәлдә дә ташламаган булыр идем, Нәзифәм!

* * *

Тирә-юньне алтынсу-кызгылт яктылыкка манып, таң сызылып килә. Менә кояшның тәүге нурлары бакча түрендәге шомырт агачы очларына төште. Бер мизгелгә генә күзләренә йокы эленгән сандугач, дерт итеп уянып, өздереп сайрый башлады.

– Керик, Нәсим. Әни дә, борчылып, йокыга китә алмый ята торгандыр. – Нәзифә егетнең кочагыннан аз гына тартылып куйды.

– Юк инде, Нәзифәм, мин сине беркая да җибәрмим. Менә хәзер сезгә керәбез дә: «Нәгыймә апа, мин Нәзифәне яратам, ризалыгың бир», – дип әйтәм.

– Юләрем минем.– Нәзифә егетнең күзләренә тутырып карады. – Алай сандугач кебек сабырсыз булма. Иртән килерсең, яме, сөеклем!


Җиңелчә генә җил исеп куйды. Күз яшедәй саф чык тамчылары кунган яфраклар талгын җилдә шыбырдашып куйдылар. Әйтерсең лә, алар да бу яшь насыйпларга бәхет тели иде.



*Шәриф Хөсәенов.*



*Үсмер чагы. Зөһрә апасы*
*һәм Гали абыйсының кызы*
*Фирая белән.*



*Рәсем артында Шәрифнең язуы: «Балаларны һәм барлык җан ияләрен мин бик-бик яраттым. Апаларымның кызлары (Талия, Роза) һәм этебез».*



*Кояш Тимбикова кулында «Совет әдәбияты»ның « Мәхәббәт сагышы» басылган саны. Сулдан: Аяз Гыйләҗев, әсәрнең авторы Шәриф Хөсәенов, Асия Бикҗанова; артта Саимә Ибраһимова.*



*«Яшь язучыларның III Бөтенсоюз киңәшмәсендә катнашучы Татарстан даһилары төркеме. Утырганнар (сулдан): Р.Төхфәтуллин, Г.Бәширов, Х.Госман, Р.Шәйхетдинов; икенче рәттә: Х.Камалов, Ш.Хөсәенов, Ю.Малевинский». Рәсем артына Шәриф әнә шулай язган.*



*Дуслар белән шаярсаң да була. Алда утырганнар: Шәриф Хөсәенов, Аяз Гыйләҗев, артта Илдар Юзеев, уртада Шәүкәт Галиев.*



*Шәриф Хөсәенов. «Әни килде». Инсаф ролендә Ринат Таҗетдинов, Ана – Галимә Ибраһимова. Г.Камал театры. 1970 ел.*

*Фотолар Татарстан китап нәшрияты һәм Рәйсә ЙОСЫПОВА архивларыннан алынды.*

# ИКЕ ӘНИ

ОЧЕРК

## Берсе юкә чәчәге, икенчесе мәтрүшкә...

– Истанбул һавасы дымлы. Син ияләшмәгән... Ыхламур чәе эчеп куй. Эч, эч, җылы чагында.

Әни ясап китергән, өстендә парлары биеп торган чәйнең борыныма килеп бәрелгән хуш исе бик тә таныш тоелды. Ышанмыйча гына:

– Юкә чәчәк аткандагы ис таралды, – дидем.

Яшькелт-алтынсу чәйне кабып куйдым. Юкә бит ул – безнең як агачы! Төркия исә кызыл, сары, шәмәхә, яшел – берсеннән-берсе матуррак төстәге җимешләр, яшелчәләр белән тулган ил!

Әнигә минем чәйне шулай аптырап кына кабып-кабып куюым бик ошап бетмәде, күрәсең. Коры гына:

– Ыхламур ул, ыхламур чәе. Шифалы, суык тимәсен өчен эчәләр, – диде. Тизрәк рәхмәт әйтергә ашыктым, чәй өчен сөенүемне күргәч куанды. Башка бүлмәгә чыгып китте.

Кайнар, әмма искиткеч йомшак тәмле чәйне эчә-эчә «ыхламур»ны сүзлектән карыйм – юкә чәчәге шул!

Төркиягә килгәнче миңа, ни өчендер, төрекләр һәрвакыт, һәркайда каһвә генә эчеп йөриләрдер кебек иде. Төрек каһвәсе бөтен дөньяга танылган, мактаулы бренд булганга күрәдер, күңелдә сиздермәстән шундый бер ышану барлыкка килгән. Чыннан да, Төркиядә кая барсаң да, бармак очы кадәр кечкенә филҗанга ясалган һәм бер бокал гадәти су белән эчелә торган әче төрек каһвәсен еш тәкъдим итәләр. Әмма бу ил миңа әнинең юкә чәе белән бергә бөтенләй башка яктан ачылды. Шулай бит ул: тормышны бер төрле күзаллыйсың, хыялланасың, әллә ниләр булырдай итеп көтәсең, ә ул сиңа шундый таныш бер тарафыннан моңа кадәр ни өчендер һич абайланмаган яңа бер капкасын киереп ачып куя.

Юкә чәчәген маркетларында ничек кенә тәкъдим итмиләр! Чәй кебек ваклап тутырылган каплысы да, кечкенә пакетларга салынганнары да бар. Базарларда исә киптерелгән чәчәкләре йөзем, груша, помидор, кыяр белән беррәттән тау-тау өелеп тора.

Аһ, юкә чәенең хуш исе! Аһ, татлы тәме! Тын юлын иркәли, күзәнәкләрне тынычландырып, язып җибәрә. Хәтта баштагы тәртипсез, чуалып бетеп ялыккач, күңелне йолыккалый башлаган килде-китте фикерләргә кадәр үз урыннарын табып йоклап китә төсле.

Чәйне, тиз бетүеннән курыккандай, аз-азлап кына йотам, үзебезнең якларның яшел болыннарында үскән эреле-ваклы кыр чәчәкләре исләрен сеңдергән бал тәмен тоеп ләззәтләнәм. Юкә балы тәме... Шунда бер мизгелгә әллә ничә мең чакрым ераклыкта яшәүче үз әниемнең көрән мәтрүшкә салып ясалган чәен бал белән эчкәндәге халәтемә күчкәндәй булам.

И әни, ерак юлга җыенган кызыңның күзләренә карап, фал ачкандай әйткәнсең бит:

– Бианай белән үз әниең арасында аерма ярма бөртеге кадәр генә!

...Берсе Вәсилә, икенчесе Әминә. Икесе дә бер чор балалары, яшь аермасы санаулы

гына. Әни – 1943, бианай – 1941 елгы. Икесенә дә татарның бик матур әйтеме туры килә: «кечкенә дә төш кенә». Нәкъ шулай, әллә ни озын буйлы түгелләр, җыйнак кына гәүдәле, җитез куллылар, үзләре йөгерек фикерле, кайчак кырыс, кайчак тапкыр сүзле.

Икесе дә сабый чакта ук, берсе әтисез, икенчесе әнисез калып, ятимлекнең, үксезлекнең ачысын-төчесен җитәрлек татыганнар.

Икесе дә – дүрт бала анасы һәм гомерләренең күп өлешендә шул балаларын ялгызлары гына аякка бастырганнар.

Икесе дә – татар авылында туып-үскән татар кызлары. Берсе Актаныш районындагы Усыдан, икенчесе Чифтәләр районына караган Корыһөектән. Икесе дә – бер тарих кыйпылчыгы. Авыллары төрле районнарда гына түгел, хәтта диңгезләр, таулар аерып торган төрле илләрдә урнашкан. Әмма ата-бабалары бер туфрактан – Татарстаннан.

...Җылы чәйдән тәнем эреп, шактый онытылып утырганмын. Әле генә хуш исле парлары биеп торган йомрым бушап калган, кәгазьгә исә бары бер җөмлә сыенган: «Берсе мәтрүшкә, икенчесе юкә чәчәге...»

Әлеге юкә чәчәге чәе белән танышкан көздән соң, бер еллап вакыт узгач, каенанам рәхмәтле булды. Төркиядә мәрхүмнәр хакында шулай әйтәләр. Рәхмәтле булды. Ягъни Аллаһның рәхмәтенә иреште. Амин. Әни рухына багышлап, догалар укытканнан соң берничә ай үтте. Минем исә теге чактагы «Берсе мәтрүшкә, икенчесе юкә чәчәге...» дип башланган, тәмамланып бетмәгән җөмләм сабыр гына дәвамын көтте. Һәм кипкән юкә чәчәкләре күпләп-күпләп кибетләргә чыга башлаган быелгы көз башы аны янә хәтерләтте.

...Берсе – мәтрүшкә, икенчесе – юкә чәчәге. Берсе – җир, икенчесе – агач чәчәге. Төрле җирләрдә туып-үскән, гомер иткән әниләрне гомер-гомергә өй чоланында, чормаларда киптереп саклаган, җанга-тәнгә сихәт, көч бирүче, күңел керләрен эретә торган менә шул шифалы чәчәкләргә охшаттым. Безнең халык көрән мәтрүшкәне җитмеш төрле авырудан дәва дип саный. Юкәне зурлап «Юкәнең чәчәге – бал, кабыгы – юкә, агачы – сөян», дигән. Икесеннән дә әллә никадәр файда күргән, икесен дә кадерләгән.

Ә әниләрем...

Алга таба Татарстанның Актаныш районында урнашкан Усы авылында дүртенче бала булып дөньяга килгән Вәсилә Талипова һәм Төркиянең Чифтәләр районында татарлар нигез салган Корыһөек авылында туган, бер тараф бабалары Лениногорск районы Сарабиккол (Әби) авылыннан, икенче тарафы – Башкортстан якларына күченгән татарлардан чыккан Әминә Акчура хакындагы сүземне, ике татар хатынын чагыштырып та, охшатып та дәвам итәсем килми. Бәлки, минем белән уртаклашкан фикерләрен, хатирәләрен аларның җаннарыннан, калебләреннән чыккан мәгънә эчендә җиткерә алсам, татар әниләренә хас нурлылыкның, җылылыкның, шифалыкның, зиһеннең, куәтнең меңнән бер өлешен генә булса да күрсәтә алырмын.

## Туган җир туфрагы саклар

Татарстанда яшәүчеләр өчен таныш хатирәләрдән башлыйм. Үз әнием – сугыш елларында туган бала. Сугыш чоры балалары сугышның үзен күрмәсәләр дә, бу афәт ботарлап-актарып ташлаган илдәге һәр авырлыкны, һәр михнәтне кечкенә, нәзек җилкәләрендә күтәргәннәр. Ул вакытларны искә алып, әни болай сөйли: «1943 елның җәендә дөньяга килгәнмен. Көннәре кояшлы, әмма йөзләрдә елмаю юк. Авылда – ачлык. Илдә сугыш барган авыр еллар. 1944 елны 4 сабыен ачлык тырнагында калдырып, авыру анама кайгы-хәсрәт өстәп, шыткан бодай ашаган әтием вафат булган. Үстерелгән икмәк кырып-себереп фронтка озатылган ул чакта. Барысы да – җиңү өчен! Әзмәвердәй ир-егетләр һәммәсе фронтта. Сабанга – сыер, алар янәшәсенә хатын-кыз үзе җигелгән. Безнең әниләр, Бәдәр, Әдия, Фәрхенур, Мөхәтдимә, Мәгъфурә күршеләребез... Әле дә табигать мәрхәмәтле. Яз җитсә, кукы, кузгалак, кычыткан, балтырган, кәҗә сакалы җитешә. Бакчаларда көздән балчык астына яшеренеп калган өшегән бәрәңгеләр табыла. Алары өчен беркем ачуланмый. Соңрак җиләк өлгерә. Әле дә хәтердә... Сугыш беткәнгә 5-6 ел узгандыр. Сугыштан соң да әле авыллар тиз генә мантый алмады. Чөнки аннан бөтен нәрсә сыгылып алынып беткән, хәерчелектә калган,

4 ел эчендә туздырыласы туздырылган иде. Өй рәтеннән берәр сынык ипи бирмәсләрме дип, кемнең генә капкасын ачмый идем. Икенче классларда авылдашларыма хат язарга өйрәндем. Ачлык, суык йөрәкләргә төште. Өй салкын булганлыктан тәрәзәгә боз ката. Кисәү агачын кыздырып, шуның белән аны эретеп тышны карый идек. Сигез чакрым ераклыктагы Киров авылындагы мәктәпкә укырга барганда, аяк катып, кирза итеккә ябыша... Әнинең безне – дүрт баласының тамагын ничек туйдырыйм, өйне ничек җылытыйм дип, бәгырьләре телгәләнә иде. Бервакыт аның күзләре күрми башлады. Без аны җитәкләп йөри башладык. Күршебез, авыл советы рәисе Нургали абый Усыда санитарка хезмәтен башкаручы Нурлыгайшә апаны чакырып алды да әнине Суксу больницасына алып барырга кушты. Бер айдан әни якты дөньяны кабат күрү бәхетенә иреште. Бала чакларны искә алганда, тамакка төер утыра. Ләкин ул вакытларда никадәр генә авыр булмасын, эшкә иренү, сайланып тору, яисә низаглашу юк иде. Үзем туыпүскән Усы авылында халык бер гаилә кешеләре кебек тату яшәделәр, эшләделәр, авырлыкларны бергә күтәрделәр... Әйтик, кул белән арыш урының көнлек нормасы 18 сутый булса, аны 30 – 35 сутыйга җиткерделәр. Басу уртасында бала тапкан аналарның да хезмәт өлешләре ул... Хезмәт көнен тутыру мәҗбүри. Үзебезнең бакчага утыртылган бәрәңгене алырга да мөмкинлек юк. Карлы-яңгырлы вакыт җиткәч, әнием бакчага чыкты. Көрәккә тотынуы булды, бригадир ажгырып килеп җитте, сүгенә-сүгенә әнинең көрәген бер якка, чиләкләрен икенче якка ыргытып та бәрде. Әни ник бер сүз әйтсен, тагын өйдән чыгып китте. Ачы көз. Тышта караңгы, салкын яңгыр ява. Ә тәрәзәне һәр көн килеп кагалар. «Бурычыгызны түләргә килегез», «кәнсәгә дәштеләр», «авыл советы чакыра»... 56 нчы ел истә калган. Җәйге каникул чорында бозаулар карый идем. Сабантуй көннәре, һич онытасым юк. Бозаулар бик йончу. Кыш көне үпкәләренә суык тигәннәре мантып китә алмады. Ай, авыр булды бозаулар үлгәнне күрү. Ул вакытта үлгән малны күрше Киров авылына алып барып, мал табибына күрсәтергә кирәк иде. Сабантуй көнне бер бозавым үлгәч, аны тартмага салып, Кировка киттем. Кая ул бәйрәм шатлыгы! Урамда очраган бер кеше: «Үскәнем, кая барасың? Тартмада нәрсә бар, әллә берәр әйбер сатасыңмы?» – дип гаҗәпләнеп калды. Ә минем башта йөз төрле уй. Әле табибка җавап бирәсе бар. Мин бу очракта укучы бала түгел, бозау үтерүче бит. Табибка күрсәткәч, үләт базына илтеп ташлагач, калган малларны көтүдә йөрткәч, караңгы төшкәндә генә, өйгә кайтып егылдым...»



*Вәсилә Талипова*

Шуны да әйтергә кирәк: бик күп совет кешеләренеке кебек, әнинең дә тормышында җылы якларга китеп яшәгән еллар бар. Алар бик озынга сузылмаган. Шулай да бу хакта ул бераз сагынып та, бераз үртәлеп тә искә төшерә. Җылы якларга, чит-ят җирләргә чыгып китүнең төп сәбәбе шул: ул килен булып төшкән авылны «бетәчәк» диләр, чөнки алгарышка сәләтле түгел икән, 70 нче елларда «перспективасыз» дип табылган татар авыллары шактый була. Бу исә яшь гаиләләргә анда эшләргә, яшәргә ирек бирмәү, өй салырга рөхсәт итмәү дигән сүз. Әни ул еллар турында сөйләгәндә, иң башта юлга әзерләнгәнен һәм беренче дәресен искә төшерә: «Әбиең эндәшминитми генә йөрде. Аннары: «Кызым, юлга мәтрүшкә, кечкенә генә булса да, каен пиннеге һәм ширпы кабына салып, авыл туфрагын ал. Алар бәла-казалардан саклар, ялгыз калганда, күңелеңне юатыр, авырлыклар килгәндә җиңәргә көч бирер», – дип, үзе хәстәрләп, сумкага ук салып куйды. Татар көйләре язылган пластинка да тыктым шунда... Аны беренче дәрестә үк файдаландым. Укучыларым татар җырларын тын да алмыйча тыңладылар. Ә татар кызлары Роза, Римманың күңелләре тулды хәтта. Җыр бетүгә балалар бер-бер артлы сораулар яудырырга керештеләр. «Туган тел» белән башланган тәрбия сәгате мине укучыларыма якынайтты, арага җылылык иңдерде. Тора-бара ата-аналар, хезмәттәшләр «Мөгаллимә җан» дигән исем таптылар миңа».

Әни миңа җылы якларның истәлеге дип, шактый зур керәч чәйнеген бүләк итте.

Әлеге 50 яшьлек чәйнек эчендә Төркмәнстанның Теджен районы Башкарма комитеты 1970 елда СССР Югары советы исеменнән тапшырган «В.И. Ленинның 100 еллыгы» медале саклана. Әнинең әлеге медальне тагып йөргуен хәтерләмим дә. Әмма гомер буена чит җирдә кыска гына вакытта күрсәткән хезмәтен зурлаулары аның өчен зур горурлык булды.

Әни башта туган авылыннан Кировка йөреп, аннары Пучы авылында интернатта яшәп белем ала. Мәктәпне тәмамлагач, Алабуга институтында әүвәл читтән, соңгы курсларны торып укый, укытучы һөнәрен үзләштерә. Читтән кайткач төпләнеп калган Усы авылының күршесе Качкында яши. Байтак вакыт төрле авыл мәктәпләрендә укыткач, дистә елдан артык биш авылны: Усы, Качкын, Айман, Колын, Чиялекне берләштергән Айман авыл советында эшләде.



*Әминә Акчура*

...Бервакыт авылда чәй эчеп утырганда әни берничә мәртәбә Казаннан бүләк итеп алып кайткан күлмәкне карап килде. Сизелеп тора, сөенече эченә сыймый. Аннары миңа чәй ясагач, җай гына күңелендәгесен әйтеп бирде:

– Кызым, мин, бәләкәй чагында матур күлмәкләрем күп булсын иде дип, бик тели идем. Ә бер күлмәгем хәзер дә күз алдымда. Без 4 класстан Киров мәктәбенә йөреп укыдык. Берничә көн калгач, әнкәй белән бакчада кул белән казып, яшь бәрәңге алдык, берничә кабак салдык, бәләкәй арба белән Киров совхозына шуларны сатарга киттек. Юлыбыз уңды, «казанскийлар» бәрәңгене тиз алдылар. Акча булгач, кызыл бөрчекле ситсы сатып алдык, мәктәпкә барырга яңа күлмәк кирәк бит. Аны күршебез Фәрхенурттәй тегеп тә бирде. Иртәгә уку диясе көнне Мария Павлова дигән укытучы Кировтан килеп, укучыларны барлап чыкты. Ул безгә дә керде. Формаң бармы дигән сорауга, мин кызыл бөрчекле күлмәгемне сөенә-сөенә алып килеп күрсәттем. Ул матур итеп елмайды да чыгып китте. Күлмәкне тузганчы кидем. Ә хәзер... Ходаем, нинди генә күлмәкләрем юк!

Мин көлеп бүлдердем:

– И-и-и, әни, теләгең бигрәк зур булган икән!

– Ялангачлык җанга үткән. Менә хәзер вакытның ничек тиз узганын да сизми калабыз бит, кызым, чөнки, бердән, ач утырмыйбыз, икенчедән, өс-баш бөтен. Әгәр ипи булмаса, көнебез үтмәс иде, салкында катып утырсак, кыш үтеп китмәс төсле иде...

– Чын! Безгә вакыт җитми! Ни юк, шуны телисең инде, әйеме, әни?

– Шулайрак булып чыга икән... Икенче – өченче теләгем үсә төшкәч барлыкка килде: кияүгә этиле кешегә чыксам иде, дип теләдем. Һәм килен булып төшкән авыл урман буенда урнашкан булсын иде, дидем. Үзебезнең этисез үсү, аннары 8-10 чакрым ераклыктагы Киров урманыннан әниемнең аркасында утын ташулары – барсы да үзәккә үтеп калган. Бар теләкләрем тормышка ашты.

– И әни, теләкләр белән бергә бәхет тә җитәкләшеп йөрсә икән...

– Иң мөһиме, кызым, сабыр булып, башкаларга яхшылык теләп, тормыш матурлыгын күреп яшәү. Менә шул бер мөрәвәт, менә шул зур бәхет, кызым.

...Әнинең әлеге сүзләре күңелемә уелып калды. Еш кына вакыт тиз үткәнгә генә түгел, хәтта вакытның үзенә, ягъни заманасына зарлану теләге тел очында кала бирә, әниләр кичергән тормыш михнәте хәтергә килеп, сабак бирә.

## Сыла-и рәхим – иман билгесе

Инде һәм вакыт, һәм чакрымнар белән караганда, күпкә ераграк хатирәләргә күчәм. Бианай Әминәнең әнисе ягыннан нәсел тарихын кыска-кыска гына хронологик рәвештә бирсәм, яхшырак аңлашылыр кебек.

1750 нче еллар... Казан тирәсендә яшәгән һәм Казан ханлыгы яулап алынганнан

соң башланган изүләрдән иза чиккән һәм яңа җирләрдә иркен яшәргә өмет баглаган 200 гаиләлек зур бер төркем Казан сәүдәгәре Сәед Хаяли тарафыннан оештырылган күченү сәфәренә кузгала. Оренбург тарафына юл тоткан татарлар арасында Әхмәт бабай гаиләсе дә була. Нәкъ менә шушы татарлар – мәдрәсә-мәктәпләре, мәчетләре һәм сәүдәгәрлек белән дан казаначак Сакмар елгасы буендагы Каргалы авылына нигез салучылар. Әхмәтнең нәсел дәвамчысы  – Шахиның бу авылда 1831 елда туганы билгеле.

1863 нче еллар... Каргалыда халык саны елдан-ел арта. Күпләр биредән күченеп китә, башка татар авылларына нигез сала. Шахи да гаиләсе белән яңарак кына барлыкка килгән Акманга барып урнаша. Яңа авылда яңа мәчет калка. Аның хакында халык теленә шундый сүзләр кереп кала: «Шахи мулланың ярдәме белән корылган мәчет». Шахи мулланың 5 ир, 3 кыз баласы туа.

1890 нчы еллар... Рус патшасының «мөселманнар теләгән өлкәгә күченә алырлар» дигән бер бик кыска вакытлы фәрманын Шахи мулла отып ала. Нәселләре 30 ел гомер кичергән Акманнан Госманлы иленә мөһаҗирлеккә китәргә карар итә, паспорт юнәтә... Болар барысы да тиз-тиз эшләнә, югыйсә җитешми калулары бар бит. Ләкин ике кызы гаиләле булу сәбәпле, китә алмый, зар елап кала. Барысы 9 кеше җәннәттәге кебек матур якларны һич билгесез мөһаҗирлек юлына алыштыра, гомерлеккә туган-үскән газиз җирләреннән аерыла. Акманнан киткәч, мең төрле газап белән Севастополь шәһәренә килеп җитәләр. Истанбулга китәргә 6 ай көймә көтәләр. Инде кулларында ни бар – шуны берәм-берәм сатып, көнне көнгә ялгыйлар. Оренбург тирәсеннән кузгалган башка татар мөһаҗирләрен очратып, барлыгы 20 гаилә булалар.

Алга таба әлеге күчмәннәр турында шунысы мәгълүм: алар Истанбулга килгәч, Төркиянең туган җирләренә охшаш урыннарын эзлиләр. Күңелләрендә исә уртак хәвефле уй-теләк: «Балаларны йортсыз, җирсез, туфраксыз калдырмыйк...» Диннәрен, гореф-гадәтләрен, нәселләрен саклау ниятеннән зур шәһәрләрдә калудан баш тартып, тигезлектә авыл коруны хуп күрәләр. Шактый ара узып, Истанбулдан 300 чакрым ераклыктагы Искешәһәрне үтеп, тигезлеккә килеп урнашкач, тезләнеп, учларына туфрак алган мәлдә, иреннәре җирсү хисеннән тетрәнеп пышылдый: «Бодай туфрагы, авыл туфрагы...» Шунда үзләре белән алып килгән туган як истәлекләре, чигүле, тукылган урын-җир җәймәләреннән, юрганнардан чатырлар корып урнашалар. Ә якын бер җирдә кое табылганын ишеткәч, шул кое тирәсенә күченәләр. Аркан белән үлчәп авыл урамнарын, һәркемгә йорт-куралты җирен, мәчет, мәктәп урынынын бүлеп чыгалар. Менә кайда алар балаларына, туачак оныкларына яңа нигез тергезәчәкләр!

Бераз соңрак һәр гаилә җиренә «нигез» салына: ирләр дүртпочмаклы чокырлар казыйлар, бу арада хатыннар күлмәк итәкләре белән таш ташып торалар. Аннары ирләр ул ташлардан ярты метр чамасы биеклектә итеп дивар үрәләр. Шул чокырларның бер ягына агач тезәләр, икенче ягы ачык калдыралар. Менә өйләре шул! Ниһаять! Таш ташып арган хатыннар тузанлы күлмәкләрен, яулыкларын каккалап, «өйле» булу куанычларын яшерә алмый торалар. Шунда гына юл газабы – гүр газабыннан тәмам арган җаннар җиңел сулыш алгандай була. Һәртөрле кыенлыкларга теш кысып түзә-түзә өзгәләнгән бәгырьләре ул көнне куанган кадәр тагын бер тапкыр куандылармы икән?!

Менә шулай итеп, 1895 елда бер төркем татар мөһаҗирләре, туган җирләрендәге авыл төзү тәртибен саклап, Корыһөеккә нигез салалар. Авыл үзәгендә татар мәчете урнашкан, урамнары төз, өйләр бер рәткә тезелгән.

Әминәнең икенче тарафы – әти ягына күчик.

1905 ел. Татарстанның Лениногорск районы Сарабиккол (Әби) авылында Ариф һәм Хәнифәнең малайлары туа, аңар Хәниф исеме кушалар. Әни сөйләгәннәр буенча Ариф бабасы гаиләсе белән мөһаҗирлек юлына 1910 елларда чыга. 18 нче гасыр башында ук барлыкка килгән борынгы Әби авылыннан татарларның китү сәбәбе башкаларныкына аваздаш – җирсезлек, ярлылык, күтәрә алмаслык салымнар, инкыйлаб якынлашу...

Ариф гаиләсе бер төркем юлдашлары белән Төркиянең Юзгатлы шәһәренә урнаша. 1914 елларда әрмәннәр бу шәһәр тирәсендә яшәгән төрекләрне кысрыклый, басым

ясый башлыйлар. Шул сәбәпле татарлар да Әфьюн шәһәре янындагы Болвадин районындагы татарлар янына юл тота. Бу вакытта Ариф бабайның Корыһөектә яшәгән кардәшләре аларны үзләре янына чакырып хат язалар. Шуны да әйтик: Юзгатлы шәһәре янындагы Чампынар (Чураклы) авылыннан киткәндә, Ариф берникадәр җирләрен сата, берникадәрен мәчет карамагына калдыра. Мәчет мәхәлләсе күп еллар дәвамында шул җирләрдән файда күреп яши. Ариф бабай Балвадинда вафат булгач, балалары Корыһөеккә килеп урнаша.

1930 нчы еллар. Ариф бабай улы Хәниф һәм Шахи мулла улы Җиһаншаның кызы Өммегөлсем авылда гаилә кора.

1951 нче ел. Өммегөлсем 42 яшендә дөнья куя. 5 баласы ятим кала, дүртенчесе Әминәгә ул вакытта 10-11 яшьләр тирәсе була.

Бианай бу вакытларда ятимлек ачысын, юклыкны күп күрә. Ул чакта Төркия татарлары да, нәкъ бездәге кебек көн-төн басуда иген игеп, терлек асрап, тормышларын алып барырга тырыша. Әни авыл егетенә кияүгә чыга, яшь гаилә эш эзләп, Истанбул тарафларына юл тота. Шунда ире белән бергә татар җәмгыяте эшләрендә катнаша. Көн-төн тегү белән шөгыльләнгән, азмы-күпме шулай акча юнәтергә тырышкан Әминә оста тегүче булып таныла. Ул төрек ханымнарына гына түгел, татар яшьләренә дә төрле мәдәни чараларда татар халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятен күрсәтү өчен сәхнә костюмнарын тегә, чигә...

Бүгенге көннәр. Төгәлрәге 2011 ел, 16 июль.

Тау итәгенә ышыкланып димме, әллә бераз качыпмы урнашкан Сарабиккол авылы урамында ник бер адәм йөрсен! Беркем күренми, кызыл, ак кирпечтән салынган өйләр тезелеп киткән урамнары буп-буш. Әйтерсең, авыл шулай, меңәр чакрымнар узып, буыннар алыштырып кайткан кунакларын күргән дә телен йотып, гаҗәпкә калган. Ә кунаклар дигәнем, бабалары җиренә аяк баскан Әминә улы белән һәм аларның юлдашлары.

Әни бу сәфәр иртәсендә йокыдан төшендә әтисен күреп уяна. Шатлыклы, күтәренке рухта күрә ул аны. Кызына «сыла-и рәхим», ягъни, туганлык, кардәшлек җепләрен өзмәгән, бабалары җирен зиярәт кылган өчен рәхмәтле булуын, сөенечен белдерә. Динебезнең иң мөһим бер нәсихәте, иман билгесе бит ул сыла-и рәхим: «Туганлык җепләрен өзмәгез, шул вакытта тормышыгыз бәрәкәтле, гомерегез озын булыр!»

Кунаклар авыл мәчетендә беркемне очрата алмый, кемнең капкасын ачарга, кемнең ишеген шакырга белми торганда, сөбханалла, урамга җан биреп, кап-кара ат җиккән 10-12 яшьлек малай узып бара! Арбасына яңа гына чабылган яшел сусыл печән түшәгән. Кечкенә куллары дилбегәне кысып тоткан. Кунаклар, ниһаять, сәлам бирер кеше очратканнарына куанып, кепкасын кашларына кадәр батырып кисә дә, якты йөзе әллә каян балкып торган сары малайга күңелләренә җыелган сорауларны тезәләр:

– Сәлам! Исемең ничек? Ни хәлләрең бар? Әти-әниеңнәр ни хәлдә? Ничек яшисез?

Авыл малае атын беразга туктатып, бөтен сорауга: «Әйбәт!» – дип, җавап бирә дә үз юлы белән китеп тә бара. Аннары инде кунаклар авыл урамнарын карагач, фотоларга төшкәч, иске зиратка юл тоталар. Шушында җирләнгәннәр арасында безнең дә туганнарыбыз, кардәшләребез бардыр дигән уйга килеп, мәрхүмнәр рухына «Ясин» укып, янә бабалары җиреннән аерылалар...

Беренче һәм соңгы мәртәбә Татарстанга кайткан әнинең сәфәре, әлбәттә, авыл белән генә чикләнми. Мәшһүр тарихи Болгар җирләренә аяк басалар, меңәрләгән халыкны җыйган Болгар җыенын күреп гаҗәпкә калалар. Мәшһүр Казаныбызның иң күркәм урыннарын карап соклananалар, чит илләрдә яшәүче татарлар да яхшы белгән бөек шагыйребез Тукайның туган яклары Арчага һәм дин әһелләре белән очрашырга Нурлатка, башка районнарга баралар.

Соңгы елларда кемгәдер авырлык, мәшәкать китерүдән уттан курыккандай курыккан хаҗия әни еш кына бер теләген кабатлады: «Йа Раббым, догамны кабул ит: өч көн ятак, дүртенче көн туфрак булыйм». Ходай аның догасын кабул итте, майда ураза тотты, соңгы көннәренә кадәр намазын укыды, аннары өч көн хастаханәдә

атты да мәңгелеккә күзләрен йомды. Белгән кадәре 1750 еллардан башланган һәм 3 гасырга сузылган (!) мөһаҗирлек тарихына ия татар нәселенең бер парчасы булган әни бабалары сөйләгән хатирәләргә үзенең Татарстанга зиярәте вакытында күргәннәрен – Татарстанның яңа заман сулышын да өстәп китте.

***

...Бүген күп гасырларга сузылган гыйбрәтле тарихын саклаган, нык рухлы, алгарышка омтылган, зур мәртәбәгә һәм югары мәдәнияткә ия кадерле, газиз туган җиребез үзенең бер түгәрәк датасын – ТАССР ның 100 еллыгын бәйрәм итәргә җыена.

Бу 100 еллык – төрле илләрдә үскән, тамыр җибәргән, гомер кичергән милләттәшләребез кичергән дәвер ул.

Чөнки Татарстанның, ата-бабаларыбыз җиренең һәр чоры – һәр йөз еллыгы дөнья буйлап сибелгән миллионлаган татар халкының тарихы, үткәне һәм үтә алмаган чакрымнары, хәтта еллары. Бүгенгесе һәм киләчәге. Гадәтләнгән тормышлары, күнгән, иләшкән рәвешләре. Танымаган һәм һич белмәгән дөньялары. Балаларының кендек каны тамган җире. Бабаларыннан кан белән күчкән җирсү хисе. Михнәтләре һәм өметләре. Байлыклары, мираслары һәм югалтулары. Моң, тел, дин берлеген тәшкил иткән рухлары. Бу берлекне җуйган мизгелләре һәм моны геннары аша тоеп яшәгән чаклары...

Бу 100 еллык – минем әниләр кебек йөзләрчә, меңнәрчә әниләр күтәргән дәвер ул. Һәм аның әниләр алдында үз хисабы бар.

Чөнки бу дәверне әниләр «уф Алла арбасы»на җигелеп тартканнар.

Унар бала табып-багып, «Герой ана» исеме белән данлаганнар.

Кара төндә колхоз сарыкларын ашарга килгән ач бүреләрне таяк белән куып йөргәндәй, һәр төрле бәлагә каршы курыкмыйча чыгып саклаганнар. Аннары сугышта югалган балаларын, ирләрен көтеп, сагыш йотып гомер иткәннәр...

Балалар күңеленә мәрхәмәт, гыйлем орлыгы салган мәртәбәле укытучы, тәүлекләр дәвамында авырулар яныннан китмәгән дәрәҗәле табиб яки таңнан торып авыл хуҗалыгына хезмәт иткән мактаулы агроном, сыер савучы, бригадир һәм тагын башка күп, күп төрле һөнәр ияләре буларак, бу дәверне якты киләчәк өчен бөтен көчләрен биреп яшәткәннәр.

Шул ук вакытта төрле сәяси басымнар корбанына әйләнгән әтиләрен сагынып, яшерен генә кан-яшь түккәннәр, мөһаҗирлеккә чыгып китәргә мәҗбүр булган кардәшләрен юксынып яшәгәннәр, кача-поса Аллаһтан ярдәм сорап, намазын укыганнар, догасын кылганнар, дисбесен тартканнар. Бер күрешүгә зар-интизар булган читтәгеләр исә, балаларына, оныкларына нәсел мирасын, рухи көчләрен җирсү, ватанны сөю, кардәшлек хисләренә төреп калдырганнар. Һәр ике тарафта яшәгән әниләрнең калебләреннән саркып чыккан изге теләкләре, Аллаһтан туган җирләрен ярлыкауны, газаплардан, авырлыклардан арындыруны сорап кылган догалары дәверне ачы яраларыннан шифалаган, ә бишек җырлары, моңлы мөнәҗәтләре, үзәк өзгеч бәетләре «биш еллык», «ун еллык» планнарын тормышка ашыру, коммунизм үрләрен яулау белән мавыккан дәвернең хәтерен сихәтләп торган.

Бу 100 еллык – йөз төрле дәва һәм көч-куәт бирүче кипкән мәтрүшкәләр, кипкән юкә чәчәкләре дәвере...

**Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА.**
*Төркия.*

# «СОҢГЫ ТАМЧЫ КАНЫМ ФИДА...»



Һәр милләтнең үсеш дәрәҗәсен билгеләүче үрнәк шәхесләре була. Алар шул милләтнең яшәешенә һәм алга китешенә билгеле бер дәвердә рухи көч-куәт өстәүчеләр, аны әйдәп баручылар. Россиянең танылган сәнәгатькәрләре Шакир белән Закир Рәмиев тә татар зыялыларының шушы иң югары катламына керә. Рәмиевләр – элекке Оренбург губернасының күп кенә авылларында мәчетләр төзеткән, мәктәп-мәдрәсәләр ачкан һәм тоткан шәхесләр. Оренбургтагы атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсенең тышкы идарәчеләре – иганәче һәм юнәлеш бирүчеләре дә.

Шәҗәрәләре Казан ханлыгы чорына барып тоташкан морза Рәмиевләр элекке Оренбург губернасына караган Җиргән авылында туганнар. Бу авыл хәзер Башкортстанга керә. Авыл Уфа белән Оренбург шәһәрләре аралыгында, Агыйдел елгасы буенда урнашкан. Әниләре Хәнифә Дашкова да борынгы морзалар нәселеннән. Күпчелек морзалар гаиләсенә хас рәвешле, Хәнифә бик укымышлы, тәрбияле кыз була. Дәрдемәнднең замандашлары: «Хәнифә бикә балаларына яхшы белем бирә. Шәрык вә көнбатыш әдәбияты үрнәкләре белән дә әүвәл үзе таныштыра», дип язалар.

Әтиләре сәүдәгәр Садыйк Рәмиев бик тынгысыз җан була. Урал суы буендагы Оренбург, Орск шәһәрләрендә узучы ярминкәләрдә катнаша. Җиргәннән өч йөз чакрым ераклыктагы Юлык базарына да барып чыккалый. Аларга Урта Азиядән затлы тукыма, чәй ише әйберләр килә торган була. Һәм 1862 елда ул Орск өязенә кергән, Сакмар елгасы буенда урнашкан Юлык авылында төпләнергә ниятли. Бу өязгә кергән авыллар тирәсендәге тау-ташлы җирләр алтынга бай. Садыйк Рәми дә озакламыйча бер алтын приискасын (шахтасын) сатып ала. Шул көннән башлап, Рәмиевләр нәселе алтын чыгаручы сәнәгатькәрләр исемлегенә кертелә. Үз гомерендә ул егермеләп алтын чыганагын ача. 1892 елда вафат була. Бай мирасын ул ике улына – Шакир (1857-1912) белән Закирга (1859-1921) калдыра.

Закир Рәмиевнең кулына каләм алып, иҗат итә башлавы Төркиядә яшәү елларына (1880-1881) туры килә. Шул ук елларда ул «Дәрдемәнд тәхәллүсен ала», дип фаразлый галимнәр. Әйе, Орск шәһәрендәге мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, ул Истанбулга килә. «Төрек телен үзләштерә, төрек әдипләре белән таныша, ирекле рәвештә Истанбул университетындагы дәресләргә йөри», дип искә алалар соңрак аның даирәсенә кергән шәхесләр. Орскига, Шакир агасына ул Төркиядә нәшер ителгән газета-журналларны, китапларны даими рәвештә җибәреп тора. Агасы исә аңа басмаханәләр эшчәнлеге белән танышу, кулланыштагы басма хәрефләрнең хакы белән кызыксыну кебек киңәшләрен дә яза.

Дәрдемәнднең Төркиядә вакытта тәрҗемә иткән һәм язган кечерәк күләмле проза әсәрләре һәм шигырьләре үз илендә чирек гасырдан соң гына басылып чыга. 1905 елгы халык күтәрелешеннән соң татар телендә дә газета һәм журналлар нәшер ителә башлый. Бертуган Рәмиевләр дә 1906 ел башыннан «Вакыт» газетасын һәм 1908 елдан «Шура» журналын чыгаруга рөхсәт алалар. Дәрдемәнднең Төркиядә вакытта иҗат ителгән тәүге хезмәтләренең бер өлеше әүвәл шул журнал битләрендә дөнья күрә. Ә 1908 ел ахырында үз басмаханәләрен ачкач, 1910 елда Дәрдемәнднең бердәнбер китабы – «Балалар өчен вак хикәяләр»е басылып чыга. Оренбург янәшәсендәге Каргалы авылында яшәгән күренекле шагыйрь һәм дин әһеле Һибәтулла Салиховка

багышланган хат рәвешендә язылган шигырен – «Каргалының Сибгатулла хаҗига мәктүб»не дә Дәрдемәнд Истанбулда иҗат итә башлый. Автор шигырьнең «госманлы ләһҗәсендә» (төрекчәгә тартым шивәдә) язылуын да теркәп куя. Кулъязмада исә әсәрнең тәмамлану вакыты дип 1884 ел күрсәтелгән. Ул күләмле әсәр «Шура» журналының иң беренче санында һәм шагыйрьнең Совет хакимияте елларында нәшер ителгән «Дәрдемәнд әсәрләре» (1929) китабында урын алган.

Истанбулда яшәгәндә, Дәрдемәнд чәчмә әсәрләр дә тәрҗемә иткән, дидек. Аларның бер өлеше соңрак балаларга атап чыгарылган китабына кергән, әмма «Шура» журналының 1909 елгы өч санында урын алган «Абакамның көтепханәсе» хезмәте әлегә кабат басылмаган.

Әдәбият фәнендә «Дәрдемәнднең тәүге шигырьләре 1902 – 1903 елларда Кырымда чыгучы «Тәрҗеман» газетасында күренә башлыйлар», дип әйтелә. Ризаэддин Фәхреддиннең 1903 елда нәшер ителгән «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә, авторы күрсәтелмичә, Дәрдемәнднең «Үткән көннәр» шигыре басылып чыга. 1906 елдан соң шагыйрьнең иҗат үрнәкләре яңа гына чыга башлаган «Казан мөхбире», «Вакыт» газеталарында да әледән-әле күренгәли. «Дәрдемәнд» тәхәллүсе белән кемнең иҗат иткәнлеге ачык билгеле булмаган көннәрдән үк аның шигырьләре укучы күңелен җәлеп итә, телгә керә. Мисал итеп, шул чорның яшь әдәбият галиме Габдрахман Сәгъдинең «Шура»да (1911) басылган «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» хезмәтен искә төшерик. Шагыйрьнең үзенчәлекле иҗатына уңай бәя биргәннән соң ул: «Дәрдемәнднең кем булуы безгә мәгълүм түгел», дип тә өстәп куйган. Яңарак кына Төркиядән кайткан, чит-ят җирләрдә укытып йөргән Г.Сәгъди түгел, Оренбург, Казан, Уфаларда яшәүче иҗат кешеләренең дә күпчелеге байтак вакыт Дәрдемәнд тәхәллүсе белән язучының кем булуын белмәгәннәр. Ә шагыйрьнең хикмәтле сүз-әйтемгә, сәнгати төгәл сурәтләүгә бай шигырьләре белән кызыксыну көннән-көн арта барган. Мәгәр, шигырь җыентыкларын кат-кат нәшер итү мөмкинлекләренә ия кеше булса да, үзе исән вакытта Дәрдемәнд аларны бер китапка туплап чыгармаган. Көндәлек матбугат сәхифәләрендә күренеп алулары белән канәгатьләнгән.

Дәрдемәнд иҗатында тормышка милләт язмышы аша караш – төп сыйфатларның берсе. Аның күпчелек шигырьләре берничә строфадан гына тора. Ләкин шул уналты-егерме юллык әсәрдә кешегә ил, ватан, милләт язмышын күз алдына китереп бастыру хас. Милләте турында уйлануларын ачык итеп әйтмәгән хәлдә дә аның әсәрләрен укыганның соңында күңелдә шул хис яңара. Ирексездән милләтеңнең үткәне һәм киләчәге турында уйлана башлыйсың. Аларда кеше язмышы да, борынгы тарих рухы да, киләчәк өмет нурлары да җемелдәп күз алдыннан үтәләр. Җиңел укылышлы теле, төгәл сыйфатлаулары, куәтле фикере ярдәмендә Дәрдемәнд өч-дүрт кенә җөмләле шигырьдә дә гомумиләштерү тирәнлегенә ирешә. «Дәрдемәнд татар әдәбияты дөньясына сигезенче елның башында куәтле тавышлар илә шауламакта булган диңгезнең дулкыннарын ярып барган могъҗиз «Кораб» өстендә заһир (пәйда) булды... «Менә татар сәнгате әдәбиясе күгендә яңа бер йолдыз заһир булды», – димешләрдер. Чөнки аңарда, чынлап та, яңа рух сизелә – нindидер әдәби мәдәнилек, чын каләм сәнгате, матур өслүб, җыйнак вә кыска тәгъбирләр... Гүя ул, нindидер бер сихерле куәт белән, әйтергә теләгән мәгънәсен йөрәгеңә турыдан-туры яра да сала... Алыйк «Кораб»ны, «Без»не, «Өмидләр», «Бүзләрем мана алмадым», «Бәллү»не... «Бәллү», югарыда сөйләп кителгән һәммә кәмалләрне (камиллекне) үзендә җыйдыгы кебек, өслүбенең матурлыгы, гаҗәеп аһәңе илә дә бөтен матбугатымызда беренче урынны аладыр», дип язган иде классик әдибебез Галимҗан Ибраһимов 1913 елда чыккан «Татар шагыйрьләре» очеркында.

Дәрдемәнднең 1929 елда чыккан китабының кереш өлешендә аның иҗатына багышланган мәкаләсендә Фатих Кәрими мондый фактлар да китерә: «Ул Шәрык дөньясындагы Газзали, Фәхерразый, Ибне Рөшд, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Нәваи, Фөзули, Габделхак Хәмит, Әкрам, Тәүфикъ Риза, Габдулла Җәүдәтләр (иҗаты) белән таныш булган шикелле, Гареб дөньясындагы Гегель, Кант, Вольтер, Лютер, Шиллер, Һейне... Толстой, Пушкин, Горький вә башкалар иҗаты белән дә бик төпле таныш иде», – ди.

Үз бәяләмәсен язганда, Г.Ибраһимов белән Ф.Кәрими фикерләрен икенче бер

әдип һәм галим Габделбари Баттал да куәтли. 1925 елда Төркиядә басылган «Казан төрекләре» китабында ул: «Дәрдемәнд мәгънә ягыннан фикерче бер шагыйрь... Шигырь төзелешендә тиешенчә хәбәрдар... аһәңгә, рифмага һәм вәзенгә бик игътибарлы. Һәм, бу яктан караганда, Казан төрки шагыйрьләре арасында иң өстен шагыйрьләрнең берседер. Иске төрки әдәбияты белән дә җитди шөгыльләнгән, Нәваи, Лотфи, Бабур кебек чагатай шагыйрьләренең җыентыкларын игътибар белән укыган булуы да ачык билгеле. Шуңа күрә Дәрдемәнд шагыйрьләр арасында иң белемлесе саналырга хаклы», дип белдерә.

Бүгенге чор татар әдәбияты галимнәреннән Тәлгат Галиуллин, Дания Заһидуллина, Нурмөхәммәт Хисамов, Альбина Сәяпова да Дәрдемәнд иҗатын барлауга зур өлеш кerttеләр.

Замандашлары шулай олылаган зур шагыйрь, олуг фикер иясе, абруйлы җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәнд исеме 1917 елгы түнтәрелеш вакыйгаларыннан соң күпмедер вакыт күренми тора.

Дәрдемәнд шигъриятенең кабат үз милләтенә кайтарыла башлавы илленче еллар тирәсенә туры килә. 1947 елда аның берничә шигыре югары уку йортларында укучылар өчен чыгарылган әдәбият дәреслегенә кертелә. Ә 1959 елның декабрендә тууының йөз еллыгы тантаналы рәвештә билгеләп үтелә. Тел, әдәбият һәм тарих институты тырышлыгы белән уздырылган ул тантанада байтак кына татар зыялылары катнаша. Шул юбилей алдыннан гына Дәрдемәнднең «Сайланма әсәрләр»е басылып чыга (зур кереш мәкалә авторы Мөхәммәт Гайнуллин, төзүче Исмәгыйль Рәмиев). Тагын ун елдан соң, Дәрдемәнд шигырьләренең русчага тәрҗемә китабы нәшер ителә («Стихи»: китапны төзүчеләре Сибгат Хәким, Ренат Харис. Казан, 1970). Ә 1980 елда шагыйрьнең татарча өченче шигырь китабы «Исә җилләр»не ТАССРның халык шагыйре Сибгат Хәким (кереш мәкалә авторы) белән әдип Рәис Даутов (төзүче һәм искәрмәләр авторы) әзерләп чыгардылар... 1999 елда ике телдә «Агарган кыл» – «Поседевшая струна» исемле сайланма шигырь җыентыгы нәшер ителде (төзүче һәм кереш сүз авторы Ренат Харис, җыентыкка фотолар тәкъдим итүче Л.Хәмидуллин). «Татар поэзиясе антологиясе» (татарча – 1956, 1992, русча 1957 ел) һәм «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980) томнарында, «Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе» сериясенең 38(102) томында да (1977) Дәрдемәнд шигъриятенең асыл үрнәкләре урын алган. Бу елларда төрле матбугат битләрендә дә («Азат хатын» (соңрак «Сөембикә»), «Казан утлары» журналлары һ.б.) Дәрдемәнд эшчәнлегенә һәм иҗатына багышланган хезмәтләр басылды. Аерым әсәрләре күренгәләде.

Шул рәвешле, Дәрдемәнднең «корыч кебек өслүбле, тирән мәгънәле, музыкалы аһәңле» (Г.Ибраһимов бәяләмәсе) тиңсез шигъри иҗаты татар әдәбияты дөньясында үзенә тиешле бәяне алды, шагыйрь исеме олуг тиңдәшләре янәшәсендә беркетелде.

Шагыйрьнең туган һәм үскән җирләре белән дә танышып үтик.

Бабалары Исмәгыйль (?–1801) белән Габделкәрим (1774–1851) исә Зәй елгасы буендагы Тайсуган авылыннан. Шул ук нәселдән чыккан Исмәгыйль Рәмиев хәбәр итүенчә, Казан ханлыгы яуланганнан соң, ерак бабалары Урманай морза яңа чик буе сагына җибәрелгән йомышлы татарлардан санала. (Шул ук төбәктәге Урманай авылы әлеге морзага бәйледер, бәлки.) Шагыйрь бабасы Габделкәрим Тайсуганда мәдрәсә тәмамлаган, шул тирәләрдәге бер авылда мулла вазифасын башкарган. Ул арада атасы, бертуганы Сәлим ахун чакыруы буенча Агыйдел буендагы Җиргән авылына барып, шунда сәүдә эшенә керешкән була. Берникадәр вакыттан соң, Габделкәримне дә шунда чакырып китерә, үзе башлаган сәүдә эшен аңа тапшыра.Сәүдәгәр Рәмиевләр эшчәнлеге шушы Җиргән һәм аңа кырык чакрымдагы Эстәрлетамак каласыннан башланып киткән. Ә тагын ике-өч буыннан соң инде татар әдәбияты һәм мәдәнияте мәйданына Сәлим ахун нәселеннән Сәгыйть Рәми белән Исмәгыйль Рәмиев, Тайсуганнан чыккан мулла Габделкәрим оныгы шагыйрь Дәрдемәнд килеп керәчәк.

Рәмиев морзаларның Татарстанның Зәй, Чишмә елгалары тирәсендәге авылларда яшәү дәвере әле өйрәнелмәгән. Исмәгыйль, аның энесе Сәлим мулла һәм Исмәгыйль улы Габделкәрим мулланың Тайсуган авылыннан булганлыгы гына Рәмиевләргә багышланган шәҗәрәдә теркәлгән. Ул шәҗәрәне барлап, нәшер

итүче Ризаэддин Фәхреддин дә «элгәреге бабаларының язмышы безгә мәгълүм түгел», дип яза.

Җиргәндә бүген дә Рәмиев фамилияле кешеләр бар. Ун еллар элек алар «бай Рәмиевләр утары»н ачыкларга булыша. «Йорт диварына, «монда шагыйрь Дәрдемәнд туган» дигән хәтер тактасы да элдек», дигән хәбәр 2009 елда матбугатта булды.

Дәрдемәнд атасы Мөхәммәтсадыйк Җиргәндә туган. Ризаэддин хәзрәт язмасында аның «1892 сәнәсендә... 63 яшендә вафат итмеше, Юлык авылы зиратында җирләнмеше» күрсәтелгән. Шунда ук аның «1850 елның мартында Хәнифәгә өйләнмеше» әйтелә. Хәнифә шул ук Эстәрлетамак өязенең Яуш авылы морзасы Әлмөхәммәт Дашков кызы, диелә. «Ул 1825 елның соңгы көннәрендә туган вә 1896 сәнәсе март башында ... вафат булып, Юлык авылы зиратында дәфен ителмештер.» «Мөхәммәтсадыйк тынгысыз кеше булган. Сәүдә эшләре белән күп йөргән, башкорт, казакълар белән еллык алыш-биреш килешүләре башкарган», – дип искә ала Юлык картлары. Шундый бер сәфәре вакытында ул Юлыкта бөтенләй төпләнеп калу фикеренә килә. Өй һәм кечерәк бер «сабын заводы»н сатып ала. Озакламыйча монда кибет тә ача. Шул рәвешле өч яше дә тулмаган булачак шагыйрьнең икенче туган авылы барлыкка килә. Әлбәттә инде, ул Юлыкны үз итә, ярата төшә. Соңрак аның табигатен тасвирлаган шигырьләре дә язылачак.

Рәмиевләрнең Юлыктагы утар-йорты авыл уртасындарак булган. Аның урам як маңгай тәрәзәләре әлеге яшел чирәмле тауларга, ишегалды тәрәзәләре көньякка караган була. Зур-зур унбер бүлмәле ул йортта Совет хакимияте урнашкач, башлангыч мәктәп ачыла. Ә 1929 елда «мәктәп» йортын сүтеп, бай бураны Баймак каласына күчереп утырталар. Рәмиевләр утарында хәзер тау ташыннан төзелгән зур келәт һәм шундый ук таштан эшләнгән койманың бер өлеше генә бар. Таш келәтнең тимер ишекле җир асты өлешендә элек дәүләткә тапшырыласы алтын сакланган. Колхоз оешкач, ул келәтне тегермән итеп үзгәрткәннәр. Юлыкта элек ике мәчет эшләгән. Шуның берсе – Рәмиевләр 1890 елларда төзеткән таш мәчет. 1990 еллардан соң, ул кабат халыкка мәчет буларак хезмәт итә.

Мәчет төзелгән елларда авылда җәмәгать китапханәсе оештырыла. Аны тотуны Рәмиевләр үз мәчетләре мөәзине белән аның хатынына йөклиләр. Шул хезмәт өчен өстәмә эш хакы түлиләр. Китапханә ир-атлар өчен атнага дүрт, хатын-кызлар өчен ике көн ачык була. Бу тирәләрдә дә болганышлар башлангач, китапханәне саклап калу өчен 1919 елның кышында монда Орскидан драматург Мирхәйдәр Фәйзи җибәрелә. Өяз үзәгеннән Мирхәйдәрне монда җибәрүче түрә дә Рәмиев фамилияле кеше. Драматург көндәлегендә аның исеме дә теркәлгән. М.Фәйзи биредә драма түгәрәге оештыра, бер-ике пьеса яза. Юлыкка багышлы бер шигыре дә бар.

1881 елның көзендә Закир Төркиядән Орскига әйләнеп кайта. Сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Җәй айларының бер өлешен, гадәттәгечә, алтын приискалары бистәләрендә дә уздыргандыр. Төркиядән кайтуының икенче елында ул Орскиның атаклы сәүдәгәре Мостафа Муса улы Борнаев кызы Мәхүбҗамалга (1861–1943) өйләнә. Сәүдәгәр Борнаевларны Казан янәшәсендәге Әтнә якларыннан килгән, дип әйтәләр иде. Закир белән Мәхүбҗамалның сигез баласы туган, шуларның җидесе балигъ булган: Өммегөлсем (1883-1921, кияве Оренбург сәүдәгәре Гариф Камалов), Искәндәр (1886–1943), Рауза (?–1938, кияве сәүдәгәр Вәли Яушев), Зәйнәп (1891–1977, кияве язучы Ярулла Вәлиев), Гариф (1893–1971), Җәгъфәр (1895–1976), Морад (1898–1918). 1903 елда туган Фоад яшүсмер чакта вафат була.

Яшь гаилә озакламыйча губернаның үзәк шәһәренә күчеп китә. Аларның анда төпләнүе ике гаилә өчен дә кирәк булгандыр. Шуңа күрә шәһәр уртасындагы булачак «шалаш»ларын да бик тиз төзеткәннәрдер. Искәндәр улы Бәшир ага Рәмиев: «Әти дә, мин дә Оренбургта туганбыз», – дигән иде. Димәк, алар гаиләсе Оренбургта 1885 елдан яши башлаган. Оренбургның хәзерге Ленин урамында әлеге гаилә өчен төзелгән матур йорт үз урынында әле. Иркен ишегалдындагы таш келәтләре, ат абзарлары, төп йорт янәшәсендәге «Вакыт» типографиясе бинасы гына күптән сүтелгән инде. Төп бинага хәзер Оренбург төбәге нефть-ягулык тармагына караган бай гына оешма хуҗа.

Дәрдемәнд гомеренең байтак өлеше шушы ике шәһәр һәм Орск, Верхнеуральск

өязләрендә урнашкан дистәләгән алтын приискалары утарларында уза. Ике бертуган Рәмиевләрнең төрле җирдә егермеләп приискасы булган.

1994 елда Зөфәр Бәширов белән икебезне Башкортстанның баш геологы Басыйр Мәгадиев кабул итте. Шул идарәдә эшләүче Дәрдемәнд оныгы Равил Искәндәр улы Рәмиев оештырган иде ул очрашуны. Алар безгә Рәмиевләр приискалары урнашкан урыннар билгеләнгән карталарны, һәр приискадан кергән табышны теркәп барган кырыклап калын журналны күрсәттеләр. Рәмиевләр приискалары урнашкан төбәкләрдән хөкүмәткә кырык тоннадан артыграк алтын тапшырылган. Шуның биш тоннадан артыграгы Рәмиевләр өлешенә туры килә, диде безгә Басыйр әфәнде. Алар төзеп биргән картаны без соңрак «Дәрдемәнд» альбомын чыгарганда кулландык. Ул картада ике буын Рәмиевләр гаиләсенә нисбәтле кырыклап прииска да күрсәтелгән.

Бертуган Рәмиевләр приискаларының иң күп алтын биргәннәре хәзерге Чиләбе өлкәсе Нагайбәк районы Балкан авылы тирәсендә урнашкан була.

Закир Рәмиев-Дәрдемәнд гомеренең утыз биш елга якын өлеше Оренбург шәһәрендә узган. Биредә ул заманының күренекле шәхесләрен кабул иткән, алар белән утырдаш булган. Гыйльман ахун Кәримов, аның улы Фатих Кәрими, Ризаэддин Фәхреддин, Шәриф Камал – бу өйнең даими кунаклары. Әдипләрдән Галиәсгар Камал, Нәҗип Думави, Галимҗан Ибраһимов, җәмәгать һәм сәясәт әһелләре Хәсән, Йосыф Акчуриннар, бертуган Максуди кияү-кодалар, Зәки Вәлиди, Габделбари Баттал һ.б. да шагыйрьнең Введенская урамындагы адресын яхшы белгәннәр. (Шәһәр җәмәгатьчелеге тырышлыгы белән 1989 елда хәзерге Ленин урамындагы Дәрдемәнд яшәгән йорт диварына истәлек тактасы куелды.)

Оренбургта яшәгән дәвердә Дәрдемәнд актив җәмәгать хадиме була – берничә мәртәбә шәһәр Думасына халык вәкиле буларак сайлана. «Хөсәения» мәдрәсәсе оешкан 1889 елдан ул – Тышкы иганәчеләр һәм идарәчеләр әгъзасы. XX гасыр башында Оренбург һәм Орскида оешкан берничә хәйрия җәмгыяте әгъзалыгына, «Оренбург мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте» рәислегенә сайлана. Россия мөселманнары мәнфәгатен зур трибуналардан торып яклар дип өмет ителгән «Иттифак әл-мөслимин» партиясен оештыру җыелышында катнаша.

Соңрак Дәрдемәнд, 1917 елгы Февраль революциясе көннәрендә, кабат яңарып киткән милли хәрәкәтләр эшендә бик теләп катнаша башлый. Шул елның июль аенда Казанда узган Бөтенроссия мөселманнары корылтаена килә, анда Вакытлы Милли идарәнең Малия (финанс) нәзарәтендә эшләячәк әгъза итеп сайлана. Ләкин андый яңарыш чоры гына кыска гомерле булып чыга.

Зур өметләр баглап каршы алынган 1917 елның Февраль революциясе хөррияте озакка бармый. Шул елның көз айларында ук яңа түнтәрелеш була – Рәмиев ише мал-мөлкәтле кешеләр өчен хәтәр көннәр башлана. Совет хакимияте игълан ителгән көннән соң бер тәүлек үтмәстән, «байларның байлыкларын алу» турында декрет чыгарыла. Дөрес, Оренбург төбәгендә ул карарны гамәлгә ашырырга бераз соңлыйлар. Оренбургның үзендә совет хакимияте беренче тапкыр гыйнвар азакларында, тулаем губерна күләмендә тагын бер елдан соң гына урнаштырылачак. Ә аңа хәтле, 1917 елның ноябрь азакларында шәһәрдә Бөтенбашкорт корылтае уздырыла. Зәки Вәлиди җитәкчелегендә мөстәкыйль Башкорт Мохтарияты игълан ителә. Мохтарият чикләренә кергән җир өсте һәм җир асты байлыклары аның милке дип белдерелә. Ә ул чикләргә Рәмиевләрнең барлык приискалары да сыеп бетә диярлек. Җир асты байлыкларының яңа мохтарият карамагына күчү хәбәрен Дәрдемәндкә дә җиткерәләр. Зәки Вәлиди белән яхшы мөнәсәбәттә булганлыктан, ул аңа бик борчылмаган, ахрысы.

Рәмиевләр XIX гасырның сиксәненче елларында, Закир Төркиядә белем эстәп йөргән вакытта ук газета нәшер итү, басмаханә булдыру турында үзара хәбәрләшәләр, дидек. Төркиядән кайтышлый Дәрдемәнд, Бакчасарайга кереп, Исмәгыйль Гаспринский белән дә очрашкан булса кирәк. Татарча газета чыгару уенда булган Исмәгыйль морза белән шул көздә үк Казанда бергә туры килүләре очраклы түгелдер. Кырым морзасы килгәнче үк бертуган Рәмиевләрнең аны каршы алу чараларын күргәнлеге турында да хәбәрләр бар. «Тәрҗеман»ның иганәче һәм абунәчеләре исемлегендә дә Рәмиевләр фамилиясе беренчеләрдән булып теркәлә.

Соңрак Рәмиевләр дә үз газеталарын чыгарырга талпынып карый. Ләкин патша түрәләре Идел-Урал төбәге татарларына андый мөмкинлек бирүдән тыела. Галимҗан Ибраһимов, «Революция тарихына материаллар» хезмәтендә (1922) шундый фактларга тукталып, түбәндәге сүзләрне китерә: «Безнең Идел-Урал буенда газета чыгару өмиде ул заманда байтак кешеләрнең башларында булган. Рәшид казый (Ибраһимов), Һади Максуди, мәрхүм Шакир вә Закир Рәмиевләр, тагын әллә кемнәр ул караңгы вакытларда төрлечә исемнәр белән бер газета булдыру турында кузгалганнар. Ләкин хөкүмәт рөхсәт бирмәгән». Ә Россия канаты астына яңарак кына кереп сыенган милләтләргә андый «прәннек» тоттырылган: Бакуда «Игенче», Тифлистә гомуми төрки телдә «Зыя-и Кавказия» газеталары борын төрткән. Казакъ кардәшләребез дә кабаттан Акмола шәһәрендә «Дала вилаяте гәҗите»н чыгаруга ирешәләр.

1906 ел башында «Вакыт» газетасын нәшер итәргә рөхсәт бирелгәч, Рәмиевләр мөхәррирлеккә Фатих Кәримине чакыралар. Ул – Төркиядә укып кайткан, берничә китап авторы булган әдип. Рәмиевләр аның гаиләсе белән электән таныш була. Фатихның атасы, Бөгелмә өязе ахуны Гыйльман Кәримовның Оренбург шәһәрендә төпләнеп, татарча китап басу эшенә керешергә ниятләгән чагы була. Гани бай белән бертуган Рәмиевләр дә булышкач, Гыйльман ахунның да хыялы эшкә аша: Оренбургта 1901 елда беренче шәхси «мөселман басмаханәсе» барлыкка килә.

«Вакыт»ның беренче саны 1906 елның 21 февралендә шул «Кәримовлар басмаханәсе»ндә нәшер ителә.

Рәмиевләр 1907 елның декабрендә «Шура» журналын чыгаруга да рөхсәт алалар. Ул айга ике мәртәбә, елына 24 сан булып чыга. Беренче саны 1908 елның гыйнвар башында дөнья күрә. «Наширлары Мөхәммәтшакир һәм Мөхәммәтзакир Рәмиевләр». 1906 елның октябреннән «Вакыт» газетасы мөхәррир урынбасары булган Ризаэддин Фәхреддинов «Шура»ның мөхәррире итеп күчерелә. «Шура»ның һәр саны зур форматта 36 битле булып, вакыт-вакыт ул төрле-төрле рәсемнәр белән басылган.

И.Рәмиев китабында «Шура» журналының 1918 ел башына чаклы нәшер ителүе, барлыгы 240 саны чыкканлыгы әйтелә. «Әдәби, гыйльми, тарихи журнал. Татар журналлары арасында иң күренеклесе. Дәвамлы, тәртипле чыгып торуы белән дә абруй казанды, күп таралды, күп укылды... Үз заманында, һичшиксез, беренче урынны тотты», дип яза Исмәгыйль ага. Журнал беренче елында шулай ук «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкәсе»ндә басыла.

Бу газета һәм журнал редакцияләрендә шул чорның танылган журналист вә әдипләре Борһан Шәрәф, Габделбари Баттал, Шәриф Камал, Җамал Вәлиди, Зариф Бәшири, Кәбир Бәкер һ.б. эшли. Читтән торып, алар эшендә Галимҗан Ибраһимов, Йосыф Акчура, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Муса Ярулла Биги, Зәки Вәлиди, Һади Атласи, Чыгътай һ.б. язучылар, шагыйрьләр, «җәмәгать хадимнәре һәммәсе диярлек үзләренең каләмнәре белән катнашалар».

«Вакыт» белән «Шура»ны татар, башкортлар гына түгел, башка кардәш халыклар, мәсәлән, үзбәк, казакълар да үз итеп укыйлар. Газета һәм журнал битләрендә әдәби, гыйльми, дини эчтәлекле әсәр һәм хезмәтләр байтак урын алган, алар арасында үзара ярышлар уздырылган. Ярышларда җиңеп чыккан әсәрләр, газета һәм журнал кушымталары рәвешендә Рәмиевләр тарафыннан аерым китап итеп тә бастырылганнар. Редакцияләргә килеп тә, төрле сәбәпләр белән аларда урын ала алмаган шигырь, хикәяләр дә еш кына аерым җыентыкларга тупланып чыгарыла торган булган.

«Закир Рәмиев редакция эшчеләренең тормыш ягыннан яхшы тәэмин ителүләре... яшәүләре ягына нык күз сала, аларга, ул чорларда һичбер җирдә күрелмәгән рәвештә зур жалованье – «Вакыт» газетасы редакторы Фатих Кәримов белән «Шура» журналы редакторы Риза казыйга аена 130 сум бирә иде. Моны күпләр «министрлар жалованьесе» дип йөртә торганнар иде», дип яза 1908-1909 елларда Оренбургта «Чүкеч», «Шура» журналларында эшләп алган әдип Зариф Бәшири («Замандашларым белән очрашулар», 1968). Шул ук елларда эш аты белән сыер хакының 10-12 сумнар тирәсе торганлыгын әйтеп китү кирәктер. «Рәмиевләр, бигрәк тә Закиры, матбугат һәм әдәбиятка зур мәхәббәт белән караганлыктан, бу эшкә сәүдә-табыш ягыннан килмәделәр... Үткән елларда «Вакыт» һәм «Шура»дан, алтын хисабы белән, ун мең сумлап зарар күрделәр», дип яза З.Бәшири.

1907 елда Рәмиевләр үз типо-литографияләрен ачу хәстәренә керешәләр. Дәрдемәнд йорт-утарының иркен ишегалды почмагында, Водяная урамында бина сатып алына. Ул төзекләндерелгәч, анда заманча типография җиһазлары урнаштырыла, мөхәррир һәм корректорлар өчен эш бүлмәләре булдырыла. «Вакыт» белән «Шура» 1909 елның 1 гыйнварыннан шунда ярыйсы ук сыйфатландырылган рәвештә чыга башлыйлар. Ә Риза хәзрәтнең «Мөхәммәд» китабы исә берәр ай элегрәк үк шунда «борын төртә». «Вакыт» басмаханәсе» мөһере сугылган әдәби, мәдәни, тарихи эчтәлекле китапларны һәм дәреслекләрне нәшер итүгә дә керешелә. Басмаханә 1918 елның гыйнвар азакларына кадәр Рәмиевләр карамагында була. Ә 1920 елдан Казакъ автономиясенә бирелә.

«Вакыт» типографиясендә кайсы әдип вә галимнәребезнең китаплары нәшер ителгән соң? Кемнәр Рәмиевләр матбагасына якын торган? Беренче урында, әлбәттә, Рәмиевләр тарафыннан бик ихтирам ителгән, Дәрдемәндкә яшьтәш булган Риза хәзрәт Фәхреддинов хезмәтләре. Аның дини, әхлакый-тәрбияви һәм тарихи эчтәлекле 35 китабы Рәмиевләр ярдәмендә дөнья күрә, шуларның бер өлеше «Вакыт» типографиясендә басыла. Икенче, өченче урында Шәриф Камал һәм Галимҗан Ибраһимов. Ш.Камалның революциягә чаклы дөнья күргән барлык әсәрләре дә диярлек башта «Шура» белән «Вакыт» битләрендә урын алган, аннары аерым китап рәвешендә басылганнар. (Петербургта басылып чыккан беренче китабыннан кала.) 1910 елда «Козгыннар оясында» исемендә озын хикәясе, 1914 елда унбиш әсәрен берләштергән «Хикәяләр төркеме», 1915 елда «Акчарлаклар» повесте укучыга «Вакыт» басмаханәсе тарафыннан тәкъдим ителгән. Г. Ибраһимовның да беренче иҗат дәвере хикәяләренең күпчелеге әүвәл «Вакыт» белән «Шура» битләрендә, аннары аерым китап буларак басылган. «Диңгездә» (1911), «Йөз ел элек» (1911), «Уты сүнгән җәһәннәм» (1912), «Карт ялчы» (1912) хикәяләре һәм күләмле «Татар шагыйрьләре» (1913) очеркы шулай нәшер ителгәннәр. Габдулла Тукай шигырьләре дә «Вакыт» белән «Шура» битләрендә еш басылган. Үз басмаханәсе булган Ф.Кәриминең дә кайбер хезмәтләре «Вакыт» типографиясендә чыга. Мәсәлән, «Истанбул мәктүпләре» исемле калын (450 бит) китабы һәм «Дөнья халыклары» исемендәге берничә китапчыгының язмышы шундый. Иҗтимагый, мәдәни, әдәби хәл-әхвәлне күзалларга ярдәм иткән Г. Сәгъдинең «Әдәбият кануннары», Г. Батталның «Габделвәли Яушев» китаплары, «Шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» күмәк җыентыгы, Җ. Вәлидинең «Татар әдәбияты хакында», «Таңчылар» төркеменең актив әгъзасы Шакир Мөхәммәдьяровның «Алпавытлар заманы» һ.б. хезмәтләр дә – «Вакыт» җимеше. Мәсәлән, Казандагы укытучылар семинариясе укытучысы Николай Ашмаринның «Очерки литературной деятельности казанских татар-мухамеддан 1880-1895» китабы да монда татарчага тәрҗемә итеп бастырыла. «Вакыт»та чыккан тәрҗемә китаплар арасында Төркиянең күренекле әдибе Әхмәт Мидхәт әсәрләре, инглиз язучысы Конан Дойль, рус әдибе Леонид Андреев китаплары да бар. «Вакыт» басмаханәсендә дөнья күргән дәреслекләр саны да ишле генә булган.

1918 елның 23 гыйнварында Оренбург шәһәре биш айга большевиклар кулына күчә. «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналы чыгудан туктый.

Аңлашыла ки, Дәрдемәнд әле шул еллардагы түнтәрелешләрдән соң тыныч тормыш киләсенә ышанган була. Барлык мал-мөлкәтне яңа хакимияткә тапшыргач та, нәрсәдер эшләрлек мөмкинлек тудырылачак, дип тә хыяллана.

Бу елларда аның иң ышанычлы киңәшчесе, әлбәттә, улы Искәндәр булган. Германиядә укып, Европада яшәүчеләрнең тормыш-көнкүрешен күреп кайткан кеше буларак, атасы аңа ышанган. Ә Искәндәр исә аңа патша Россиясендәге тормыш-яшәешнең артта калганлыгын искә төшергәләп торгандыр.

Дәрдемәнд белән Мәхүбҗамал шул елның февраль азакларында Орск тарафына дип юлга чыгалар. Башка елларда приискалары урнашкан өяз тарафына алар апрель урталарында гына китә торган булалар. Соңрак ачыклавымча, бу кышта аларның ашыгып юлга чыгуының җитди бер сәбәбе булган икән. Совет хакимияте Оренбург шәһәрен үз кулына төшерер алдыннанрак кына аларның ике улы – 24 яшьлек Җәгъфәр белән 20 яшьлек Морад үз теләкләре белән Мөстәкыйль Башкорт мохтарияты гаскәренә

язылалар. Һәм алар хезмәт иткән полкларның шул кышта Орск тирәләрендә сугышып йөргәнлеге ачыклана. Ата белән ана, мөгаен, уллары белән хәбәрләшү мөмкинлеге булмасмы, дип уйлаганнардыр. Шул сәбәпле тизрәк Орскига китәргә ашыкканнардыр инде...

Өлкәнең ике шәһәре арасында сугыш барганлыктан, Рәмиевләр Орскига урау юл белән китәләр. Өч йөз чакрымдагы Актүбә каласына поездда, аннан соң йөз кырык чакрымлык юлны Мәхүбҗамалның кече энесе Мәхмүтҗан җибәргән чаналарда узалар. Мостафа байның төп йортында да шушы Мәхмүтҗан калганлыктан, Закир белән Мәхүбҗамал ике ел шунда яшәячәкләр. Ә Орскида да совет хакимияте урнашкач, ике катлы бу сәүдәгәрләр йорты шул хакимият карамагына күчкәндер, мөгаен. 1920 ел башында алар Мәхүбҗамал әнисенең энекәше Хәкимовлар йортына күченә. Ә көзгә табарак исә бер авылда кибет ачкан сәүдәгәр Билал Мусин йортын арендага алалар. Шагыйрь Дәрдемәнднең гомере бер елдан соң нәкъ шушы Мусиннар йортында өзеләчәк тә.

Шәһәр өчен каты сугышлар барган вакытларда Дәрдемәндләр якындагы авылларга да китеп торгалаган. 1919 елның җәендә шәһәрдән Җүнәй авылына качып килүчеләр арасында Дәрдемәнд тә бар иде, дип язган көндәлегенә Мирхәйдәр Фәйзи. Орскида яшәү дәверендә шагыйрьнең бер мәртәбә Казанда булганлыгы да мәгълүм. 1919 елның гыйнварында татар язуын камилләштерүгә багышланган конференция оештырыла. Унынчы елларда ук имля алыштыруга карата үз фикерен матбугатта белдергән Дәрдемәнд тә аңа чакырылган була. Шул конференциягә багышлы бер хезмәтендә тарихчы Нияз ага Субаев: «Закир Рәмиев тә чакырылды», – дип телгә ала. Ул вакыйгада актив катнашкан Ф.Хәмидуллин, 1960 елларда чыккан бер мәкаләсендә «Дәрдемәнд тә анда булды», дип язды.

1993-1994 елларда шагыйрьнең ике оныгы белән очрашып сөйләштек. Ул әңгәмәләрдә Зөфәр Бәширов та катнашты. Ике-өч көн Мәскәүдә шагыйрь оныгы Бәшир ага Рәмиев өендә булдык. Үзен, атасы белән бабасына бәйле кайбер истәлекле әйберләрне һәм китапларны Зөфәр фотога төшереп алды. Шуннан соң Уфада Равил ага белән очраштык. Ә Җәгъфәр кызы Зөбәрҗәт белән без сиксәненче еллардан ук хат аша хәбәрләшеп тордык. Әмма берсе белән дә әлеге авыр еллар турында сөйләшенмәде диярлек. Бу күңелсез вакыйгаларны тулаем искә төшерерлек мөмкинлек булмады. Бәшир ага анасы Шәрифзадәне санамаганда.

Орскида яшәү дәверендә Дәрдемәнд, нигездә, приискаларына бәйле эшләр белән шөгыльләнгән. Алтын чыгару чыгымнарына дип алыннан зур кредитларны, аларны каплар өчен тапшырылган алтынга кагылышлы документларын шундагы банкларда барлау, тәртипкә китерү мәшәкатьләре булгандыр... Приискаларны яңа хөкүмәт вәкилләренә тапшыруны рәсмиләштерү – бу эшләрнең барысын да аңа һәм Искәндәргә башкарып чыгарга туры килгәндер, мөгаен. Мәрьямбикә Рәмиева апа да, 1980 елларда очрашу вакытында: «Закир абзый белән Искәндәр абый 1919 елда җәй дәвамында бездә, Юлыкта булдылар. Атналар буе ерак авылларда йөреп, арып-талып кайталар иде. Нәрсә эшләгәннәрдер, белмим», – дип сөйләгән иде. Ә 1920 елда инде алар Орскидан беркая да китмичә көн уздырган кебегрәк фикер туа. Димәк, яңа хөкүмәт белән аралар өзелгән, байлык тулаем «тартып алынган». Эшлисе эшләр калмаган... Бәшир Рәмиев хәбәр итүенчә, шул елның урталарыннан аның әтисе рәсми рәвештә өяз карамагындагы бер оешмада эшли башлаган. «Шул ук приискаларга бәйле оешма булырга тиеш. Шул елларда ул командировкаларга еш йөргән», – дип әйткән иде. Ә 1925 елның көзендә Искәндәрне Баймактагы алтын һәм бакыр кою заводына баш технолог итеп билгелиләр. Зур гаилә, ике чанага төялеп, шунда күчеп китә.

Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең кая барырга, нишләргә белмичә интеккән көннәре 1920 ел урталарына туры килә. Мөхәммәтҗан Борнаев улы Рәшит (аңа ул вакытта ун яшь була): «Ул җәйдә бабай мине балык тотарга алып баргалады. Кучер безне Урал буендагы күлләргә алып бара иде. Күлдә балыклар күп чак. Күл өстендә сары төнбоек чәчәкләре чайкалыша... Кучер янәшәсенә утыртып, мәчеткә дә алып баргалады бабай. Ул җәйдә мин аларда еш булдым. Кичләрен бергәләп Зауральная рощага да чыккаладык», – дип сөйләгән иде Рәшит Борнаев. Әлеге «Роща» дигән

урын шәһәр халкы элек яратып ял иткән, Дәрдемәнд гаиләсе яңарак яши башлаган Лафарг тыкрыгы башында гына урнашкан усаклык һәм аның иркен аланнары була. Дәрдемәнднең гомерен багышлаган эшеннән, даими аралашып торган кешеләрдән, ата-бабалары чорыннан бирле тупланып килгән бай мирасыннан аерылырга мәҗбүр ителгән көннәр истәлеге шул бу.

Оренбург төбәгендә тиф, ваба ише йогышлы авырулар киң таралган чак. 1921 елның көзендә тиф зәхмәте шагыйрьнең олы кызы Өммегөлсемне аяктан ега. Шагыйрьнең барлык сабырлык-түземлекләренә чик куйган фаҗига шул була инде. Дәрдемәнд кызы белән көрешергә һәм ярым ятим хәлдәге оныклары язмышын хәл итәргә дип, Оренбургка юлга чыга. Шул ук Әсма Рәхмәтуллина көндәлеген ачыйк: «Апам (Сара) хәсрәтеннән айный алмый торганда, тагын бер хәсрәт килде... Җизни Гөлсем апаның хәлен белергә, азык илтергә дип, Оренбургка китте», дип яза ул.

Авыру кызы Дәрдемәнд килгәч тифтән үлә, диючеләр дә, ул китеп бераз торгач, Өммегөлсем җан биргән, дип әйтүчеләр дә бар. Әсма да, «җизни киткәч, салкын төшкәч, туң карбыз ашагач үлгән Гөлсем апа», дип яза. Кияве Гариф тә авыр хәлдә була. Сентябрьнең соңгы көннәрендә шагыйрь, ике кечкенә оныгын ияртеп, Орскига кайтып китә. Гөлсемнең олы кызы Рабига җәй башында ук сеңлесе Рауза Яушева белән бергә Ташкентка озатылган була. Икенче оныгы Суфияне Дәрдемәнд атасы карамагында калдыра. 1915 елда туган, бабасы белән киткән «зуррак кыз» Кафия апа Камалова-Усманова белән дә хәбәрләштек. Орскидан сиксән чакрымдагы Сара станциясенә бер иске вагонда кайттык, дип сөйләде ул. «Сарадан арбалы атка утырып киттек. Яңгыр яугалап тора иде. Бабай плащын Галия белән икебез өстенә ябып, безне кочаклап алып кайтты», – дигән иде Кафия апа. Ул вакытта әле тимер юл төзелеше Сара авылына гына җиткән була. Сарадан Орскига сиксән чакрым... Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең ат-арбада интегеп уздырган соңгы чакрымнары була инде бу... Кайтып бер атна чамасы авыргач, 1921 елның 9 октябрендә Закир Рәмиев-Дәрдемәнд вафат була. Әсма: «Җизни бронхиттан үлә», – дип яза. Шул елларда Эстәрлетамакта нәшер ителгән «Башкорт» газетасында Дәрдемәнднең тифтән үлгәнлеге хәбәр ителә. Дәрдемәнд балалары Зәйнәп һәм Җәгъфәр белән аралашкан М.Гайнуллин да шул ук фикердә. Шагыйрь шәһәр янәшәсендәге Ильяс бистәсе зиратына җирләнә. Ул Урал-суның аргы ягындагы үрдә урнашкан. Шәһәрнең хәллерәк кешеләрен элек-электән шунда җирләгәннәр. Чөнки шәһәр читендәге ике зират та Урал елгасы ташыган елларда су астында кала иде. 1957 елда үземә дә Урал-суның дуамаллануын, Иске шәһәр урамнарыннан фәкать «солдат көймәләрендә» генә йөреп булганлыгын күрергә туры килгән иде.

Ильяс бистәсенең зират ягы башына 1941 елда каяндыр «патрон заводы»н китереп утырталар. Дәрдемәнд кабере сугыштан соң әле койма читендәрәк була. Кабер өстендәге истәлек ташын мин әле сугыштан соң рәтләп киткән идем, дип сөйләде миңа 1950 елларда бер абзый. Ул Борнаевлар нәселенә якын кешеләрнең берсе иде. Хәзер ул зират тулаем хәрби завод биләмәсендә калды. Андагы кабер ташлары да төрле корылмалар нигезендә сакланадыр әле... Зөфәр Бәширов белән без ул завод биләмәсен уратып алган ике метр биеклектәге таш койма тирәсен дә әйләнеп чыктык. Элекке зират калдыкларын очратмадык...

Дәрдемәнднең тирән фикергә бай эчтәлекле кабатланмас шигырьләре, халкының бәхетле киләчәге өчен дип кылган изге эшләре мәңге онытылмас. Татар халкының горурлыгы булган шагыйрь Дәрдемәнд рухы күңелләребездә мәңге сакланыр! Әдәби вә җәмгыяви эшчәнлеге, һичшиксез, киләчәктә башка халыкларга да мәгълүм булыр. Аның әсәрләрен кардәш казакъ, үзбәк, төрек телләренә тәрҗемә итү чараларын да күрәсе иде.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

## Газаплы язмыш

*(Искәндәр агама багышлыйм)*

Ни уйларга, ни дияргә? Нәрсә бу?
Шашкынлыкмы, җинаятьме? Кайсы бу?
Үтте еллар... Акладылар эш узгач...
Киселә гомер... дошман эзләү бер азап...

Кем бу корбан? Кем бу шәһит?
Кемдер бу?
Йөзләр, меңнәр, күп-күп меңнәр.
Күпләр бу!

Кемдә гаеп? Ник җәзасыз калды ул?
Аңа каршы күтәрмәде һичкем кул...
Төям йодрык. Кайный каным ачудан.
Тыелалмый «Ләгънәт!» димен ярсудан!

**Җәгъфәр РӘМИЕВ***

*Җәгъфәр Рәмиев - Дәрдемәнднең улы. Шигырь 1957 елның 5 февралендә Искәндәр Закир улы Рәмиевнең аклану хәбәрен алган көнне язылган.



*Җәгъфәр Рәмиев*
*Гражданнар сугышыннан соң.*




*Искәндәр Рәмиев –*
*Санкт-Петербург гимназисты.*



*«Хөсәения» мәдрәсәсенең Тышкы идарәчеләре һәм мөфтият кунаклары. Уңнан (утыралар): мәдрәсә мөдәррисе Габделгалим Дәүләтшин, Уфа кунаклары, казыйлар Хәсәнгата Габәши, Гыйниятулла Капкаев, Нурмөхәммәт Мәмлиев. Мөтәвәллиләр: Закир Хәеров, Фатих Кәрими, Габделхәмит Хөсәенов, Мәхмүт бай Хөсәенов (рәис), Гайса Еникиев, Закир Рәмиев, Хәсән Акчурин, Мәхмүт Госманов. 1909 ел.*



*1914 елгы сәяхәттән күмәк фото. Бельгия, Льеж шәһәре. Сулдан уңга: Әхмәт-Мидхәт Шакир улы Рәмиев, Искәндәр Закир улы Рәмиев, Зәйнәп Рәмиева-Вәлиева, Гариф Закир улы Рәмиев, Камилә Рәмиева-Максудова, Садри Максуди, Закир Рәмиев.*

*Фотолар Лирон ХӘМИДУЛЛИН архивыннан алынды.*

# ТАЯНУ НОКТАСЫН ЭЗЛӘГӘНДӘ...

## Хәзерге татар поэмасына бер караш

Яңа гасырның икенче унъеллыгы шагыйрьләре каләменнән төшкән поэмаларыбыз нинди казанышлары белән сөендерәләр, меңъеллык әдәбиятыбызның «йөзенә кызыллык» китермиләрме, хәзерге хәятыбызны, рухи дөньябызны тулы көчкә чагылдыра алалармы дигән сорау бер мине борчымый торгандыр. Поэманы шигъриятнең башка төрләреннән аерып өйрәнү кирәкме, чөнки аның бар жанрлары да бер үк максатлар белән яши, диючеләр дә табылыр. Чыннан да бер каләм иясе шәхеснең холкын, олы дөнья белән күп яклы мөнәсәбәтләрен, эчке дөньясын кыска лирик шигырьдә ачып бирә алса, икенчесенә тормыш фәлсәфәсен, иҗтимагый-сәяси барышны, каһарманының хисси халәтен, менәзен укучыга ирештерү өчен күләмлерәк әсәр кулайрак булырга мөмкин.

Дәрдемәнд, белгәнебезчә, үз чорының татар халкы тарихының, язмышының ифрат катлаулы вә четерекле табышмакларын берничә юллы шигырьләренә сыйдырган («Кораб», «Бүзләрем маналмадым», «Сөт калыр, ватан китәр» һ.б.). Халык авыз иҗатыннан үрнәк-өлге алып, М.Ногман, Г.Зәйнашева, М.Шиһапов һ.б. тирән эчке хис-тойгыларын, замана рухын җыр калыбында ачып бирә алганнар.

Поэманың тормышны иңләбрәк сурәтләү, типик образлар тудыру, композицияне төрләндерү мөмкинлеге зуррак булуга ышанычны күренекле рус шагыйре, «Возмездие», «Двенадцать» кебек мәшһүр әсәрләр авторы А.Блокның «поэма сирәк, әмма озакка туктый торган бригада станциясе»нә тиңләве күңелемә сеңеп калды. Аннан килеп, Тукай, Такташ, Бабич, Туфан, Ә.Фәйзи, С.Баттал, М.Җәлил, Ф.Кәрим, С.Хәким кебек классикларыбыз иҗтимагый-сәяси, милли мохитне, табигать матурлыгын, рухи дөнья хасиятләрен лирик шигырьләрендә дә тирәнтен ачсалар да, аларның кабатланмас шигъри йөзләре, милләт мәнфәгатьләре белән янып-көеп яшәүләре эпик оеткылы әсәрләрендә тулырак чагылуы бәхәс уятмас дип уйлыйм. Шигъриятебез тарихына күз салсак та, анда да поэма файдасына «тавыш» бирә торган бер үзенчәлеккә, ягъни язма-басма әдәбиятыбызның юл башында, олы жанрның асыл үрнәге балкып торуына тап булырбыз. Кол Галинең XIII гасыр башында иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» дастаны лиро-эпик төрнең үсешенә этәргеч-юнәлеш биреп, «күзәтеп» торуын истән чыгару яисә читләтеп үтү мөмкин түгел. Поэма жанры узган данлыклы юл әдәбият белемендә, шул исәптән минем күзәтүләрдә дә[1], күпмедер күләмдә өйрәнелгәнлеген исәпкә алып, аның соңгы, безнең чордагы катмарлана барган үсеш үзенчәлекләренә, эзләнүләр юнәлешенә игътибарны юнәлтү кирәгрәктер дип уйлыйм. Үткәнебез белән горурланып яшәсәк тә, безне күбрәк хәзергебез һәм киләчәгебез борчырга тиеш. Ник дисәгез, әле генә аяз күкне кара болытлар каплап алгандай, милли телләрне кысу сәясәте, 90 нчы елларда ирешелгән демократик чалымнарның юкка чыгарылуы, халыклар арасындагы дуслыкка гамьсез генә дан җырлап, Татарстан күкрәгеннән чыккан кара алтынның башка илләргә агуын хуплаган җырлар-поэмалар сырлаган тезмәчеләр югалыбрак калдылар, тантаналы шатлыктан арынып, «нигә болайрак борылды соң әле бу дөнья» дип, ачы хакыйкатьне чагылдыру юлларын эзли башладылар.

Олы тарихлы, берничә дәүләт тоткан халкыбызның, телебезнең хәзерге хәле җәмәгатьчелекне, шул исәптән каләм әһелләрен тәшвишкә салды. Табигый ки, төрле мәүзугъларны, сюжет канваларын үзәккә алсалар да, лиро-эпик әсәрләр милләт, тел язмышын читләтеп үтә алмыйлар, меңъеллык мираслы халыкның яшәргә тиешлеген исбатлап та, дәгъвалап та чыгалар. Бу юнәлеш Р.Харис, М.Мирза, Р.Шәрипов,

[1] Галиуллин Т.Н. Поэманың барыр юллары. Китапта: Яңа үрләр яулаганда. Татар.кит.нәшр., 1972. – 58-93 б.

Р.Гарифуллина, яшьрәк буын шагыйрьләрдән Ф.Гыйләҗев, Р.Мөхәммәтшин һ.б. эзләнүләрендә ачык чагыла. Милләт мәнфәгатьләре, аның киләчәге турында уйланып яшәүче кешеләрнең, бигрәк тә каләм әһелләренең борчылуын, дөресрәге, хыялын шагыйрь Ф.Гыйләҗев аерып, бабасының чорлар аша «иңдергән» кисәтүендә әйттерә.

*«Үз Кирмәнең*
*Корырга син, улым, онытма!*
*Үз дәүләтең булсын – үз телеңдә*
*Сөйләшсеннәр өчен оныклар...»*

Ф.Гыйләҗев. «Иске Казан-Кирмән нигезе».

Федерализм калдыкларының юкка чыгарылып, үзәкләштерүнең, буйсынган халыкларның тел иреген кысуның елдан-ел «азынуы» поэмаларда килешмәүчән публицистик юнәлешнең, аналитик фикернең, сәяси ялкынның көчәюенә алып килде. Шул ук вакытта кешенең эчке дөньясына да игътибарны, лирик-медитавлыкны саклый алды тынгысыз каләм иясе. XX йөз ахыры, яңа гасырның беренче чиреге поэмасының гомуми торышы, үсеш дәрәҗәсе турында сүз куеруга иллеләп поэма, либретто, шигъри драма, шул исәптән «Исемсезләр» шигъри романы авторы, күренекле әдип, җәмәгать эшлеклесе Ренат Харис каләменнән өзелеп төшкән әсәрләр күз алдыннан уза.

Р.Харисның шигърияте, аеруча поэмалары турында язган, уйланган кеше буларак[2], аңа инде темпны киметеп, кайсыдыр күләмдә кабатланса да, гафу итәргә дә мөмкиндер, иҗат кешесе гомере буена шедеврлар гына «иңдереп» тора алмый, таләпчәнлекне дә киметергә туры килмәсен дип, 2016 елда нәшер ителгән «Атлар чаба» җыентыгын кабат укырга керештем. Соңгы җиде-сигез елда язылып, мәҗмугага тупланган дүрт әсәре («Татар Титанигы», «Урам», «Мәхәббәт», «Бәкер сазы») янына 2017 ел «Казан утлары»ның 12 нче санында тәкъдим ителгән, күләме белән җыйнак, мәгәр өреп тутырылган туп мисле, «тыгыз тәнле» «Уба» поэмасы эчтәлекләренең кабатланмас булулары, композицион камиллекләре, алтын бөртекләредәй сибелгән чагыштырулары, нечкә күзәтүләре, сүз-сурәт тантанасы белән гаҗәпләндереп сокландырдылар.

Алгарак китеп булса да, шуны искәртү лазем: шагыйрь әлеге әсәрләрендә, нигездә, реализмның нәзакәтле юнәлеше – метафорик фикерләүгә өстенлек биргән өслүбенә турылыклы калган. Хәер, ошбу поэмаларына да бер үк «камытны» кидереп булмый. «Уба», «Татар Титанигы», өлешчә «Урам» поэмаларында иҗтимагый эчтәлек, публицистик аһәң өстенлек итсә, «Мәхәббәт»тә интим хис конфликтның чишелеше барышында ачылса, «Бәкер сазы»нда мифологиягә нигезләнгән романтизмның «йөрәге тибә».

Төрле эчтәлекле поэмаларында шагыйрь укучысына бергәләп, уйланып, киңәшеп, үз фикерендә калуга мөмкинлек биреп, дөнья сурәтенең бер төсмерле генә була алмавына басым ясый.

## «Сталинизмны» җиңә алдыкмы?

Р.Харисның иң соңгы әсәрләренең берсе – «Уба» мәҗлестәш дустының «Сталинистмы, әллә түгелме син» дигән, лирик герой күңелендә капма-каршы хисләр өермәсен кузгаткан сакраменталь сорау белән башланып китә. Ул аңа «юк» дип кистереп җавап бирер иде, үсмер чагында башкаларга «Яшә, даһи Ста-а-алин!» дип кычкырулары, юлбашчы үлгәч, мәктәп, бөтен «авыл белән үксеп» елаулары келт итеп исенә төшә.

Сталин исеме Бөек җиңүгә бәйле җылы хисләр уятса, икенче яктан – шәхес культы чоры явызлыклары «кузгата нәфрәт буранын». Шагыйрь фикеренчә, бу шаукым үткәннең сагышлы сәхифәсе генә дип сөенсәк тә, «ист», «изм» кебек ярлыклар белән өркетүләр аңны сагайтып, һаман да җанны сискәндереп торалар. Чөнки ул учакта янып бетмәгән күсәк кебек: әле пыскып, әле кабынып, дөрләп китә, «чөнки шундый илдә, шундый заманда яшибез». Лирик затның хәтере, кинәт ялтырап алган яшен кебек, үткән гомер мизгелләрен әрнетеп уятса да, ил, җәмгыять, милләт язмышы турындагы

[2] Галиуллин Т.Н. Ренат Харис поэмалары. Китапта: Яктылык. Татар.кит.нәшр., 2011. – 83-98 б.

уйлары «сталинизмны» берьяклы гына бәяләүдән туктатып тора. Телибезме, юкмы, ул – безнең каны саркып торган тарихыбыз.

Шәхес культы «чәчәк аткан» чорда гадәти бер татар авылында булган хәлне искә төшерү поэманың фикри юнәлешенә ачыклык кертә. Яла корбаны тракторчы «булган икән», ифрат тырышып, үзен аямыйча, көнне төнгә ялгап эшләп, «төрле бүләкләр алган», аның уңышлары турында «гәзитәләрдә язганнар».

Бик хыялланса да, мактау тактасына эләкмәгән, трибуналарга күтәрелә алмаган икенче тракторчы көндәше өстеннән, Сталин исемен йөрткән тракторны хурлавы турында «тиешле җиргә» шикаять язып җибәргән.

*Ә дан тирәсендә һәрвакытта*
*Бөтерелә бер көч – көнләшү,*

– дип, бу аяныч хәлгә шагыйрь төгәл бәясен бирә.

Уңган егет Колымада ун елын утырып кайтканнан соң, әүвәл «Теге исән-саумы, нәрсә эшли, кайда тора ул», – дип белешә һәм дөньяда ахыр чиктә дөреслек тә бар, Ходай Тәгалә барыбызны да тигез күрә икән дигән иман-ышаныч уятырлык җавап ала:

*«Җир йотты бит аны, – дип әйтәләр, –*
*Шул ук елны, август башында...»*

Авылдашлары сүзләренә шунда ук ачыклык кертәләр.

*Көпә-көндез... Тигез, такыр кырда...*
*Ышанмас та хәтта беришең...*
*Җир өстендә тик ыржаеп калган*
*«Сталинец» зурлык бер тишек.*

«Мистикамы бу? Әллә риваятьме?» «Мәҗүсилек көчле әле бездә», дип, имеш-мимешкә ышаныр-ышанмас шагыйрь шикаятьчене «җир йоткан» урынга бара һәм бомба шартлагандай убылып төшкән, ыржаеп халыкны өркетеп торган урынны үз күзләре белән иңли. Чокырга нәрсә ташласалар да, барысы да җир астына китеп югала икән. Ул да халык фикеренә кушылып, һәр явызлык үз бәясен алырга тиеш дип, кайчандыр барлыкка килгән убылуны кешеләр күңелендә яткан хөсетлек-көнчелек кебек гадәтләрне фаш итү максатына юнәлтергә кирәк дигән уйда ныгый һәм янәдән әсәрнең башында күтәрелгән «Сталинистмы, әллә анти...мы мин?», «Кем үлчәгән шулар күләмен» дигән борчылуына әйләнеп кайта.

Шагыйрьнең нахакка рәнҗетелгән тракторчыны күреп сөйләшәсе килсә дә, ул төрмә газаплары нәтиҗәсендә фани дөньяны ташлап киткән була.

Фикер сөрешеннән, юллар арасындагы кинаяләрдән аңлашылганча, иҗтимагый-сәяси халәтебезнең сталинизм элмәгеннән арына алганы юк икән әле. Ул зәхмәт алым-ысулларын үзгәртә барып, агулы угын «сиптерүне» дәвам итә. Әйтик, торгынлык елларында, нәкъ шәхес культы чорындагы мисле, «иҗатчы» имзасын куярга оныткан хатлар югары дәрәҗәләрдә тикшерелеп, җәзалар бирелде. Хәзерге чорда буйсындырылган халыкларның телләренә каршы алып барылган сәясәт, милли кадрлар әзерләүче факультет-бүлекләрне кыскарту, матбугат ирегенең кысыла килүе шул ук ленинизм-сталинизм шаукымының дәвамы түгелме?

Поэманың композицион төзелешенә нисбәттән бер теләгемне әйтми калдыра алмыйм. Бәлки, «үгезне мөгезеннән» алып, поэманы ике тракторчы арасындагы низагны сурәтләүдән, җир убылып төшү турындагы риваятьтән (әсәрнең исеме дә «Уба») башлап, сталинизм шаукымы, хәзерге рухи халәтебез, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең иҗтимагый яшәешкә тәэсире турында уйлану – бәяләрне бер тирәгәрәк тупласаң, поэманың төзелеше камилрәк булыр иде, дип язмакчы идем дә, аңыма килеп, абзый, тукта әле син, дип, каләмемне читкәрәк куйдым.

Сталинизм, шәхес культы шаукымы күңелләргә шом төшереп торган кара корымдай шул чаклы тирән кереп утырган ки, аңардан тиз һәм җиңел генә котылып булмас

шикелле. Ул чор калдырган физик югалтулар, күңел яралары бик күп әсәрләрнең нигезендә ята, хис-фикер үсешенең юнәлешен билгели.

Бу мәүзугъ М.Мирзаның соңгы елларда иҗат ителгән «Бакы – кубарык җил» һәм «Хәбибҗамал» поэмаларының асылын тәшкил итә. Соңгы әсәренең сюжет канвасын дини вә хәлле нәселнең 1917 елгы түнтәрелеш нәтиҗәсе буларак туган фаҗига тәшкил итә. Поэманың үзәк каһарманы Хәбибҗамал карчык, башка образлар аның туганнары, якыннары.

*Хәбибҗамал абыстай – Ерак әбкәм*
*Ярты гасыр безне ташлап киткәнеңә.*

Шул беренче «таныштыру» акрынлап Хәбибҗамал абыстайның нахакка Себергә сөрелгән ире Нурлыгаян, балалары, оныклары, күрше-күләннәре белән «аралаштыру» мөмкинлеген бирә.

Татарның иң уңай, тормышчан, кешелекле сыйфатларын, кояш нурларын үзенә җыеп алгандай сеңдергән карчык, язмыш басымына бирешмичә, гаҗәеп бер үҗәтлек белән балаларын, оныкларын тәрбияли, әхлакый дөрес юлга бастыра. Җөмләдән, нәсел дәвамчысы, карчыкның оныгы Фаягөл алдынгы тракторчы булып китә.

Шагыйрьнең төп максаты Хәбибҗамал образында шәхес культы тегермененә эләккән буынга хас сыйфатларны тулырак ачып бирү. Нинди генә авырлыклар күрмәсен, татар хатыны сынмаган, сыгылмаган, тешен кысып булса да, чыдаган, рәнҗемәгән, аның «Талангач та каргамадың – түздең, бәгырь», дигән сыйфаты битараф калдыра алмый.

Тулаем поэманың фикер вә зиһният сөрешен хуплаган хәлдә дә, түбәндә китереләчәк өзекне укыгач, шагыйрь эчтәлекле юнәлешне дөрес сайласа да, нәтиҗәсе «искечәрәк» дигән тәэсир кала.

*Кубарылып үзгәрешләр җиле исте –*
*Ни күрер ил, әлегә аңлап булмас та...*
*Яңа Кормаш яңарып килә яңадан.*

«Үзгәрешләр җиле»нең булмагандай, күптәннән үтеп китеп, татар теленең, гомумән, милләтенең язмышы кыл өстендә торуын, баш очыбызда кара болытларның куерганнан-куера баруын күрми калмас Мөхәммәт Мирза. Россиядә авылларның, шул исәптән татарлар яшәгәннәренең дә «глобализация» дигән шаукым аркасында югала, балалар булмау нәтиҗәсендә, мәктәпләрнең ябылуын «яңадан яңарып килгән» Кормаш авылы (шулай булган тәкъдирдә дә) гына милләт язмышын үзгәртә алыр микәнни? Их, шулай, шагыйрь хыялланганча гына булса иде дә бит!

«Хәбибҗамал» шәкли тарафтан традицион өслүбтә язылып, ритмик рәсемне төрләндерүне, абыстайны җылырак итеп сурәтләүне сорап торса да, Такташның «Алсу», «Мокамай» әсәрләреннән куәт алган җитди эчтәлекне тар мәйданга сыйдырган «миниатюр» поэма, 60-80 елларда Ш.Галиев, И.Юзеев, Э.Мөэминова, Р.Вәлиева, М.Шабаевлар яулаган үрен югалтыбрак бара иде кебек. Шул тарафтан да кыска күләмдә уңай образ тудырып, иҗтимагый мәсьәләләрне калкытып куйган М.Мирза поэмасы хуплауга һәм җылы сүзгә лаек.

«Хәбибҗамал» поэмасыннан элегрәк язылган «Бакы – кубарык җил» әсәрендә М.Мирза ил өстеннән дуамал давыл кебек хәятны «кубарып» узган соңгы сугышның яңа бер кыйтгасын ача. Поэма хронотобының нигезендә үткән сәхифәләрне бүгенге күзлектән бәяләү, яисә икеләтелгән проекция ята. Хәзер диңгезнең аръягы...

*Бирге яктан күренми яры...*
*Атна, айлар үткәннәр кәрваннар*
*Җиде ятларның төяп малын,*
*Йолдызларга багып, юл табып...*

Шундый романтик үткәнне сагыну янында ук халык башына ишелеп төшкән XX гасыр фаҗигасе.

*Бер хәбәрсез югалганнарның,*
*Сулган гөлдәй ятим, толларның,*
*Хәсрәтенә беркем тармасын*
*Ундүрт яугыр кайткан авылга*
*Җитмеш йортта – үксез ятимнәр...*

Бик күп яралыларны Баку хастаханәсе кабул итеп, һәммәсенә хәлдән килгәнчә ярдәм күрсәткән. Шагыйрьнең әтисе Мирза Ибраһимов ике аягын шунда кистергән, бик күп дуслар тапкан, аның исемен зурлаганнар, хәтта җирле егеткә кызларын биреп кодалашканнар да.

Поэманы бизәүче шәхес – Мирза Ибраһимовның рухи дөньясы, аерым алганда, сугышка мөнәсәбәте, бәясе ачылып бетмәгән дип ачынып, үрсәләнеп утырганда, Дәрдемәнднең «Сөт калыр, ватан китәр» дигән табышмагын дәвам иткәндәй яңгыраган юлларга юлыгып, шагыйрь өчен сөенеп куйдым.

*Барын-югын күрдек ил белән...*
*Ил дигәнем – үзебез инде,*
*Үксез ятимнәрнең тиңнәре...*

Бу өзектә аның азатлык өчен күпме корбаннар биреп, газаплар күрсәк тә, «ил дигәнебезнең» буйсынган халыкларга мөнәсәбәте үзгәрми дигән фикер чагыла.

Сугыш калдырган афәт күңелләрдә, йөрәкләрдә, хәтерләрдә озакка сакланса да, тыныч саналырга лаеклы яшәешебездә дә аянычлы хәлләр туа. Тормыш сынауларны җибәрә тора.

## Фаҗига баскычлары эзеннән...

Көтмәгәндә-уйламаганда, көннәрнең берсендә Болгар каласыннан кайтканда, «Булгария» теплоходы кешеләре белән бергә су астына китә. Ошбу фаҗигане шагыйрь Р.Харис та авыр кабул итә, җаны тетрәнә, бу хакта онытасы килеп карышса да, түзә алмый, күңелен биләгән сагыш, рәнҗү хисе шигъри юлларга агыла. Эчке карышуга буйсынмаган йөрәк әрнүе психологик нечкәлек белән ачыла.

*Мин карышам*
*Язмыйм...*
*Ак кәгазьгә*
*Сүз коя-коя елыймын.*

Архитектоникасының нигезендә «Булгария» пароходының батуын дөнья күләм атаклы «Титаник»ның һәлакәтенә тиңләү ята. 40 илдә тарала торган «Писатель и время» газетасында басылып чыккан поэмасын Р.Харис «Татар Титанигы» дип атый. Дөрес, ике чор фаҗигасе арасында аерма да биниһая икән. Беренчесендә, акчаларын кая куярга белми интеккән байбичәләр яңа, комфортлы пароходта кәеф-сафа корырга чыккан җирдән һәлак булалар. Әлбәттә, алар да кызганыч. Икенче очракта, мөселман-татарлар, изге җан-балалар, өлкәннәр дини үзәгебездән дога кылып кайтканда, шундый афәткә юлыгалар.

*Каютаның бикле ишегенә*
*Бер кыз бите эчтән ябышкан.*
..................................................
*Карт һәм карчык җан биргәннәр суда*
*Кайткан чакта татар хаҗыннан.*

Халык хәсрәтен йөрәге аша үткәргән шагыйрь бу очрактан киңрәк гомумиләштерү мөмкинлеге таба: «Һәркөн саен берәр хәтәр хәбәр! Иблис безгә җенен өстерә». (Иблис белән җен берүк түгелме икән?)

Илне «яңартабыз», «алга алып барабыз», дип шапырынучыларга һәрвакыт сак

сәясәтче Ренат Мәгъсүм углы кискен мөһерен суга: «Димәк искергән». Ошбу кайгылы вакыйга иҗтимагый-икътисади тигезсезлекләр турында уйландыра. «Кем намусы бездә?» соравына үзе дә тәгаен җавап таба алмый, үз тавышыннан үзе курыккандай, бездә кем бәхетле дигән бәхәскә «нефть сатучымы?» фаразын әйтү белән чикләнә.

«Булгария» пароходының фаҗигасе ваемсыз хәтер төпкелләрендә онытылып калмасын, гамьсезлек тузаны намусны сөрсеткәндә дә, ихлас кешеләр күңелендә саклансын дип, Р.Харис үз әрнүенә халык кайгысын кушып, җитди иҗтимагый нәтиҗәләргә килә.

*Бик озакка килде, ахры, илгә*
*Гадәттән тыш хәлләр заманы.*

«Гадәттән тыш хәлләр»не хакимият үзе уйлап чыгарып, халыкның матди-икътисади хәлен яхшырту турында кайгыртасы урынга, берәү дә безгә янамаган килеш, бар байлыкны ашкынып-котырынып кораллануга тотуны берничек тә аклап булмый, ди кебек шагыйрь. Ул бу вазгыятьне һәр сүзенең энергетикасына басым ясап, шактый төгәл күз алдына бастыра:

*«Алга,*
*Алга,*
*Алга», дип, Россия*
*Корал яңартырга тотына.*

Шагыйрьнең хәсрәтенә уралган «Татар Титанигы» әле һаман да аста» тезмәсе, гомумән, халкыбызның язмышына ишарә кебек тә аңлашыла, һәрхәлдә, шулай тәфсилләүгә, бәяләүгә урын калдырыла. Шигъри сүзнең тәэсир көче, эчке җегәре күп мәгънәлелектә, юллар астына яшерелгән рәмзи (символик) образлылыкта.

«Булгария» көймәсен кешеләре белән «су йоткан» дәвердә, күләме белән кечерәк, әмма мәгънәсе буенча шундый ук үкенечле фаҗига була. Юл һәлакәтендә күренекле җырчы, җәмәгать эшлеклесе, кыю милләтпәрвәр Вафирә Гыйззәтуллина вафат була. Оптимист җырчының үлеме берәүне дә битараф калдырмады.

Язучылар, сәнгать әһелләре, җәмәгатьчелек бу югалтуны юлыбызга яктылык сирпеп торган шәмнең сүнүенә тиңләделәр. Вафирәнең табигый талантын, көчле рухын, бәйсез холкын югары бәяләгән С.Хәким, Ф.Бәйрәмова, М.Юныс, И.Юзеев, И.Шакиров, Ә.Авзалова кебек язучылар, артистлар мондый фидаи затларның сирәк туууына басым ясап, тирән борчулары белән уртаклаштылар.

Вафирә образын мәңгеләштерүгә милли рухлы, рәнҗетелгән кешеләр язмышына игътибарлы Рәниф Шәриповның алынуы табигый кабул ителде. «Вафирә» поэмасын иҗат иткәнче, бу жанрда ул шактый тәҗрибә туплаган иде. Үз тормыш чылбырының бер буынын фабула канвасы итеп алган «Алмагачлар сагышы», гади авыл хатынының фаҗигаи хәлләрне җиңеп чыга алуына мөкиббән китеп язылган «Фатыйма мәхәббәте», тирәлекне, табигатьне саклауга бәйләп әхлакый мәсьәләләрне күтәргән, сурәтен, җан-рух тибрәнешләрен төрле төсмерләре белән ачуга омтылган «Ут», «Бакча», «Йорт иясе» поэмалары Р.Мостафин, Н.Сафина, Г.Садә, Ш.Мостафин, М.Вәли-Барҗылы кебек каләмдәшләренең җылы мөнәсәбәтенә лаеклы булганнар иде.

Әйтелгәнчә, Р.Шәрипов нинди генә мәүзугъны сюжет үзәгенә салмасын, милли мәнфәгатьләрне, телебезне, гореф-гадәтләребезне саклау ихтыяҗын калкытып куюдан бер кәррә дә чигенми. Чирләре борчып, ачы әрекмән сагышы күңеленә үрләгәндә дә, берәүгә дә буйсынмаган яшәешнең мәңгелегенә инануы аңа һәрдаим рухи таяныч биреп торды.

Р.Шәрипов, минемчә, тәнкыйть сүзенә дә, мактауга да артык исе китмичә, авыр йөкне берүзе тартып баруга җайлашкан эш аты мисле, тормышчан реализмга, аның да натуралистик юнәлеше өстенлек иткән канатына таянып, классик силлабик системага нигезләнгән әсәрләрен «коеп» кына тора.

«Вафирә» поэмасында автор каһарманның ике төп үзенчәлеген ачу нияте белән «юлга чыга». Әүвәл ул аны халкыбызның «моңлы сандугачы» – күренекле җырчысы буларак олылаcа, икенче тарафтан, Вафирә милләте өчен җан атып яшәгән көрәшче һәм

шул изге юлда җан койган фаҗигале шәхес буларак сурәтләнә: *«Ә сугыш корбаннарсыз булмыйдыр, язмышлар Раббыбыз кулында»*.

Вакыйгалы сюжет канвасы поэманың үзәк каһарманы тирәсендә бөтерелсә дә, шагыйрь үзен, халыкны борчыган мәсьәләләрне калкытып кую җаен да таба.

Әле күптән түгел генә тормышыбыз башкачарак, шау-гөр килеп, киләчәкнең өмет чаткыларын күреп яши идек, ә хәзер «өметсез чор килә авылга», дигән нәтиҗә ясый шагыйрь.

*Килерме бәхетле киләчәк,*
*Хәтердә берни дә калмаса.*

«Татарның акылы төштән соң» мәкале «Татарның акылын таш баса» әйтеменә «юл ача», җырчы образын тирәлек фонында сурәтләргә мөмкинлек бирә. Түрәләрнең һәм, гомумән, халыкның телебезне, яулап алынган бәйсезлегебезне саклап калу өчен көрәшмәве, битарафлыгы иҗатчының «канын кайната».

*Барысы да, димәк, ал да гөл!*
*Тик калмады бары дәүләт кенә.*
*Калмас кебек хәтта туган тел...*
*Түрәләргә кемнең кирәге бар?*
*Асылында халык битараф.*

Ошбу юлларда Вафирәнең яшәү, фикерләү рәвешенә якынлык, халкына тугрылыклы һәр шәхеснең фани дөньядагы миссиясе, табигате турында уйлануларга алып чыга.

*Казанның җаны бар, даны бар,*
*Атаклы исеме – аты бар.*
*Вафирә кебек зур балкышның*
*Олырак исемгә хакы бар.*

Шул бәйләмдә Вафирәнең ике дөньяны «берләштергән» символик-аллегорик образы калкып чыгуы да табигый кабул ителә.

*Күрегез! Урамда бер шәүлә*
*Вафирә йөри бит эш эзләп!*

Тулаем алганда, Вафирә Гыйззәтуллина җәмәгать эшлеклесе, милли мәнфәгатьләр өчен көрәшче буларак шактый эзлекле ачылган. Бу юнәлештә конкретлык кына җитенкерәми кебек. Аерым алганда, мөстәкыйльлек өчен көрәш елларында, Казан педуниверситеты ректоры Р.Юсупов оештырган «Республика» фиркасенең иң актив җитәкче әгъзаларының берсе Вафирә булуны искәртеп үтү зарар итмәс иде.

Мәгәр поэмада өстән-өстән генә үтеп кителгән мәүзугъ – Вафирә талантына көч биргән нигезләрне ачыклау, ягъни булачак җырчының нинди гаиләдә, мохиттә тәрбияләнүе, кайсы композитор, текст авторы белән хезмәттәшлеген күрсәтү отышлы булыр иде. Мәсәлән, аның күренекле шагыйрь С.Хәким белән күпьеллык иҗади дуслыгы сокландырды.

Җырчының яратып башкарган әсәрләренең эчтәлеге, юнәлеше белән таныштыру иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген тирәнрәк аңлауда ачкыч булып торыр иде.

Тулаем алганда, Вафирәнең якты истәлегенә багышланган поэма бар.


Әсәр яңгырашы ягыннан көйле, ягъни ритмик агым сакланып, рифмалары төгәл булса да, табигый сәләттән килгән зәвыклылык, матурлыкны ачып бетерү җитми, милләт, тел язмышы турындагы публицистик юлларның бер-берсенә мәгънәви якын булып, гелән маңгайга бәреп кабатлануы һәрдаим отышлы яңгыраш алып, гаҗәпләндерми башлый.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

*(Ахыры киләсе санда.)*

# ШИГЪРИ ДУСЛЫК КҮПЕРЛӘРЕ

Азәрбайҗан һәм Татарстан арасындагы әдәби һәм мәдәни бәйләнешләрнең тулы бер тарихы һәм бай традицияләре бар. XIX йөз һәм XX йөз башларында бу элемтәләр аеруча ныгый һәм бер баскыч югарыга күтәрелә. Күренекле галим Мирза Казембәкнең Казан университетында эшләгәндә алып барган фәнни-агарту эшчәнлеге ике халык арасындагы элемтәләр ныгуына да уңай йогынты ясый. Халыкны рухи агарту эше, гомумән алганда, әдәбият, мәдәният, мәгариф, фән һәм иҗтимагый фикер үсешендәге казанышларны үзара алмашу тугандаш республикалар арасындагы бәйләнешләрнең төп асылын тәшкил итә.




Тугандаш халыклар арасындагы рухи бәйләнешләрне ныгытуда татар классигы, танылган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Тукайның азәрбайҗан язучылары, шагыйрьләре, мәгърифәтчеләре белән дус булып, иҗади элемтәләр урнаштыруы да моңа бер этәргеч була. Азәрбайҗанның танылган язучысы һәм дәүләт эшлеклесе Нариман Наримановның Казандагы иҗтимагый-әдәби тормышта актив катнашуы да элемтәләрнең ныгуына китерә.

XX гасыр башында татар әдипләре әсәрләренең азәрбайҗан матбугатында басылуы да куанычлы күренеш була. Мәсәлән, азәрбайҗан телендә чыгучы «Молла Насреддин» журналы тугандаш татар халык язучылары иҗатына аеруча зур игътибар бирә.

Советлар Берлеге чорында бу бәйләнешләр бердәм дәүләт кысаларында аерым бер үсеш юлын уза. XXI йөздә исә азәрбайҗан-татар багланышлары демократик җәмгыять калыпларына таянып төзелә. Бу уңайдан, 2019 елда Татарстанның халык шагыйре, күренекле җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиевнең Бакуга эшлекле сәфәрен һәм аның «Көзге яңгырлар» исемле китабы басылып чыгуын тугандаш халыкларның мәдәни элемтәләрен ныгытуга тагын бер җитди адым һәм яңа сулыш итеп кабул итәргә мөмкин.

Разил Вәлиев өч дистә ел Татарстан Дәүләт Советында халык депутаты һәм чирек гасыр буе Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты җитәкчесе була. Әлеге өлкәләргә кагылышлы күп кенә яңалыкларны тормышка ашыруда Разил Вәлиевнең эшчәнлеге уңай нәтиҗәләр бирә.

Казан дәүләт университетының журналистика факультетында ике ел укыгач, ул Татарстан Язучылар берлеге юлламасы белән Мәскәүгә барып, М.Горький исемендәге Әдәбият институтында югары белем ала. Укуын тәмамлап, Казанга кайткач, озак еллар матбугат һәм мәдәният өлкәсендә хезмәт итә. Татарстан Милли китапханәсе директоры булып эшләгән елларында китапханәнең дәрәҗәсен тагын да югарырак күтәрә һәм нәтиҗәле эшләр башкара. Бүгенге көндә Разил Вәлиев Татар ПЭН-үзәге президенты буларак та халыкара аренада үз милләтенең әдәбиятын һәм мәдәниятен пропагандалау эшен уңышлы алып бара. Ул шулай ук «Җыен» иҗтимагый берләшмә фонды рәисе буларак та зур эшләр башкара.

Разил Вәлиевнең күпкырлы әдәби иҗатында төп урынны лирика алып тора. Күпсанлы шигырь китаплары укучылар тарафыннан яратып кабул ителә һәм ул татар поэзиясенең күренекле шагыйре булып таныла.

2019 елның август аенда Татарстан-

*Вәлиев Р.И. «Payiz yagmurlari» («Көзге яңгырлар»). – Баку: «XAN» нәшрияты, 2019. – Тәрҗемәче Х.Шәми. – Кереш сүз авт. Ш.Сәдиг.*

ның халык шагыйре Разил Вәлиевнең Бакуга эшлекле сәфәре ике халык арасындагы мәдәни багланышларны ныгытуда тагын бер мөһим вакыйга булды. Азәрбайҗан язучылар берлегендә Разил Вәлиевнең «Payis yagmurlari» («Көзге яңгырлар») китабын тәкъдим итү тантанасы булып узды. Яшь төрки язучыларның Халыкара Ассоциациясе инициативасы белән «Хан» нәшриятында әлеге җыентыкның азәрбайҗан телендә басылуы аерым кыйммәткә ия. Бу китапның азәрбайҗан әдәби дөньясында киң резонанс белән кабул ителүе дә әлеге вакыйганың әһәмиятен күрсәтеп тора. Азәрбайҗан Республикасы Милли Мәҗлесенең-парламентының Фән һәм мәгариф комитетында Разил Вәлиев белән очрашу да оештырылды. Анда азәрбайҗан-татар әдәби һәм мәдәни элемтәләрен киләчәктә тагын да киңәйтү зарурлыгы хакында җитди фикер алышу булды.

Разил Вәлиев үзенең шигырьләрендә туган халкын һәм республикасын аеруча тирән мәгънә биреп сурәтли. Аның социаль лирикасында без бу юнәлешкә хас булган гадәти пафослы өндәмәләр һәм идеяләр күрмибез, шагыйрь үз иҗатында образлы, фәлсәфи фикер, поэтик нечкә уйлануларга өстенлек бирә. Татар халкының танылган шагыйре шигъри сүзнең асыл остасы булып, үзенең иҗатчы миссиясен югары һәм дөрес кимәлдә торып үти.

«Җиргә мәдхия» шигырендә ул, шагыйрь һәм ватандаш буларак, үз фикерен болай җиткерә:

*Кояш кояш түгел – җир яктысы,*
*Ә йолдызлар – җирнең маягы,*
*Мине сугыш исән калдырмады,*
*Мине шушы җирем аяды.*

Разил Вәлиев – һәрчак туган җирен, туган халкын олылап, аны яратып дан җырлаучы үзенчәлекле шагыйрь. Туган ягының калын урманнары, киң үзәннәре, елга-таулары, авыл һәм шәһәрләре, татар халкының рухи байлыгы шигъри юлларга күчеп, безне үзенә гашыйк итә. Шулай итеп, без поэзия дигән сернең бөеклегенә тагын таң калабыз.

*Туган телдә җырлый чишмә,*
*Туган телдә шаулый таллар.*
*Туган телдә дәшсәм генә,*
*Туган халкым мине аңлар.*

Разил Вәлиев «Утлы хәтер» шигырьләр циклын Бөек Ватан сугышына багышлый. Бу дәһшәтле коточкыч афәт Татарстан халкын да читләп үтмәгән. Татар халкының күркәм бәйрәме Сабантуйның сугыш башланган канлы көнгә туры килеп, күңелләрдә никадәр каршылык тудыруын; гүзәл кызларның күз карашлары бер сәгать эчендә үзгәрүен һәм яшь егетләрнең сугыш утына кереп, үлмәс батырларга әйләнүен зур тетрәнү белән яза шагыйрь. Сугышның никадәр канкойгыч, кеше гомерләрен яндырып юкка чыгаручы фаҗига икәнлеген аңлата ул. Ни өчен Европа канлы «Сабантуй» оештырган да, ни өчен халык язмышларына балта белән кизәнгән? Шагыйрь җавап эзли, җавап таләп итә.

*Соңгы тапкыр кичә көлде дөнья,*
*Соңгы тапкыр кояш балкыды.*
*Таң атмады бүген, таң атмады, –*
*Алды җирне сугыш ялкыны.*

Татар халкының данлы шагыйре, Советлар Берлеге Каһарманы Муса Җәлил һәм аның «Моабит дәфтәрләре»нә багышлап язылган шигъри юллары да күңелне кузгата, тирән уйга сала. Ил батырлары турында язганда, шагыйрь бу сугышны зур «канлы диңгез» дип атый. Утлы төергә әверелеп, ул халык хәтерендә мәңгегә сакланачак.

*Балалар уйныйлар «сугышлы» уены,*
*Сугыш ул – аларга тик уен.*
*Ә минем уемда кайтмыйча калганнар –*
*Егерме миллион, егерме миллион...*

*Карыйм да кояшка, эндәшәм дөньяга:*
*Тынычмы күңелең, ни гамең, ни уең?*
*Мин түгел, мин түгел, эндәшә дөньяга*
*Егерме миллион, егерме миллион...*

«Көзге яңгырлар» исемле китапның исемен укуга ук табигать турында уйлана башлыйсың. Шагыйрь табигатькә аеруча игътибарлы. Табигатьне ул, еш кына яшь кызга тиңләп, аның барлык матурлыгын укучыга күрсәтә. Шигырьләрдә «сары күлмәк кигән кыз», «оялчан кызый», «керфекләре дымлы кыз»га әверелгән табигать үзен яраттыра, сокландыра. Разил Вәлиев үз шигырьләрендә һәрвакытта да табигатьне җанландыра, терелтә. Ул

аеруча көзне якын күрә. Гадәттә, гомуми шигъриятькә хас булганча, ул көзне яфрак яңгыры, табигатьнең сүнүе итеп кенә кабул итми, ә бу фасылның фәлсәфи ачкычын табып, гомер юлының дәвамы булган какшамас бер канун итеп күрсәтә. Шагыйрь көзенең «ике бите ике алмадай», шагыйрь көзе – җиңүче!

*...Тынычлыгын бүлдерергә куркып*
*Исеме юк шушы фасылның,*
*Әкрен генә көзгә кереп барам,*
*Аңлый барам тормыш асылын.*

«Төсләр» циклында төрле төсмерләрне семантик планда карап, аларны мәгънәви катламга күчереп яктырта автор. Иҗтимагый-фәлсәфи карашларын да төсләр аркылы ача һәм укучы аңына җиткерә:

*Тургайлы үзәнгә карыйм да*
*Җанымны җылыткан уй табам.*
*Кызыл төс күрдисәм, кан уйный,*
*Зәңгәр төс күңелгә моң сала.*
*Нигәдер төсләргә табынам,*
*Тормышым бертөсле булса да.*

Әлеге цикл – автор талантының тирәнлеген һәм тормыш тәҗрибәсенең байлыгын күрсәткән бер үрнәк. «Төсләр» циклын укыгач, шул аңлашыла – Разил Вәлиев бар җаны белән туган ягын, аның яшәешен, табигатен тоя һәм югары бәяли белә. Бу бәйләмне Азәрбайҗан шагыйре Рәсүл Рзаның дөньякүләм танылган «Буяулар» циклы белән янәшә куеп булыр иде.

Разил Вәлиев лирикасында игътибарны җәлеп иткән тагын бер үзенчәлек бар, ул – аның шигъриятенә хас сюжетчанлык. Әмма шигырьләрдәге сюжет сызыгы һәм сюжет элементлары поэзиядә вакыйга коруга китерми, ә лириканың тирәнәюенә, мәгънәви көчен арттыруга хезмәт итә. «Алма» шигырендә шагыйрь «Минем йөрәгем өзелергә әзер алма кебек», дип яза. Монда авторның лирик халәте «күктән алма өзелеп төште» дигән таныш мотив белән чагыша. «Тормыш арифметикасы», «Хәтер», «Вәгъдә», «Шагыйрь», «Сугыш икмәге» шигырьләрендәге нечкә сюжет элементлары лирик гомумиләштерүнең нигезен булдыралар, шигъри сүзне хыялый максатка якынайталар. Сюжет линиясенең мондый үрнәкләрендә эпик ноктаны лирик башлангыч белән тоташтыру өчен автордан зур осталык таләп ителә. Разил Вәлиевнең «Сугыш икмәге» шигырен замана поэзиясенең сюжетлы лирика үрнәге буларак күрсәтергә мөмкин.

Разил Вәлиев шигырьләрендә кешенең тирә-юньгә игътибарлы карашы, табигатькә булган мәхәббәте, кешенең бар кешелек белән бергә, бердәм булып яши алуы төп эстетик башлангычны формалаштыра. Мәсәлән, «Бәхет» шигырен иҗади эзләнүләр квинтэссенциясе дип әйтергә була.

*Хозурланып тауда басып торам –*
*Болытларга башым орына.*
*Кыяларга менми аңламассың –*
*Бу шигырем – бәхет турында.*

«Көзге яңгырлар» китабында шигырьләрнең азәрбайҗан телендәге тәрҗемәләре татар телендәге оригинал шигырьләр белән бергә бирелә. Талантлы тәрҗемәче Хәят Шәминең оригинал шигырьләр рухына тугры булып, аларның матурлыгын, мәгънәсен барлык тулылыгында ачып бирүе дә игътибарга лаек.

«Көзге яңгырлар» китабы Разил Вәлиевнең талантын азәрбайҗан укучысы өчен дә ача. Шигырьләрнең идея-сәнгать дәрәҗәсе һәм поэтикасының тирәнлеге автор иҗаты хакында постсовет киңлегендәге һәм төрки халыклар әдәбиятындагы әһәмиятле әдәби факт буларак сөйләшү өчен мөмкинлек бирә. Язучы һәм күренекле әдәбият белгече Шамил Сәдиг китапка «Туганнан – туганга йөрәкләрне бәйләүче күпер» дигән баш астында мәгънәле кереш сүз язган. Чыннан да, Бакуда дөнья күргән «Көзге яңгырлар» китабы тугандаш Азәрбайҗан һәм Татарстан әдәбиятларын бәйләп торучы үзенчәлекле күпер булып тора.

**Иса ГАБИББЕЙЛИ,**
*Азәрбайҗан Фәннәр академиясенең вице-президенты, Низами Ганҗәви исемендәге Әдәбият институты директоры, академик.*

**Айсылу ИМАМИЕВА** *тәрҗемәсе.*

# ҮЗБӘКСТАН ӘДӘБИЯТЫНДА МОДЕРНИЗМНЫҢ ЯҢАРУЫ: ФИРГАНӘ МӘКТӘБЕ

Элеккеге СССР территориясендә яшәгән төрки телле әдәбиятлар өчен уртак күренешләр шактый. Шуларның берсе – советчыл режим җимерелүгә үк модернизмның кабат яңаруы. Әмма ул һәр әдәбиятта үз юлы белән бара.

Бу яңарышның иң көчле дулкыны Үзбәкстанда күтәрелә һәм ул Фирганә үзәнендәге рус телле әдәбият белән бәйле була. Дөнья әдәбияты тарихына «Фирганә мәктәбе» дип, иң беренче чиратта, Шамшад Абдуллаев исеме белән кергән феномен бу. Аны күзәтү милли әдәбиятыбыз, аның үсеш сукмаклары, модернизмнан соң нинди юлларны ни өчен сайлавы хакында аерым бер нәтиҗәләргә китерә.

Вакыт ягыннан, әлеге күренешнең оешуын 1991 елда «Звезда Востока» («Шәрык йолдызы») журналына Сабит Мадалиев һәм Шамшад Абдуллаевларның эшкә килүе белән аңлаталар. Яшьләр журналга яңа концепция белән килә: модернизм юнәлешен мәйданга чыгару – шулай итеп, Үзбәкстанда яңа әдәбият тудыруның максаты билгеләнә. 1996 елда бу хәрәкәтне җитәкләүчеләр журналдан китәргә мәҗбүр ителә. Әмма Фирганә үзәнендә башланган экспериментның үзбәк әдәбиятына, башка төрки әдәбиятларга да (мәсәлән, азәрбайҗан шагыйре Ниҗат Мамедов үзен шушы мәктәп традицияләрен үстерүче иҗатчы дип саный), дөнья мәдәниятенә дә йогынтысы зур була.

Минем китапханәмдә әлеге мәктәп вәкилләре үзләренең иҗат җимешләрен туплап чыгарган җыентык бар. «Поэзия и Фергана» («Шигърият һәм Фирганә») дип аталучы бу тупланмада (Үзбәкстан, 2000, 207 бит) Ш.Абдуллаев, Даниил Кислов, Григорий Коэлет, Вячеслав Усеинов, Хамдам Закиров, Вячеслав Ахунов, Сергей Алибековларның прозасы һәм шигырьләре, моннан тыш, Абдулла Хәйдәр, Ольга Гребенникова, Юсуф Караев, Александр Гутин, Евгений Олевский шигырьләре, моннан тыш тәрҗемәләр урын алган. Бүген бу авторларның күбесе төрле илләрдә яшәп иҗат итә, аларның әсәрләрен интернет битләрендә табып укырга мөмкин. «Фирганә мәктәбе»нең укучы алдында өр-яңа гаҗәеп бер дөнья ачарга сәләтле әлеге әдәбияты постсовет чоры татар әдәбиятында, башка төрки әдәбиятларда «яңартылган» модернизмнан үзенең тирәнлеге, тәэсир көче, серлелеге, вакыйгалылыктан баш тартуы белән дә нык аерылып тора. Бигрәк тә әдәбиятка әле яңа килә торган яшь язучыларга бу күренеш белән танышырга кирәк.

Әлеге феноменның үзенчәлеген Ш.Абдуллаев 1998 елда манифест формасында аңлатып карый. Аның фикеренчә, бу яңа юнәлеш Көнбатыш Европа, америка-инглиз әдәбиятларындагы югары модернизмга һәм җирле үзбәк әдәбияты контекстына йөз тотарга бурычлы. Шушы киселештә туган яңа иҗат итү рәвеше, стиле генә – яңа әдәбиятның укучы белән сөйләшү теле була ала дип ассызыклана.

Ягъни әлеге күренешне мәйданга чыгаручылар модернизм яңартуны үзбәк әдәбиятын социалистик реализм басымыннан коткару юлы дип күрәләр. Шуңа да рус әдәбиятын читкә куеп, үзләре әйткәнчә, «Урта диңгез», «инглиз-америкал» әдәбиятларындагы казанышларны файдалану таләбе яңгыратыла. (Чагыштыру өчен: Үзбәкстанда да шул ук елларда рус телле язучыларның модернизм әдәбияты тудыруга йөз тоткан һәм «Ташкент мәктәбе» дип исемләнгән берләшмәсе була, аңа Санҗар Янышев, Евгений Абдуллаев һәм Вадим Муратхановларны кертеп карыйлар.) Бу таләпнең дөньяга чыгуына «Фирганә мәктәбе» төркеменә тупланган зыялыларның интеллектуаль дәрәҗәсе, укымышлылыгы, зәвыгы – чит телле әдәбиятларны үз җирлекләренә күчереп утыртырлык югары булуы да йогынты ясый, әлбәттә.

Рус модернизм әдәбиятына шул ук инглиз-америкал әдәбиятларының йогынтысын исәпкә алганда, бу мәсьәләдә сәнгатьлелек ягыннан нинидер көтелмәгән

казанышларга килеп чыгу мөмкинлегенең зур булмавын да искәртергә кирәк. Поэтик яктан, чыннан да, рус әдәбиятына аваздашлыкны инкарь итеп тә булмый. Әмма «рус әдәбиятын читкә кую» таләбе, бу очракта, советчыл идеологиядә арыну һәм үзгә, постколониаль милли дөнья сурәте тудыру кебек шәрехләнә. Милли дөнья сурәте – үзбәк мәдәнияте җирлегенә европа казанышларын күчереп үстерү нәтиҗәсендә хасил була ала дигән фикер XX йөз башы татар зыялыларының татар әдәбиятын үстерү юлын «үз туфрагыбызда чит ботактан киң ябалдашлы агач үстерү» (Җ.Вәлиди идеясе) кебек күзаллавын искә төшерә.

Татар әдәбиятында без модернизмның – XX йөз башындагы милли әдәбият белән «сөйләшеп», Татарстандагы рус телле язучылар иҗатында исә рус әдәбияты белән диалогта яңаруын күрәбез. Ләкин XX йөз башы татар әдәбиятында борынлаган күп кенә хасиятләр «Фирганә мәктәбе» декларациясендә бар. Татарстандагы рус телле язучылар иҗатында да татар телле текстларда булмаган, әмма фәлсәфи-психологик кимәлдә кызыклы яңалыклар тәкъдим ителә.

Ш.Абдуллаев фикеренчә, «Фирганә мәктәбе» текстларында гибрид стилистика – ягъни төрле, бер-берсеннән ерак торган компонентлардан букбөтен күренеш хасил ителү шарт. Бу сыйфат XX йөз башы татар модернизм әдәбиятында да бик әһәмиятле, әйтергә кирәк, төп үзенчәлекләрдән. Романтизмга хас сагышлы интонациянең калкулануы; социаль чынбарлыктан ерагаерга омтылу; ирреаль җирлеккә урнаштырылган предметларны натурализм чигенә җиткереп тасвирлау һ.б. шундый күренешләр дә, төп рольне үтәмәсәләр дә, XX-XXI гасыр чиге татар әдәбиятында күзәтелә.

Шулай итеп, Үзбәкстан мәдәниятендә яңартылган модернизм, вакыйгалар үзгәрешеннән бигрәк, кеше халәтенең, күзаллавының, кичереше-фикеренең, тышкы дөньяның, табигатьнең, вакытның хәрәкәтен тасвирлау объекты ясый, шуның белән һәр мизгелнең, һәр кеше күңеленең, һәр гомернең кыйммәте хакында сөйли башлый. Һәм моны милли тирәлектә, җирлектә башкара. Нәтиҗәдә бик кыска вакыт аралыгында яңа үзбәк әдәбияты туу өчен поэтик база булдырыла һәм әлеге яңа әдәбият мәйданга чыга. Алай гына да түгел, «Фирганә мәктәбе» төркеменә кергән зыялылар милли үзаң, үзбәк тәңгәллеге, үзбәк теле һәм сәнгате турында концептуаль күзаллау формалаштыра башлыйлар, үзбәк милләтенең яңа, постсовет мәдәнияте нинди булырга тиеш дигән сорауга җавапның бер варианты калыплаша. 1990 еллар ахырына Үзбәкстанның бу проектны кабул итәргә әзер булмавы ачыкланса да һәм ул өзелеп калса да, аның XXI гасыр үзбәк әдәбиятына йогынтысы гаять көчле була. Ул әлеге милли әдәбиятка кыска вакыт арасында үз тамырларына әйләнеп кайтырга, башка төрки әдәбиятлар белән чагыштырганда да, милли дөнья сурәтенә һәм милли хикәяләү рәвешенә тизрәк якынаерга мөмкинлек бирә.

Постсовет чоры башка төрки әдәбиятлар турында сөйләгәндә, алардагы күренешләрне үзебезнең татар әдәбиятындагы процесслар белән чагыштыру табигый. «Фирганә мәктәбе» төркеменә кергән язучылар, шагыйрьләр әсәрләрен укыганда, рәсемнәрне караганда алар татар менталитетенә бик якын, үз тоелалар. Араларында XX йөз башы татар язучылары әсәрләренә аваздаш мотивлар һәм хикәяләү рәвеше еш очрый. Роман жанрын нык активлаштырган бу төркем язучылар иҗатында татар әдәбиятындагы нәсер, парча, лирик-фәлсәфи, психологик проза белән якынлык аермачык. Текстларның, рус телендә язылуларына карамастан, милли әдәбият үрнәге буларак кабул ителүләре гаҗәеп бер тәэсир тудыра.

«Фирганә мәктәбе» язучылары иҗаты татар әдәбиятында рус телле язучыларга бер яклы гына карашның һәм татар әдәбиятына, һәм рус телле язучылар иҗатына зыян салуы хакында искәртә кебек. Бу күренеш бүгенге татар әдәбиятында хәтта модернизм юнәлешендәге әсәрләрдә дә социаль башлангычның, әхлакый мотивларның нык саклануының һәм күпчелек очракта зыян китерүенең сәбәпләре хакында да уйландыра. Шул ук вакытта фикердәшләр булган бер төркем яшьләрнең мең еллык тарихка ия милли әдәбиятны үзгәртә алу, аңа кыска вакыт аралыгында сикереш ясау юлын табу мөмкинлегенә ия булуы турында да сөйли.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

## Соравыма күрә җавабы

«Бердәм Россия» партиясендә ТР Дәүләт Советына сайланачак кандидатлар белән беренче очрашулар мәдәни проблемалар хакында иде.

И.Р.Метшин чыгышыннан соң, мин батыраеп киттем, шәһәр башлыгы белән күрешү бәхете гел тәтемәс дип, тел очымдагы сорауны бирергә ашыктым. Һәм ике арада диалог булып алды.

– Илсур Рәисович! Сез, Казан мегаполисының мэры буларак, «Эфир» каналында чыгыш ясаганда: «Шәһәрнең 190 ишегалдын төзекләндерү буенча эш башланды», – дигән идегез. Соравым шул: ул программага мин яшәгән Четаев урамының 24 нче йорты да кердеме икән?

– Без глобаль матурлык, шәһәр культурасы хакында сөйләшәбез. Ә сез ниндидер «ямочный ремонт»ка күчтегез.

– Гафу итегез, Илсур әфәнде, ишек төбендәге чокырларда машиналары ватылган водительләр бер дә культурный сүзләр әйтмиләр шул...

Шул көнне үк Илсур Метшин белән Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары башлыгы Тимур Алибаев, «Уютный дом» компаниясе идарәчесе Марат Нуриевлар безнең ишегалдында иде инде. «ДА!..» – дигән хуплаулары мине бигрәк сөендерде...

Һәм тиз арада җимерек ишегалды яңача дизайнлы балалар мәйданчыгына; өч йортны берләштергән ватык сукмак шомырт кара тротуарга; өйгә кайта торган сикәлтәле тыкрыклар шар тәгәрәтерлек тигез юлга әверелде!

Елмаюны тыяр хәл юк. Нинди матур икән бит безнең урам! Кылт итеп кенә Ф.М.Достоевскийның: «Красота спасёт мир» дигәне искә төште. МИР – Метшин Илсур Рәис улына туры килеп тора бит, әй!..

**Камил КӘРИМОВ,**
*язучы-сатирик,*
*Г.Тукай исемендәге Дәүләт*
*премиясе лауреаты.*





*Автор фотолары.*

Печән Базары

*Сатирик әсәрләр*

## ШӘРИФИЗМНАР

• Яшь чагында ыңгырашу белән картайгач ыңгырашу арасында бик зур аерма...

• Наданнар арасында наданраклар, акыллылар арасында акыллыраклар да була.

• Илебезнең сайлаган юлы нигәдер һаман да дөрес булып чыкмый, югыйсә үзебездән сайлаталар бит.

• Ишәкнең колагын кисеп кенә ат ясап булмый.

• Һавадагы самолётның да ишеген каты ябып чыгып китәргә була...

• Телевизорның бер каналында – ашарга, икенчесендә – ябыгырга, өченчесендә дәваланырга өйрәтәләр.

• Керпенең энәләрен санау белән шөгыльләнүчеләр күбәеп китте.

• Елан, песи түгел, аякка сырпаланып тормый.

• Табигать үз баласы – адәмнән курка.

• Арыслан таныштыруга мохтаҗ түгел.

• Әби бабайдан яшьрәк булса да, бергә яшәгән еллары тигез.

• Хатын-кыз елады ни, кыз бала елады ни, барыбер ана елый.

• Күңелсез вакытта күңелеңне күтәрергә теләүләреннән дә күңелсез нәрсә юк.

• Бүгенге сайлауларны карап торса, В.Шекспир «Чыннан да бөтен дөнья театр икән» дип кабатлар иде.

• Аяк чалучылар күп булу сәбәпле, өйдә генә утырам.

• Кояштагы тапларны нурлар каплый.

• Сөяркә «сөям» – дигәнне ярата, хатын «яратам» – дигәнне сөя.

• Урын кешене бизәмәсә дә, ул урынны бирергә ашыкмыйлар.

• Буйдак – өйләнгән ирләрнең ачуын китерүче кеше.

• Алданырга теләмәгән кешене алдап булмый. Алданырга теләгәнен алдыйсы да килми.

• Бу түгәрәк көзге төне буе йокламаган, ахры...

• Илебез шундый бай, хәерчелек белән күренми.

• Нигезең булса – кайтам, булмаса – барам.

## Заманага яраклашкан мәкальләр

• Күршенең тавыгы минем күркәдән шәбрәк.

• Син дә кунак, мин дә кунак, гастарбайтерлар эшли.

• Күз курка... кул урлый.

• Коега төкермә... Суын шешәгә тутырып, үзеңә үк сатарлар.

• Ни чәчсәң, шуны урырсың... килеп тотканчы.

• Эт оясында көчле... бу безгә кагылмый.

• Юлга чыксаң, дустыңның кесәсе калынрак булсын.

**Раушан ШӘРИФ**

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ЮБИЛЕЙЛАР

Татарстан Язучылар берлегенә – 85 ел. Шул уңайдан Казандагы Корстон күңел ачу үзәгендә тантана-мәҗлес булып узды. Каләм ияләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады. Ул берлеккә ТР Президентының Рәхмәт хатын тапшырды. Юбилей тантанасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов чыгыш ясады. Язучыларыбызны Россия Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе Валерий Киселёв, Азәрбайҗан Язучылар берлеге рәисе Анар Рзаев котладылар. Таҗикстан Язучылар берлеге рәисе Низом Косим, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Зәки Алибаев, шулай ук Чувашия, Удмуртия, Марий Эл республикалары Язучылар берлекләре җитәкчеләре каләмдәшләрен видеоязмада тәбрикләп узды. Ул көнне Корстонда Г.Камал театры артистлары тарафыннан шагыйрьләребезнең төрле елларда язылган шигырьләре укылды. Экранда классик язучыларыбызның портретларын күрергә мөмкин иде. Тантана республикабыз сәнгать осталарының җыр-биюләре белән үрелеп барды.

***

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында каһарман-шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 110 ел тулуга багышланган «Җырым аша белсен халкым» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды. Фатих Кәримнең (К.Тинчурин театрыннан Артём Пискунов башкарды) һәм хатыны Кадриянең (К.Тинчурин театрыннан Резеда Сәлахова) бер-берсен сагынып хат язуларын тамашачы нигезендә драматик сюжет яткан бер спектакль кебек кабул итте. Кичәдә шагыйрьнең «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасы (аны Г.Камал театры артисты Хәлим Җәләй укыды), шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Аларны республикабызның нәфис сүз һәм сәнгать осталары ирештерде. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, каһарман-шагыйрьнең кызы Ләйлә Кәримова, Калининград өлкәсе (Ф.Кәрим шушында һәлак була) язучылар оешмасы җитәкчесе Александр Малышев, Ф.Кәримнең туган ягы Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылы җирле үзидарә башлыгы Радик Гыйлаҗетдинов, шушындагы музей директоры Рәйсә Хафизова чыгыш ясадылар. Ул кичне шагыйрьләр Ренат Харис, Илдар Юзеев, Харрас Әюпов, Флёра Гыйззәтуллина, Резеда Вәлиеваларның Фатих Кәримгә багышлап язган шигырьләрен дә укыдылар. Кичәдә ТР җыр һәм бию ансамбле дә катнашты.

***

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма театрында Татарстанның халык шагыйре, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Зиннур Мансуровка 70 яшь тулу уңаеннан «Җәрәхәтле йөрәк җылырак» дип аталган әдәби кичә булып узды. Анда ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин ТР Президенты Указы белән Зиннур Мөҗип улы Мансуровның «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнүен игълан итте һәм юбилярга шушы олы бүләкне тапшырды. Әлеге чарада ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең Котлау хатын укыдылар. Бәйрәмдарны шулай ук Таҗикстан Язучылар берлеге рәисе, Таҗикстанның халык шагыйре Низом Косим, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, шагыйрьнең якташлары – Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Вадим Никитин, гармунчылар ансамбле котладылар. Ул көнне тамашачылар сәхнә түренә куелган экран аша Сибгат Хәким, Роберт Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Фәнис Яруллин, Клара Булатова кебек шагыйрьләребезнең төрле елларда Зиннур Мансуров иҗатына биргән бәяләмәләрен дә ишеттеләр. Кичәдә юбилярның татар кызы Сөембикә белән рус кызы Ярыслауна егълауларын берләштергән поэмасыннан һәм Г.Тукай белән әңгәмәләреннән өзекләр, шигырьләре, җырлары яңгырады. Әсәрләрне Г.Камал театры артистлары укыды, җырларны республикабызның сәнгать осталары башкарды.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрь Шәүкәт Гаделшага 70 яшь тулу уңаеннан «Аучы җыры» дип аталган әдәби кичә үткәрелде. Анда әдәбият галимәсе Флёра Сәйфуллина юбилярның иҗаты турында сөйләде. Бәйрәмдарны ТР Мәдәният министрлыгының сәнгатьне үстерү бүлеге

мөдире урынбасары Рәшит Фәтхуллин (ул шагыйрьгә министрлыкның «Мәдәниятне үстерүдәге казанышлары өчен» күкрәк билгесен тапшырды), Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, каләмдәшләре Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Рафис Корбан, Ленар Шәех, Фәнил Гыйләҗев, Рифат Сәлах котладылар һәм Шәүкәт Гаделшаның шигырьләрен укыдылар. Кичәне прозаик, шагыйрь Галимҗан Гыйльманов алып барды.

### РОМАННАР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Татарстан Язучылар берлегенең әдәби тәнкыйть секциясе утырышында язучы-прозаик, җәмәгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ринат Мөхәммәдиевнең күптән түгел генә «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Ак кәгазь нидән саргая?» дип аталган романы турында сөйләшү булды. Утырышта утыздан артык каләм әһеле катнашты. Шушы роман турында башланган сүз әлеге әсәрдә күтәрелгән әләкчелек һәм әдәбиятта плагиатлык проблемасы турында сөйләшүгә күчте. Утырышта катнашучыларның фикере уртак: яңа роман тәэсирле, гыйбрәтле, уйландырырлык. Сөйләшүдә автор Ринат Мөхәммәдиев үзе дә катнашты һәм чыгыш ясады.

***

«Татар китабы йорты»нда язучы-прозаик, публицист, җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллованың «Казан утлары» журналында (быелгы 4нче, 5нче саннар) дөнья күргән «Язмыш җиле» романы турында сөйләшүгә багышланган «түгәрәк өстәл» үткәрелде. Тукайның бөеклеген тагын бер тапкыр раслаган, татар хатын-кызларының данын еракларга таныткан Гөлсем Камаловага, атаклы Акчуриннарның изге эш-гамәлләренә сүздән һәйкәл куйган бу әсәргә әлеге чарада катнашкан каләм ияләре Рәдиф Гаташ, Ркаил Зәйдулла, Ринат Мөхәммәдиев, Рәмис Аймәт, Луиза Янсуар, Рөстәм Галиуллин, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Фирүзә Җамалетдинова, Ландыш Әбүдәрова һ.б. югары бәя бирде. Автор Роза Туфитуллова үзе бу әсәрне язганда туган хис-кичерешләре белән уртаклашты. Роман турында сөйләшүне әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов алып барды.

### СӘФӘРЛӘР

10-12 октябрь көннәрендә бер төркем татар дин әһелләре һәм язучылары Туймазы белән Уфа шәһәрләренә сәяхәт кылды. Сәфәр Башкортстанның 100 еллыгы һәм тарихыбызда тирән эз калдырган күренекле шәхесләребезнең юбилейлары уңаеннан, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан оештырылды. Татарстан делегациясе вәкилләре Туймазы шәһәрендә «Төмәнәк» татар иҗтимагый тарихи-мәдәни үзәгендә түгәрәк өстәлдә катнашты, Туймазы районының Төмәнәк авылында урнашкан «Бабай утары» белән таныштты, Уфа шәһәренең мөселман зиратында татарның күренекле дин эшлеклеләре каберләрен зиярәт кылды, «Хәсәния» мәдрәсәсендә, имам Сатаев йортында, Зыя Камали йортында, «Галия» мәдрәсәсендә, «Хакимия» мәчетендә, сәүдәгәр Хәкимов йортында, Госмания мәдрәсәсендә, Уфа шәһәре Җәмигъ мәчетендә булды, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин һәм Башкортстан мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти Айнур хәзрәт Биргалин белән очрашты. Татарстанның Баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев Уфа шәһәренең «Ихлас» мәчетендә вәгазь сөйләде, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Җомга намазын алып барды.

Әлеге чараларда язучылар – Татарстан язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Татарстан китап нәшрияты мөхәррире Галимҗан Гыйльманов, шулай ук Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты рәисе урынбасары Марс Тукаев, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары Мөселман мәдрәсәсе» җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин һ.б.лар катнашты.

***

«Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев, бүлек мөхәррирләре Камил Кәримов, Фәнил Гыйләҗев Оренбург өлкәсенең Әсәкәй районы Мәдәният йортында укытучылар, китапханәчеләр, мәдәният хезмәткәрләре, әдәбият сөючеләр белән очраштылар.

2019 елның 9 октябрендә 66нчы яшендә Казан федераль университетының халыкара мөнәсәбәтләр институты доценты, тарих фәннәре кандидаты, татар халкының тарихи һәм мәдәни мирасын саклауга һәм популярлаштыруга зур өлеш керткән археограф, тарихи чыганаклар һәм төрки фәннәр белгече **Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин** вафат булды.

2019 елның 21 октябрендә 75нче яшендә Азнакай районының элекке башлыгы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь **Әнәс Гатуф улы Исхаков** вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: мистическая повесть Р.ГАБДУЛХАКОВОЙ «Пройдёт зима, и я вернусь», повесть Х.ИСМАГИЛОВА «Калымщик Джаудат»,*
*повесть А.БАЙМУХАМЕТОВА «Дети улицы», повесть А.МУТАЛЛАПОВА «Семья»; аллегорическая поэма Х.БАДИГИ, стихи М.КАБИРОВА, Р.ДЖАМАЛА, Э.ХАМАТШИНА.*
*«Новые имена»: стихи Ф.ХАСАНОВОЙ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Из литературы родственных народов»: стихи О.ВЕЛИ (переводы с турецкого языка Р.АЙМЕТА).*
*Конкурс «Исцеляющие руки»: рассказ Ф.ЗАРИФА «Я вижу мир».*
*Фотоархив: 90 лет со дня рождения Ш.ХУСАИНОВА.*
*«Татарстан. История. Личности»: очерк А.ГАРАЕВОЙ-АКЧУРЫ.*
*«160 лет со дня рождения Дэрдменда»: статья Л.ХАМИДУЛЛИНА; стихотворение Д.РАМИЕВА.*
*Фотоархив: моменты из жизни семьи Рамиевых.*
*«Литературная критика»: статья Т.ГАЛИУЛЛИНА.*
*«Книжное обозрение»: И.ГАБИББЕЙЛИ. «Поэтические мосты дружбы» (перевод А.ИМАМИЕВОЙ).*
*«Тюркские литературы и современность»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Страницы юмора»: подготовил К.КАРИМОВ.*
*«Сенной базар»: Р.ШАРИФ. «Шарифизмы».*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: дом Рамиевых в городе Оренбург. Фото А.Мирзаханова; литературный критик Ляйля Мингазова.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: mystical novel by R.GABDULKHAKOVA «Winter passes, and I will return», novel by KH.ISMAGILOV «The Dower Jaudat», novel by A.BAYMUKHAMETOV «Children of the street», novel by A.MUTALLAPOV «The Family»; allegorical poem by H.BADIGI, poems by M.KABIROV, R.JAMAL, E.KHAMATSHIN.*
*«New Names»: poems by F.KHASANOVA.*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«From the literature of related peoples»: poems by O.VELI (translations from Turkish by R.AYMET).*
*Competition «Healing Hands»: story by F.ZARIF «I see the world».*
*Photo archive: 90th anniversary of SH.KHUSAINOV.*
*«Tatarstan. Story. Persons»: essay by A.GARAEVA-AKCHURA.*
*«160 years since the birth of the poet Dardmend»: article by L.KHAMIDULLIN, poem by D.RAMIYEV.*
*Photo archive: moments from the life of the Ramiev family.*
*«Literary criticism»: article by T.GALIULLIN.»*
*«Book Review»: I.GABIBBEYLI. «Poetic bridges of friendship» (translation by A.IMAMIEVA).*
*«Turkic literature and modernity»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Pages of Humor»: prepared by K.KARIMOV.*
*«Hay Market»: R.SHARIF. «Sharifizms».*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: the Ramievs' house in the city of Orenburg. Photo by A.Mirzakhanov; literary critic Lyaila Mingazova.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Оренбург шәһәрендә Закир Рәмиев-Дәрдемәнд яшәгән йорт. А.*Мирзаханов фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* галимә, әдәби тәнкыйтьче Ләйлә Минһаҗева.